# Казан утлары

6

июнь

1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**6**

ИЮНЬ
1969

## Бу санда:

### ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**Ленин, Горький, Казан** . . . . . . . . . . . . 3
**Хафизлар яңа җыр башлады.** Таҗик халык җыры. **Мәйданда тирмә күренә.** Кыргыз халык җыры. **Ялкынлы Ленин.** Үзбәк халык җыры. **Төркмән сөйли.** Төркмән халык җыры. **Яңа кояш.** Дүнгән халык җыры . . . . . . . . . . . . . . 8
**Җ. ИШМОРАТОВА, И. ИШМОРАТОВ. Кокушкинода розалар үсә.** Очерк . . . . . . . . . 11

### РОМАН, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Яшел Яр.** Роман . . . . . . . 21
**Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Ильич дивары. Аклы-каралы Мәскәү. Яшьлек кырлары. Кырларда җил. Июнь иле.** Шигырьләр . . . . . . . . . 74
**Ә. БАЯНОВ. Дөньяга ялвару. Урман. Сентябрь. Гомер — биек тау бугай ул. Җырлый белсә елан. Була сүзләр. Җиңәргә тиеш. Элегия.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 79
**М. ХӘБИБУЛЛИН. Чын төш.** Хикәя . . . . . . . 84
**Ф. ЯРУЛЛИН. Кешелек якыная Ильичка. Ике елга. Төсләр.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 93
**К. БУЛАТОВА. Мөмкиндер дә кебек. Сөйләр сүзләр әле никадәр. Яфрак-яфрак кар яуганда. Кайда булдың дисең. Сукмакларга сары келәм түшәп.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 94
**А. ХӘЛИМ. Кайсыгызны юатыйм! Матурларым минем. Топ ана сүзе. Дуска. Экспромт.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 97
**Р. ЗАКИРОВ. Өермә. Моң. Онытылган кайгым булсаң да. Бер күңелдә. Күк гөмбәзе...** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 101

### ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**М. МОСТАФИН. Еллар һәм юллар.** Очерк . . . 103

### РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**Әкият булып күтәрелә Казан.** Интервью . . . . 115

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ХӨСНИ. Кайда сез, олы язмышлар . . . . 123
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Җепләрне ныграк тәйнисе бар. 138

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

Н. ХИСАМОВ. Матурлык хакына . . . . . . . 143

Безнең сафка . . . . . . . . . . . . . . . 150

ЯЗМАЛАР, ИСТӘЛЕКЛӘР

Г. КАШШАФ. Башкортстанда . . . . . . . . 152
Г. МИҢНУЛ. Яшьлек эзләреннән . . . . . . . 164

ТӨРЛЕСЕННӘН

М. ГӘРӘЕВ. Сочида үсә бер агач . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. МИННУЛЛИН. Җылылык хисе . . . . . . 177
Р. ЮСУПОВ. Белмәмеш татарча сөйләшә . . . 179

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

З. НУРИ. Сәгать. Кичә, бүген, иртәгә. Берсе тирги, берсе аклана . . . . . . . . . . . . . . 185

Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21. Җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 11/III-1969 ел. Басарга кул куелды 26/V-1969 ел. ПФ 09014.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 82 646 экз.
Заказ В-204. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы матбугат идарәсенең Кәмил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казань, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.

*ЛЕНИН—*
*БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*




# ЛЕНИН, ГОРЬКИЙ, КАЗАН

**В. И. Ленин белән А. М. Горький арасындагы дуслык, аларның иҗтимагый һәм әдәби мөнәсәбәтләре — XX гасырдагы революцион хәрәкәт һәм иҗтимагый фикерләү тарихында гаять зур урын алып тора. Яңа гасыр — XX гасыр килер алдыннан дөньяга ике титан исемнәре — Ленин һәм Горький исемнәре яңгырый: Ленин дөньяда беренче социалистик җәмгыятькә нигез салучы булса, Горький дөнья әдәбиятында яңа эраны башлап җибәрде.**

**Бөек юлбашчы һәм бөек язучы уртак бер нәрсә: азатлык өчен көрәштә халыкка ничек итеп яхшырак, уңышлырак ярдәм итү турында уйладылар.**

**Горький Ленин белән бөек политик һәм философ булганы өчен генә түгел, аны кабатланмас күпкырлы кеше булганы өчен дә кызыксына. Горький Ленинда үзе өчен бик кадерле, башкалардан бик күп эзләп тә таба алмаган сыйфатларны күрә. һәм ул В. И. Ленин турында язганда, аны бөек рухының яртысы белән киләчәктә яши дип, хәзерге көнгә шушы киләчәк күзлегеннән карый белә, гадәттән тыш сәләткә — идеяләрнең киләчәктә тормышка ашуын күрү сәләтенә ия булган кеше итеп сурәтли.**

**Ленин хакыйкатенә Максим Горький чын күңеленнән соклана. Ул Ленинда революциянең көчен күрә һәм 1918 елда ук: «Бөтен дөньяга яктылыгы төшкән рус революциясенең факелы Владимир Ленин кулында»,— дип белдерә.**

**Ленин да Горькийны яраткан һәм аңа:**

**«Революция эшенә чиксез бирелгән кеше»,— дип бәя биргән, аны хезмәт ияләрен азатлыкка чыгару өчен бик күп эшләгән гениаль язучы итеп таныган.**

**...Владимир Ильич Ленинның һәм Алексей Максимович Горькийның тормыш юллары иң беренче Казанда очраша.**

**XIX йөзнең 80 елларында Алеша Пешков университетка керү теләге белән Казанга килә. Ләкин аның теләге тормышка ашмый, капитализм шартларында тормыш төбенә ташланган кешеләр тормышы, авыр хезмәт аның өчен университет булып әверелә. Шулай да ул революцион фикердәге алдынгы Казан яшьләре белән элемтәгә керә. Владимир Ильичның үзенең революцион эшчәнлеген башлаган мохит нәкъ менә шунда бит инде.**

1887 елда университетта юридик факультетның 1 курс студенты Володя Ульянов катнашында булган студентлар күтәрелешенең шаһите Алексей Пешков та була. Шул ук елны ул беренче рус марксистларыннан Н. Е. Федосеев белән таныша. В. И. Ульянов член булып торган түгәрәктәге бик күпләрне Алексей Максимович яхшы белә. Ләкин шулай да алар Казанда бер-берсе белән таныш булмыйлар әле.

Алар бер-берсе белән танышканчы шактый гына еллар уза. Моңарчы әле аларның бер үк журналларда әсәрләре дә басылып чыга. Мәсәлән, 1897 елда «Новое слово» журналында бер үк вакытларда Ленин мәкаләләре һәм Горький хикәяләре басыла. Ә икенче бер журналда — «Жизнь»да «Авыл хуҗалыгында капитализм», «Нежданов әфәндегә җавап» һәм В. И. Ленинның башка мәкаләләре чыккан саннарда М. Горькийның «Фома Гордеев», «Егерме алты һәм бер» әсәрләре басыла.

Владимир Ильич, әлбәттә, бу журналны даими укып барган. Шуңа күрә дә ул: «...Ярыйсы журнал! Андагы беллетристика яхшы, хәтта бүтәннәрдәгедән яхшырак!» (46 том, 26 бит, 5 басма, рус телендә),— дип яза. Бу бәя, иң элек, Горький әсәрләренә карата булуы бәхәссез.

Е. Д. Стасова үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «В. И. Ленин М. Горький язган һәр нәрсә белән бик нык кызыксына иде. Һәм без, партия работниклары, Горький язганнарның һәрберсе белән аны таныштырып барырга тырыша идек».

А. М. Горький да Ленин әсәрләрен зур игътибар белән күзәтеп бара, аларны игътибар белән өйрәнә. Ленин «Искра»сын уку, Владимир Ильичның анда басылып килгән хезмәтләре М. Горькийга марксизмның әһәмиятен, аның революцион асылын аңларга зур ярдәм күрсәтә, иҗади үсеше өчен юнәлеш бирә.

1909 елда В. Гурвич-Кожевникова В. И. Ленинга: «М. Горький «Искра» яклы, аның бөтен симпатиясе бары тик безнең якта, ул ихтирамга лаеклы, талантлы һәм кызыклы итеп бары тик «Искра»ны, иң нык һәм дәрәҗәле итеп бары безнең оешманы таный»,— дип яза.

«Чын революционлыкны мин большевикларда, Ленин мәкаләләрендә тойдым»,— дип яза Алексей Максимович үзе. Һәм нәкъ менә 1900 елларда ул, илдә барган революцион күтәрелеш йогынтысында, алга, революциягә юл күрсәтә торган күп кенә драма әсәрләрен иҗат итә, әсәренең герое — эшче-машинист Нилдан ачыктан-ачык: «Кем эшли — хуҗа шул», дип әйттерә.

1901 елда Е. Д. Стасова Ленинга М. Горькийның яшертен таратылган «Борынын чөйгән язучы турында» дигән памфлетын күчереп җибәрә, ә 1902 елда «борынын чөйгән язучы» тәгъбире Ленинның «Нәрсә эшләргә» китабында кулланыла.

«Давыл хәбәрчесе турында җыр» әсәренең — революциягә чакырып кына калмыйча, аның җиңеп чыгачагын раслый торган әсәрнең — Ленинга гаять зур тәэсир ясавы билгеле. Бу җырдан алып ул үзенең «Давыл алдыннан» мәкаләсендә өзекләр китерә.

1902 елда В. И. Ленин үзенең әнисе Мария Александровнага Мюнхеннан:

«...Горькийны, Скиталецны алдым һәм гаять зур кызыксыну белән укыдым. Үзем дә укыдым, башкаларга да бирдем» [1],— дип яза, ә 1903 елның февралендә: «Немец театрында булдык, Рус Художестволы театрында буласы, «Тормыш төбендә»не карыйсы килә» [2],— ди.

В. И. Ленин Горькийның газеталарда чыгышы зур күләмле әдәби әсәрләр иҗат итүенә комачауламавын да кайгырта. Шул ук вакытта ул, әгәр Алексей Максимович большевиклар матбугатына үз әсәрләрен тәкъдим итә икән, бик сөенә. «Италия турында әкиятләр»не күз алдында тотып, В. И. Ленин 1912 елда аңа: «Менә дигән «Әкиятләр»егез белән сез «Звезда»га зур ярдәм күрсәттегез һәм бу мине бик нык шатландырды»,— дип яза [3].

В. И. Ленинның Горький иҗаты белән ни дәрәҗәдә кызыксынуын «Ана» романын кулъязма хәлендә үк укып чыгуы да ачык күрсәтә. Н. К. Крупская истәлекләре буенча Ленинга аеруча «Ана», «Мещанлык турында мәкаләләр», «Лачын турында җыр», «Давыл хәбәрчесе турында җыр», «Страсти-мордасти», «Егерме алты һәм берәү» әсәр-

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 55 том. 5 басма. 223 бит. (Рус телендә.)
[2] Шунда ук. 229 бит.
[3] Шунда ук. 48 том. 47 бит.

ләре ошаган. Каты авыру хәлендә вакытта ул Горькийның «Короленко заманы», «Минем университетларым» әсәрләрен тыңлап яткан.

Әйе, Владимир Ильич М. Горькийны үз буынының барлык сүз художникләры, пролетар язучылар арасында беренче урынга куя.

«Горький — һичшиксез, пролетариат сәнгатенең иң күренекле вәкиле, ул аның өчен күп эшләде һәм тагын да күбрәк эшләячәк. Социал-демократик партиянең һәрбер фракциясе үзендә Горькийның булуы белән законлы рәвештә горурлана ала»[1],— дип бәяли. Ә икенче бер хезмәтендә бөтен дөнья пролетар хәрәкәткә зур файда китергән һәм китерәчәк «...Гаять зур художество таланты»[2],— дип яза.

В. И. Ленин һәм А. М. Горький 1905 елның ноябрендә беренче тапкыр очрашалар. Бу ике бөек кешенең очрашуы турында М. Ф. Андреева болай дип яза:

«1905 елның ноябрендә, ниһаять, Петербургка китәргә җыенгач, Алексей Максимович поездда миңа иң элек «Новая жизнь» редакциясенә керәчәгебезне әйтте... Каршы алырга килгән туганнар һәм дуслар әйберләребезне алып калды, Горький белән без вокзалдан ерак түгел, Невский проспектына урнашкан редакциягә юнәлдек.

Менә шунда Горький һәм Владимир Ильич Ленин беренче мәртәбә очрашып таныштылар да инде. Хәтерлим: Ленин арттагы кайсыдыр бүлмәләрнең берсеннән чыкты да кызу гына атлап Алексей Максимович янына килде. Алар озак кына бер-берсенең кулын кысып тордылар. Ленин шатлыклы көлде, ә Горький, нык кына каушап, шул ук вакытта гадәтенчә үзен аеруча җитди тотарга тырышып, калын тавыш белән һаман бер сүзләрне кабатлады:

— Әһә, менә сез кинди... Яхшы, яхшы! Мин бик шат, бик шат!

Горький белән Ленинның бу очрашуы РСДРП Үзәк Комитетының коралллы восстание һәм беренче легаль большевистик орган — «Новая жизнь» газетасын чыгару мәсьәләләренә багышланган утырышында булды».

«Новая жизнь» газетасы большевистик партиялелекнең чын байрак йөртүчесе ролен үти. Горький өчен Ленин редакцияләгән бу зур большевистик газетада эшләү менә диган идея-политик һәм иҗат мәктәбе була. Ленин газетасы язучыны вакыйгалар агышында төп нәрсәне күрү һәм революцион күренешләрне дөрес гомумиләштерә белү сәләтенә өйрәтә.

Бу газетаның дүрт санында Горькийның «Мещанлык турында мәкаләләр»е басыла, бу газетада 1905 елда В. И. Ленинның «Партия оешмалары һәм партияле әдәбият» мәкаләсе чыга. Ленинның бу даһи хезмәте бөек язучының иҗади методы формалашуда зур роль уйный. Нәкъ менә шул вакыттан башлап Горький, әдәбиятның партиялелеге принцибына таянып, социалистик реализмның күренекле әсәрләрен — «Ана» романы, «Дошманнар» пьесасы кебек дөнья һәм рус әдәбияты тарихында беренче тапкыр эшчеләр сыйныфын тарихның әйдәүче һәм хәлиткеч көче итеп күрсәткән әсәрләр тудыруга керешә. Ленинның «Ана» романының революцион хәрәкәт үсешендәге әһәмиятенә ничек бәя бирүе һәркемгә билгеле.

1905 елдан, аеруча партиянең V съездыннан соң (1907 ел) Ленин һәм Горький арасында чын дуслык башланып китә. В. И. Ленин Горькийны бөек язучы, җәмәгать эшлеклесе буларак кына түгел, кеше буларак та бик зур хөрмәт итә. Моны раслый торган документлар бик күп.

«Ленин өчен Горький кебек якын мөнәсәбәттә булган кешеләр күп түгел иде,— дип яза М. И. Ульянова.— Алексей Максимович белән күрешкәндә, аның йөзе һәрвакыт ничектер җанланып китә иде. Ул аның белән сәгатьләр буена сөйләшеп утыра ала һәм күренеп тора: бу әңгәмәләрдән ул чын-чынлап канәгать кала иде. Горький мөлаем, гади, сөйкемле кеше иде. Һәм бу аларны бер-берсенә якынайтты».

«Владимир Ильич сезне бик ярата иде»,— дип яза Н. К. Крупская Горькийга язган хатында.

Ленинның Лондонда Алексей Максимовичка карата зур кайгыртучанлык күрсәтүе турында М. Ф. Андреева да яза.

«Гостиницадагы Горький номерын Ленин үзе кереп карады,— ди ул,— яктылык җитәрлекме, чисталык ничек, простынялар дымлы түгелме — барысын да тикшерде.

---

[1] Шунда ук. 19 том. 251 бит.
[2] Шунда ук. 31 том. 49 бит.

Горькийның үзе турында кеше кайгыртып йөргәнен яратмаганны белгәнгә, пышылдап кына болай диде:

— Простынялар бөтенләй дымлы бит, шушы хәерсез камин алдында булса да, аларны киптерергә кирәк. Безнең Алексей Максимович йөткерә башласа, бу бит бердә әйбәт булмас».

1908 һәм 1909 елларда В. И. Ленин Горький янына Капри утравына, ә 1911 елны Парижга килә. Бу очрашулар гаять тә дусларча була, һәм алар язучының идея-политик үсешендә бик зур роль уйныйлар. Революция юлбашчысы Россиядә социалистик революциянең һичшиксез җиңеп чыгачагына Горькийда ышаныч тудыра, партия эчендәге ул вакыттагы көрәшнең мәгънәсен аңлата. Шул замандагы тормышта, әдәбиятта язучының тоткан урынын күрсәтеп, В. И. Ленин Горькийның идея позициясендәге чатаклыклар турында, аларга карата үзенең тискәре карашы турында ачыктан-ачык әйтә. Ленин аны шул замандагы иҗтимагый агымнарны аңларга өйрәтә.

В. И. Ленинның фикерләре, киңәшләре, тәнкыйте Горькийның бөтен әдәби эшчәнлегенә дә, аның киләчәктәге бөтен язмышына да зур йогынты ясый.

А. М. Горький Н. К. Крупскаяга болай дип яза:

«Капри утравында шул замандагы әдәбият турында сөйләшкәндә, ул минем буын язучыларын бик үткен итеп характерлады, рәхимсез һәм җиңел итеп аларның чын асылын ачып салды, минем хикәяләремдәге кайбер кимчелекләрне күрсәтте, һәм аннары: «Юкка гына сез үзегезнең тәҗрибәгезне кечкенә хикәяләргә бүлгәлисез, сезгә аларны бер китапка, нинди дә булса зур китапка тупларга вакыт»,— дип үпкә белдерде. Мин аңа бер семьяның 100 ел, ягъни 1813 елда Мәскәү шәһәре торгызыла башлаганнан алып бүгенге көннәргә кадәрге вакыт эчендәге тарихын язарга исәбем барлыгын әйттем. Ул бик игътибар белән тыңлады, сорашты, аннары: «Менә дигән тема, әлбәттә, кыен, бик күп вакыт таләп итәчәк, мин моны сез булдырып чыгар идегез, дип уйлыйм, ләкин күрмим: сез аны ничек тәмамларсыз! Хәзерге чынбарлыкта аның ахыры юк. Юк, моны революциядән соң язарга кирәк, ә хәзер «Ана» кебек берәр әйбер яхшы булыр иде»,— диде. Китапның ахырын, әлбәттә, мин үзем дә күрми идем әле».

М. Горький, нәкъ В. И. Ленин әйткәнчә, бу теләген Бөек Октябрь революциясеннән соң гына тормышка ашыра: капитализмның, һичшиксез, череп таркаласын һәм җимереләчәген сурәтләп, менә дигән роман — «Артамоновлар эше» әсәрен яза.

Ленин тәэсирендә Каприда трилогия язу фикере туа. Бу турыда М. Ф. Андреева болай дип хәтерли:

«Алексей Максимович Владимир Ильичка Нижний Новгород, Идел, үзенең балачагы, яшьлеге, читтә йөрүләре турында, әтисе, әбисе Акулина Ивановна, бабасы турында сөйләде. Ленин аны гадәтенчә очкынлы күзләрен кысыбрак гаять зур игътибар белән тыңлады һәм җаен туры китереп Горькийга: «Язарга иде, атакаем, бу турыда сезгә! Боларның барысы да бик тә гыйбрәтле, менә дигән...» — диде. Горький кинәт туктап, тынып калды, каушап йөткергәләде һәм күңелсез генә: «Язармын әле, кайчан да булса»,— дип куйды».

Горький бу вәгъдәсен дә үти. Аның «Балачак», «Кешеләрдә», «Минем университетларым» трилогиясе — патша Россиясендәге түбән катлам халыкларның авыр язмышын сурәтли.

В. И. Ленин дустының сәламәтлеге турында да туктаусыз кайгырта. 1913 елда, Алексей Максимовичның үпкә авыруы көчәйгәч, Владимир Ильич Каприга болай дип хат җибәрә: «Сезнең авыруыгыз турында язуыгыз мине бик нык борчуга төшерде... Ул Италиядә беренче класслы врачлар бармы!..» Ә 1921 елда, үзе авыру хәлендә булуга карамастан, Владимир Ильич, Горькийның сәламәтлеге начарлануы турында ишеткәч, болай дип яза:

«...Сез кан төкерәсез, ә үзегез китмисез!! Бу намуссызлык һәм сансызлык... Китегез, дәваланыгыз. Киреләнмәгез, үтенәм Сездән!»

Ленин, Горькийга якын дусларча мөнәсәбәт белән караган хәлендә, аңа карата гаять таләпчән һәм принципиаль дә була. Реакция елларында һәм соңрак, 1917—18 елларда, А. М. Горький җитди генә политик ялгышлар җибәргәч, В. И. Ленин аның тормышында гаять зур роль уйный.

Горький реакциянең беренче елларында дөрес булмаган позициягә баса; ул,

социалистик революция әле әзерләнеп җитмәгән, дип исәпли. Ә инде шулай да революция җиңеп чыккач, Горький, пролетариат крестьяннарга түгел, ә башлыча интеллигенциягә, фән һәм культура эшлеклеләренә таянырга тиеш, дип саный.

Шул вакытларда да Ленин Горькийның бу ялгышлыкларны җиңеп чыгачагына, чын пролетар, әзлекле революцион позициягә аяк басачагына шик тотмый.

«Аның миңа мөнәсәбәте,— дип яза Горький үзе дә,— кырыс остаз һәм мәрхәмәтле, кайгыртучан дус мөнәсәбәте иде».

Горький үзенең соңгы көннәренә кадәр В. И. Ленин хезмәтләрен өйрәнә. Ленин үлем алдыннан Горький әсәрләрен тыңларга теләгән кебек үк, Горький да якты дөнья белән саубуллашыр алдыннан аның турында, аның белән очрашулары турында сөйли, бөек юлбашчы тормышындагы, характерындагы һәр детальне, һәр сыйфатны онытып калдырмаска тырыша.

А. М. Горький В. И. Ленин турындагы беренче истәлекләре белән 1920 елда чыга. Ләкин әлегә бу зур теманың кереше генә була.

1924 елның 21 гыйнварында В. И. Ленин үлә.

Юлбашчының үлеме А. М. Горький өчен — гомуми зур кайгы гына түгел, тирән шәхси трагедия дә.

«Мин Владимир Ильичны тирән һәм кайнар ярата идем,— дип яза Горький,— һәм беркайчан да үземне ул үлгән елдагы кебек шундый ятим итеп, шундый кайгысы итеп тойганым юк иде». Ул Ленин турында язуны, аның мәңге онытылмас образын сурәтләүне үзенең иҗат бурычы итеп куя. һәм 1924 елда ук инде А. М. Горькийның «В. И. Ленин» дигән очеркы басылып чыга. 1930 елда язучы бу очеркын кабат эшкәртә һәм тулыландыра.

«В. И. Ленин» очеркында Горький Ленинның йөзен, аңа характерлы хәрәкәтләрне, аның портретын бик ачык һәм рельефлы итеп, дәһи кешенең эчке асылын күз алдына китерерлек итеп сурәтли.

Горький Владимир Ильичны Плеханов белән түбәндәгечә чагыштыра.

«Мине Плехановка тәкъдим иткәндә,— дип яза ул үзенең очеркында,— ул [Плеханов — ред.], кулларын күкрәгенә куеп, җитди һәм эчпошулы кыяфәт белән карап тора иде, үз бурычларыннан ялыккан укытучы тагы бер яңа шәкертенә шулайрак карый. Ул миңа бик гадәти генә бер фраза әйтте: «Мин сезнең талантыгызга гашыйкмын»,— диде. Шуннан башка ул минем хәтеремдә калырлык бер генә нәрсә дә әйтмәде. һәм съездның бөтен дәвамында аңарда да, миндә дә «эч серләрен ачып» сөйләшү теләге тумады.

Ә бу пеләш, сакау, тыгыз тәнле, нык гәүдәле кеше, бер кулы белән Сократныкы төсле маңгаен угалап, икенчесе белән минем кулны тарткалап, гаҗәеп җанлы күзләрен ягымлы ялтыратып, шунда ук минем «Ана» китабымның кимчелекләре турында сөйли башлады, ул аны кульязма килеш И. П. Ладыжниковтан алып укыган булып чыкты. Мин китапны ашыгып язганлыкны әйттем, ләкин ни өчен ашыкканлыгымның сәбәбен аңлатырга өлгермәдем, Ленин, раслау билгесе итеп башын селкеп, моны үзе аңлатты: ашыкккан булуың бик яхшы, китап кирәкле, бик күп эшчеләр революцион хәрәкәттә аңсыз, стихияле рәвештә катнаштылар һәм хәзер алар «Ана»ны укып үзләренә зур файда алырлар.

«Бик вакытлы язылган китап». Бу аның бердәнбер комплименты, ләкин минем өчен гаять зур комплименты булды...»

Н. К. Крупская, А. М. Горькийның бу очеркын укып чыкканнан соң, авторга болай дип яза: «Сезнең Ильич тере. Лондон съезды турындагы язганыгыз бик яхшы. Барысы да дөрес. Сез Ильичны ярата идегез. Яратмаган кеше болай яза алмас иде».

А. М. Горький Ленин идеяләренең мәңге яшәячәгенә ышанып яза. Шуңа күрә дә аның сүзләре хәзер дә яңа көч белән яңгырый:

«Владимир Ленин үлде. Аның акылының һәм ихтыярының варислары исәннәр. Исәннәр һәм эшлиләр, шундый итеп эшлиләр, дөньяда берәүнең дә беркайчан да беркайда да болай уңышлы эшләгәне юк әле».

НИКИФОРОВА И. К.
А. М. Горький музееның фәнни
эшләр буенча директор урынбасары

## Хафизлар яңа жыр башлады

*Таҗик халык җыры*

Без, таҗиклар, җыр сөябез,
Моң күп бездә, җырлы без.
Җырга лаек һәрнәрсәне
Көйгә салып җырлыйбыз.
Әгәр берәр яхшы ат күрсәм,
Шул атны мактап җырлыйм.
Җырым яңа җыр булмас дип
Шикләнеп-куркып тормыйм:
Чөнки җырда җырланырга
Бик күп атның хакы бар,
һәркем үз толпарын мактый —
һәркемнең үз аты бар!
Ләкин бар шундый җырлар да —
Хафизлар [1] җырлаган җыр,
һәммә төштә эз калдырган,
Юл йөреп туймаган җыр,
Гасырлар күрке булган һәм
Ут булып уйнаган җыр.
Шундый җырны Фихрат [2] язган
һәм Нахани җырлаган.
Алар сүзе гүзәл кызны
һәм чәчәкне зурлаган.
Хафизлар хәзер дә күп ул —
Җыр сөйгән киң күңелләр.
Фихраттан һәм Наханидан
Алар һич ким түгелләр.
Инде алар җыры хәзер
Яңа ирек турында,
Инде самолет канаты
Гүли алар җырында.
Ләкин Ленин турында җыр —
Арада иң олысы,
Чөнки яңа җыр җылысы —
Бөек Ленин сулышы.
Әгәр дә Ленин булмаса,
Җыр елар, шыңшыр иде,
Җырчылар бары патшага
Ярарга тырышыр иде.
Тез чүгеп тә, баш иеп тә
Җырларлар иде алар —
Көне-төне тик байларны
Зурларлар иде алар.
Ленин әйтте: яшә, хафиз,
Йөрәк кушканны җырлап.
һәм хафизлар җыр башлады
Бөек Ленинны зурлап!

## Мәйданда тирмә күренә

*Кыргыз халык җыры*

Мәскәүдә, безнең таш калада,
Кешеләр күп килгән урында,
Бер мәрмәр таш тирмә күренә
Ялтырап зур кояш нурында.

Беләбез, без аның эчендә
Ленинның ятканын беләбез.
Борчулы, кайгылы чакларда
Без шуңа карарга киләбез.

һәм кайгы югала, тарала
Үзәннән агымсу үткәндәй,
Югала — яфраклар шул суда
Дулкынга ябышып киткәндәй.

[1] Хафизлар — шагыйрьләр (XIV гасырның атаклы Иран шагыйре Хафиз Шәмсетдин Мөхәммәт Ширази исеменнән).
[2] Фихрат һәм Нахани — Иран шагыйрьләре.

Ә күңел керешә ярсынып
Каргарга агулы үлемне —
Ул алды зур илнең әткәсен,
Ул чакты Юлбашчы Ленинны...

Шул мәйдан ягына юллыйбыз,
Юллыйбыз авыр сүз даладан:
Арада сау-исән Ленин юк,
Ул инде терелмәс яңадан.

Далабыз шикелле якын ул —
Ленинны без шулай сөябез!
Җәл түгел далабыз киңлеге,
Җәл түгел куебыз, дөябез.

Ләкин юк... Белмибез Ленинны,
Белмибез кайлардан эзләргә.
Йөрәкләр, киң дала, йолдызлар
Елый да — яшь тула күзләргә.

Беләбез, Ленинны хәтерләп
Елый бит йолдызы да, дала да.
Ул якын бу җирдә һәркемгә —
Туган һәм туачак бала да

Онытмас Ленинны, онытмас!
Мәңгегә якын ул кыргызга.
Җирдә ул тиң кеше далага,
Кояшка, айга һәм йолдызга.

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре

## Ялкынлы Ленин

*Үзбәк халык җыры*

Җир өстендә, биеклеккә басып,
Башы белән йолдызлардан ашып
Торды Ленин илләр, җирләр күреп,
Ерак сулар тавышын ишетте ул.
Җир йөзенә бөек хаким булып,
Талмас акыл белән эш итте ул.

Изге учак диеп атадык без
Ленин чорын,— шулай аңладык без,—
Ул — яктылык, җылылык бирәүләргә,
Бирәүләргә — ут һәм ялкын бирде.
Шул учакта үзе дә калды көлгә,—
Илгә мәхәббәттән янды-көйде.

Хәятны ул эштә күрде бары,
Тукталмады арып — гел атлады.
Атлады ул максатына таба,
«Эшлә!» — диде боерып акылына,
Яңа уйлар туды яна-яна,
Үзе дә янды шуның ялкынында.

Дөнья тора баш очында аның,
Кайгы каплый Ватан далаларын...
Күңелен биреп мазлум, ятимнәргә,
Үзен генә даһи гел онытты.
Күптән белә идек нинди хәлдә
Икәнлеген, ләкин гаҗәп утны
Сүндерергә көчсез иде кешеләр:
Җир янгынын басар нинди көч бар?!

Ә Ленинның йөрәгендә янгын
Көчле иде аннан меңнәрчә кат!
Ул табутта чакта бар дөньяның
Йөзен алды кара кайгы каплап.
Тик атабыз бик бәхетле иде —
Мазлумнарга мәңге бәхет бирде.

## Төркмән сөйли

*Төркмән халык җыры*

Күп белем алды ул, сөрелде, төрмәгә утырды,
Туган як җибәргән хатлар да шатланып укылды.
Ул бер сүз әйтсә дә дошманнар калтырап чигенде.
Ә андый тәгълимат уятырмы җанда шигеңне?

Хикмәтле әйтсәк без — өйрәнде ул җиде гасырлык,
Ант итәм һәм шигем юк минем сүземнән кайтырлык:
Бит Ленин акылы ярлыга зур бәйрәм китерде.
Ә андый тәгълимат уятырмы җанда шигеңне?

Ул үлгән кешене терелтердәй булып күкрәде,
Тылсымлы җим биреп имләде сырхау кош күкләрне.
Мазлумнар, хәлсезләр көч алды батырлар шикелле.
Ә андый тәгълимат уятырмы җанда шигеңне?

Ул — туган атасы җирдәге ятимнәр, толларның:
Аңарга Гыйракның, Иранның тутырып юлларын
Агылды бар халык, санламый киртәне-чигеңне.
Ленинчыл тәгълимат уятмас беркайчан шигемне!

## Яңа кояш

*Дунгән халык җыры*

Төнлә, кап-караңгы җирдә кинәт таң атты яктырып.
«Бу нинди тылсымлы таң?» — дип әйтте халык, йокыдан торып.
Җил сызгыра, яңгыр ява, ә якты җәелә бара.
Кояштан да якты Ленин! Ленинга бит төн юк аңа!

Гаҗәеп хәл! Бөтен ярлы халык бер гаилә хәзер.
Әйдә хаклык, акыл белән халык хөкем йөртсенче бер.
Мондый кояшны җир йөзе күргәне юк иде элек.
Ленин әйтте: — Яшәсен,— дип,— ярлыга ярлы кул биреп.

**НУРИ АРСЛАНОВ** тәрҗемәләре

Җ. Ишморатова,
И. Ишморатов

# КОКУШКИНОДА РОЗАЛАР ҮСӘ



Димитрий Ильич аны тыйнак кына җиһазландырылган кечерәк бер бүлмәгә чакырды һәм, беренче сүзеннән үк, бик күп истәлекләр белән бәйле булган Кокушкино авылы турында сораштырырга кереште. Кокушкинода яңа гына ачылган музей-йорты директоры Шәмсеруй Шәйнурова Ленинның энесе янына Горкига нәкъ әнә шуның өчен, Казан янындагы бу истәлекле урынның үткәне һәм хәзергесе турында сөйләшү өчен, килгән иде инде.

Бу очрашу икесе өчен дә бик дулкынландыргыч булды. Мөгаен, Димитрий Ильич күбрәк тә дулкынлангандыр әле. Кокушкинодан килгән кунак аның күңелендә балачак хатирәләрен яңартты бит, әнисе, абыйлары, кыз туганнары белән бәйле урыннарны искә төшерде.

Алар бик озак сөйләшеп утырсалар да, һәр икесенең дә сүзләре бетәрлек түгел иде.

— Бабабыз йортының, ниһаять, торгызылуы бик әйбәт,— диде Димитрий Ильич сүз арасында.— Бик кызганыч, барып кайта алмыйм. Барын да үз күзем белән күрер идем, каһәр төшкән авыру аяктан екты бит.

Ул беравык тынып калды, аннары кисәк кенә җанланып сорап куйды:

— Кокушкинода чәчәкләр әле дә үсәме!

— Әйе, үсәләр,— дип җавап бирде аңа Шәмсеруй апа.— Сиреньнәр үсә, розалар үсә. Алсу катыш ак чәчәкле розалар.

Бу сүзләрне ишеткәч, Димитрий Ильичның йөзе бөтенләй яктырып китте, күзләре очкынланды һәм ул шатлыктан елмаеп:

— Әнкәй мәрхүм менә шул роза чәчәкләрен үстерергә ярата иде,— диде.— Рәхмәт сезгә, күгәрченкәем, рәхмәт. Мин кадерле әнкебез белән очрашкандай булдым...

Бу сөйләшүдән соң өч дистә ел үтте инде, ә розалар һаман үсә. Һава хәлләре ничек кенә булмасын — җилме, яңгырмы, кояшмы, салкынмы,— алар һаман үсәләр, куе чикләвек куаклары белән әйләндереп алынган түтәлләрдә ел саен матур булып чәчәк аталар. Бу изге урында яшәгән гүзәл кешеләрнең җанлы хатирәләре алар.

* * *

...Күптән була инде бу хәл — узган гасырның урталарында ук. Губерна каласы Казаннан кырык чакрымнар ераклыкта Яңасала — Кокушкино дип, ике исем белән йөртелгән авылда доктор Александр Димитриевич Бланк семьясында биш кыз үсә. Аннушка, Любочка, Катенька, Машенька, Софьюшка дип дәшәләр аларга. Әниләре һич тә көтмәгәндә үпкә авыруыннан үлеп киткәндә, иң олысына бары тик җиде генә яшь була. Кызлар яшьли дөнья куйган әниләренең апасы — кырыс, таләпчән Екатерина Ивановна кулында калалар. Бик яшьли үзләрен үзләре карарга күнегәләр, хуҗалык эшләрендә ярдәмләшәләр, кырдагы эшләргә катнашалар.

Берсеннән берсе матур булып үсә кызлар. Шул матурларның да иң матуры, иң чибәре Машенька була. Аны һәркем ярата — бөтәнчә ничек булсын: ул бик тыныч, ләкин таләпчән, тыйнак һәм үзеннән ниндидер бер нур бөркеп тора сыман. Барыннан да бигрәк, Машенька хезмәт сөя, һич кенә дә эшсез тора алмый, һәр чакта үзенә бөтен күңелен биреп эшләрлек эш таба: я кухняда апасына булыша, я чигү яки тегү белән шөгыльләнә, я рояль янында күнегүләр уздыра, я чит ил телләренә өйрәнә яки классикларның әсәрләрен укый.

Бакча эшләрен ул барысыннан да артыграк күрә. Чәчәкләр — аның иң яраткан нәрсәсе. Я тын гына, я булмаса үзенең яңгыравыклы һәм ягымлы тавышы белән яраткан җырларын җырлый-җырлый, Машенька роза, георгин түтәлләре арасында йөри, чүпләрен утый, төпләрен йомшарта, сулар сибә.

Еллар бер-бер артлы үтә тора. Апалары һәм сеңлесе инде барысы да кияүгә чыгалар, ә Машенька әле һаман әтисе йортында. Ниһаять, ул да гашыйк була.

Үзенең мәхәббәтен Пенза шәһәрендә таба ул. Ә бу шәһәргә Мария үзенең олы апасы Анна янына кунакка барган була. Менә шунда ул Аннаның ире — Иван Димитриевич Веретинников белән бергә Дворяннар институтында эшләүче, өлкән укытучы Илья Николаевич Ульяновны очрата. Бер-берсенә алар ошыйлар. Ульяновның тәкъдименә кыз ризалык бирә, ләкин шарт куя: читтән торып имтихан биргәнче һәм укытучы дипломы алганчы егет көтәргә тиеш.

1863 елның июль аенда Яңасала — Кокушкино авылында Мария Бланк һәм Илья Николаевич Ульянов бик зурлап туй үткәрәләр. Туйга килгән кунаклар аларның пар килүенә зур соклану белдерәләр.

Туйдан соң яшьләр авылда берникадәр кунак булалар да Илья Николаевичның яңа эш урынына — Нижний Новгородка китәләр...

...1863 елда, кызы кияүгә чыгып нәкъ бер ай үткәннән соң, Александр Димитриевич Екатерина Ивановнаны җирли. Бик зур кайгы була бу аның өчен. 1838 елдан бирле Екатерина Ивановна Бланклар семьясыннан аерылмый яши, алар белән Петербургта, Пермьдә, Златоустта тора, ниһаять, 1847 елда Кокушкинога килә, бик яшьли дөнья куйган Анна Ивановнаның балаларын карап үстерә, аларны кеше итә.

Карт доктор бу югалтудан соң бик озак вакытлар кайгырып йөри, мәрхүмәнең үткән тормышы, үзенең язмышы турында уйлана.

Язмыш кайларга гына илтмәде аларны. Башкалада зыялы гаиләдә туып-үскән, тумыштан гаять сәләтле, берничә Европа илләре телендә иркен сөйләшә алган, әдәбиятны яраткан, музыка белән мавыккан Екатерина Ивановна төсе-бите белән дә чибәр була. Үзәктән ерактагы ниндидер бер авылда үлеп калырмын дип уена да китермәгәндер ул. Константиновка дигән өяз шәһәрендә туып үскән мещан улы Александр Димитриевич үзе дә картлык көннәрен Яңасала — Кокушкино дигән җирдә — элек Казан ханнары карамагында булган авылда үткәрермен дип уйладымы икән!!

Александр Димитриевич дәвалау эшчәнлеге дәвамында Россиянең бөтен Европа өлешен йөреп чыга. Петербургта да тора, чит илләрдә дә була, ә күңеленә Идел буе — Казан янындагы матур табигатьле шушы кечкенә авыл гына якын булып кереп урнаша.

Александр Димитриевич гадәттән тыш тырышлыгы аркасында гына медицина — хирургия академиясен тәмамлый ала. Яшүсмер чагында ук хезмәтенең кирәклеген аң-


лый һәм аның бөтен гомере эштә үтә.

Академияне тәмамлагач та белемен күтәрүне дәвам итә, медицинаның төрле өлкәләрен өйрәнә һәм барлык төр авырулар буенча белгеч булып җитлегә.

Доктор Бланк үз заманындагы алдынгы кешеләрнең карашларын уртаклаша, меңнәрчә талантларны һәлак иткән крепостной правога нәфрәт белән карый.

Смоленск губернасының караңгы бер почмагында булган хәл аның бөтен гомерендә онытылмаслык булып хәтеренә кереп урнаша.

Яңа гына лекарь булып килгән егет янына аңын югалтыр дәрәҗәдә кыйнап ташланган бер крестьян кызын китерәләр. Кыйналуның сәбәбен сорый яшь врач. Сәбәбе шул икән: алпавыт бәйләнгәч, кыз аңа ризалык бирмәгән...



Володяның бабасы А. Д. Бланк.

Мондый очраклар бик күп була аның тормышында. Гомере буе шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрү, ишле семья белән казна фатирларында тору туйдыра аны. Аннары медицина буенча күптән башланган хезмәтен — «Ни белән яшисең, шуның белән дәвалан» дигән китабын да язып бетерәсе бар. Һәм ул, картлык көннәрен авыл табигате кочагында уткәрергә уйлап, алпавыт Верегинның Яңасала — Кокушкино авылындагы менә шушы кечкенә генә утарын бурычка сатып ала.

Александр Димитриевич үз кул астындагы крестьяннарның тормышын яхшырту өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли: налог алуын бик нык киметә, үз җирләрен бик арзан бәя белән арендага бирә, терлек-туар алуда аларга ярдәм күрсәтә, хәтта крестьяннар өчен дәүләт салымнарын да үзе түли...

Семьясы таралып, үзе генә калгач та Александр Димитриевич күрше дворяннар белән аралашмый, элеккечә, кешеләрне дәвалаудан тәм таба. Авырулар аның янына тирә-як авыллардан да, Казаннан да, башка шәһәрләрдән дә киләләр. Берсен дә кире бормый ул. Шуңа күрә дә аны күрше-тирәдәге дворяннар «акылы авышкан карт» дип йөртәләр.

Җәй көннәрендә утар җанлана, шау-шу, балалар черелдәве белән тула: үзләренең балалары, ирләре, дуслары белән кызлары кунакка кайтып төшәләр. Кунаклар шул хәтле күп җыела, хәтта аларга зур өйдә дә урын җитми. Менә шуңа күрә инде Александр Димитриевич алар өчен флигель салдыра. Хәзер инде кызлары, үзләренең бала-чагалары белән кайткан чакларда, шунда урнаша торган булып китәләр.

Бары тик Ульяновлар семьясына гына зур өйдә аерым бүлмә билгеләнгән була. Бик бәхетле бабай була Александр Димитриевич. Үләр алдыннан аның оныклары ике дистә ярымга җитә.

1870 елның апрель аенда, аңа 71 яшь тулганда, Сембер шәһәреннән тагын бер оныгы — Володя Ульянов тууы турында шатлыклы хәбәр килә.

Озакламый Александр Димитриевич авырып китә. Әтиләренең авыр хәлдә икәнен ишетеп, кызлары Кокушкинога җыелалар. Алар арасында өч айлык Володя белән Мария Александровна да була.



Е. И. Эссен — Мария Александровнаның апасы.

Александр Димитриевич 15 июльдә дөнья куя. Аны Екатерина Ивановна Эссен белән рәттән күмәләр. Аның кабере өстендә «Кадерле әтиебезгә кызларыгыздан» дигән язулы таш әле дә саклана...

Володя Кокушкинога икенче тапкыр сигез яшендә килә. Ул инде, монда килгәнче үк, бу тирәләрнең табигате турында олыларның сокланып сөйләвен күп ишеткән. Ләкин мондагы матур күренешләр аңа көткәннән дә артыграк тәэсир ясый. Казаннан чыккач та ул Кокушкино юлындагы табигать күренешләрен һич туймастай булып күзәтеп бара. Юлның һәр ике ягында офыкка тоташкан киңлекләрдә игеннәр өлгереп килә, яшел урманнарда, берсеннән берсе уздырырга тырышкандай, төрле кошлар сайрый, чокыр төпләрендә чишмәләр чылтырап ага. Мондый эссе көндә, шул чишмәләрнең тешне сындырырлык салкын саф суларын ярга ятып ничек эчмисең дә, юл тузаны кунган бит-кулларыңны ничек юмыйсың инде!.. Менә алар Шигале, Починка, Чирмеш иле (Апакай) авылларын үтәләр. Күз алдына карт юкәләр, бөдрә каеннар, зифа топольләр үсеп утырган парк килеп баса, шунда ук — алмалары, чияләре өлгереп килгән бакча. Ә астарак күзгә көбек булып буа суы ялтырап күренә, ярлары әрәмәлеккә күмелгән Үшнә елгасы ягыннан су тегермәне шыгырдавы ишетелә...

Болар барысы да Ульяновларның балалары күңеленә онытылмаслык булып кереп кала. Һәм алар җәйге каникул вакытларында ял итәргә монда килә торган булып китәләр. Бабалары үлгәч, аналарының ике апасы кулына калган хуҗалык еллар үтү белән шактый таркала. Балаларга хәтта бу ошый да, чөнки ни эшләсәләр дә тикшерүче юк, алар ишек урынына тәрәзәдән йөрергә дә күп сорап тормыйлар. Ә Илья Николаевич, сигез яшьлек Володяга тәрәзә төбенә менү кыен икәнлекне күреп, басма да ясап бирә.

Володя иртәдән алып кичкә кадәр туганнары белән уйный, алар уенына Кокушкинодагы малайлар һәм кызлар да кушыла. Алар балык тоталар, су керәләр, төбе тишек көймәдә «йөзәләр», җиләк, гөмбә, чикләвек җыярга урманга йөриләр.

Володяны кайчагында абыйсы Александр Мкшәгә дә алып бара. Кокушкино малайлары төннәрен аны ат сакларга чакыралар.

Володя, үсә төшкәч, крестьян эшендә дә көчен сыный: көлтә ташыша, печән чаба, гади хезмәт кешеләре белән аралашып, милли гадәтләрне өйрәнә, халык телендәге үткен тәгъбирләрне үзләштерә. Ул еш кына Апакай авылындагы дусты Бәһави янына йөри, анда татар халкының гадәттән тыш кунакчыллыгын, хезмәт сөючәнлеген, милли гореф-гадәтләрен күрә.

Кокушкинода алар торган өй тәрәзәсеннән Үшнә елгасы аръягында Себер трактының бер өлеше — Уфа юлы күренеп тора. Ульяновларның балалары Россиядәге иң озын бу юлның коточкыч тарихы белән дә таныш булалар.

Илья Николаевич, йөрергә чыккан вакытларда, балаларга халык бәхете өчен көрәшүчеләр турында сөйли, халык җырларын җырлап күрсәтә. Аның иң яраткан җыр-

ларының берсе шагыйрь-демократ А. Н. Плещеев[1] сүзләренә җырлана торган Казан студентлары җыры була:

Рухи яктан без бер туганнар,
Котылырбыз, моңа ышанабыз,
Туган илнең коллыгына каршы
Соңгы сулышкача дошманнар без.

Сугу белән дәһшәт сәгате,
Бар халыклар йокыдан уянганда,
Азатлыкның изге гаскәре
Үз сафында безне күрер анда.

Синең йөрәк изге халыкка
Мәхәббәттән ярсып тибә, беләм.
Кайтавсыздай кушылыр килеп өнең,
Сатылмас, саф минем тавышым белән.

Балалар әтиләренең бу җырны яруча күңел салып җырлавын сизәләр, аңа кушылып үзләре дә җырлыйлар...

* * *

...1887 елның 8 маенда патша палачлары Ульяновларның олы улы Александрны җәзалап үтерделәр. Ләкин ана, кайгы никадәр генә зур булса да, бирешмәде: башка балалары да бар бит аның. Ә алар ананың ярдәменә мохтаҗ. Барысыннан да бигрәк төрмәдә утырган олы кызы Аннага аның ярдәме кирәк. Аның кызын биш елга Себергә сөргенгә җибәрмәкчеләр. Ана кеше моның белән килешә алсынмыни инде! Ул күп тапкырлар полиция департаменты бусагасын таптады. Ниһаять, чиновниклар, әгәр якын туганнарыннан кем дә булса үз җаваплылыгына ала икән, сөрген урынын алыштырырга риза булдылар.

Мария Александровна сөрген урыны итеп Кокушкиноны билгеләүне сорады. Анда аның ике апасы — Анна белән Любовь тора бит, әлбәттә, алар ярдәм итәчәкләр...

Хөкем карары яңадан каралды...

Кокушкино авылы Анна Ильинична өчен иң кадерле истәлекләр белән бәйле. Александр Димитриевич Бланк исән вакытта ук аның бирегә килгәне бар. Бу урыннар мәрхүм Александр белән дә бәйле: әле узган ел гына алар каникулны биредә бергәләп үткәрделәр. Ә хәзер менә ул юк... Бу сөргеннең дә, әлбәттә, аның язмышы белән бәйләнеше зур. Энесе үзенең серен аңа ачмады. Ләкин полицейскийлар моңа ышанмадылар: гаепләрлек бернинди сәбәп булмаса да, ул да берничә ай төрмәдә утырды. Ә менә хәзер биш ел гомерне бу авылда үткәрергә кирәк...


...Анна бу кичне бик озак укып утырды. Төнен өй эче шактый суынды, ул калтыранып куйды да урыннан торды: вакыт соң, йокларга кирәк. Шул вакыт ишек алдында кинәт ниндидер тавышлар ишетелде: кемдер килде бугай. Анна Ильинична барып кухня як ишеген ачкан иде, киемнәре салкыннан бәсәреп ап-ак төскә кергән Володя, Маняша һәм әнисе килеп керде. Анна шунда ук күңеле белән сизенде: нәрсәдер булган! Ә Мария Александровна тыныч тавыш белән:

— Анечка, тизрәк чәй әзерли күр, юлда туңдык,— диде дә толыбын салып чөйгә элде.

Ярты сәгатьтән чәй янында ул барысын да сөйләп бирде: университетта студентлар сходкага җыелганнар, сходканы оештыручыларның берсе Володя булган һәм аны моның өчен бирегә сөргенгә җибәргәннәр...

---

[1] Нури Арсланов тәрҗемәсе.



В. И. Ульянов сөргендә яшәгән йорт.

Кыш ул елны салкын һәм буранлы булды, әйтерсең, табигать тә жандармнар белән сүз куешкан: урамга чыгарлык та, Казандагы туганнар, дус-ишләр килерлек тә түгел иде. Хәер, полицейскийлар салкын дип тормыйлар, әледән-әле килеп тикшерәләр.

Володяның аларга да, табигатькә дә артык исе китмәде, ул китапларга күмелде, журналлар укыды, университет программасы буенча әзерләнүен һәр көнне дәвам итте. Аның фикер йөртүе бу шартларда хәтта гадәттәгегә караганда да үткенәйде. Өйдәге китаплар арасыннан ул Чернышевский, Герцен, Добролюбов, Некрасов әсәрләрен табып алды һәм аларны йотлыгып укырга кереште. Һәр томны кулына алган саен, бу тыелган китапларны Кокушкинога китергән мәрхүм Александр Иванович Пономаревны — Люба апасының ирен рәхмәт белән искә алды.

Апасы Анна һәрвакыт аның янында, ул һәрнәрсәдә ярдәм итәргә әзер тора. Ләкин үзе кирәкмәгән сүзләр белән тынычсызламый, аның гаебе аркасында бөтен семья тормышының менә тагын кыен хәлгә калуын әйтеп, канга тоз салмый.

Володя укый да укый. Укып белгәннәре турында уйлана, аларны тирә-юньдәге чынбарлык белән чагыштырып карый. Аннары бергәләшеп Некрасов шигырьләрен ятлыйлар, кем тизрәк һәм күбрәк шигырьне күңелдә калдыра — ярышалар, барлык семья члennары бергә яшәгән вакытта җыелышып уйнаган уеннарын уйныйлар.

Сирәк-мирәк туганнары, әнисе килеп китә. Алар килгән көннәр чын бәйрәм була. Шунысы кызганыч: Ольга белән Митя гел килә алмый — алар укыйлар. Бөтен кыш буена, әниләре һәм нянялары Варвара Григорьевна белән килеп, бары тик бер ай чамасы гына торып киттеләр. Менә ул көннәр чын-чынлап күңелле булды, әнисе һәм Ольга рояльдә уйнадылар, барысы бергә җыелгач, киләчәк тормыш турында киңәштеләр.

Володя мылтыгын асып чаңгыда йөрергә ярата. Сирәк-мирәк, полицейскийдан качып, якын-тирәдә сөргендә булган иптәшләре — университетта дуслашкан егетләр янына барып кайта. Хәтта кайвакыт, бергә укыган дусларын күреп кайту өчен, Казанга барырга да тәвәккәллек итә.

Мондый очрашулардан соң, Володя бөтен дөньясын онытып тагын укырга керешә. Чернышевский әсәрләре — аның өчен бигрәк якын. «Нәрсә эшләргә!» романын ул кабат-кабат укый, укыган саен аннан яңа мәгънә таба.

Ә Анна Ильинична кичләрен немец һәм итальян хикәяләрен рус теленә тәрҗемә итә. Бирёдән, Кокушкинодан, ул балалар журналына бер әкият, ике шигырь дә язып җибәрә...



Г. Милентьевның «Володя Кокушкинода» рәсеменнән репродукция.

1888 елның язы иртә килде, кар да тиз эреп бетте. Менә инде урманнарга, чокыр читләренә чирәмиәр чыкты, кырлар, урманнар да яшеллеккә төренде.

Володя һәм Анна Ильинична кояшлы көннәрдә, язгы табигатькә сокланып, сабан тургае җырын тыңлап, басуларда йөрергә ярataлар. Ләкин яз шатлык кына алып килмәде. Яз көне авылдагы ярлы кешеләрнең хәле тагы да кыенлашты. Шул ук вакытта байларның артык ашлыклары амбар тулы иде. Ярлылар көз көне икеләтә-өчләтә артык итеп түләү шарты белән алардан ашлык алып торырга мәҗбүрләр. Дыдыкин дигән бер комсыз байга Люба апалары да бурычка керде.

Казан губернасында бу елны янгыннар ишәйде. 1888 елның маенда губернада 171 янгын булып, мең ярымга якын йорт янды. Бары тик Лаеш өязендә генә дә Щетинка һәм Поповка авыллары бөтенләе белән диярлек янып бетте. Әйе, уйланыр нәрсәләр күп иде Володяга.

Эшчеләрнең, крестьяннарның хәле турында Володя Уралда врач булып эшләүче туганнан туган апасы һәм абыйларыннан да күп ишетте. Федор Александрович Ардашев, Александр Андреевич Залежский, Анна Ивановна Веретенникова — талантлы, заманның алдынгы кешеләре иде, һәм алар шәһәрләрдәге уңай тормышка караганда илнең караңгы почмакларында халыкка хезмәт итүне артыграк күрделәр. Ләкин мондый авыр тормыш аларны якты дөньядан бик яшьли алып китте...

Владимир Ильич, уйлана торгач, шундый нәтиҗәгә килде: юк, туганнан туган абыйларының һәм апасының, халыкка хезмәт итәм дип, үз-үзләрен аямый эшләүләре дә, Александр кебек террор юлына басу да патша коллыгыннан халыкны азат итмәячәк!..

1888 елның июлендә Александр Ильичның университетта



В. И. Ленинның туганнан туган апасы А. И. Веретенникова.

бергә укыган дусты Марк Тимофеевич Елизаровның Кокушкинога килүе барысы өчен дә зур шатлык булды. Владимир Ильич аның белән шахмат та уйнады, сөйләшеп утырырга да ярата иде. Аның сөйләгәннәреннән Урта Идел буендагы крестьяннар хәле турында Володя күп нәрсә белде...

Көзгә таба кунаклар таралдылар. Алар киткәч, ялгызлык үзен бик нык сиздерә башлады. Җитмәсә, туганнан туган апасы Анна Ивановна Веретенникова да үлеп китте. Володя җаны-тәне белән Казанга омтылды, укуын дәвам иттерергә рөхсәт сорап әллә ничә прошение язды...

* * *

1888 елның көзендә Казанда ару-талуны белмәс оештыручы һәм революционер Н. Е. Федосеев җитәкчелегендә ныклы марксистик юнәлештәге берничә түгәрәк эшләп килә.

Казанга кайтканнан соң, Владимир Ильич та шул түгәрәкләрнең берсенә йөри, шунда революцион теорияне үзләштерә: К. Маркс, Ф. Энгельсның күп кенә хезмәтләрен укый һәм җитди рәвештә «Капитал» әсәрен өйрәнергә керешә. Пролетариатның Россиядәге патша самодержавиесен һәм буржуазияне бары тик марксистик теория белән коралланып кына җиңәчәген ул нәкъ менә шушы түгәрәккә йөргәндә күрә. Ниһаять, озак вакытлар эзләгән дөрес юл табыла!..

Улының Казанга кайтуы Мария Александровнага җиңеллек китерми, әлбәттә. Бик нык яшеренеп кенә булса да, Владимир Ильич революцион фикердәге яшьләр белән очрашуны дәвам иттерә, алай гына да түгел, хәтта ул яшерен түгәрәк эшләре белән элеккедән дә күбрәк шөгыльләнә.

Ана, улын бәла-казадан саклап калырга теләп, аның игътибарын хуҗалык эшләренә юнәлтергә уйлый. Җае да чыгып куя: Любовь Александровна Кокушкинодан бары бер чакрым арырак Бутырка авылында утар сатылуын хәбәр итә. Ләкин бу авыл Мария Александровнаны канәгатьләндерми, чөнки Казанга бик якын. Ул Самара янындагы Алакаевка авылын артыграк күрә.

Шулай да Ульяновлар семьясы моннан соң да күп тапкырлар Кокушкинода була. Мәсәлән, 1894 елда җәй көне биредә Мария Александровна, Димитрий Ильич һәм Мария Ильинична ял итә. Аларның шул вакыт бергәләп төшкән фото-рәсемнәре әле дә саклана.

А. Д. Бланк нәселе акрынлап таралып бетә, утар варисларының күбесе үлә; аны сатарга дигән карарга киләләр.

Владимир Ильич Себердән 1897 елның 15 июнендә М. Т. Елизаровка болай дип яза:

«Кокушкиноның сатарга хәл ителүе һәм Митяның бу эш буенча Казанга китүе минем өчен яңалык... Бу эшнең ни белән бетүе турында языгыз. Бер яктан, аның, ниһаять, тәмам бетүе яхшы кебек, ә икенче яктан, бу «бетү» шулай да бик күңелсез, мәшәкатьле һәм, мөгаен, зыянлыдыр...»

1897 елның 1 июлендә Мария Александровнага ул: «...Кокушкино эше турында язган хатыңны алдым,— дип яза,— һәм аңа җавап та язган идем. Кичә шулай ук Митядан да хат алдым. Ул анда Казанга баруы турында сөйли...»

В. И. Ленинның тагын бүтән хатларыннан күренгәнчә, утарны сату мәшәкатьләре 1898 елга кадәр дәвам итә.

Бу таркалган хуҗалыкны сатып алырга Апакайда да, бүтән күрше авылларда да атлыгып тормыйлар. Ниһаять, утар Фадеев дигән кулак кулына күчә. Авылдагы крестьяннар бөек Октябрь революциясенә кадәр аңардан бик күп җәбер-золым күрәләр...

Яшь Совет республикасы авыр чор кичерә: һәр җирдә ачлык, җимереклек. Гражданнар сугышы әле беткән генә. Кокушкино авылы да ярым җимерек хәлдә. Крестьян

хуҗалыклары тәмам бөлеп беткән. Кемгә мөрәҗәгать итәргә, кем белән киңәштабыш кылырга!

Һәм алар үзләренең элеккеге авылдашлары В. И. Ленинга хат язарга булалар.

*«Кадерле иптәшебез, Владимир Ильич!— дип башлана бу хат.— Иң башлап сиңа авыл картларыннан, синең белән бергә шамай уйнап йөргән, так-җөп уеннары уйнап йөргән, атлар саклап урманнарда куныл йөргән, сине яхшы белә торган һәм яхшы хәтерли торган авыл картларыннан сәлам җибәрәбез. Ул заманнардан бирле 45 ел гомер үтте. Бу еллар эчендә күп үзгәрешләр булды. Совет властеның беренче чакыруы белән үк без 1917 елның октябрендә үзебезнең алпавытларның, шул исәптән Бланклар имениесендә 25 ел утырган кулак Николай Фадеевның да тубәсенә утырттык. 1918 елда барыбыз бер кешедәй булып Кызыл Армиягә бардык һәм Советлар властен аңа һөҗүм иткән дошманнарыннан: алпавытлардан, генераллардан, капиталистлардан сакладык. Шуның соңында, безнең якларда икмәк уңмыйча калып, ачлык килде. Халык һәм терлекләр үләт чире вакытындагыга караганда күбрәк кырылды. Шуларның барысыннан безнең хуҗалык шундый бөлгенлеккә төште ки, бу үлек хәленнән аны бөтен мир белән генә тергезеп булачак. Җанлы көч юк. Бер генә тәзек әй юк. Бөтен нәрсәне ачлык ялмап алды. Алпавытлардан һәм кулаклардан коткарганың өчен без сиңа бүләк итеп сөенә-сөенә ни булса да җибәргән булыр идек, әмма бернәрсәбез дә юк. Натурналогны һәм ике гомуми-гражданлык налогын тәгаллап түләдек. Безнең ике бәлабез бар: ат юк һәм авылда мәктәп юк. Советлар властеның атсызларга кредитка ат биргәнен беләбез без. Үзебезнең элекке авылдашыбыз буларак, без синнән безнең өчен Совет хөкүмәте алдында ат алу өчен кредит бирелүен үтенүеңне сорыйбыз. Атсыз — бер кулсыз: җиребез бар, шул җирне эшкәртер әйберебез юк. Тагын шул турыда сиңа белгертмәкче булабыз: Без Татарстан республикасы хөкүмәтеннән авылыбызда һөнәр һәм грамота мәктәбе салдыру турында үтенәбез, ул мәктәпкә синең әниең мәрхүмәнең исемен — Мария Александровна исемен бирмәкче булабыз. Сүзебезне йомгаклап, синнән шуны үтенәбез: зинһар, сәламәтлегеңне сакла, син бит безнең бөтен Россиягә бердәнберебез. Мәктәп салынуга сине үзебезгә кунакка чакырабыз, үткәннәрне искә төшереп алырбыз. Бүгеннән башлап Кокушкино авылы синең исемең белән атала, иптәш Ленин. Шуның соңында хуш, исән бул.*

*Туганлык сәламе белән Черемышево волостеның Ленино (Кокушкино) авылы җәмәгатьчелеге».*

Бу хат, Владимир Ильич каты авыру хәлендә булганга, «Правда» газетасының җаваплы секретаре Мария Ильиничнага тапшырыла...

1923 елның январенда Кокушкино крестьяннары тагын җыенга җыелалар. Алар «Правда» газетасында басылып чыккан үзләренең хатларын укыйлар.

— Әйе, безнең хатны газетаның түренә урнаштырганнар,— диләр крестьяннар.— Димәк, Владимир Ильич үзе дә аны укыган...

Озакламый бу хатның нәтиҗәләре дә күренә: крестьяннарга хөкүмәт атлар, яңа йортлар салу өчен бүрәнә, орлыкка ашлык бирә. Мәктәп тә ачыла. Укытучы булып Владимир Ильичның туганнан туган апасы Евдокия Александровна Ардашева-Жакова килә.

Кокушкино крестьяннары В. И. Ленин белән бәйле урыннарны сакларга, мәңгеләштерергә тырышалар. Менә шуңа күрә 1922 елда авылны Ленино дип үзгәртергә карар кабул итәләр. 1931 елда оешкан колхоз да В. И. Ленин исеме белән йөртелә башлый.

Укытучы Евдокия Александровна, авылдашларының соравы буенча, бу урыннардагы В. И. Ленин белән бәйле истәлекле урыннарны мәңгеләштерү эшләре турында киңәшү өчен Анна Ильинична Ульянова-Елизарова янына бара, «Правда» газетасына хат яза.

Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы тарихи истәлекләрне саклау комитеты бу хатны алгач, В. И. Ленин Үзәк музеена, Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советына Кокушкинода В. И. Ленин белән бәйле урыннарны мәңгеләштерү өчен чаралар күрүне сорап мөрәҗәгать итә.

Шулай итеп Кокушкино авылында В. И. Ленин музей-йорты ачарга карар кылына. Оештыру эшләре өчен махсус комиссия төзелә.

Владимир Ильич һәм Анна Ильинична сөргендә вакытта яшәгән флигельне яңадан салырга кирәк була. Мирзаян Миңнегулов һәм башка авыл картлары флигельнең элеккеге нигезен күрсәтәләр, Евдокия Александровнаның ире П. К. Жаков бинаның проектын әзерли. Владимир Ильичның туганнан туган энесе Н. И. Веретенников, төзелеш вакытында килеп, бинага күп кенә төзәтмәләр кертә. Утарны элекке хәленә китергәндә Анна Ильинична, Мария Ильинична һәм Димитрий Ильич Ульяновларның да күрсәтмәләре искә алына.

Ниһаять, 1939 елның 23 январенда Кокушкинода тантаналы төстә В. И. Ленин музей-йорты ачыла.

Музей-йортның беренче директоры, 1924 елдан КПСС члены Шәмсеруй Шәйнурова күп мәртәбәләр Н. И. Веретенниковны күреп сөйләшә, Димитрий Ильич янына бара. Аның тырышлыклары аркасында Ленинградтан В. И. Ленинның скульптура һәйкәле китертелә һәм ул утар тирәсендәге паркның түренә урнаштырыла...

1969 елның январенда Кокушкинодагы В. И. Ленин музей-йорты ачылуга 30 ел тулды. Бу вакыт эчендә авылда зур үзгәрешләр булды. Якында гына М. А. Ульянова исемендәге мәктәп өчен яңа бина салынды, Кокушкино һәм Апакай авыллары Ленино-Кокушкино совхозы булып берләштеләр. Бик күп яңа йортлар, җәмәгатьчелек биналары барлыкка килде.

Совхозда бик зур кош үрчетү фабрикасы салынып бетеп килә. Бишьеллык ахырында ул елга 40 миллионнан артык йомырка бирәчәк. Озакламый 1800 кешелек яңа поселок салуның генераль планы расланачак, шулай ук В. И. Ленин туганнарының каберлеге дәүләт сагы астына алыначак...

Җирдә дулкынланмыйча үтү мөмкин булмаган юллар бар. Шундый юлларның берсе Казан белән Ленино-Кокушкино арасы.

Бирегә кешеләр елдан-ел күбрәк килә. Кышын да, җәен дә, көзен дә, язын да киләләр алар. 1967 елда Кокушкинодагы В. И. Ленин музей-йортын алтмыш меңгә якын кеше карады. Кешеләр музей-йортны илебезнең барлык почмакларыннан килеп карыйлар. Алар арасында барлык милләт вәкилләре дә бар.

Бу йорт турында чит илләрдә дә беләләр. Чит ил кунаклары Германия Демократик Республикасыннан да, Польшадан да, Румыниядән дә, Чехословакиядән дә, Франциядән дә һәм башка илләрдән дә килә. Һәрберсе В. И. Ленин турында күбрәк белергә тели, һәрберсен бөек юлбашчының тормышы һәм халык бәхете өчен колач җитмәс эшчәнлеге дулкынландыра...

Яз көннәрендә һәм җәйләрен килгән кунаклар В. И. Ленин музей-йортын карап чыгалар да биредәге парк буйлап йөрергә яраталар. Барысы да — Ленин баскан эзләр, Володя таптаган сукмаклар. Ә тирә-якта — чәчәкләр, сирень, шомырт чәчәкләре... Чикләвек куаклары астында махсус түтәлләрдә розалар үсә. Елдан-ел ишәя һәм бик матур булып чәчәк ата алар...

Габдрахман Әпсәләмов

# ЯШЕЛ ЯР


РОМАН

Кадерле укытучыларым Нурый абый Юсупов, Җәләл абый Хәсәнов, Фазыл абый Исхаков, Мария Константиновна Пятницкая, Мәһинур апа Фәйзуллина, Александра Дмитриевна Аитова... Мин һаман сезне сагынам, сезнең турыда уйлыйм. Минем алдымда сез дөньядагы иң гадел, иң яхшы һәм иң зур кешеләр.

*Габдрахман Әпсәләмов*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1



Томан...

Дөньяны аксыл томан сарган. Ике адымнан да бер нәрсә күренми, беленми, әйтерсең, яр буйлап сузылган куе нарат урманы да, тын гына аккан киң Идел дә, ярга кысылып, туктаусыз гудок бирә-бирә әкрен генә баручы теплоходлар, үзйөрешле баржалар, катерлар да юк, барысын да шул мамык кебек аксыл томан йоткан, ә яр буендагы зәгыйфь тавышлар — алар мәңгегә тынар алдыннан соңгы инрәүләр генә. Тагын берничә минут үтәр-үтмәс барысы да бетәр, һични кузгалмас, шылт иткән тавыш ишетелмәс, бары тик аксыл томан гына йөзәр.

Агач башыннан чык кунып авырайган яфрак өзелеп төшә. Ул гадәттәгечә үтә күренмәле зәңгәр һавада үз алдына очмый, төшимме, төшмимме дип икеләнми, бәлки өстенә сарылган вак энҗе бөртекләрен артык күтәрә алмыйча, томан эченнән башы гына күренгән агач төбенә үк тавыш-тын чыгармыйча ята. Аннары икенчесе, өченчесе төшә. Алары да, гүя менә безнең урын монда икән, дип язмышларына буйсыналар. Ләкин бу тыштан гына шулай, мәңгелек тынлык һәм тынычлык юк, ак томан эченнән кояшның беренче нурлары бәреп чыга. Башта алар йомшак, буйсынучан булып күренәләр, чынлабрак карасаң, алар бер дә курыкмый, чигенми, киресенчә, дөньяны сарган аксыл томанга һөҗүм итәләр. Томан башта күзгә күренмичә, аннары инде ачыктан-ачык дерелдәп куя, тартыла, сузыла, сирәгәя. Томан эченнән агач башлары, дача каралтыларының түбәләре, бераздан теплоход

сыртлары калка. Тора-бара алар инде ачыграк күренәләр, томан инде җиргә сарылып, агач араларына посып, яр буйларына сыенып агыла башлый, гүя артына карый-карый китә дә ничектер кинәттән генә юкка чыга. Бөтен җир балкый, Идел үзенең ярлары, җем-җем иткән шаян дулкыннары, бихисап дачалары, көймәләре белән кабатланмас бер төс ала, барысы да кояшны сәламли...

Нәкъ шул минутта Гәүһәр, иңенә чачаклы сөлге асып, су буена килеп басты. Тулы ак йөзендә, сылу гәүдәсендә йокы ләззәте дә бетмәгән кебек иде әле, әллә кай ягы белән ул яңа гына мичтән чыккан җылы ак күмәчкә охшый иде. Әнә өстеннән күренер-күренмәс җылы буы күтәрелә кебек. Ә бераздан тамырларындагы бу җылы талгынлык юкка чыгар. Менә тын яткан суга таба бер адым, ярты адым гына атлыйсы калды. Гәүһәрнең озынча кара күзләре киңрәк ачылып китте, йөзенә елмаю чыкты, шунын артыннан ук як-ягына каранып алды. Былтыр су дачалар янында ук иде, быел әнә ничек кимегән, коеныр өчен дә ап-ак ком өстеннән әнә күпме барырга кирәк. Җәй башында Идел төбендә йомылып яткан кечкенә утраулар әле анда, әле монда калкып чыкканнар. Идел өсте инде тоташ су көзгесе түгел, ул чуарланып беткән, әллә ни хәтле култыклар барлыкка килгән. Бигрәк тә Иделнең бу сөзәк ярында шулай. Былтыр дулкыннар йөгерешеп йөргән урыннарда быел бер дә батмыйча автомобильләр чаба.

Кайтып бетмәгән дачниклар да бу вакытта изрәп йоклыйлар әле, эшкә барырга да, болай йорт тирәсендә тулганырга да иртә. Яр буенда беркем юк. Августның икенче яртысында су керүчеләр гомумән сирәгәя, ай ахырына таба алар да бетә, бары тик һәвәскәрләр генә кала. Әмма аларны инде рәтләп күрмисең дә, чумып алалар да тизрәк өйгә йөгерәләр. Яшь укытучы Гәүһәрне исә һәвәскәрләр исәбенә кертеп булмый, ул көнеле теләгәндә генә коена. Суык тияр дип һич тә курыкмады, шулай чыныккан идеме, болай нык үзәкле кеше идеме, бу турыда да Гәүһәр баш ватмады. Ул күтәрелеп килгән кояшка, аннары ничектер үтә матур Идел өстенә тагын бераз көлемсери төшеп карап торды. Аның бу ваемсыз көлемсерәвендә, исе китмәгәнрәк бер кыяфәт белән басып торуында үз-үзенә эчке ышану да, тормышыннан тирән канәгатьлек тә, бәхет тою да бар иде. Шул ук нәрсә аның бөтен хәрәкәтләренә дә күчкән кебек: менә ул ашыкмыйча, кабаланмыйча эре бизәкле халатын салды, резин башлыгын рәтләде дә, эссе җәй көнендәгечә рәхәт тоеп, суга таба атлады. Чирканмады, суга кереп йөзеп китте. Тик су салкынлыгыннан сулышы гына капты. Икенче секундта инде ул бернинди тартыну сизмичә колач салып йөзә иде.

Күңеле булганчы коенгач, ярга чыгып, әйбәтләп сөртенде дә халатын киде, резин башлыгын салып озын толымнарын сүтте. Чәче юешләнә төшкән икән, әзрәк кипсен, өйдә үрермен дип, толымнарын аркасына таратып җибәрде. Аннары тагын бер тапкыр Иделгә карап алды: киң дә, тыныч та, мәһабәт тә. Күңелгә саласы иде шул олылыкны, аннары кыш буе йөртәсе иде шулай, кешеләрнең исен китәреп.

Ишек алдындагы бакчада чәчәкләр чалмаларын кыңгыр салып утыралар. Җәйнең җәй буе Гәүһәр аларны карады, кадерләде, үстерде. Озакламыйча аларны өзәргә туры килер. Вазада алар матур матурын, тик озакка түгел, шуңа күрә кызганыч. Дөрес, киләсе елда аларның яңалары, тагын да матурраклары үсәр, шулай да болары кызганыч, өзмисе иде аларны, бураннарга, салкыннарга карамыйча, кыш буе саклыйсы иде шунда. Идел ярындагы эчке шатлыгын куып, күңелен нәрсәдер чеметеп алгандай булды, ул инде үзенең бер нәрсә дә эшләтә алмавын сизде. Дөресрәге, бер нәрсә дә эшләтергә кирәкми иде, чөнки табигать законнары барыбер үз юлыннан бара, алар синең катнашуына мохтаҗ түгел. Гәүһәр яңадан исе китмичәрәк елмайды, юләрләнә кайчак яшь күңел.

Наратлар арасына салынган гаражга, җәйге кухняга Гәүһәр йөгерек караш кына ташлады, гүя алар чит кешенеке иде. Ике ягына да чалмалы чәчәкләр үскән тар гына юлдан тиз генә үтте дә, тәнендә юеш купальникның салкынчалыгын тоеп, ашыгып өйгә кереп китте.

Дачалары ике бүлмәле иде. Берсе — алдагысы аш һәм килгән кунакларны кабул итү, икенчесе — арттагысы, йокы бүлмәсе. Арадагы ишек ачык калган. Гәүһәр башын гына сузып карады: ире Җәгъфәр мендәрен кочаклаган да тын гына мышнап йоклый. Гәүһәр елмаеп куйды да, террасага узып, чишенә башлады...

Инде киенеп, кухняга чыгам дигәндә Җәгъфәрнең тавышы ишетелде:

— Гәүһәр, вакыт күпме соң? Һай, иртә ич әле, нишләп шулай иртә тордың?

— Мин инде киенеп та мендем. Бар, син дә коен, су май кебек.

— Сөйләмә юкны.

Җәгъфәр тәмле итеп киерелеп алды.

— Кара, йокыңны качырасың ич,— диде Гәүһәр һәм көлә-көлә кухняга чыгып китте. Узышлый, ишек алдындагы чәчәкләргә тагын карап алды. Алар гүя тиздән өзеләчәкләрен сизәләр, кыңгыр салган чалмаларында ниндидер тирән моңсулык бар. Вакыты житкәч, өзми дә чараң юк шул. Анысы шулай, тик нигә соң Гәүһәр элегрәк моңа игътибар итмәде, ул бит чәчәкләрне өзәргә туры киләсен белә иде. Әллә, көне житмичә кош сайрамый дигәндәй, вакыты житмичә бу уйлар да кешенең башына килмиме?

Кухняда Гәүһәр, бераз боегып, сәгатенә күз ташлый-ташлый эшләде. Хәер, иртәнге ашка вакыт әллә ни кирәкми, көндез Гәүһәр мәктәбендә, Җәгъфәр институтында тамагын туйдырыр, ә менә кичкә аш әзерләр өчен кибеткә яки базарга кагыласы булыр. Ике кешегә булса да нәрсәдер кирәк бит, өйдә запас юк, шәһәрдәге квартираларында да такыр. Гәүһәрнең мондый хәлгә бер дә калганы юк иде. Шәһәрдә әллә ни запас җыеп булмаса да, шулай да тегесен-монысын алгалый иде ул. Җәгъфәр, җәйнең соңгы аенда ял итеп калыйк, дип бәйләнде бит. Аның теләгенә буйсынып, Гәүһәр бер атна инде шәһәрдәге квартираларына кайтканы юк. Хәер, Җәгъфәрне генә гаепләп булмый. Гәүһәрнең үзенең дә соңгы атнада табигать кочагында ятасы килде, мәктәптә эшли башлагач, бу рәхәтләр бик эләкмәс әле, иртәдән кичкә кадәр чабарсың, мәктәп тормышы шундый инде ул. Аннары, ял итүдән бигрәк, җәен башлаган этюдларын тәмамлыйсы килде аның. Вакытында Гәүһәр художество мәктәбендә укый алмады, ул чакта әти-әниләре исән булсалар да, авылда рәсем ясауның кирәкле эш икәнен кем белгән. Соңыннан Арча педучилищесында укыганда да аның бу теләге ничектер йомылып калды. Актыккы курста укыганда ул Җәгъфәр белән танышты һәм аңа кияүгә чыкты. Ире аны авылга җибәрмәде, Гәүһәр үзе дә авылга китәм дип өзелеп тормады. Шәһәр мәктәпләренең берсендә аңа эш табылды. Менә шунда инде, башлангыч классларда укыту белән бергә, ул рәсем эшенә дә кереште. Җәгъфәр моңа әллә ни каршы килмәде, яшь хатынның яшьлек мавыгуы, күңеле кайткач, үтәр дә китәр, булмаган да диярсең, дип уйлады. Чыннан да икенче елны ук Гәүһәр бу эшен ташлады. Бер елдан соң мольбертын кулына алса да, Җәгъфәрнең моңа тагын артык исе китмәде, тагын ташлар, дип уйлады. Ул кандидатлык диссертациясен язып бетереп килә иде. Ире үзе әйтмәсә дә, Гәүһәр аның нинди зур эш башкаруын бик яхшы белә, өйдә аңа эш өчен шартлар тудыру — Гәүһәрнең төп бурычы булып китте. Билгеле инде, мондый чакта үз эшләреңне, күңелең никадәр яратса да, артка чикми булмый. Соңыннан Җәгъфәр диссертациясен уңышлы тәмамлап, югарырак эштә эшли башлагач һәм үзенә хас бер өлгерлек белән Идел буенда дача да салып җибәргәч,

Гәүһәр яңадан рәсемнәренә тотынды, аның бу эшкә мәхәббәте сүнмәгән иде, әйтерсең, ак көл астында һаман шул алтын чаткы яшәгән. Дөрес, хәзер ул элеккечә мавыкмый, атаклы художник булу турында хыялланмый, әмма күңел юанычы өчен бу кадәресе дә ярый. Ул я Идел күренешләрен, я үз классындагы балаларның рәсемнәрен ясый. Җәен дачада да балалар күп була, ләкин Гәүһәр күргән бер нәрсәгә ташланмады, ул бөтен нечкәлекләренә кадәр үзе яхшы белгән балаларны гына — үз классындагы балаларны гына алды. Ире, иҗат өчен моның асла кирәге юк, төрлелек, киресенчә, художникны баета гына, дип әйтә башлагач, Гәүһәр, елмаеп, әкрен генә каршы килә яки: «Җәгъфәр, зинһар, минем эшемә катышма, мин бит шаярам гына», дия иде. Моны ул әллә чынлап, әллә юри әйтә, тик бу сүзләрдән соң ул бик озак уйланып утыра иде. Аның рәсемнәре арасында Юлдаш дигән бер малайның сурәте бар. Читтән караган кешегә бу рәсем тәмамланган кебек күренсә дә, Гәүһәргә аның кай җиредер ошамый иде. Җәй буе төзәтте, төзәткән саен бозды гына бугай. Ахырда бөтенләй ташлады. Менә мәктәптә тагын күзәтер әле, җитмәгәнен бәлки табар...

Гәүһәр аш әзерләгән арада Җәгъфәр йокыдан торган иде. Ул әйбәтләп юынды, аннары машинасын карады. Өр-яңа «Москвич». Мондый әле күпләрнең төшенә дә керми. Җәгъфәр аны капотыннан сыпыргалап та алды. Бу аның иң тирән канәгатьләнүен белдерә иде. Ул, башкалар кебек, машинасы белән сөйләшмәде, аны мактамады, гомумән аның яраткан берәр нәрсәсе турында сөйләгәне булдымы икән. Барысын күңелендә йөртте, бер нәрсәне түкмәде, чәчмәде.

Иртәнге ашны уен-көлке белән ашадылар. Гәүһәрнең кәефе күтәренке иде. Ашагач, эчкәч, ул ирен дә ашыктыра башлады. Җәгъфәр сәгатенә карады да көлеп җибәрде: үз машинасы булган кеше шундый иртә кузгаламы соң! Егерме, егерме биш минутлык юл, ә хәзер сәгать ярым вакыт бар әле. Ләкин хатынына тагын бер карап алгач, сүзне артык куертмады. Бүген бит беренче сентябрь, Гәүһәрнең таң тишегеннән торуы да шуның белән бәйләнгән. Бүген инде аны өйдә тота алмыйсың, бу кадәресен Җәгъфәр яхшы белә иде. Ул, рәхмәт әйтеп, урыныннан торды да киенергә кереп китте.

Бераздан өстенә әйбәт кара костюм, костюм өстеннән ефәк кара плащ кигән, ялан башлы, озын буйлы Җәгъфәр машинага кереп утырды. Янына күн папкасын куйды. Гәүһәр аның белән янәшә урнашты. Машина җиңел тәгәрәп урамга чыкты. Хәер, дачаның урам дип әйтерлеге юк иде. Башта алар агач арасыннан бардылар, аннары асфальт юлга борылдылар. Җәгъфәр кирәгеннән артык кызу йөрергә яратмый иде, әмма асфальтта тизлекне арттырмыйча түзмәде. Гәүһәрнең уйлары исә тагын да кызурак иде. Быел Гәүһәр алтынчы ел укыта инде, һәр ел беренче сентябрьдә ул нигәдер аеруча дулкынлана. Балаларны да, классны да сагынган иде ул. Ихтимал, үз балаларының булмавы да монда роль уйный торгандыр. Дөресен әйткәндә, Гәүһәр бала ярата, бала булмавы аны бик нык борчый иде. Тик гаепне кемгә сылтарга белмәде. Җәгъфәр исә бу турыда артык борчылмый, ыбыр-чыбыр асрарга өлгерербез әле, башта азрак яшәп калырга кирәк, гомер ике килми, ди иде. Әлбәттә, Җәгъфәр моны шаяра төшеп әйтә, Гәүһәрне күңелсезләндермәс өчен бар гаепне үз өстенә ала. Әмма чын дөресен белмәгәнгә, Гәүһәргә дә сүз озайтырга урын калмый. Шуңа күрәдер инде ул үз классындагы балаларга артык бәйләнгән. Алар гүя аның ниндидер җитешмәгән ягын тулыландыралар иде.

Алда шәһәр күренә башлады. Бистә урамнарына килеп керү белән үк бүген беренче сентябрь көне икәне күзгә бәрелә башлады. Ак алъяпкычлар, ак якалы күлмәкләр кигән, кулларына чәчәк, портфель тоткан балалар, әби-бабаларын, әти-әниләрен иртеп, мәктәпләргә

ашыгалар. Сонга кала күрмик, дип уйлыйлардыр инде. Гәүһәр аларга карый-карый ихтыярсыз көлемсерәп куйды. Монда сез түгел, сездән зурраклар да пошына шул, күгәрченнәрем. Аның күңелен тулысынча балалар биләп алды. Ничек яшәде соң ул алардан башка җәй буе? Юк, бу чын мәгънәсендә тормыш булмагандыр, бу... Кызык, ләкин бүген ул икенче мәртәбә инде бер үк уйга килде: күрәсең, вакыты житкәнче кеше онытылып тора, ә аннан соң...

Җәй буе Гәүһәр этюдлар белән мәш килде, кунакларына да шуларны гына күрсәтте. Ә хәзер инде болар артка чикте, онытылды. Бары тик балалар гына, мәктәп кенә калды. Әнә дүрт катлы мәктәп үзе дә. Асфальт, газоннар һәм бихисап балалар...

Гәүһәр, машинадан төшеп, туры мәктәпкә юнәлде. Җәгъфәр эшләгән җиренә китеп барды. Мәктәп янында Гәүһәрне бер төркем балалар каршы алды. Шаулашып-гөрләшеп исәнләштеләр. Гәүһәр гадәтенчә аларның башларыннан сыйпады, аркаларыннан сөйде. Балаларның күбесенең кулларында чәчәк. Әмма алар үзләре дә чәчәккә охшыйлар иде.

Гәүһәр балалар белән бергә мәктәпкә керде, аннары икенче каттагы укытучылар бүлмәсенә юнәлде, балалар өченче катка — үз классларына йөгерделәр. Укытучылар бүлмәсендә Гәүһәр дуслары белән исәнләште. Кайберләре белә алар дачада бер тирәдәрәк торганнар иде, күбесен Гәүһәр җәй буе бөтенләй күрмәде, алар курортларда, санаторийларда, ял йортларында булганнар. Яңалыкларның очы-кырые юк, бик кызыклыларын шунда ук сөйләделәр. Ул арада бүлмәгә яңадан-яңа укытучылар тулды, кергән берсе я кул биреп, я баш иеп исәнләштеләр дә иң якын дуслары янына уздылар.

Яше шактый өлкән булса да, гәүдәсе төз, кояшта янган йөзендә нур уйнап торган ак чәчле мәктәп директоры Шәриф Гыйльманович Исмәгыйлов күренде. Ул барлык укытучылар белән ягымлы гына күрешеп чыкты, Гәүһәргә дә елмаеп кул бирде. Бер-ике сүз белән генә җәйге ял турында сорашты. Гәүһәр моннан бер атна элек мәктәпкә кереп чыккан иде, ләкин директорны күрмәде, завуч белән генә сөйләште.

— Кайда болай кызындыгыз, Шәриф Гыйльманович? Сез ялга да бармадыгыз шикелле?

— Иделдә яшик тә, кояшта кызынмыйк, имеш,— диде директор, кашын сикертеп.— Картая төшкәч, сез дә, Гәүһәр, Иделгә гашыйк булырсыз әле.

— Мин болай да Иделгә гашыйк, Шәриф Гыйльманович. Җәй буе Иделдән чыкмадым.

— Күренеп тора,— диде директор һәм башка укытучыларга кул бирде.

Ниһаять, коридорлар буйлап беренче көчле звонок — бәйрәм звоногы яңгырады.

## 2

Укытучылар арасында күптәннән бер сүз йөри: әле мәктәп күрмәгән, укый-яза белмәгән жиде-сигез яшьлек нәни баланың күңеле ап-ак кәгазь бите кебек, диләр. Укытучы анда үз «исемен» теләсә ничек яза ала, соңыннан бу язуны һәрвакыт күрергә, укырга мөмкин, имеш. Гәүһәр Арча педучилищесында укыганда да, диплом алгач та бу турыда аз хыялланмады, ләкин теләгенә ансат кына ирешә алмады. Мәктәптә аңа икенче классны тәкъдим иттеләр, классны, аның элекке укытучысын мактадылар. Гәүһәр бу класстан кискен рәвештә баш тартты. Ире Җәгъфәр моны белгәч, шаккатты, ләкин гадәтенчә тавышын күтәрмичә, сабыр гына әйтә куйды:

— Тапкансың икән эш, Гәүһәр. Беренчегә булды ни дә, икенчегә булды ни. Мондый мәктәпкә алуларына шөкер итәргә кирәк иде.

Гәүһәр моны ире әйтмәсә дә белә иде. Җәгъфәр аз тырышмады, тик шул ук вакытта үз ролен күпертмәде. Иренең бу сыйфатын белми иде әле ул, күңеленнән аңа мең рәхмәтләр укыды, менә шулай үзенне күккә чөймичә яхшылык чәчеп йөрсәң иде, дип хыялланды һәм ирен тагын да ныграк ярата башлады. Айнык акыллы ире булмаса, үз сүзлелеге өчен аңа бик кыенга туры килер иде шул. Яшереп торасы юк, кайчагында Гәүһәр бөтенләй бала шикелле кылана, кая барасын да, ни эшлисен дә яхшы белми. Эш эзләгән борчулы көннәрдә Җәгъфәр аңа: «Әллә рус мәктәбенә генә урнашасыңмы?» дип тә әйтеп карады. Татар авылында туган, татар мәктәбендә укыган, русчаны училищеда гына өйрәнгән Гәүһәр рус мәктәбенә керергә бер дә батырчылык итмәде. Җәгъфәр дә бу тәкъдимнең урынсыз икәнен аңлап артык басым ясамады. Ире үз тәкъдимен бик каты яклар дип Гәүһәрнең коты очкан иде. Җәгъфәрнең кире кайтуын күргәч, эченнән аңа рәхмәттән башка нәрсә әйтә алмады. Чыннан да нинди бәхетле ул! Әгәр ире аны ярты сүздән аңламаса, әллә нинди күңелсез нәрсәләр килеп чыгар иде бит. Гәүһәр үзен бик бәхетле сизде. Юк, ул иренең кадерен белергә тиеш, ире белән һәрвакыт бер сүздә торса, ул югалмас.

Мәктәп директоры Шәриф Гыйльманович Гәүһәрнең тәкъдим ителгән класстан ни өчен баш тартуын сорашты да, күрәсең, яшь укытучының күңелен аңлап, тагын бер уйлап карарга булды. Җавап алыр өчен берничә көннән мәктәпкә кагылырга кушты. Ниһаять, Гәүһәр мәктәп директоры янына керде.

— Мин уйладым,— диде Шәриф Гыйльманович, яшь укытучыга туры карап,— сезнең үтенечне канәгатьләндерергә булдым. Ак кәгазьгә үз исемегезне язарга тырышуыгыз миңа ошады. Ләкин, Гәүһәр, шуны онытмагыз, яхшы теләк бер, тәҗрибә бөтенләй икенче нәрсә. Асылда сезнең тәҗрибәгез бөтенләй юк. Сезгә класс ышану — бик зур тәвәккәллек. Сезгә үз өстегездә бик күп эшләргә туры киләчәк. Әлбәттә, без дә читтә калмабыз, әмма укытучы — сез, сезнең эшне тартып барырга җыенмыйбыз. Сезнең эш сезнеке булып калачак. Килештекме?

Гәүһәр курка-курка гына беренче класста укыта башлады. Чыннан да аның алдында ак кәгазь икән. Ләкин ни язарга, ничек язарга? Укытучы исеме ул фамилия генә түгел бит.

Башта Гәүһәр бик нык газапланды, бер нәрсә дә чыкмас кебек тоелган көннәре дә булды, икенче классны алмавы өчен дә үкенде. Иске эздән бик рәхәтләнеп барыр иде, ә балалар гел иске укытучыны күз алдында тотарлар иде. Моның нәрсәсе хәтер калдыргыч? Әгәр бик күпкә китсә, укыту эшендәге кайбер уңышсызлыкларны да аңа сылтарга мөмкин бит. Ләкин икенче секундта Гәүһәр мондый уеннан нәфрәтләнә, тизрәк завуч, директор янына йөгерә, үзенең барлык уңышсызлыкларын яшермичә сөйли. Өлкән иптәшләре аның чәпчүен тыныч кына тыңлыйлар, үз-үзенә ныграк ышанырга чакыралар. Нигәдер Шәриф Гыйльманович Гәүһәргә аеруча нык тәэсир итә. Ул әллә ни әйтми дә кебек, ә Гәүһәр аның яныннан үз-үзенә ныграк ышанып чыга. Анннары Гәүһәрнең тынычлануында Җәгъфәрнең роле дә зур иде. Ул бит һәрвакыт Гәүһәр янында, аның пошынуларын гел күреп тора, шуңа күрә аның киңәшләре дә төплерәк шикелле.

— Башта үз көчеңнең чамасын белмисең, Гәүһәр. Соңыннан үзеңнең шундый беркатлы булуыңа үзең үк гаҗәпләнәсең. Син тынычлан, Гәүһәр.

Җәгъфәр шулкадәр дөрес әйтер икән. Бар да ул дигәнчә булды. Башта Гәүһәр тынычланды, үз-үзен кулга алды, ярты елдан соң инде үз-үзенә көлемсерәп карый башлады. Инде күр, аның классы дүртенчене бик уңышлы тәмамлады, бер укучыга да тартып-сузып өчле куярга

туры килмәде. Гәүһәр намусына тап төшермәүгә бик шатланды. Яшь укытучыны завуч та, директор да мактады, ләкин яшь укытучы үзенең беренче тәҗрибәләрен онытмады, еллар үткәч тә болар истән чыкмады. Хәзер ул тагын икенче ел яңа классны укыта, шактый тәҗрибә туплады, Шәриф Гыйльманович янына да азрак керә башлады.

— Сез бик һаваланып китмәдегезме, Гәүһәр? Әйткәнне авырга алмагыз, ара-тирә без картлар янына кергәләгез, онытып куймагыз.

— Сезне онытаммы соң, Шәриф Гыйльманович. Күңелемнән әле булса сезгә рәхмәт әйтеп йөрим.

Кеше дигәнеңә, бер карасаң, бик күп нәрсә кирәк, икенче карасаң, кеп-кечкенә нәрсәгә дә ул бик канәгать, хәтта баладай шатлана, сөенә, бөтен яшәеше шул якты нур эчендә үтә кебек. Аннан дөнья тагын да киңәя төшә кебек. Ул бүген дә, иртәгә дә, аннан соң да шул нур эчендә мәктәпкә йөрер, нәкъ сәгать тугызда класс ишеген ачар һәм: «Исәнмесез, балалар!» дип дәшәр. Балалар аңа хор белән җавап бирерләр, баскан урыннарында кузгалмаслар, Гәүһәрнең: «Утырыгыз, балалар!» дигән гадәти сүзләрен көтәрләр. Бер секунд, бәлки аннан да кимрәк Гәүһәр аларга карап торыр, барысын берьюлы күрер, башыннан бик күп уйлар кичәр, хыялы әллә кайларга китәр, балалар дәү булып аның янына басарлар,— хыял тиз йөри бит.

Көн артыннан көн үтә торды. Балалар әле тын калып, ниндидер могҗиза көткән кебек Гәүһәрнең сүзен тыңлыйлар, әле башларын кыңгыр салып, тел очларын чыгарып язалар, хисап мәсьәләләрен чыгаралар. Бармаклары карага буялып беткән, бер-берсен төрткәлиләр дә, бер-берсен үчекләп алырга да өлгерәләр. Әнә тәрәзә янында гына Гәүһәрнең сөеклесе — Юлдаш утыра. Гәүһәр бу баланы нигәдер бик ярата, җәй көннәрендә хәтта дачасына да алып баргалый иде. Әнә кара инде: бер күзе урамда, бер күзе класс эчендә. Үзе көлемсери дә, үзе җитди дә кебек. Дәресен сорасаң, күзен дә йоммыйча җавап бирә. Киеме генә бераз шапшаграк, тапланып беткән, әйтерсең, бөтен уйнаганы кара гына. Хәтта битендә дә кара табы бар. Хәер, башкалары да Юлдаштан әллә ни аерылмыйлар. Башта гына, беренче класста укыганда гына алар Гәүһәргә бер төсле сыман тоелганнар иде. Соңыннан барысы да үзгәрде, утыз алты баланың холкы утыз алты төрле булып чыкты. Менә инде син аларның җаннарына ачкыч тап! Кайчак Гәүһәр тәмам алҗып бетә иде, ләкин бер вакытта да алардан күңеле кайтмады, киресенчә, бу балалардан башка тормыш та юк кебек тоела иде аңа.

Сентябрь урталары якынлашса да, Гәүһәрләр әле һаман дачада торалар. Көннәр бик матур, җылы, җәй белән саубуллашырга вакыт дигән уй башка да керә чыкмый. Аннары үз машиналары булган кешеләргә күп дигәндә утыз минутлык юл — монысы инде бөтен тукталышларны санаганда — юлмыни ул. Бик ашыксалар егерме минутта да шәһәргә барып җитәләр. Җәгъфәр эштән кайтканчы Гәүһәр шәһәр квартираларына керергә өлгерә, кайчак кибетләргә дә кагыла, кайчак өй эчен аз-маз җыештыргалый — хатын-кызга өйдә һәрвакыт эш табыла бит. Балаларның дәфтәрләрен Гәүһәр, кагыйдә буларак, дачада карарга ярата иде. Хәзер бит Идел ярларында кеше аз, синә берәү дә комачауламый. Син кечкенә кояш яктырткан Иделгә карый-карый ачык тәрәзә каршында утырасың. Кайчак, дәфтәрләрдән аерылып, терсәгеңә таянган килеш хыялга да чумасың. Кечке Идел уйландыра. Ничектер буыннан-буынга шулай килеп чыга инде, без Иделдә бик күптәннән торсак та, аның матурлыгына бәя биреп житкермибез, аңа гади бер нәрсәгә караган шикелле карыйбыз. Хәлбуки, Идел — тиңдәше юк нәрсә, аның ярында иң нечкә ләззәтне алырга мөмкин, тойгыларың тупасланмаган булса, аның ярында бер вакытта да эчең пошмас. Ул бит гел бер төсле генә җәелми, ул һава хәленә карап та, кешенең кәефенә

карап та мең төрле үзгәрә, күңел чоңгылыннан әллә нинди уйларны калкытып чыгара һәм син шундый уйларның барлыгына, яшәвенә кайчак үзең дә гаҗәпләнәсең. Кара, дисең, нинди матур, тирән уйлар, ә алар йомылып ятканнар, син аларның барлыгын да белмәгәнсең. Шуннан соң Гәүһәр бер кадәр вакыт таң калып утыра, аның җырлыйсы да, кычкырып көләсе дә килә. Кайчагында ул, киресенчә, ничектер басынкылана, моңлана, җылыйсы, үкерә-үкерә җылыйсы, барысын да өр-яңадан башлыйсы килә. Әле соң түгелдер, гомер әле үтмәгәндер... Хәер, Гәүһәр моның нәрсә икәнен белми, бу уйларның ник тууын да аңламый. Әле генә аның кәефе шәп иде бит, әле генә ул бөтен дөньясыннан канәгать иде, хәтта ерак киләчәккә карап та берниндн исәп тотмый иде. Күрәсең, бу яшьлектер, яшьлегендә кеше йөгәнсез уйлар белән хыялланырга тиештер, шуның өчен дә кешегә яшьлек бирелгәндер.

Өстенә пижама гына кигән Җәгъфәр күп вакытта китапларына төртелеп утыра, яктырак булса, машинасы янында чуала, Гәүһәргә комачауламый. Тик хатынының, сагышланып, бер нәрсә дә эшләми утыруын күрсә генә янына килә, гүя өзелгән җирдән генә башлап, берәр мәзәк сөйләп ала, көлдерә, үзе дә тыйнак кына көлә. Аңа авыр сүз әйтергә дә белмисең, нигә көчәнәсең, дип читкә кагарга да мөмкин түгел, Җәгъфәр барысын да белә, күрә, кирәк булса, һәммәсен сөйләп тә бирә, тик күп вакытта кирәк кенә тапмый, юри юк-бар нәрсәләр белән көлдерә. Кәефе бик кырылган чакларда гына Гәүһәр иренә берике авыр сүз әйтеп ала. Ләкин шунда ук кире дә кайта, гафу үтенә. Ул бит үзе дә фәрештә түгел, шуңа күрә ирләргә нәрсә гаҗәпләнәсең, ирләр бит ни әйтсәң дә бераз башкарак инде.

Җәгъфәр хатыны янында бүген гадәттәгедән озаграк утырды. Караңгы төшсә дә ут кабызмадылар, бер-берсенә сыенып, вакыт-вакыт көлешеп тә алгаладылар. Кайчагында алар менә бүген бер-берсенәниндидер сер әйтерләр кебек тоела иде, ләкин нинди сер? Үзеңә дә аңлашылмас нәрсәләрне кешегә әйтәләрме?! Сүз сүзне чыгара бит, әллә ниләр әйтеп ташларсың, аннары үкенеп бетә алмассың.

Әмма вакыт соң иде инде. Җәгъфәр беренче булып урыныннан кузгалды. Кухняда чәй куйган идем, кайнап бетмәгән булса, хәзер кертәм, диде. Гәүһәр ире чыккач та берничә минут утырып торды әле, аннары урыныннан кузгалып, ут кабызды. Эшләнеп бетмәгән этюды күзенә чалынды. Елмаеп куйды. Бу баланың үзенчәлеген таба башлаган иде ул. Ашыгырга гына кирәкми. Кем белә, бәлки Юлдашның рәсеме аңа дан китерер. Аның турында художник дип сөйли башларлар.

Озакламый чәй эчтеләр. Гәүһәрнең кәефе ачылып китте, ул күп көлде. Аның көлүе Җәгъфәргә дә ошый иде, Гәүһәр бөтенләй эчкерсез, хәтта беркатлы кебек көлә, ә кешенең беркатлылыгы, эчкерсезлеге аның сафлыгын күрсәтә түгелме? Җәгъфәр үзен дә бәхетле итеп тоя башлады. Иртән ул бик иртә торырга, Гәүһәрне шәһәргә җилтерәтеп кенә илтергә уйлады. Иртәгә шимбә, җәй белән саубуллашыр өчен берничә пар кунак та чакырырга кирәк булыр. Гәүһәргә бу турыда иртәгә, машинада барганда гына әйтер, алдан әйтеп хатын-кызның башын катырасы юк, алар бит әллә нәрсә уйлый башлыйлар, көтмәгәндә булса, уйларга вакытлары да калмый.

Иртә белән Гәүһәр гадәтенчә бик иртә уянды, ирен борчымас өчен сакланып кына ишек алдына чыкты. Көн бүген бик яхшы булырга тора, гадәттә булмаганча җылы, тын. Коенмыйча ничек түзәсең. Соңгы көннәрдә Гәүһәр инде коенмый башлаган иде, бүген сөлгесен, резин башлыгын алды. Яр буена килгәч, Иделгә карап торды. Ул инде суның салкынайганлыгын белә, ләкин бүген моңа бер дә ышанасы килми, уләннәр дә юри генә корыган кебек, кояш та юри генә ялкаулана кебек, югыйсә ул җәйдәге кебек ялтырар төсле. Тик су гына тагын кими төшкән, утраулар да арткан.

Гәүһәр гадәтенчә чирканмыйча чишенде, чирканмыйча суга керде. Су салкын иде, Гәүһәрнең сулышы капты, бик кызу йөзеп китте. Әмма тәне җылынмады, ул бераз йөзгәч тә ярга борылды. Тик сөртенеп, киемен кигәч кенә тәне кыза башлады.

Өзелми калган чәчәкләр кояшка борылганнар иде. Күр, кояш кызуы аларны нишләтә. Шулай да чәчәкләр вакыты үткән, алар инде җәйдәгечә шатландырмый да. Гәүһәр дә тизрәк өйгә кереп киемен алмаштырырга ашыкты.

Җәгъфәр инде торган иде, машинасын көйләгән, чәен куйган. Гәүһәр урын-җирне җыештырып бетерүгә Җәгъфәр чәйнекне алып керде. Бик күңелле итеп чәй эчтеләр, Гәүһәр Иделдә коенуның рәхәтлеге турында сөйләде, ире, күз кысып, әкрен генә көлгәләп утырды. Ул хәзер түгел, җәй уртасында да коенырга ашыкмый. Хәер, Гәүһәр инде моны күптән белә, иренең бу гадәтеннән көлә-көлә туйган да иде.

Җәгъфәр, алдан уйлап куйганча, машинаны бик кызу алып барды. Ул канәгать иде, йөзе алсуланган, күзләре очкынланып киткән. Юк, гомер буе яшә, гомер буе өйрән икән! Гәүһәрнең әле ирен мондый итеп күргәне юк иде, эчке сөенеч белән аңа карады. Җәгъфәргә шул гына кирәк тә иде, чак кына көлемсерәп, башын какты да кунаклар турында әйтте. Гәүһәр иренең көтелмәгән кунакларын кайчак яратып бетермәсә дә, аның тәкъдименә бер сүзсез риза булды.

— Алайса мин, әйберләр алып, сине өйдә көтәрмен, син озаклама,— диде.

Шимбә көнне балалар аеруча бер күтәренкелек белән каршы алалар, бу көн мәктәптә гомумән ничектер бик тиз үтә. Гәүһәр соңгы дәрес килеп җиткәнен сизмәде дә. Менә инде балалар шау-гөр килеп өйләренә агылалар. Гәүһәр аларга карый да көлемсери, бик кызу чапканнарын тыя төшә. Хәер, әгәр мөмкин булса, ул үзе дә алар белән бергә чабар иде. Эше артык күп булганга түгел, болай, юри генә чабар иде. Әнә балаларның ашыгырга сәбәпләре бармыни? Юк бит. Йөгерәселәре килә, шуңа йөгерәләр.

Кибеткә кереп Гәүһәр тегесен-монысын алды да өйгә ашыкты. Җәгъфәр кайтмаган иде, ниһаять, кайтып кергәч тә нигәдер бераз күңелсез торды. Гәүһәр моңа шунда ук игътибар итте, сәбәбен сорады.

— Шимбә көнгә юри үч иткән кебек эш өяләр,— диде ул һәм хатынынннан: — Син әзерме? — дип сорады. Гәүһәр күптән әзер иде.

Утыз минуттан алар инде дачада иделәр. Монда Җәгъфәрнең кәефе бик тиз ачылды. Ул аеруча бер дәрт белән хатынына табын әзерләргә булыша башлады, бигрәк тә эчемлекләрне тырышып тезде. Ул үзе күп эчми, Гәүһәр күпме торып та аның бер тапкыр да исергәнен күрмәде, әмма эчемлекләрне әзерли белә иде. Гәүһәр гаҗәпләнүен яшерә алмыйча, кайдан мондый шәрапларны табасың, мондый маркалы, печатьле, медальле, мондый шешәле коньяклар кибеттә юк бит, дип сораштыргалап та карады.

— Кирәк булгач, табасың инде,— диде Җәгъфәр, тыйнак кына.— Кунак бит синең өстәлгә куйганыңны барысын да эчеп бетерми, ә ни куйганыңны күзәтә. Бигрәк тә хатын-кызлар.

Дача Иделгә карап салынганга, бүлмәләрдән һич кояш китми, Идел аръягына төшеп кызарып баеган чагында да тәрәзәдән бик яхшы күренә. Көннәр әле бик яхшы тора, күктә бер болыт кисәге юк, кояш нәкъ җәйдәгечә көлә, тик Идел өсте генә каралган кебек.

— Быел әллә нәрсә генә булган диярсең, җәй белән көз урыннарын алмашкан кебек. Хәерлегә генә булсын иде,— диде Гәүһәр. Аның йөзе көләч тә, аз гына сагышлы да кебек.

Җәгъфәр елмаеп куйды.

— Минемчә, укытучы моны белергә тиеш. Бездә кунак булмый торып, көннең бозылырга нинди хакы бар. Аннары көз матурлыгы көн

кояшлы булганда гына күзгә күренә бит. Шулаймы, жан кисәгем? — Җәгъфәр, берничә адым арткарак чигенеп, бер күзен кыса төшеп, өстәлгә карап торды.— Булган бит, әй!

— Харап инде,— диде Гәүһәр, көлеп.— Өстәлгә шәрап куюда әллә нинди шигърият күрәсең.

— Юк, Гәүһәр, моны миңа кадәр мең еллар элек күргәннәр, без бары тик кабатлыйбыз гына. Вакыт күпме икән? — Ул күзгеле өстәлчек өстендәге түгәрәк сәгатькә карап алды.— Әһә, вакыт бар икән. Өлгерәбез.

## 3

Бу вакытта инде дачалар тирәсендә автомобильләр күп йөрми иде. Шуңа күрә, еракта машиналар гүләве ишетелгәч, Җәгъфәр бер дә ялгышмады: бу кунаклар иде. Ике-өч минуттан инде «Победа» белән «Москвич» Җәгъфәрләр каршына килеп туктадылар. Алдагы машинадан хатыны белән инженер Исрафил Дидаров төште. Ул кыска муенлы, таза гәүдәле, күркәм генә бер кеше иде. Күп булса, аңа илleләр тирәседер. Хатыны шактый яшь күренә. Өстендә бик модный итеп тегелгән, нечкә билле, карасу кызыл төстәге күлмәк, иңенә генә салган бик әйбәт фуфайка. Арттагы машинадан өстенә яшькелт плащ кигән, чәче агара башлаган, алтын күзлекле бер ир белән шулай ук урта яшьләрдәге бер ханым төште. Хатынның өстендә кичке кара күлмәк. Тонык җирән төс бөркеп торган чәченә, Исрафил хатыны кебек, куп-шы укладка ясатмаган, бәлки биек итеп өеп куйган.

Исрафил Дидаров Җәгъфәр белән кул биреп күрешсә, Гәүһәрнең кулын үпсә, әлеге алтын күзлекле, карап торырга бер галим сыман күренгән ир бик нәзакәтле итеп башын гына иде, аннан күреп хатыны да бик эре исәнләште. Аларның беренче килүләре, Гәүһәр хәтта кем икәнлекләрен дә белми. Иң актыктан машинадан хатыны белән төшкән кеше шактый яшь, күп булса аңа утызлар тирәсе булыр. Хатыны тагын да яшьрәк. Аларның киемнәре дә, үз-үзләрен тотышлары да гадирәк. Аннары машинаны да ул үзе йөртә, чөнки алдагы машинада гына шофер бар иде.

— Ничек, дуслар, өйгә керәбезме, әллә әзрәк су буйларын әйләнеп киләбезме?— диде Җәгъфәр кунакларына.

Барысы да алтын күзлеклегә карадылар. «Монда иң зур кунак шушы икән», дип уйлады Гәүһәр. Җәгъфәр бераз таныш булган Дидаровлар гына булыр дигән иде. Шуңа күрә Гәүһәр ят кунаклар алдында югалып калды. Үзен ничегрәк тотарга да белмәде. Әллә инде бу кунаклар алдында, үзеңне түбән төшермәү өчен, бик эре кыланырга, әллә, киресенчә, үзең турында уйламыйча, аларның кәефләрен күрергә?

— Өйгә караңгы төшкәч тә керергә өлгерербез, хәзер Иделне әзрәк карыйк,— диде алтын күзлекле.

— Алайса бик шәп, менә шушы сукмактан киттек. Ул яр буена алып чыга, аннары яр буйлап китә. Һәркем теләгәнчә барсын, ашыгасы юк,— диде Җәгъфәр.

— Җәннәттә торасыз икән,— диде Дидаров, тирә-ягына каранып.— Бу карагайлар, ә! Мин Казан тирәсендә булгалаган кеше, ләкин монда гаҗәп икән, әй. Бигрәк тә заводтан соң сулышлар киңәеп китә. Бер дә диңгез һавасы кирәкми.— Дидаров әле кичке кояшның соңгы нурлары белән яктыртылган мәһабәт наратларга, әле агач арасыннан ялтырап күренгән Иделгә карап сокланып барды да: — Кеше дигәнең матур урыннарны таба белә икән,— диде.— Мин үзем Урал якларында туган, анда менә шундый искиткеч матур урыннар, мәһабәт карагайлар бар. Яшь чакта, билгеле, аның кадерен белмәгәнбез, аяк астында шу-

дый матурлык ятсын, имеш.— Дидаров башын селкеп әкрен генә көлеп җибәрде.

— Бәлки, фамилиягезнең тарихын да сөйләп җибәрерсез,— диде Җәгъфәр, елмаеп.— Бер вәгъдә иткән идегез бит.

— Була,— диде Исрафил.— Туган яклар бер искә төшкән икән, нигә сөйләмәскә. Белмим, әллә Диндаров, әллә тагын башка шуның шикелле бер кушамат булган инде бездә. Сөйлиләр иде, безнең бабайның бабасы бик гайрәтле кеше булган, имеш. Әлбәттә, Урал таулары арасында адашкан бер татар авылында революционерлар яшәмәгән, ул сүзне алар ишетмәгәннәр дә. Теленә ни килгән, шуны такылдаган. Әйтәләр иде, бабайның бабасы мулла булырга да бик кызыккан, дин турында да бик белдекле булып кыланган. Әйтәләр иде, бабай икешәр-өчәр көн тоташтан бәхәсләшкән. Яшьлегендә, мәдрәсәдә укып йөргәндә схоластикага оста булган. Аннан аны ни өчендер куганнар. Мин үзем хәерче булганга куганнардыр дип уйлыйм. Сөйләгәндә бик күп «ди-ди» кыстыра торган булган. Әллә шуның өчен инде аңа «дидар» дип кушамат такканнар. Соңыннан бабайлар, әткәйләр шул кушаматны фамилия иткәннәр булса кирәк. Татар арасында сирәк очрый торган фамилия, шуңа күрә мине күбесе әзербәйҗан яки башка берәр Кавказ халыкларыннан түгелме дип тә йөриләр. Хәлбуки, күрәсез, борын да, төс-баш та бөтенләй аларныкына охшамаган, чеп-чи татар.

Бу вакытта алар, Җәгъфәр белән култыклашып, шактый киткәннәр иде. Алар артыннан, бераз кала төшеп, хатыны белән алтын күзлекле, алардан соң хатыны белән көләч егет һәм иң арттан Дидаровның хатыны белән Гәүһәр бара иде. Дидаровның хатыны, ире кебек, шактый сөйләмчәк кеше икән. Башта ул ирен мактады, бик уңган, бик булдыклы кеше, ди, кирәк әйберне таш астыннан да таба. Аның белмәгән кешесе юк, һәр җирдә әшнәсе бар. Бу алтын күзлекле дә аның бик якын дусты икән. Исрафил әйтә, ул бик зур урында эшли, ди. Ә хатыны бер копировщица гына ди, карап торсаң, үзен әллә кемгә саный,— дип, Дидаровның хатыны аны яратмавын да яшермәде.

— Ә яшь егетләр кемнәр? — дип сорады Гәүһәр.

— Бер инженер диме шунда. Минемчә, аны машинасы өчен генә йөртәләр шикелле. Мин аны әллә ни белмим дә.

Кайчагында очраклы гына бер очкын кешене баштанаяк яктыртып җибәрә. Шуннан соң син аңа карыйсың да исең китә: улмы соң бу, кинәт алмаштырмадылармы? — дисең.

Йөзен кечкә кояш нуры яктырткан Исрафил хатыны нәрсәдәндер әкрен генә көлә башлады. Кеше үзе көлә, үзе... гаҗәп кызганыч! Күзләрендә ниндидер яшерен курку. Үзе һаман иренә карый, гүя ул хәзер аңа ниндидер коточкыч нәрсә әйтергә тиеш. «Фәнүзә апа, ни булды сиңа?» дип кычкырасы килде Гәүһәрнең. Ләкин кычкырырга кирәкми иде. Фәнүзә кояш күзеннән чыкты һәм, берни булмаган кебек, Гәүһәр белән янәшә бара башлады. Тик ара-тирә генә иренең тавышына колак салып башын кыйшайта иде ул.

Ирләр су янында ук туктадылар. Киң һәм тыныч елга өстенә кечкә кояшның кызгылт нурлары җәелгән. Кояш үзе түп-түгәрәк кызыл шар — бөтен көченә балкый. Берничә минуттан ул Идел аръягындагы таулар артына яшеренер. Хәзер бик җылы, хәтта көндезгедән дә җылырак кебек. Еракта пароходлар бөтен утлары белән балкып үтәләр. Музыка уйный. Кич белән, су өстендә, музыка гаҗәп тәэсирле, моңлы була бит, әллә нәрсәләр сөйли, әллә нәрсәләр искә төшерә кебек. Гәүһәр менә шул күренешне рәсемгә төшерсән иде дип уйлады. Су өстенең чак-чак кына тибрәнеп торуында, кояш яктысы белән саубуллашкан мәһабәт нарат урманында, кечкә тоныкь яктылыкта, озын-озын күләгәләрдә, пароходның үзенә бер төрле мәһабәт барышында музыка

бар шикелле. Менә шуны рәсемдә бирсәң иде дә, рәсемең, музыка кебек, кешене иркәләсен иде.

Кояш инде тау артына яртылаш баткан. Аның тирәсендә бер генә болыт та юк. Димәк, иртәгә дә көн яхшы булачак. Ул да булмады, кояш Идел аръягына төшеп яшеренде. Хәзер офык буе алсу кызыллык белән капланды. Бездә ерак көньяклардагы кебек кояш югалу белән җиһанны караңгылык сармый, алсулык шундый саф, Идел аръягындагы таулар шул саф алсулыкта шундый ачык күренәләр, аларга бик озак карап торасы килә һәм күңелдә гаҗәеп уйлар туа. Ә алсулык көчәя генә бара. Бу алсулык көзгедәй шома су өстенә дә, бу яктагы ап-ак комга да, өстәрәк сузылып киткән карасу-яшел урманга да йоккан кебек.

Шулай да бераздан кояш баешындагы алсу төсләр әз генә тоныклана башлады, аның каравы кичке зәңгәрлек көчәйде, көз булса да караңгылык тантана итәргә ашыкмады. Киресенчә, буп-буш су буенда йөрүе хәзер ничектер аеруча рәхәт иде, кайдадыр күзгә күренмәгән моторлы көймә тавышы шул хәтле ачык һәм йомшак булып ишетелә, син аңа игътибар да итәсең, итмисең дә кебек. Элек бар идеме, юк идеме — яр буйлап сузылган, минут саен карала барган урман өстендә ай да күренде. Ул әле тулып җитмәгән, шулай да яртысыннан узган инде. Хәзергә әле ул бик якты да түгел, офыктагы алсулык тәмам сүнгәч кенә ул күк гөмбәзендә бер ялгызы калып, көмеш нурларын яр буйларына, киң Идел өстенә, урманнарга сибеп, аларга кабатланмас бер төс бирер.

Төркемнәр бер-берсеннән ун-унбиш адымнарда туктаганнар иде, аннары бергәрәк тупландылар.

— Инде кайтсак та була торгандыр. Ничек, Гәүһәр? — диде Җәгъфәр.

— Кунаклар ни әйтер бит? Табигать матурлыгын күреп туйдылар микән?

— Кайтыйк,— диде алтын күзлекле. Ул шаяруны да, уен-көлкене дә белми иде, ахрысы. Һич югында, Гәүһәрнең шаян сүзләренә нинди булса комплимент кирәк иде.

Шул ук юл белән әкрен генә, сөйләшә-сөйләшә, кайттылар. Дидаров нәрсәдәндер кычкырып-кычкырып көлә иде. Арада бердәнбер җанлы кеше ул гына бугай. Гәүһәр элек аны нигәдер бик үк яратып бетерми иде, бүген аның белән турыдан-туры сөйләшмәсә дә, аңа башкачарак карады.

Ниһаять, кайтып җиттеләр. Гәүһәр алгарак узды, кунакларга ачык йөз белән:

— Рәхим итегез. Кулларны юарга әнә уң якта,— диде.

Ун-унбиш минуттан инде алар түгәрәк өстәл янына утырдылар.

— Я, рәхим итегез, һәркем теләгәнен алсын. Менә алма, виноград, җимешләр. Менә кыяры, помидоры, кәбестәсе. Менә салаты.

— Ә без хәзер күгәрчен суларын ачабыз. Менә мускат, кара күзләр, аурио, сухое да, юеше дә. Коньякның болгарские, ак — үзебезнеке. Кем нәрсәдән тели, рәхим итегез.

Башта виноларны күрсәтеп, мактап, хатын-кызларга салдылар, аннары Дидаров, коньякка үрелеп, аның шешәсен әйбәтләп карады да алтын күзлекле иргә мөрәҗәгать итеп:

— Безгә шуннан ярардыр инде, ә? — диде һәм күңелле генә көлеп җибәрде.— Җан газиз диләрме? Газиздән башлыйк.

Алтын күзлекле кешенең салкын йөзенә беренче тапкыр елмаю кунгандай булды. Шуннан барысы хуҗаларның исәнлегенә-саулыгына тост күтәрделәр. Хатын-кызлар рюмкаларына иреннәрен генә тидерделәр, Җәгъфәр, Дидаров һәм алтын күзлек ялтыратып эчтеләр, яшь ир

рюмкасына кагылмады. Аның машина йөртүен белгәнгә, хуҗалар да, кунаклар да артык кыстамадылар.

Аз таныш кешеләр арасында була торганча, башта кунаклар гүя хатыннарын гына беләләр, уйларында да гүя алар гына. Өч-дүртәр рюмка эчкәч, кунаклар җылына башладылар, аннары гүя мәҗлесне уятып җибәрделәр, барысы сөйләшергә тотынды, һәммәсенең чырае ачылды. Әмма барысыннан да бигрәк алтын күзлекле ачылып китте. Җитдилеге, салкынлыгы — бар да ясалма булган икән. Ул хатын-кызларга сипкән комплиментлары дисеңме, мәҗлеснең бөтен игътибарын үзенә тарткан анекдотлары дисеңме, сүзгә елгырлыгы дисеңме — җемелдәп, балкып кына тордылар. Тора-бара ул гомумән мәҗлеснең күркенә әверелде, ә Исрафил Дидаров аның янында бер сын гына булып калды. Хатын-кызлар да әкренләп алтын күзлеклегә игътибар иттеләр. Күрәсең, ул моңа күнеккән иде, берсенә дә үзенең хатыныннан артык игътибар итмичә, уен-көлкеләрен сибә торды. Бус-сыны, төсе-башы һәм үзенең ир уртасы булуы белән дә ул гүя мәҗлес түренә юри утыртылган бер зат иде. Ул хәтта художниклар, композиторлар турында да сөйләде. Башта Гәүһәр бу аннан-моннан укыганнарын гына, ишеткәннәрен генә чәчә дип уйлаган иде, алтын күзлекле безнең җирле художниклар белән композиторларга да тукталып, аларның иҗатлары турында яхшы ук тирән фикерләр әйтә башлагач, карашын үзгәртте. Гәүһәр хәтта стеналарны тутырган үз рәсемнәре өчен оялып утырды. Рәсемнәрне бездә аңлаучы бармы икән димә, бөтенләй син уйламаган җирдән алар чыга да куя икән ул. Гәүһәрнең шушы шикләнүләрен сизгән кебек, алтын күзлекле стеналардагы этюдларга күзен йөртеп, елмаеп:

— Һәр җирдә ни сөйләгәнеңне белеп сөйлә диләрме,— диде,— ә мин шунда лыгырдап утырам тагы. Мин күрәм, бу өйдә сәнгатьне бик нечкә белгән һәм яраткан бер кеше бар икән. Мин, әлбәттә, Гәүһәр ханымнан гафу үтенергә тиешмен.

— Ни сөйлисез,— диде Гәүһәр, кызарып,— мин бары тик һәвәскәр генә. Болар чын сәнгатьнең янында да тормаган.

— Тыйнаклык кешене бизи, диләр. Ләкин сез, Гәүһәр ханым, үзегезне үзегез яманламагыз. Бу рәсемнәрдә мин ниндидер орлык барлыгын күрәм. Дөрес, бу өлкәдә мин бик кечкенә кеше, минем фикерләр игътибарга да лаек булмас. Әгәр мин үземә яхшы таныш булмаган өлкәдә фикер йөртәм икән, моңа һәр кешегә хас бер йомшаклык итеп кенә карарга кирәк.

Гәүһәрнең бу сөйләшүне бик дәвам иттерәсе килсә дә, Дидаров рюмкаларга шәрап салды, аннары рюмканың берсен Гәүһәргә тоттырып:

— Яшь художникның киләчәк уңышлары өчен,— диде.

Барысы рюмкаларын күтәрделәр, алтын күзлекле, Гәүһәрнең рюмкасына рюмкасын чәкеп:

— Сезнең сәнгать баскычларыннан югары күтәрелүегезне чын күңелемнән телим,— диде.

Барысы шаулашып эчеп җибәрделәр, шуннан соң инде сүз яңадан сәнгатькә кайтмады. Башка темалар өстенлек алды, кайчагында хәтта кемнең нәрсә турында сөйләгәнен дә белеп булмый башлады. Гәүһәр, кунакларны сыйлый-сыйлый, яңадан сүзнең сәнгатькә кайтуын теләде, ләкин алтын күзлекле дә, башкалар да гүя монда сәнгатькә якын торган бер кеше барлыгын оныттылар. Соңыннан Гәүһәр үзе дә моның белән килеште, нинди ул сәнгать хезмәтчесе. Чын художник бәлки аның буяуларын карамас та.

Кунаклар сәгать уникенчеләрдә генә кайтып китте. Җәгъфәр белән Гәүһәр аларны урамда озатып калдылар. Кайдадыр еракта, борылышта, машина уты ялтырап сүнгәч, Гәүһәр белән Җәгъфәр өйләренә таба

ки теләр. Тышта — ай яктысы. Кукта бер болыт әсәре юк, әйләнә-тирә тып-тын, бер тавыш ишетелми. Тик елга буенда гына нәрсәдер күрсенә кебек. Әллә яр буена барып утырыргамы? Ай яктысында Идел бик күп уйлар уята бит. Гәүһәрнең су буена бик барасы килә, ләкин Җәгъфәр инде авызын ачып исни. Соңга таба рюмкасын яшергәләсә дә, шактый эчте ул. Ә кунаклар бөтенләй исермәделәр. Күрәсең, күнеккәннәр. Гәүһәр шулай икеләнеп торганда, Җәгъфәр кинәт туктап, хатынына:

— Йокларга күптән вакыт булса да, ашказаны бик авырайган. Әллә су буен бераз әйләнеп киләбезме? — диде.

Гәүһәр бер сүзсез риза булды. Агачлар арасындагы күләгәлектән бераз баргач, яр буена килеп чыктылар. Монда көмеш ай яктысы, су өстенә ай юлы сузылган. Менә шул юлдан сәнгать дөньясына кереп китсәң иде. Бу алтын күзлек Гәүһәрнең күңелен җилкендереп җибәрде. Җәгъфәр һәрвакыт хатынының рәсемнәренә көлемсерәп кенә карый. Алар шулай көлке генә микәнни? Бәлки сәнгатьне тирәнрәк белгән кешеләр анда чыннан да ниндидер орлыклар күрә торганнардыр. Ләкин уйларын Гәүһәр хәтта иренә ачарга да курыкты. Шул чакта корсагын сыпыра-сыпыра барган Җәгъфәр кинәт көлеп җибәрде.

— Син инде ай яктырткан Иделгә карап, сәнгать турында хыялланa торгансыңдыр. Бу алтын күзлекнең сүзләрен чынга ала күрмә. Ул һәр җирдә шуларны сөйли. Аның өчен аерым художниклар юк, аның өчен гомумән сәнгать кенә бар. Теге-бу художникның фамилиясен сүз арасына кыстыра икән — анысы күз буяр өчен генә. Ул шаблоннан оста файдалана.

— Җәгъфәр, кешене яманлама әле. Минемчә, ул сәнгать турында айнык фикер йөртә.

— Шулай әйтерсең дип уйлаган идем. Ул бухгалтер ич.

— Булса... Ул үзен художник дими ич.

— Ярый, шуның белән сәнгать турындагы бәхәсне бетерик, чөнки без аны белмибез. Белмәгән килеш бәхәсләшү, минемчә, оятсызлыкның аръягы.

Алар буп-буш яр буеннан тагын бераз бардылар да кире борылдылар. Гәүһәрнең күңелендә иренә тагын әйтәсе сүзе булса да, бу айлы төндә бәхәсләшүгә караганда, уйлану яхшырак иде. Алар тын гына кайттылар. Тик Җәгъфәр генә, ара-тирә ике кулы белән корсагын сыпыргалап, каты итеп көрсенгәләде.

Икенче көнне иртүк һава бозыла башлады, салкынаеп киткән җил корыган яфракларны, саргайган ылысларны очырткалады, аннары җил тәмам басылды, яңгыр сибәләргә тотынды.

— Менә әбиләр чуагы да бетте,— диде Җәгъфәр уйчан гына.— Бик кыска гомерле, алдаучан да.

— Син нәрсә сөйләнәсең? — диде Гәүһәр.

— Болай гына... Табигатькә карап уйлануым,— диде Җәгъфәр, бераз аптырашка калгандай булып. Аннары кинәт җанланып китте: — Ә кунакларның бәхете бар икән. Кичә нинди матур иде. Әллә аерылышканда юри шулай буламы икән?

Гәүһәр, иренең сәерлеген сизсә дә, төпченмәде. Ә мәктәптә аңа Юлдашның машинага тапталып һәлак булганын әйттеләр. Бу шулкадәр көтелмәгән авыр хәбәр иде, Гәүһәрнең күз аллары караңгыланып китте. Көч-хәл белән генә дәресен тәмамлады, аннары туры Юлдашларга юнәлде. Гәүһәр Юлдашның әти-әниләрен белсә дә, әйтергә сүз, юатырга әмәл тапмады. Бергәләп еладылар, ничек булганын сөйләделәр. Шимбә көн мәктәптән кайткач булган икән. Гәүһәргә шунда ук әйттергән булганнар да...

Кич белән Җәгъфәр, хатынын күргәч, барысын да аңлады.

— Гафу ит, Гәүһәр,— диде ул,— мин моны шимбә көн үк белсәм дә, сиңа әйтергә базмадым. Кич белән су буенда әйтермен дигән идем,

тагын телем әйләнмәде. Иртән тәрәзә янында уйланганда да... Синең никадәр йомшак күңелле булуыңны белгәнгә әйтмәдем. Гафу ит. Аннары, Гәүһәр, мин барысын да белештем, өенә кайткач, бер-ике сәгатьтән соң булган хәл...

— Кирәкми, Җәгъфәр, сөйләмә,— диде Гәүһәр таркау гына. Кинәт ике кулы белән йөзен каплап, үксеп елый башлады.



## 4

Моннан ике ел элек Җәгъфәр уңышлы рәвештә кандидатлык диссертациясен яклады һәм шәһәрдәге югары уку йортларының берсендә иҗтимагый фәннәр укыта башлады. Тагын берничә урында консультантлык эшләре дә бар иде аның. Семьяның материаль хәле күзгә күренеп яхшырды, машина, аннары дача алганда бераз өзелеп торганнар иде, инде ул яклар да рәтләнде. Дөрес, нәфсеңә юл куйсаң, акчаның кирәк урыны бик күп, аны күбрәк алган саен ул азрак булып күренә, шулай да юрганыңа карап аяк сузарга кирәк. Гәүһәрнең элек бик ярап торган эш хакы хәзер ул хәтле кирәк түгел, хәзер Гәүһәр әзрәк ял итсә дә була. Өйдә үз кулың булу — ай-һай зур эш бит ул. Җәгъфәр Башкортстанда торучы әнисен китертергә дә бер уйлаган иде, ләкин әни янында үги әтисе һәм туганнары бар. Аларны барсын чакыртып булмый лабаса. Авылда аларның, яхшымы-яманмы, үз хуҗалыклары, ә Казанда алар бер Җәгъфәрнең эш хакына карап торырлармы? Бигрәк тә Җәгъфәр үги әтисен, ереле-ваклы эне-сеңелләрен яратмый иде. Ул ун классны бетергәч үк авылдан китте, шуннан соң бер тапкыр да иленә кайтмады. Тормышы бик кыен чакларда да үги әтисеннән ярдәм сорамады, әнисе исә ярдәм итәрлек хәлдә түгел иде. Соңгарак аларның тормышлары беркадәр аруланган — ара-тирә килгән хатларыннан шул күренә иде. «Бик яхшы, куанычы белән торыгыз»,— дип уйлады Җәгъфәр һәм әнисенә исән-саулыгын белдереп кенә хат язды, алардан сорамады да, аларга әллә ни ярдәм дә итмәде. Өйләнешкәч, Гәүһәр, әнине чакыртыр идең, күрәсем килә, дип әйткәләп караса да, Җәгъфәр өзеп җавап бирмәде, әле авылда эш вакыты дигән булды, әле юллар начар чак, бездән тимер юл ким дигәндә йөз километр бардыр, диде. Ахырга таба Гәүһәр иренең тел төбен сизде, ахрысы, бу соравын бирми башлады, Җәгъфәр үзе дә бу турыда сүз кузгатмады. Тик бер генә тапкыр:

— Әллә әнине чакыртыргамы икән, сиңа бик кыенга килә бит, мәктәпкә дә чап, өй эшләрен дә кара,— диде.

Гәүһәр бу тәкъдимгә кискен рәвештә каршы килде.

— Әнине кунакка чакыртсаң чакырт, бик яхшы каршы алырмын, әмма өй эшләрен аңардан эшләтмәм,— диде.

Шуннан соң күпмедер вакыт үткәч, Җәгъфәр хатынына икенче бер тәкъдим ясый башлады, янәсе, болай бик кыен бит сиңа, әллә вакытлыча эштән китеп торасыңмы? Ял да итәр идең, этюдларыңны да караштырыр идең, өй эшләрен дә...

Гәүһәр бу турыда да ишетергә теләмәде, аннары аяк астыннан чыккан бәла кебек, әлеге мәктәптәге вакыйга. Билгеле, Гәүһәрнең тырнак очы кадәр дә гаебе юк, ләкин шундый чакта китсәң, гайбәтчеләр ни сөйләмәс, аларга азык кына бир. Әлбәттә, яшәр һәм зур эшләр эшләр өчен туган баланың шундый мәгънәсез үлеме ата-анага гына түгел, укытучыга да бик авыр, әмма нишләмәк кирәк, сирәк булса да очрый торган хәл, башны ташка бәрмәссең. Хәзер бер генә табиб бар — ул вакыт. Никадәр авыр булса да, вакыт үз эшен эшләр, бу караңгы көннәр онытылыр, артка чигәр. Җәгъфәр моны бик яхшы аңлый, шуңа күрә Гәүһәрнең авыр көннәрен җиңеләйтергә тырышты, бик игътибарлы булды, бернинди очракта да авыр сүз әйтмәде,

Гәүһәргә эше һәм читтән торып укуы өчен кирәкле китапларны табып китерде, бала үлемен тикшерүче белән элемтәгә керде. Бала мәктәптән тыш вакытта, кичен, машинага тапталып үлгән. Монда хәтта шофер да гаепле түгел, малай прицепка асылынган, шофер күрә дә алмаган. Сүз юк, авыр хәл, ләкин укытучының тагын утыз биш баласы бар, алар турында да уйларга кирәк. Әнә университетта бер студентны өмәдә электр сугып үтерә, икенчесен больницага озаталар. Нишлисең, фаҗига, әмма аңа карап укуларны туктатып булмый бит. Тормыш шулай инде ул.

Гәүһәр, иренең барлык акыллы дәлилләренә колак салмыйча, боегып, үз эченә бикләнеп йөрде. «Әйе, хатын-кыз үз йомшаклыгының колы булмаса, аны хатын-кыз да димәсләр иде», дип уйлады ахырда Җәгъфәр, ә тыштан бер нәрсә сиздермичә, хатынын дачага чакырды, ял көне бит, машинага утыруың була, барып та җитәсең, аннары туйганчы урманда йөрерләр. Гәүһәрнең көзге бизәкле урманны, үзенә бер төрле тынып калган су буйларын үлеп яратуын белгәнгә, Җәгъфәр бу тәкъдимгә риза булуына аз гына да шикләнмәде, шуңа күрә хатынының каршы килүе аны шактый кәефсезләндерде, әмма барыбер, ир кеше буларак, күтәрелеп бәрелмәде. «Ихтыярың, мин сиңа яхшылык кына теләгән идем. Табигатьнең тынычландыра торган сихәте бар бит. Сәнгать кешеләре моны аеруча нык тоя, диде. Гәүһәр иренә рәхмәт белән карады. Шундый авыр минутларда иренең тигез холыклы булуы, тиле нервларга һич тә юл куймавы, кызмавы, чәпчемәве аңа көч бирде. Ире үз дигәнен генә үткәрергә тырышса, әллә нәрсәләр килеп чыгар иде бит. Гәүһәр үзе турында уйламады, кайбер мәсьәләләрдә ул ээлекле булып бетә алмый иде шул.

Гәүһәр, эшләнеп бетмәгән рәсемгә борылып, аңа карап тора башлады (бу рәсемнәрне дачадан алып кайткач иде). Нәрсә уйлый иде икән ул? Бәлки хәзер, малай дөньяда булмагач, бу рәсемне тизрәк тәмамлау теләге көчәйгәндер аңарда? Бу — малайга үзенә күрә бер һәйкәл салу булыр иде. Баланың ата-анасы да, мәктәп коллективы да моның өчен Гәүһәргә рәхмәт кенә әйтерләр иде бит. «Әллә шул турыда сүз кузгатыйммы икән? — дип уйлады Җәгъфәр, аннары бу уеннан кайтты.— Юк, ярамый, әгәр андый уе бар икән, үзе әйтсен, ә Җәгъфәр аны хуплар гына, югыйсә үз уеңны башкалар әйтсә, әллә ничегрәк чыга, күнелең кайтуы да мөмкин».

Ял көне, кичкә якларда, бер дә көтмәгәндә Исрафил Дидаров шалтыратты. Җәгъфәр, моңа шатланып, аны үзләренә чакырды, бераз сөйләшеп утырырбыз, диде.

— Барыйммы икән, Гәүһәр ханымның кәефе бик начар түгелме? — диде Исрафил.

— Менә шуңа күрә чакырам да. Кеше килгәч, әзрәк язылмасмы дим, Исрафил абый.

Гәүһәр гомумән кунак яратса да, бу юлы артык сөенмәде. Хәер, моның сәбәбен аңлавы читен дә түгел иде, үз уйларын караңгы булгач, кунак шатлыгы гына күзгә күренми шул. Җәгъфәр хатынын җылы сүзләр белән юата башлагач, ул, урыныннан торып, кухняга ук чыгып китте, мыштым гына табын әзерләргә керешә.

Утыз-кырык минуттан Дидаров та килде. Эшләпәсен баскычта ук салган, пальтосының төймәләрен дә ычкындырган, күрәсең, югары менгәндә тыны кысыла. Аннары агара башлаган чәче дә, тәртеп торган корсагы да бүген нигәдер күзгә күбрәк ташлана. Буе озынрак булса, бу корсак кына артык зыян итмәс иде, буе бераз комачаулаган. Карар күзгә Исрафил бик ыспай ир, аңарда үзенә күрә нәзакәтлек тә, житезлек тә бар. Кием-салымы, төсе-башы шулай ук чибәр, һәрхәлдә, киенә белми, хатыны карамый дип әйтмәссең, — ә хатын-кыз моңа ае-

руча игътибарлы бит. Шулай ук сөйләшүе дә, үз-үзен тотышы да тел тидерерлек түгел.

Гәүһәр икенче нәрсәне дә сизеп алган иде: ире Җәгъфәр Исрафилга эчтән соклана, аныңча шат күңелле булырга, теләсә нинди темага сүз чыкканда да аптырап калмаска тырыша. Исрафилча тиешенчә шаярта да, көлә дә һәм көлдерә дә. Кыскасы, Гәүһәрирендә аз-азлап кына Дидаров сыйфатлары күрә, икесе янәшә утырганда бу бигрәк ачык сизелә. Тик Җәгъфәр моны тышка чыгарырга теләми, янәсе, аның үз акылы бар, ул үз акылы белән яши.

Әйе, Дидаровны Җәгъфәр яхшы белә, шуңа күрә аңа карата мөнәсәбәтеңне ачыклау да әллә ни кыен эш түгел. Менә алтын күзлек шактый уйландыра. Танышкан көннәрдә Җәгъфәр монысы да шундый ук нәрсә, тик йоны гына үзгәрәк, дип йөргән иде. Ялгышты, күрәсең. Алтын күзлек бер килеп Җәгъфәрнең тәмле ашын ашады, шәрабын эчте, әҗерен тартынмыйча алды да шуның белән вәссәлам! «Син мине белмә, мин сине белмим». Күрәсең, аның төп ысулы шул. Димәк, хатынга сөйләгән сүзләр имеш-мимешләр генә булып чыкты. Уйласаң, монысы әйбәтрәк тә. Хатын-кызга барысын белергә димәгән. Һәм Җәгъфәр, хатынын борчымас өчен, алтын күзлеккә тыштан бераз мыскыллы көлеп карый бирде. Тик бик игътибарлы күзәтүче генә Җәгъфәрнең бу алтын күзлекле кешегә дә яшертен рәвештә охшарга тырышуын, сөйләшүендә, үз-үзен тотышында аңардан кайбер нәрсәләрне отып алуын күрер иде. Тагын да тирәнрәк күзәтүче булса, Җәгъфәрнең гомумән үзенә йогынты ясардай кешеләргә еш иярүен абайлар иде.

Дидаровны ачык чырай белән каршы алдылар, әкренләп өй эче шат тавышлар белән тулды. Нечкә биленә кечкенә ак алъяпкыч бәйләгән Гәүһәр, Дидаров карашынча, әйтеп бетергесез матур иде. Соңгы вакытта ул бераз суырыла төшкән, ябыккан, әмма карар күзгә бик сөйкемлеләнгән. Бер үк вакытта Дидаров хәзер Гәүһәрне ошатканлыгын сиздерергә теләмәде. Теге вакытта, дачада, Гәүһәргә ул асла игътибар итмәгән иде бит. Бу юлы да бер юләрләнеп китүе генәдер. Яшь, матур хатын-кыз яше үтеп баручы ирнең күңелен бер җилкендерми булмый торгандыр.

Җәгъфәр дә үз чиратында таңга калды. «Хатын-кыз уйнаса уйный икән», дип уйлады ул. Хатынына сөеп карады, Гәүһәрнең сүзләре аңа бер музыка сыман ишетелде.

— Нигә ялгыз килдегез, Исрафил абый, нигә Фәнүзә ханым юк?

— Һава суларга чыкканда да хатынны бимазалап булмый бит инде, Гәүһәр ханым. Бигрәк тә сезнең кәефсез чагыгыз булуын ишеткән идек. Сезнең мәктәптә минем балдызым укыта, бәлки белә торгансыздыр: Фаягөл Идрисҗанова. Үзе исемен Фая, Фаечка дип йөреткән була. Чит телләр укыткач, шулай килешә, янәсе.

Гәүһәр берни әйтмәде, чәй янында бераз утыргач, хәтта кухняга ук чыгып китте.

— Әллә инде Гәүһәр ханымның кәефен кырдым,— диде Дидаров, шактый уңайсызланып.

Хатын-кыз кинәттән генә үзгәрмәсә, аны хатын-кыз да димәсләр иде. Гәүһәр кереп чәй янына утыргач, Дидаровның шиге бөтенләй бетте. Ләкин, күрәсең, бу эштә ул шактый тәҗрибәле иде, Гәүһәрнең өзелгән сүзне ялгыйсы килмәгәнен шунда ук төшенде, үзе дә яңадан бу темага якын да килмәде, тик эченнән генә «балдыз белән борчаклары пешми икән» дип уйлады.

Киеренке һәм сак утырган Гәүһәр, Исрафилның берни булмаган шикелле юк-бар нәрсә такылдавын күргәч, бу хатын-кызга игътибарлы икән, дип үзенчә нәтиҗә ясады. Шуннан соң ул иркенрәк утырды, шулай да кәефе яхшырмады. Ахырда, гафу үтенеп, икенче бүлмәгә ук

чыгып китте. Исрафил шундый чакта килүе өчен дә, гомумән юкныбарны такылдавы өчен дә чын күңелдән гафу үтенеп калды.

— Хатынның кәефе булмаса, өйнең яме китә,— дип күрсенде ул ахырда, шуңа ялгап бөтенләй икенче тавыш белән сүз башлады: — Җәгъфәр дус, мин бит әле сине райсоветка депутат булып сайлануың белән яхшылап тәбрикләгәнем дә юк. Чын күңелемнән шатмын...— Аннары ул сәгатенә карап алды.— Миңа кайтырга да вакыт. Гәүһәр ханым ятты, ахрысы. Ярый, уятмыйк. Да, әйтергә дә онытам, син инде җомга көн безнең заводка килдсең. Начальствоң белән сөйләшкәнсеңдер? Каршы килмиләрме? Ну, бик яхшы булган. Бездә инженер-техниклар гына, икенче төрле әйтсәк, производство командирлары гына җыела. Әлбәттә, әзерләнергә кирәк... Хәер, монысын үзең дә бик яхшы беләсең. Хуш иттек. Гәүһәр ханымга күп итеп сәлам!

Җәгъфәр, ниһаять, Исрафил Дидаровны озатты да ашыгып хатыны янына керде. Гәүһәр йокламый, уйланып утыра иде.

— Башың авыртамы әллә, Гәүһәр? Төсләрең тәмам киткән.

Гәүһәр, иренең сүзләрен ишетмәгәндәй:

— Исрафил абый ник килгән? — дип сорады.

— Болай гына, хәл белә генә кергән.

Гәүһәр иреннәрен уйчан гына кыйшайтты.

— Исрафил абый алай итәрме икән?.. Ул синең эшләгән җиреңә дә баргалыймы?

— Бик сирәк. Үзең беләсең — мин аңа нинди дус. Әле миңа заводка чакырды, инженер-техникларга аена бер тапкыр политэкономиядән лекция укырга, ди.

Гәүһәр озак эндәшмәде, аннары бөтенләй икенче тавыш белән:

— Исрафил абый мине нигәдер борчый башлады...— диде.— Теге вакытта, Идел буенда, ул миңа бүтән кеше булып күренгән иде.— Шуннан ул алтын күзлекле турында сорады.

— Күргәнем юк,— диде Җәгъфәр, теләр-теләмәс кенә.— Машина алганда әзрәк файдасы тигән иде. Анда, беләсең, күпме чират...

— Син бит чиратым җитте дигән идең?

— Әлбәттә, җитте... Җитә язды. Ә сиңа нәрсәгә кирәк ул алтын күзлекле? Сәгать турында сөйләшергәме?

Гәүһәр иңбашларын җыерды.

Җәгъфәр кул сәгатенә карап алды.

— Ярар, Гәүһәр, син юк нәрсәләр турында уйлама әле. Ахыр килеп, Дидаровы да, алтын күзлеклесе дә алай баш ватарлык кешеләр түгел. Безгә үз башыбыз кадерле. Әйдә, ят, ял ит. Өстәлне үзем җыярмын.

Гәүһәр авырлык белән генә урыныннан торды, залга үтте, өстәлен сүзсез генә җыештыра башлады. Җәгъфәр аңа тегесен-монысын булышты. Өстәлдәге савыт-сабалар алынып беткәч, урындыкларны урынына куйды, аннары өстәле янына барып портфелен ачты, битләре арасына кәгазьләр кыстырган китапларын алды.

— Син ял ит, Гәүһәр, чын. Мин әзрәк утырыйм әле. Дәресләргә әзерләнәсем бар.

Гәүһәр, берни әйтмичә, икенче бүлмәгә чыгып китте. Ләкин ике сәгатьтән соң, инде сәгать беренчеләрдә, Җәгъфәр йокы бүлмәсенә кергәндә хатыны һаман йокламый иде. Җәгъфәр борчылып:

— Нигә син йокламыйсың? Юкка үз-үзеңне бетереп,— диде.

— Исрафил абыйның сиңа, депутат буларак, йомышы бар, ахрысы,— диде Гәүһәр.

Җәгъфәр кычкырып көлеп җибәрде.

— Йомышы булган кеше, Гәүһәр, болай сөйләми. Әйдә, ятыйк, сәгать бер тула инде. Я иртәгә йоклап калырбыз.— Җәгъфәр чишенә башлады.— Ярый, хәерле төн.

— Хәерле төн,— диде Гәүһәр, аннары, яртылаш чишенгән көе, тәрәзә пәрдәсен күтәреп карады. Ай яктысы, шылт иткән тавыш юк. Күзгә бирешергә теләмәгән, ышыкка кереп поскан куаклар да тирән уйга чумганнар кебек. Тик бик еракта якынлашып килгән тәнге буксирның тигез тавышы ишетелә.

Нигәдер йоклыйсы килми, ә Җәгъфәр инде әкрен генә мышный. Гәүһәр өстенә җылы халатын каплады да балконга чыгып утырды, якты айга карады.

Иксез-чиксез күктә ай йөзә дә йөзә. Вакыт-вакыт җиңелчә сыек болытлар аны каплап алалар. Ай инде болыт аша гына ялтырап күренә, кайчак бөтенләй дә күренми башлый. Анда, биектә, мәңгелек хәрәкәт, ә монда бөтен тереклек тукталган кебек, шуңа күрә Гәүһәргә дә бик авыр. Юк, кешегә торгынлык ярамый икән, ул аны бетерә, изә.

«Фая — Исрафилнең балдызы!» — диде Гәүһәр кинәт ниндидер ачыш ясаган кебек.

## 5

Гәүһәр сабыр холыклы, ул бервакытта да балаларга кычкырмый, ачуланмый дип сөйлиләр иде. Башлангыч класс укытучысы өчен бик тә кирәк бу сыйфат. Балалар бит минут саен үзгәрә. Әле генә бар да тыныч, башларын кыңгыр салып, тел очларын чыгарып инша язалар иде; тәнәфескә чыкканда да бар да тыныч иде. Гәүһәр, укытучылар бүлмәсенә кереп, биш минут утырырга да өлгермәде, аңа классында балалар сугыша дип әйттеләр. Юлдаш машинага тапталганнан соң аның нервылары артык какшаган иде. Ул укытучылар бүлмәсе белән класс арасын ничек үткәнен дә хәтерләмәде. Ишекне ачып класска керсә, бер мәлгә шаккатып калды, бар да сугышалар, китаплар, дәфтәрләр, портфельләр оча, идәнгә кара түгелгән.

— Нишләвегез бу! — дип кычкырып җибәрде Гәүһәр. Мондый чакта укытучының тавышы ишетеләмени! Малайлар бер-берсенең өстенә сикереп, җиңгәннәре тантана белән, җиңелгәннәре еламсырап кычкыралар иде. Гәүһәр, үз-үзен белешмичә, сугышучылар өстенә ташланды, кайсын әтте, кайсын колакларыннан, чәчләреннән тартты. Ниһаять, малайлар сугышуларыннан туктадылар, урыннарына утырдылар. Йөзе кызарган, үзе гомердә булмаганча гасабиләнгән Гәүһәр, авыр сулый-сулый, өстәл янына килде.

— Кем башлады? Нидән сугыш чыкты? — дип сорады ул.— Я, нигә дәшмисез? Кемнең кара савыты бу? — дип, ул идәндә челпәрәмә килеп яткан кара савытына күрсәтте.— Иясе юкмы, нигә дәшмисез? Тагын бер тапкыр сорыйм: кемнеке?

— Минеке,— диде бер кыз әкрен генә.

— Торып җавап бирергә кирәк. Я?

Кызчык аякка басты һәм әкрен генә:

— Минеке,— диде.

— Хәзер идәнне сөртегез, ватык кара савытын чыгарып ташлагыз. Калганнарга парталарны, дәфтәрләрне, китапларны һәм өс-башларыгызны тәртипкә китерергә.

Бер биш минуттан класс тәртипкә килде, идәндәге кара таплары сөртелде. Гәүһәр күзләре белән классны сөзеп чыкты; карага буялган куллары белән күз яшьләрен сөртеп утырган кызчыкка карап:

— Менә күрдегезме шаярунның нәрсәгә китергәнен? — диде.— Карагыз Зөбәрҗәтнең битләрен. Пәри булган ич!

Арадан кемнәрдер көлеп җибәрделәр, ләкин укытучының сүрән карашын күргәч, шунда ук көлүдән туктадылар. Класстагы бөтен шаяруның бердәнбер гаеплесе шул Зөбәрҗәт булып чыга иде. Хәлбуки, ул бер дә шаярмады, партадан аның кара савытын кем алуын да

бѳлми калды. Нервылары дулаган Гәүһәр исә шаярунын сәбәпләрен иртәгә тикшерәчәген, гаепләләргә каты җәза бирәчәген әйтте дә дәресен башлады. Әмма бүген дәрес дәрес булмады. Бу хәл Гәүһәрне тагын да җенләндерде, ул тизрәк звонок булуын көтте. Соңыннан укытучылар бүлмәсенә кереп туйганчы елады, класста ни булганын мәктәп директорына да сөйләде.

— Ни булганын иртәгә мин үзем тикшерермен,— диде мәктәп директоры.

Гәүһәр яшьле күзләрен күтәреп директорга карады.

— Зинһар, Шәриф Гыйльманович, бу эшкә катнашмагыз. Без үзебез хәл итик. Монда барыннан да бигрәк минем гаебем зур булды шикелле... Балалар белән башта мин үзем сөйләшим. Аннары сезгә килеп әйтермен.

— Яхшы, Гәүһәр.

Кемдер ишекне кискен ачып керде, директор белән башын иеп сүзсез генә исәнләште. Гәүһәрнең борчылып, сыгылып утыруын күргәч, үз алдына көлемсерәп, соңыннан керермен дип, янадан чыгып китте. Бу — укытучы Фая, ягъни Фаягөл Идрисҗанова иде.

Мәгълүм булганча, урта мәктәптә укытучылар байтак, арада немец теле укытучысы Фая башкалардан бик аз аерыла иде. Ул Гәүһәрдән бер-ике яшькә кечерәк булыр. Карап торырга аңарда ниндидер салкын матурлык бар. Куе сары чәчен түбәсенә урап куйган, күзләре зәңгәр, керфекләре озын, буе зифа. Кайберәүләр аны кияүгә чыккан булган, соңыннан аерылганнар, дип тә сөйлиләр. Бик ихтимал, һәркемгә дә семья бәхете тигез бирелми бит. Гәүһәр ни өчен икәнен анык кына әйтә алмаса да, бу укытучыны яратып бетерми иде. «Ике матур бер-берсен күрә алмыйлар инде», диләр кайберәүләр. Анысы да бик мөмкин. Фаяның чыраеннан астыртынлыгы сизелеп тора, күпләр белән ул аралашмый, үзе әче телле. Башын чөеп йөри, кешеләрне гүя бар дип тә санамый.

Гәүһәр ишек ачучының Фая икәнен эчке сиземләү белән генә таныды һәм бу кичне өенә бик күңелсез кайтты. Стенадагы рәсем өстеннән каядыр почмакка карап торды. Җәгъфәрне ашаткач-эчерткәч, кухняга чыкты да терсәгенә таянып утырды. Янадан күз алдына класс, идәнгә җәелгән кара табы килде. Көрсенеп куйды.

— Гәүһәр, син нигәдер күңелсез. Әллә классыңда тагын бер-бер хәл булдымы? — Җәгъфәр, тешен казый-казый, кухняга чыккан иде. Ул терсәгенә таянган хатыныннан күзен алмады.

— Әйе, Җәгъфәр. Бик күңелсез хәл. Җитмәсә, үзем... Беләсеңме, әллә ничек килеп чыкты. Күрәсең, мин...

— Тынычлан, бар да үтәр. Үтмәсә дә исең китмәсен, гомер буе мәктәпкә бәйләнеп тормассың...

Гәүһәр, куркып, иренә тирән шелтә белән карады.

— Син әле ни булганын белмисең бит, Җәгъфәр.

— Минемчә, белергә кирәкми дә. Мәктәптә нәрсәдер булган икән, төкер.

— Җәгъфәр, тукта, син ни сөйлисең, бу мөмкинме соң?

— Минемчә, бик мөмкин. Әлбәттә, мин әйткәннәрне башта ук тынласаң... Хәер, әле соң түгел, мин сөйләшә алам.

— Җәгъфәр, мин сине аңламыйм, әллә син тузга язмаганнарны сөйлисең, әллә мин үзем...— диде Гәүһәр, кинәт үксеп.— Өйдә караңгы почмакка утырып бикләнеп тыныч тору... Синең тел төбең шул бит, Җәгъфәр. Юк, син минем белән болай сөйләшмә. Мин моны теләмим, ишетәсеңме, теләмим. Башта үз гаебемнең мәгънәсен аңларга тиешмен, аннары аны төзәтергә... Гаептән качарга... бу түбәнлек.

— Син уйламыйча куертасың, Гәүһәр,— диде Җәгъфәр, йомшак кына.— Менә уйлап кара. Без акчага мохтаҗмы? Дөнья безне бугаз-

дан алганмы? Кирәк чакта эшләдең, кем сүз әйтте? Җитмәсә тагын, укыйсың. Заочный булса да уку — уку инде. Авырсаң, нишләрсең?

— Укытучылыктан минем күңелем кайтканы юк, шулай ук укудан да. Вакытлы кыенлыклар бәгырьгә төшсәләр дә...

— Бу сүзләрне җыелышта сөйләсәң, ихтимал, кем булса да колак салыр яки кул чабар иде, ә өйдә... әзер лозунглар белән... кирәкми, Гәүһәр. Хәзер син минем тәкъдимне кабул итә алмыйсың икән, мин әйттем исә кайттым дигәндәй. Ләкин иртәме, соңмы мин әйткән нәтиҗәгә килерсең. Ә хәзер, булдыра алсаң, тынычлан. Бу сиңа да, миңа да бик кирәк.

Җәгъфәр кухнядан чыгып китте. Мондый кечтеки бәрелешләр семьяда элек тә булгаласа да, алар бервакытта да Гәүһәрне куркытмады. Җәгъфәр — асылда киң күңелле кеше, аның әйткәннәреннән төбендә яхшы теләк ята. Бүген бераз арттырыбрак җибәрде бугай, ләкин ул чаклысы гына Гәүһәрнең үзендә дә була бит.

Гәүһәр дәресләрен карый башлады. Әкрен-әкрен онытылды, күрәсең, иртәгә ничегрәк эшләргә дигән фикергә килде. Икенче бүлмәдә Җәгъфәр утыра. Аның да эше бик күп шул, еш кына Гәүһәр аңа комачаулый да. Ә төптәнрәк уйласаң, тормышны алып баручы Җәгъфәр. Квартирадагы яхшы мебельләр, дача, машина, затлы кием-салым... Гәүһәрнең эш хакына боларны гомердә дә күрәчәк түгелсең. Аның аяк терәве дә шул семья иминлегенә бәйләнгән түгелме? Ул бит тормышны алып бару турында уйламый да, анысы аның ирләр кулында. Хәлбуки, уйласаң, уйларлыгы бар икән.

Сәгать инде унике тула. Гәүһәр урыныннан торды, ире янына чыкты, Җәгъфәр, өстәл лампасы яндырып, китаплар карый, шунда ук язулар, әллә нихәтле диаграммалар, таблицалар.

Гәүһәр иренең башыннан сыйпады. Җәгъфәр аның кулын тотып үпте.

— Арыдыңмы?

— Бераз бар бугай. Иртәгә яңа лекцияләр циклы башлыйм, шуңа әзрәк әзерләнә идем. Тормыш һаман үзгәрә, яңасын карамасаң, артка калганлыгыңны сизмәссең дә.

Гәүһәр ире янына утырды, башын аның кулына салды.

— Комачауламыйммы?

— Юк, мин инде тәмамлаган идем... Тынычландыңмы бераз?

— Тынычландым бугай.

— Ярый, шәп булган. Тынычлык — барыннан да кыйммәт. Тыныч булсаң, тау хәтле эш эшлисең. Армыйсың да... И, кара, синең бер ак чәчең бар?

— Кая?

— Менә, өзимме?

— Өз!

Җәгъфәр өзде дә Гәүһәрнең учына салды. Гәүһәр ак чәчкә озак карап торды. Ләкин артык берни әйтмәде, озакламыйча урын түшәделәр дә йокларга яттылар. Җәгъфәр шунда ук гырлый башлады, ә Гәүһәрнең күзенә әле бик озак йокы кермәде. Ул үзенең бөтен педагоглык гомерен уйлады. Бу гомер бик кыска, нибары биш-алты ел, анысы да ничектер шома үтте, ул бер дә ачы тәҗрибә алырга өлгермәде. Була бит шулай, класс көннәр, айлар, еллар буе тын утыра. Син аларга күнектем дип уйлыйсың, алар синең холкыңа ияләшкән кебек. Бер нәрсә дә ул холыкның син белмәгән якларын өскә чыгармый. Кинәт барысы да үзгәреп китә, син аптырап каласың... Гәүһәр нәкъ менә шундый хәлдә иде.

Иртә белән Гәүһәр гади, ләкин бик пөхтә итеп киенде. Иптәшләренең әйткәннәре бар: бу киемдә ул нур тутырган пыяла савыт кебек, эчтән яктыра, аңа карамас җирдән карыйсы килә. Шапшак киенеп,

укучылары алдына чыккан укытучыны ул шәхси дошманы кебек яратмады. Әле укытуының беренче елларында аңа параллель класстан бер шаян укучыны күчерделәр. Бу малай дәфтәр тышына үзенең укытучысын гел шайтан итеп ясый икән. Үзе дә пычрак, чәче җиткән, иртә белән, күрәсең, рәтләп юынмый да. Гәүһәр аңа мәктәп баласы болай йөрергә тиеш түгел, бүген кайткач ук мунчага барырга, чәчен төзәттерергә, чиста күлмәк киярга, галстугын үтүкләргә кушты.

— Иң элек Раушания апа үзе мунчага барсын, муенын юсын, чәчен тарасын, төймәсен таксын. Аннары мин...— диде малай, Гәүһәрне шаккатырып. Раушания — малайның элекке укытучысы,— үзенең шапшаклыгы белән телгә кергән иде. Җитмәсә, адым саен кычкыра, ачулана, акыл өйрәтә.

Гәүһәр бу күңелсез вакыйганы йомып калдырырга тырышты, әмма үзенең киемнәренә аеруча игътибар итте. Малай да бер-ике көннән соң чәчен төзәттереп килде, ә бернichә айдан аны танып та булмый башлады. Соңыннан ул өлкән классларга күчте, аны шапшаклыгы ягыннан бер вакытта да телгә алмадылар, ләкин Гәүһәр аның сүзләрен онытмады. Класска бер вакытта да өстен-башын рәтләп карамыйча кермәде. Бер күз берни дә сизмәве мөмкин, әмма уннарча яшь күзләр барысын да күрәләр!

Бөтен класс Гәүһәрне аякка басып каршы алды. Ул исәнләште, утырырга кушты һәм көндәгечә дәресен башлап җибәрде. Ул балаларның беркадәр гаҗәпләнүен күрде. Алар Гәүһәр сүзне кичәге күңелсез вакыйгадан башлар дип көткәннәр иде. Ә ул, гүя бернәрсә дә булмаган кебек, дәресен сөйли дә сөйли. Тик күзләре генә әзрәк тынычсыз, нәрсәдер сынаган кебек, укучыларга озаграк тукталалар. Тагын йөрүе бераз башкачарак. Элек ул үз тавышына колак салгандай, шул тавыш көенә генә бер урыннан икенче урынга күчә торган иде, хәзер йөреше кискен, әле карыйсың, ул класснын бер почмагында, әле карыйсың, икенче җиргә күчкән инде. Үзе беркая да ашыкмый кебек! Әлбәттә, балалар укытучыларының пөхтә киеменә күнегеп беткәннәр, аны шулай кирәк дип табалар, тик Гәүһәрнең бүген эчтән күбрәк ялтырап торуы аларны сагайта иде.

Менә шушы күзгә күренми торган бихисап вак нәрсәләр белән Гәүһәр башта укучыларның күңелләрен әкрен-әкрен яулап алды. Көн урталарына таба алар хәтта кичәге күңелсез вакыйганы оныта башладылар. Бәлки, укытучы аны бөтенләй телгә дә алмас әле. Ләкин Гәүһәр онытмаган иде. Актыкк дәрес бетәргә биш минут калгач, кинәт кулындагы китабын япты да өстәл янына килде, кырысрак күзләрен тынып калган класс өстеннән йөртеп чыкты.

— Инде кичә булган хәл турында... Бик күңелсез хәл. Ләкин иң элек мин үзем сездән гафу үтенергә тиешмен. Зөбәрҗәт, син мине гафу ит, кичә мин хаклы түгел идем. Кызып киткәнмен... Ә гомумән алганда, балалар, сугышып, сез бик начар эшләгәнсез. Әйтерсең, сез урамнан кергән малайлар. Зөбәрҗәтнең кара савытын да ватканзсыз.

— Гәүһәр апа,— диде кызчык, торып,— менә минем кара савытым. Ул ватылмаган.

— Кем китереп куйды?

— Белмим, Гәүһәр апа. Мин иртән класска кергәндә ул шунда тора иде. Капчыгы да шундый, карасы да бар.

— Утырыгыз, Зөбәрҗәт.

Гәүһәрнең классында ялагайланучылар һәм әләкчеләр юк иде. Ул көче җиткән кадәренчә балаларны ялганламаска, туры сөйләргә өйрәтә иде. Хәзер дә Зөбәрҗәтнең дөресен сөйләвенә ул шикләнмәде. Болай булгач, кара савытын ватучыны шелтәләүдә ни мәгънә? Сабак булсын өчен генә аны класс алдына чыгарып бастырыргамы? Ул үз хатасын үзе төзәткән бит. Әйтмәсә дә берәү дә белә алмас иде. Су-

гышкан вакытта кем кемгә карап тора. Ул аны ватар өчен алмагандыр да, кулына гына эләккәндер. Зөбәрҗәт бит алгы партада утыра.

— Мин Зөбәрҗәткә кем кара савыты куйганын белмим. Ләкин кем генә моны эшләсә дә үз хатасын аңлап эшләгән. Минемчә, шул ягы кыйммәт. Без аның кем икәнен белергә тырышмыйк. Моннан соң ул бервакытта да кара савытын ватмас, сугышмас. Шулай бит, балалар? — Гәүһәр сулыш алды.— Моңарчы без сугышның нәтиҗәләрен тикшердек. Ә сугыш ни өчен чыккан? Кем әйтергә тели? Я, әйтүче юкмы? Ул инде тикмәгә генә башланмагандыр. Аның беренче адымнары булгандыр. Әхмәт, син әйтәсеңме?

— Әнә Каюм, ул мактана,— диде, иң арттагы партада утырган малай, аякка басып. Ул буйга озын, шуна күрә иң арттагы партада утыра. Иптәшләре кайчак аңа шул буена ишарә ясап «жираф» диләр.— Минем лобзик, ди, бөтен кешенекеннән үткен, агачны гына түгел, тимерне дә выж итеп кисә, үзе сынмый, ди.

— Ул минем пычкыны юри сындырды,— диде стена буенда урта партада утырган Каюм.

Хәзер мәсьәлә ачык инде. Башта шул лобзик аркасында ике малай төртешеп алган. Берсе катырак суккан, ахрысы, икенчесе тагын да катырак. Аннары иптәшләре кушылган, шуннан киткән дә киткән, кара савыты да очкан, дәфтәр, китаплар да, ахырда кызлар да кушылган.

— Менә хәзер мәсьәләнең төбенә җиттек,— диде Гәүһәр.— Күрәсез, бөтен классның астын өскә китерерлек сугыш ачар өчен һичбер җитди сәбәп булмаган. Уеннан уймак чыга дигәндәй, күрәсез, нинди күңелсез хәл башлана, бөтен класска тап төшә. Шәриф Гыйльманович, безнен мәктәпнең директоры, мәсьәләне тикшерергә үзем киләм дигән иде. Мин үзебезгә тикшерергә рөхсәт итегез дип сорадым. Ул риза булды. Дәрес беткәч, мин аңа кереп сөйләргә тиешмен. Минемчә, сугышны башлаган балаларга җәза биреп тормыйбыз, алар үзләренең хаталарын болай да аңларлар. Тик каты итеп кисәтәбез, алар бик ямьсез эш эшләгәннәр, киләчәктә мондый хәлләр кабатланмасын! Монысы беренчесе һәм соңгысы булсын. Шуның белән бетерәбез. Тәртип белән генә таралыгыз.

Класстан балалар тавыш-тынсыз гына чыктылар, әмма баскычта ук алар гөрләп шаулаша башладылар. Ни әйтсәң дә, балалар балалар инде, тәртип ялыктыра аларны. Бала-чагага ирек кенә булсын.

Гәүһәр кереп барысын да директорга сөйләп бирде. Бер карт укытучы тыңлап торды-торды да әйтеп куйды:

— Тыштан карасаң, бар да дөрес кебек, ә чынлап тикшерсәң, уйга каласың. Син, Гәүһәр, авырга алма, балаларны кызганып, аларга аю хезмәте күрсәтмисеңме? Бер заман алар, синең йомшаклыгыңны сизеп алсалар, башыңа менеп утырырлар. Бу — бер. Икенчедән, нигә син балалардан гафу үтенәсең? Укытучылардан кем кызмый? Мин дөрес эшләгәнсең димим, ләкин шундый хәл булган икән, син электе хатаңны тирәнәйтмә. Укытучының авторитеты җил тимәслек булырга тиеш. Укытучы ни генә эшләсә дә дөрес эшли. Әгәр укучы моңа шикләнә икән, аннан нәрсә кала?

— Гафу итегез,— диде Гәүһәр карт укытучыга һәм көлемсерәп утырган директорга борылды,— бу шулай катгыймыни? Минемчә, һәрбер укытучы үзе уйларга тиеш. Ихтимал, ул ялгыша торгандыр. Хатасын үзе төзәтсә...

Гәүһәрнең директор алдында үзен иркен тотуы, каушамавы, барыннан да бигрәк, хатасын төзәткәнлеккә тирәнтен ышануы карт укытучыга ошамады. Менә бит ул яшь укытучылар! Монда классны түгел, укытучыны үзен тәрбия итәргә кирәк. Бүген ул кечкенә генә хатасын күрми, иртәгә зуррагын да абайламас (әле ярый, карт укытучы Гәүһәрнең кичә сугышка катнашуын белми иде). Ул урыныннан торды.

— Мин, Гәүһәр, дәрескә ашыгам, югыйсә, синең белән бик иркенләп сөйләшер идем. Утыз җиде ел балалар укытам инде мин. Шәкертләрем арасында профессорлар да аз түгел. Мин күп нәрсәләр күргән.

Укытучы чыгып киткәч, Гәүһәр тагын директорга борылды.

— Мин бит аның белән бәхәсләшмим. Миңа бары дөрес юлны табарга кирәк. Класс җыелышын дөрес үткәрмәгәнмен икән, шулай дип әйтегез, Шәриф Гыйльманович.

— Карт укытучының сүзләрен авырга алмагыз, шулай ук үзегезнең юлдан да чигенмәгез, Гәүһәр. Укыту эше һаман яңара, бурычлар һаман катлаулана. Без бит яңа кеше тәрбияләбез. Моны бер акыл белән генә эшләп булмый, һәрвакыт иптәшләрегезгә күз салырга кирәк... Инде сезнең бүгенге эшегезгә килсәк, минемчә, сез тирән уйлагансыз. Мин сезгә күрсәтмәләр бирергә җыенмыйм. Иң ошаганы миңа сезнең фикер йөртүегез булды. Үз юлыгызны табарга тырышуыгыз да әйбәт.

— Рәхмәт, Шәриф Гыйльманович.

Директор яныннан Гәүһәр күтәренке күңел белән чыкты, ләкин урамда, карт укытучыны исенә төшергәч, башын иде. Мин укытучы, укытучы исеменә тап төшмәсен өчен акны да кара димме? Балалар әле күп нәрсәне аңламыйлар дип акланыргамы? Ярый, бүген аңламасыннар ди. Берничә ел үткәч, алар шушы вакыйганы искә төшермәсләрме? Шуннан дәвамчылыктан нәрсә кала? Әллә дәвамчылык педагогик киңәшмәләрдә сөйләр өчен бер сүз генәме? Бүген, укытучының авторитетын яклап, берникадәр уңышка ирештем ди, ә иртәгә, югарырак классларда, мәктәпне тәмамлагач, ни ала? Безнең кулдан киткәч, бала (дөресрәге, яшь кеше) нишләсә дә ярыймы?

Гәүһәрнең чигәләре чатный башлады, күрәсең, болай дулкынланып уйлау аңа һич ярамый. Әмма укытучы уйларга тиеш ләбаса! Әллә, Җәгъфәр әйткәннәрне кабул итеп, үз булмаңа, матур дачаңа бикләнергәме? Балаларың да булмагач, бер иреңнең кәефен күрү әллә ни кыен булмас. Гәүһәр шунда ук үз уеннан кире кайтты. Юк, ул бу юлдан барасы кеше түгел, авыр булса булыр, тик Гәүһәр укытучылык һөнәрен алыштырмаячак. Монысы нык, гомергә!

## 6

Ап-ак кар яуды, дөньяны кер кунмаган йомшак мамык юрган каплады. Кар әле ноябрь башларында ук сибәләгән иде, җир ала-кола булып торды. Зур шәһәрнең үзәгендә, билгеле, ак төснең эзе дә юк, тик бакчаларда, кеше йөрми торган тау битләрендә генә кар яткалаган. Көннәр ярыйсы салкынча. Аннары әкренләп җылыта төште, аяк асты кап-кара боз белән капланды, егылучы, имгәнүче кешеләр күбәйде, төннәрен һәм кичләрен ярма кар яуды, тик җир агармады, киресенчә, бозлавык кына артты. Көннәр дә әллә нинди ямьсез иде, кояш бөтенләй күренмәде, сәгать өчтә, дүртенче яртыда тәмам караңгылана башлады. Хәтта көн яктысында ут кабызырга туры килгән чаклар да булгалады. Шуннан соң ничектер бер дә көтмәгәндә кинәтгөне ишеп-ишеп кар яуды, бөтен җир акка төренде, аз гына җылытып та җибәрде, аннары ялтырап кояш чыкты. Кешеләр җиңел сулап җибәргәндәй булдылар — кара көз бетте.

Гәүһәр дә, ниһаять, башын күтәрде. Караңгыда эшләнгән эш көн яктысында көлке булып күренә, үзенең үткенлеген югалта, кечерәеп кала диләр. Бүген беренче тапкыр чынлап торып кар явып, якты кояш күренгәч, кичәге һәм аннан элекке уйларына Гәүһәр үзе дә гаҗәпләнде: башны алай кайгыга салырга кирәкмәгән шул. Баланың үлеме бик авыр, әлбәттә, ләкин яшәеш дәвам итә бит, сыгылып төшеп бирәүне дә шаккатыра алмыйсың, иң мөһиме, бирәү дә сине якламый, батырлык кыенлыкларны җиңә белүдә, аларның кара агымына бирелеп,

болганчык дулкыннарда йөзүдә түгел. Караңгы уйлар — күңелне дә караңгылата. Соң шулай булмыйча! Мәктәп белән генә чикләнмичә, Гәүһәр Исрафил Дидаров турында да әллә нәрсәләр уйлап бетерде. Кешене яманларга бер дә егетлек кирәкми икән. Әз генә ошамаган өчен, дөресрәге, кинәт ошамаган өчен кешене шулай тиргәргә ярыймы соң?! Машина алганда да, дача корганда да, яңа квартирага күчкәндә дә Исрафилнең ярдәме тимәде түгел. Кешенең яхшылыгын аяк астына салып таптарга димәгән ич. Ирләр болай бервакытта да эшләми торганнардыр инде. Аларның акыллары үзләре белән шул.

Әгәр Гәүһәр Исрафил Дидаровка очып кунуының сәбәбен эзләсә яки бу эшнең төбенә караса, һичшиксез, анда Фаягөлнең томанга уралган топык гәүдәсен дә күрер иде. Исрафил Дидаров бер үзе генә булса, билгеле, Гәүһәрне бу кадәр борчымас иде. Фронтны башларыннан кичергән ирләр — бу турыда Исрафил кайчак сөйләп ташлый иде — шулай беркадәр сәеррәк булалар, артыгын да эшләп ташлыйлар инде. Мәгәр аларның бу сыйфатлары жаннары бозык булудан килми бугай. Ә менә Фая башка, аның уенда әллә нәрсәләр булуы мөмкин дип уйлый иде Гәүһәр. Теге вакытта яр буенда кояш яктысында Фәнүзәне күргәч тә Гәүһәр шул турыда уйлаган иде.

Уенда Фөягөл еш булса да, Гәүһәр бервакытта да аның исемен ире алдында телгә алмады. Гүя ире Фаягөлне күрү түгел, исемен генә ишетсә дә, әллә нишләр. Моның белән Гәүһәр үзе дә сизмәстән Фаягөлнең салкын матурлыгыннан курка иде, аның Гәүһәрдән ниндидер өстен яклары бар. Тукта, Җәгъфәр үзе Дидаровларга барып йөрмиме соң? Гәүһәр бервакытта да ирен тикшермәде. Бәлки Җәгъфәр жыелышта булмыйча, Фаяларда утыргандыр. Бу уй аңа тынгылык бирми башлады. Гәүһәр, жир ярылса, оятыннан жир тишегенә керердәй булып, ирен күзәтте. Ләкин күпме күзәтсә дә ирен гаепләрлек бернәрсә дә тапмады. Шуннан соң, серен ерак яшереп, бер көнне иренә:

— Нигәдер Фәнүзә апаны бер күреп сөйләшәсем килә,— диде.— Синең күргәнең юкмы?

— Мин кеше хатыннары белән очрашмыйм,— диде Җәгъфәр, көлеп.— Аллага шөкер, ул миннән ике тапкыр диярлек олырак.

— Апасы олы булса, сеңелесе бар,— диде Гәүһәр, кызарып.

— Күргәнем юк. Күрергә жан да атмыйм. Барыбер минем хатынымнан яхшысы булмас.

— Әйтерсең инде,— диде Гәүһәр, үзе иренә сөеп карады. Тиле, шундый алтын иреннән шикләнде бит ул. Әле дә ярый, Җәгъфәр белми, белсә егылып көләр иде.

Гәүһәр тынычланды һәм мәктәбенә ашыкты. Кер кунмаган ап-ак урамнан салкынча һава сулап, рәхәтләнеп барды. Күңел өсте дә шушы ак урам төсле. Бер таплы жире юк. Нинди хуш, нинди иркен.

Мәктәпкә кергәч, Гәүһәрнең бөтен уйларын балалар биләп алды. Аларны онытырга ярыймы соң! Алар бит Гәүһәр апаларына әнә ничек сыеналар, ул аларны дөньядагы барлык жил-давыллардан саклый дип беләләр. Аннары Гәүһәрнең кәефен ничек тиз сизәләр. Гәүһәрнең кәефе булмаганда алар тып-тын утыралар, кәефе булса әнә ничек көләләр, уйныйлар, шаяралар. Башлангыч мәктәп укытучысы моны бервакытта да онытмаска тиеш. Балалар аңсыз рәвештә аңардан барысын да күчерәләр бит. Әнә кызлар Гәүһәр апаларына ничек ошарга тырышалар, малайлар күбрәк аның эчке сыйфатларын оталар. Юк, үз уйларың никадәр ташыса да, балаларга аларны сиздермә.

Гәүһәр иртән исемлекне тикшергәндә үк Фуат Кәримовның дәрескә килмәвенә игътибар итте. Фуат еш кына авырый. Күрәсең, тагын авыргандыр дип уйлады.

— Фуатны күрүчегез булмадымы? — дип сорады ул. Балалар күрмәгәннәр икән. Шуннан соң Гәүһәр бу турыда сүзне артык куертмады.

ә дәрес беткәч туп-туры Фуатларга китте. Мәктәптә, балалар арасында, ул борчылмаган иде, хәзер аның башына төрле уйлар килде. Бала бит, шәһәр урамнарында адым саен куркыныч янавын беләме соң ул?! Юлдаш та бит уйнаган гына, әнә нинди фаҗига килеп чыкты. Гомумән, бу Юлдаш Гәүһәрнең холкын шактый үзгәртте. Элек ул бер дә борчылмый торган иде, хәзер чак кына берни булса да сискәнеп китә, әллә нинди шикләргә төшә. Укытучылар аңа: «Гәүһәр, син мондый түгел идең бит», дип әйтеп карадылар. Үзе дә белә, ләкин ни хәл итсен. Урамда да бу ярыйсы модный киенгән хатынның бер кайгысы, бер борчуы юктыр дип уйлый торганнардыр инде.

Өстенә бик әйбәт кышкы пальто, башына пыжик бүрек кигән Исрафил Дидаров очрады.

— О, Гәүһәр ханым, исәнмесез, саумысез. Кая болай юл тоттыгыз?

— Ах, гафу итегез, Исрафил абый. Башымны иеп килә идем... Кәримов дигән бер укучым дәрескә килмәде. Өйләренә барып, белешим дигән идем.

— Кәримов? Исхак малае түгелме?

— Әйе, Фуатның әтисенең исеме Исхак бугай,— диде Гәүһәр, борчылып.

— Алай булса, пошынмагыз, Гәүһәр ханым. Исхакка квартира биргәннәр. Каядыр Ленин районында диме. Между прочим, Гәүһәр ханым, депутат Җәгъфәр Мәүлиханов ярдәм итте, ди Исхак. Шундый шатланган. Квартира бит кешенең ярты гомере.

Исрафил Дидаров озак сөйләшмәде, ул каядыр бик ашыга иде. «Барып йөрмәгез, өйләрендә инде ят кешеләр, сезнең болай да вакытыгыз бик кадерле», диде дә, Гәүһәргә сәламәтлек теләп, китеп тә барды. Гәүһәр аның артыннан сокланып карап калды. Нинди әйбәт кеше ул Исрафил абый, кеше өчен ничек шатлана, ә Гәүһәр аның турында... Ярый әле, үзе белми, белсә, сөйләшеп тә тормас иде. Гәүһәр шундый дорфа уйлары өчен тагын бер тапкыр үкенде. Ләкин терсәкне тешләп булмый икән шул.

Иренең яхшы эше өчен дә Гәүһәр чын күңеленнән шатланды. Кәримовларның өендә аның элек тә булганы бар иде. Агач йорт, берме, икеме бүлмә, кысан. Кәримовның өчме-дүртме баласы, хатыны авыру. Ул бичара суына, газына, иң мөһиме кухнясына шатланыр. Хатынкызга бит барыннан да элек шунысы кирәк.

Шулай да Гәүһәр Кәримовларның квартирасына барып карады. Үз күзең белән күрмәсәң, күңел әллә нинди вәсвәсәләргә төшә бит.

Кәримовлар, чыннан да, күчеп киткәннәр икән, аларның квартираларында башка кешеләр иде инде. Гәүһәр, гафу үтенеп, үзенең кемлеген әйтте дә кире чыгып китте.

Көн якты, йомшак. Кәримовлар өчен Гәүһәр чын күңеленнән сөенеп, юл өстендәге кибетләргә керде. Җаның ни тели, шул бар. Гәүһәр ашыкмый гына әйберләрнең бәяләрен карады, аннары үзенә кирәклеләрен алды. Бүген кичке ашны мул итеп әзерләр, ире дә шатланыр, ул бит камыр аш ярата, аның тәмен белеп ашый. Гәүһәргә аның күңелен табу һәрвакыт рәхәт була, хәзер шул хәтле кичерешләрдән соң хатынының ачык йөзен, мул табынны күрү Җәгъфәрне бөтенләй шатландырыр.

Гәүһәр ашыгып өенә кайтты. Пальтосын салып, көзге каршында чәчен төзәтте, өс киемнәрен салды, халатын киде. Күптән инде квартирасын рәтләп җыештырганы юк иде. Әүвәлге дәрт белән тузаннарны сөртте, идәннәрне юды, аш әзерләде, шул ук вакытта сәгатенә карап-карап алды: тиздән Җәгъфәр дә кайтырга тиеш. Гәүһәр үзалдына көлемсерәп куйды... Җәгъфәрнең бер караганда кызык, бер караганда ачуны китерә торган гадәтләре күп: ул бусага төбендә беразга туктап тора, тыңлый, аннары кесәсеннән ачкыч чыгарып, ишекне сак кына

ача да шыпырт кына атлап алгы бүлмәгә керә, шылт иткән тавыш чыгармыйча, папкасын кечкенә өстәлгә куя, пальтосын, эшләпәсен сала, көзгегә карап галстугын төзәтә, борын төбендәге сыткы сыман бер нәрсә булса, шуны чәнчә бармагы белән капшап карый. Гәүһәр аның бу гадәтләрен бөтен ваклыкларына кадәр белә. Шуннан соң Җәгъфәр, аяк очына гына баса-баса бүлмә ишеге янына килеп, җир астыннан чыккандай, хатыны алдына баса. Элекке елларда Гәүһәр иренең мондый кыланышларыннан соң һәрвакыт бөтен гәүдәсе белән сискәнеп, «аһ!» дип кычкырып җибәрә, күкрәгенә кулын куеп, бер адым артка чигенә торган иде. Моны күреп Җәгъфәр елмая, мәгънәле генә итеп бармак яный, икенче бүлмәнең ишегеннән башын сузып, карангалап алганнан соң гына хатынын иңнәреннән тотып кочып диванга алып килеп утыра, үбә башлый.

— Көн дә шулай котымны алмасаң соң!..— дип, Гәүһәр әкрен генә ирен шелтәли.

Җәгъфәр аны, күкрәгенә ныграк кысып, шаян тавыш белән колагына пышылдап кына җырлый: «Әллә ниләр бирер идем аһ дигән сүзләреңә...»

Өйдән тыш һәр җирдә шундый кырыс, шундый җитди бу кеше өйгә килеп кергәч тәмам балага әверелә.

— Матур хатынлы ирләрнең хәле хәл инде, алар турында тикмәгә генә романнар язмыйлар.

Менә шундый шаян сөйләшүләрдән соң кайчак Гәүһәр ирен кисәтеп тә куя, кайчак, киресенчә, кычкырып көлә генә. Бүген Гәүһәр аеруча көлде.

Чиста юган бүлмәләр, хатынының назлары, тәмле аш — аның исе монда да җәелгән иде — Җәгъфәрнең кәефен тәмам күтәреп җибәрде. Чәй эчкәндә ул ашларының тәмлелеге өчен хатынын мактады.

— Мине мактамасаң да була, кибеттән алган ашлар. Менә сине,— Гәүһәр иренә күз кырыйлары белән карады,— мактасаң да ярый. Кәримовларга менә дигән квартира биргәннәр ди. Ул Кәримовларның Фуат исемле малайлары миндә укый иде бит. Шул дәрескә килмәгәч, борчылып, аларга бара идем, юлда Исрафил абыйны очраттым. Ул барысын да сөйләде.

— Биргәннәрмени? Алайса, яхшы булган. Ләкин монда минем эшем бик кечкенә, Гәүһәр. Квартираларына барып тикшергән идем... Шул гына. Аңар китсә, мин уннарча квартира тикшерәм бит, әмма тикшергән берсенә бирмиләр.

— Син үзең дә барысына да бирегез дип сорамыйсыңдыр.

— Анысы үзеннән-үзе билгеле. Райсовет депутаты районда торак хәлен белә.

Иренең үз эшен артык зурга куймавы, моның белән асла мактанмавы Гәүһәргә бик ошады.

Күптән инде Гәүһәр мондый күңел канәгатьлелеге кичергәне юк иде. Тормыш теләсә нинди яраларның да әрнүен дәвалый икән. Юлдаш турында сөйләргә кыймаса да, аны онытмаса да, вакыт инде аны читкә этәргән иде, көндәлек яңа нәрсәләр беренче урынга бастылар. Гәүһәр, билгеле, бу турыда берәүгә дә сөйләмәде, берәү белән дә киңәшмәде. Болар ничектер үзеннән-үзе эшләнделәр һәм шулай үз-үзләреннән эшләнүләре яхшы да иде.

Аштан соң Җәгъфәр үз өстәле янына газета-журналлар карарга утырды. Гәүһәр, икенче бүлмәгә чыгып, дәфтәрләрен карый башлады. Аның яхшы гына очланган кызыл карандашы бар иде. Шул карандашы белән дәфтәрдәге хаталарны сакланып кына төзәтте, билгеләр куйды. Бик яхшы билгесе кую аның үзенә дә рәхәт иде. Бәхеткә каршы, бүген бик яхшы һәм яхшы билгеләре гадәттән дә күбрәк. Ул хәтта артык йомшарып китмәдемме дип үз-үзеннән дә шикләнде, ләкин һич

тә ялгышмаган, берәүгә дә артыгын куймаган. Гомумән ул билгеләрне урынсызга үстерүдән яки кечерәйтүдән саклана иде. Бер тапкыр белеп хата ясасаң, аннары инде үзеннән-үзе китә.

Икенче көнне дә Гәүһәр мәктәпкә кутәренке күңел белән барды. Дәресләре дә ничектер бик күңелле үтте, яңа төзелешләр турында сөйләде, Фуатларга да яңа квартира бирүләрен әйтте. Фуат дәрестә юк иде, күрәсең, ул башка мәктәпкә күчәдер. Гәүһәр моңа бик үк канәгать түгел иде. Фуат әллә ни яхшы укучы булмаса да, Гәүһәр аңа ачкыч тапкан иде. Яңа укытучы ул ачкычны кайчан табар әле?

Иртәгә районда башлангыч класс укытучыларының бик зур киңәшмәсе булырга тиеш. Гәүһәр сөйләшер һәм бераз киңәшер өчен карт укытучы, кайчандыр үзен укыткан Рәхимә апаларга барырга булды. Рәхимә апалар ул чакта авылда торалар, ире — Галимҗан абый — райком секретаре иде. Гәүһәр аларның өйләренә дә барып йөрде. Алар да бу тыйнак кызны яраттылар, Гәүһәр үзе дә аларны бик тирән хөрмәт итте. Күп еллардан соң Казанда очрашкач та Гәүһәр аларда үзенә карата аз гына да үзгәреш сизмәде. Гәүһәрнең ахыр килеп педагогия училищесын тәмамлавына, тормышка чыгуына алар чын күңелләреннән шатландылар. Рәхимә апалар мәктәптән бик ерак түгел, зур яңа йортта торалар иде. Гәүһәр, балаларны озаткач, троллейбуска утырды да туп-туры аларга китте. Ул инде телефоннан аларга шалтыраткан иде. Рәхимә апа да, аның ире Галимҗан абый да өйдәләр иде. Галимҗан абыйның бераз хәле булмаган, иртәгә инде эшкә чыга. Кызлар институтта икән. Галимҗан абыйларның игезәк кызлары бар. Алар бер-берсенә шулкадәр охшаганнар, Гәүһәр әле булса аларны бутый. Чыннан да икесе дә иңнәренә төшеп торган кара чәчле, кара тутлы, озын буйлы. Тик берсе тазарак, икенчесе ябыграк. Авызлары-борыннары, күзләре-кашлары һич аерып алырлык түгел, хәтта тавышлары да бер төсле. Аларның кайсы Илсөяр, кайсы Илназ икәнен әниләре генә белә торгандыр.

Гәүһәрне бик сөенеп каршы алдылар, әй, оныттың бит, дип гадәти сүзләрне дә әйттеләр. Хәер, үзләренчә алар хаклы иде. Җәй буе да, көз буе да Гәүһәр аларга керә алмады, тик телефоннан гына хәл белеште, берничә тапкыр дачага чакырды. Кызлар җәй көне чирәм жирләрдә иде, Рәхимә апа белән Галимҗан абый ничектер вакыт таба алмадылар.

Галимҗан абый артык бирешмәгән булса да, Рәхимә апа тәмам агарган. Гәүһәр аны кап-кара чәчле, тал-чыбыктай нечкә билле укытучы килеш хәтерли. Гәүһәрләр яшертен генә сокланып, аңарга охшарга да тырышалар иде.

Рәхимә апа әүвәлге кебек укытучылык эшендә, Галимҗан абый исә партия эшеннән күптән киткән, хәзер заводта инженер булып эшли икән.

Җәгъфәр бүген соң кайтырмын дигәнгә Гәүһәр пошынмыйча утырды. Чәй эчә-эчә, сөйләшә-сөйләшә байтак вакыт үтте. Искә төшерүләр дә, укытучылар арасындагы төрле хәлләр дә — берсе дә калмады. Шуннан ничектер Кәримовларга да барып җиттеләр. Исхак Кәримов Галимҗан абыйлар заводында агент булып эшли икән, Исрафил Дидаровның бажасы.

— Дидаровның бажасы? — дип кайтарып сорады Гәүһәр.

— Әйе. Нигә сез болай гаҗәпләндегез?

— Юк, болай гына, Галимҗан абый.

— Сез моны белми идегезме?

— Каян белим, Галимҗан абый. Мин балалардан кардәшләрегез кемнәр дип сорамыйм бит.

— Алай икән... Ләкин монда гаҗәпләнер нәрсә юк шикелле, Гәүһәр. Кәримовның квартирасы чыннан да начар булган, мин моны зав-

комда ишеткән идем. Аның чираты житкәч, заводтан да бирерләр иде. Алданрак алган икән, бик яхшы булган.

Гадәттәгечә сүз бер темадан икенче темага күчеп торганда, тиздән Кәримовлар да, Дидаровлар да онытылды, башка темалар өстенлек алды. Вакытның кадерен белгәнгә, Гәүһәр ни өчен килгәнлеген дә исеннән чыгармады.

Гәүһәр инде киенеп, китәргә дип күзгә алдында бүреген төзәтеп торганда Рәхимә апа тагын шул Кәримовларны телгә алды.

— Әйтергә дип тел очымда гына тора, һаман онытам. Исхак Кәримов сезнең укытучыгыз Фая Идрисжанованың жизнәсе бит. Фая аларда тора. Жәй көне генә квартирабыз бик начар дип зарланган иде. Кара, көтмәгәндә нинди бәхетле булды.

— Әйе, берәүләргә бәхет үзләренә тимәсә, жизнәләренә тия,— дип көлемсерәде Гәүһәр. Шулай да аның өчен бу яналык иде. Фая Идрисжанова Дидаровның гына түгел, Кәримовның да балдызы икән!

## 7

Галимжан абый олы яшьләрдәге кеше булганга, заводта аны укулар белән дә, төрле түгәрәк эшләре белән дә борчымыйлар иде. Политэкономия буенча яшь галим Жәгъфәр Мәүлихановның лекцияләре буласын белгәч, ул моңа үзе теләп язылды, соңыннан чак кына да үкенмәде. Жәгъфәр лекцияләрне бик кызыклы укый иде. Заманында политэкономияне югары мәктәпләрдә азмы-күпме үткән инженер-техникларга мәктәп дәресләрен кабатлау урынсыз булыр иде. Ул яңа материалларга, бигрәк тә завод экономикасына күп урын бирде. Беренче карашка беркадәр корырак тоелган фән тәмам жанланып, тормышка якынаеп, алай гына да түгел, тормышның үзе булып китте. Хәтта заводның баш инженеры Дидаров булып Дидаров та соклануын яшерә алмыйча:

— Яшьләр алдыра, Галимжан,— диде.

Алар завод ишек алды буйлап капкага таба чыгып киләләр иде. Баш инженер политукуларга йөрмәсә дә, бүген ул да ничектер бирегә сугылган. Ул үзенең сүзләренә каршы Галимжан нәрсәдер әйтер дип көтте бугай, ләкин Галимжан башын иеп атлавында булды, гүя ул үз уйларына чумган иде. Алар проходнойга керделәр, вахтерлар белән исәнләштеләр.

— Мәүлиханов яшьләр белән калды бугай,— диде Дидаров, тирәягына каранып.— Алып кайтырмын дигән идем.

Шул чакта алар янына бер яшь кенә хатынмы, кызмы килеп, Галимжанга мөрәжәгать итеп:

— Гафу итегез, мин жизнине сездән аерам,— диде һәм Дидаровны култыклап алды.

— Галимжан, әйдә бергәләп машинада кайтабыз,— диде Дидаров.

— Рәхмәт. Мин бераз һава сулыйм. Башым нигәдер авыртып китте.

Дидаровның балдызы, укытучы Фая Идрисжанова турында Рәхимә сөйләгән иде. Шул икән, дип уйлады Галимжан. Бераз чытлыкланa төшә бугай. Хәер, рәтләп карарга Галимжанның вакыты да булмады бугай, аннары ул үзе дә хатын-кызга текәлеп карауны яратмый иде.

Бераз жәяү баргач, Галимжан троллейбуска утырды. Бу вакытта халык аз булганга, ул үзәккә кадәр бик иркен кайтты. Үзәктә Галимжан мәйданны аркылы кичте дә бакча юлына борылды. Кыш көне караңгыда аның күптән инде бу бакча аркылы үткәне юк иде. Тирәягына карана-карана баскычлардан менде. Аннары туктады. Уф! Нәрсә кага икән. Ник соң ул икенче троллейбуска яки трамвайга утырмады? Йөрәгенен чыгымчы икәнен белмимени. Бакчаны карыйсы килгәндер инде.

Бераздан ул бакча буйлап китте. Түбәндә жил бөтенләй юк иде.

кара, монда жил уйный икән, карт юкәләр дә әкрен генә гөжли, салкынча жил дә янак очларыннан чеметә. Бакча караңгы, утлар бик сирәк. Халык та бик аз, булганнары да бакчаны тизрәк үтеп, я үзәккә, я жылы өйләргә ашыгалар. Галимжан, йөрәгенә ял бирер өчен, туптуры сузылып киткән, кары көрәлгән аллеядан атлады. Төнлә капкара булып күренгән карама, юкәләргә карады. Нәрсәләрнедер хәтерләргә тырышты... Әйе, ул шунда Рәхимәсе белән беренче танышкан иде...

Партия Галимжанны кая гына жибәрмәде, авылда да, МТСта да эшләде ул, райкомда да.. Дөресен әйткәндә, аның төпләнеп утырган урыны да булмады, мең ел яшисе бар кеше төсле кая жибәрсәләр, кая кушсалар, шунда эшләде, һәр жир аңа якын, газиз иде. Ул бервакытта да бер генә жир белән яшәмәде, бер генә жирне өстен күрмәде. Хатыны да үзе шикелле илгизәр бер жан иясе, күрәсең, кайда да үзен килмешәк итеп хис итмәде. Балаларны инде әйтмисең дә, аларга күчену генә булсын.

Соңгы ун ел эчендә генә Галимжан шәһәрдә яши һәм машина төзүче заводларның берсендә гади инженер булып эшли. Дөрес, аңа директор урынын да, баш инженер урынын да тәкъдим итеп карадылар, ул риза булмады, минем елларым күбрәк башка эштә үтте, үзем сайлаган һөнәрем буенча эшли алмадым, уй-фикерне дә бүгенгечә чарлыйсы бар, диде. Аның белән килештеләр, аны байтак еллар борчымадылар. Галимжанны якыннан белгән кешеләр кайчак, хәвефләнеп, сине оныттылар түгелме, дип тә әйтеп карыйлар, Галимжан үз эшеннән бик канәгать иде. Шулай да күптән түгел бу мәсьәлә яңадан кузгалды, яңадан Галимжанга баш инженер урынын тәкъдим иттеләр. Моңа каршы Галимжан нәрсә әйтә ала иде? Хәзер инде Галимжан заводка тәмам күнегеп житте, әмма... әмма сәламәтлеге какшады. Былтыр жәй көне больницада да ятып чыкты. Менә шуны сәбәп итеп, Галимжан үзен иске эшендә калдыруларын үтенде. Нәкъ шул көннәрдә фронтовик дусты инженер Исрафил Дидаров та аңа:

— Галимжан, син бер дә саулыгыңны саклый белмисең,— диде.— Мин синең урыныңда булсам, күптән персональ пенсия кайгыртыр идем. Сиңа бит аны берсүзсез бирәләр.

Галимжан моңа башта аптырый төшеп калды, аннары башын артка ташлап көлеп жибәрде:

— Көлмә,— диде Исрафил, иелә-сыгыла төшеп,— дусларың әйткәнгә колак сал. Йөрәктән бер сигнал булдымы? Булды. Юләр булып, икенчесе артыннан чапмыйлар. Яшәргә кирәк.

Бу сөйләшү ничектер аяк өстеннән генә булган иде, аннары өлкә комитеты кешесенә Галимжан үзенең фикерен дә өзеп әйткән иде. Шуңа күрә Дидаровның сүзләрен Галимжан шунда ук онытты. Әмма беркадәр вакыттан соң ул Дидаровның аны, инженер буларак, яманлап сөйләүләрен ишетә башлады. Хәер, Исрафилнең холкында элегрәк тә шундый сәер хәлләр булгалаганга, Галимжанның моңа да артык исе китмәде. Дөрес, алар инде күптән йөрешми башлаганнар иде, әмма араны тәмам өзү турында уйлап та карамадылар. Эштә бер-беренне кыерсыткан чаклар да булгалый, кызу кулдан бер-береңә авыр сүзләр дә әйтәсең. Аның өчен генә араны өзә китсәң, чын дуслыктан, фронт дуслыгыннан ни калыр? Фронт дуслыгы ул бит ай-һай ничек, ул синең яшәвеңә көч бирә, тормышыңны матурлый.

Шул көннәрдә бугай Дидаровны бер машина конструкцияләгән өчен газетада бик мактап чыктылар. Машина чыннан да яхшы иде, файдасы да күп иде, ләкин ул асылда Дидаровның гына эше түгел, бөтен бер коллектив эше иде. Хәтта Галимжанның да өлеше бар иде. Дидаров матбугатта булмаса, берәр киңәшмәдә газетада киткән хатаны күрсәтер, дип уйлады Галимжан. Аңардан бит хәзер заводта ачыктан-ачык көләләр. Галимжан күрә торып моңа ничек түзсен. Үзе шун-

дый хәлгә очраса, иптәшләренең күзләренә карый алмас иде. Дидаров ләм-мим дәшмәде. Шуннан соң Дидаровның үзен генә очратып, Галимҗан, газетада хата киткән бит, диде.

— Әйе, әйе,— диде Исрафил тиз-тиз генә,— мин газета хәбәрчесенә икенче көнне үк шалтыраткан идем. Ул гафу үтенгән булды. Төзәтербез дигән иде, күрәсең, кайда әйткән, шунда онытккан, минем дә исемнән чыккан, каһәр суккыры... Ничек, миңа рәсми рәвештә гафу үтенергә кирәк булыр дисеңме?

Турысын әйткәндә, Галимҗан Исрафилдан мондый өлгерлек көтмәгән иде. Ул Исрафил әле уңайсызланган булыр дип уйлаган иде.

— Шулай яхшырак булыр иде шикелле, Исрафил... Югыйсә, халык әллә нәрсәләр сөйли бит.

— Әйе, шулай. Хаксызлык эчне тырнап тора. Ничек онытканмын, һич башыма сыймый. Искә төшергән өчен мең рәхмәт.

Исрафил Дидаров бу сүзләрне чын йөрәктән әйтте кебек, әмма Галимҗан бу әле суза күрмәсен дип борчылды, ләкин күп тә үтмәде, шактый зур һәм авторитетлы бер җыелышта Дидаров, сүз җаен бик оста туры китереп:

— Газета хәбәрчеләре шулай инде, үзләренә уңай моментны гына гайлыйлар, ә сиңа никадәр зыян китерүләрен уйлап та карамыйлар,— диде һәм бөтен бер коллективның эшен бер Дидаровка кайтарып, аны күтәреп, коллективны чиксез түбәнәйтүен сөйләде.

Галимҗан Дидаровтан бик канәгать булып калды. Әнә коллективка карата нинди канатлы сүзләр әйтте бит. Гомумән ул завод җәмәгатьчелегенә югары бәя бирде, бу җәмәгатьчелек киләчәктә бик зур бурычларны үтәргә әзер тора дип сөйләде. Башкалар да моңа игътибар иттеләр, Дидаров бөтен коллектив алдында үсеп киткәндәй булды. Аны яратып бетермәгән кешеләр дә, бу речьннән соң, бик нык уйга калдылар. Дидаровны чынлап торып җыелышта гаепләп чыгарга уйлаган кешеләр исә телләрен тешләделәр.

Шуннан соң күп тә үтмәде, Дидаровны баш инженер итеп куйдылар. Галимҗан моңа аз гына да гаҗәпләнмәде. Дидаров элек тә югары урыннарда күп эшләгән. Соңыннан нинди дә хаталары өчен аны эшеннән алган булганнар. Инде хаталарын төзәткәч, кем аңа ачу сакласын. Аннары Исрафилның саулыгы да шәп, яше дә ул хәтле олы түгел әле, үкертеп эшләр чагы. Яшь инженер Светлана Нилина гына, кайнап торган ачулы нәфрәтен яшерә алмыйча:

— Галимҗан Нигъмәтҗанович, нигә сез шундый...— диде.

Нилина бу сүзләрен көтмәгәндә шундый кайнарланып әйтте, Галимҗан чак кына аптырап калды, аннары елмаеп:

— Ничек инде «шундый?» — дип сорады.

Алар инженер бүлмәсендә икәү генә иделәр. Светлана әле яңа гына цехтан кергән, йөзе кызарган. Кем беләндер сүзгә килгән булса кирәк, әле тынычланып та өлгермәгән. Контора тирәсеннән үзе әледән-әле цехка карый. Цех бик зур, бик озын. Пөзләрчә эшчеләр станокларына иелгән, кырган, кискән, шомарткан тавышлар ишетелә, кайчак көлтә-көлтә чаткылар сибелә. Өстә конвейер хәрәкәт итә, кирәк урыннарда туктый, детальләрне төшерә. Тышта көн яктысы булса да, монда, цехта, бөтен җирдә утлар алынган иде.

— Ничек дип... Сезгә пычрак аталар, сезне таптыйлар, сезне... Юк, мин моңа түзә алмас идем!

— Светлана, кем миңа шундый явызлык эшли, ни өчен? — диде Галимҗан, чак кына көлемсерәп.— Мин кешегә тумыштан усал җан итеп карый алмыйм.

— Ә Дидаров! — дип кычкырып җибәрде Нилина.— Мин әле генә аның белән чәкәштем. Ул хәтта синең конвейерны да, безнең бөтен коллектив эшләгән эшне дә...

— Кызмагыз, Светлана Ивановна,— диде Галимҗан сабыр гына.— Дидаров турында бер начар сүз дә әйтә алмыйм. Ул минем фронтовик дустым. Ә фронтовик дус...

— Дидаров сезнең дустыгыз?!

Светлана урыныннан сикереп торды, аннары йөгереп чыгып китте. Тимер баскычта аның үкчә тавышлары гына ишетелеп калды. Гүя аның йөрәге шулай кага иде.

Галимҗан тәрәзә янына килде. Цехка карап тора башлады. Читтән аның кызу ритмын тотып та булмый шикелле, эшчеләр гүя ашыкмыйча, сабыр гына эшлиләр, берәү дә кабаланмый. Конвейердан детальләрне алганда да, аларны станокларда эшкәрткәндә дә ниндидер төгәллек сизелә. Галимҗаннарның уе, акылы түгелме соң бу?

Галимҗан, үзенең хезмәте шактый булса да, моны бер вакытта да үзенеке дип уйламас иде. Цехта эшләнгән эш ул — коллектив эше, коллектив акылның җимеше. Аның көче дә, яшәүчәнлеге дә шунда. Менә шуңа якын булу, шуны тою Галимҗанга һәм аның ишеләргә бәхет түгелме? Дөресен әйткәндә, Галимҗанның цехтан күчәргә теләмәвенең бер сәбәбе дә шунда бит. Моны кешегә сөйләмәссең, аңлата алмассың. Хәер, моны сөйләү, аңлату нәрсәгә кирәк?

Шул уйлар эчендә Галимҗан конторага Дидаровның килеп керүен дә сизмәде. Аның өстендә яңа күк сатин халат, башы яланбаш. Авызы колакларына җиткән, иелә-сыгыла, үзен һич тә зурга куймыйча, Галимҗан белән кул биреп күреште. Аның турында әнә нәрсә сөйлиләр, юк, бу дөрес түгел, монда ниндидер аңлашылмаучылык кына.

Ул арада Дидаров, җәелгән авызын җыя алмыйча:

— Иртәгә син, Галимҗан, минем янга бер кереп чык әле,— диде.— Минем кайбер тәкъдимнәрем бар. Синең фикереңне беләсем килә. Лимонлап чәй эчә-эчә сөйләшербез. Монда эшләр ничек, барамы? Әйдә әле, корпусларга күз салыйк, анда нәрсәдер тоткарлык килеп чыккан...

Кич белән, өенә кайткач, Галимҗан үзенең фронт архивын актарды. Рәхимәләрнең бүген җыелышлары, тиз генә кайта алмас, кызлар институтка киттеләр, кичәләре бугай. Өйдә беркем дә юк. Менә бер пачка рәсем. Арадан Дидаровныкы да килеп чыкты. Зур, әйбәт рәсем. Капитан. Хәзергегә караганда Дидаров күп яшь, корсак та юк. Ләкин елмаюы шул ук, авызы колакларына җиткән. Арттарак туплар — артиллерист икәне күренеп тора. Рәсем астына эре итеп: «Дустым Галимҗанга», дип язып куйган. Әйе, бер дивизиядә иде алар. Кайсы ел икән? Әһә, 1943 ел. Кайда иде икән алар ул чакта? Эх, еллар, еллар! Үзләре сугышка катнашмаган кешеләр аңламаслар да инде бу елларны. Әнә нинди бит Светлана. Ә ул чакта Света, күп булса, бишектә яткандыр. Менә Светлана шикелле меңнәр, миллионнар тыныч үссеннәр, укысыннар, кеше булсыннар, аннары җаннары теләгәнчә эшләсеннәр дип сугыштылар бит алар. Дидаров күп тә үтмичә, яраланып, китеп барды бугай, Галимҗан Берлинны алгач та тиз генә илгә кайта алмады әле. Бары тик япон самурайларын җиңгәч кенә кайтты. Бу вакытта 1946 ел иде. Аннары тагын партия эше, район...

Иртән эшкә барганда, завод капкасыннан кергәч, Светлана Ивановнаны очратты. Ул ак берет кигән, кара манто. Кичәге кебек әсәрләнгән дә түгел, көлеп сөйләшә.

— Светлана Ивановна, кичә сез миңа үпкәләдегез бугай? — диде Галимҗан.

Бу сүзләрдән соң да Нилина дары кебек кабынмады, тик чырае гына ничектер сүрелеп китте.

— Күрәсең, сугышны башыннан кичергән кешеләрне без аңлап җиткермибездер,— диде ул, аяк астындагы карга карап.— Фронттагы дуслык хакы шундый зурдыр... Шулай да, белмим тагы, Галимҗан

Нигъмәтҗанович. Мин түзмәс идем. Бәлки сез...— Ул иреннәрен тешләде,— курка торгансыздыр.
— Нәрсәдән? Мин куркырга нигез күрмим шикелле.
— Иске дуслыкны югалтудан. Ул, сез әйтмешли, шундый кадерле дә, зур да булгач... Сез аның күләгәсен генә булса да сакларга телисездер. Ә без, яшьләр, Галимҗан Нигъмәтҗанович, сезгә, фронтовикларга, башкача карыйбыз бит. Сез фронтта явызлык белән ничек килешмәгән булсагыз, тынычта да шундый ук рыцарьлар булып каласыздыр. Әллә без алданабызмы?
Галимҗан, артык бер сүз дә әйтмичә, цехка кереп китте, Нилина идарәгә таба борылды. «Күләгәне сакларга телибез... Явызлык белән килешәбез... Их, яшьләр, яшьләр! Сүтелер, ертылыр дип тә уйламыйсыз. Шулай ук без шундый хәлгә калдыкмыни?» Галимҗан, очраган кешеләр белән исәнләшә-исәнләшә, конторага узды, аннары цехка чыкты.
Дидаров янына ул сәгать унберләрдә генә керде. Киң, якты тәрәзә, тыйнак кабинет, иркен өстәл. Дидаров урыныннан торды, елмаеп күреште, урындык тәкъдим итте, аннары секретаршасын чакырып:
— Наташенька, безгә чәй кертсеннәр әле,— диде.— Кайнаррагын, куесын һәм лимонлысын.
Дидаров урынына утырды, ике кулын кушырып өстәлгә куйды. Гадәттәгечә исәнлек-саулык сораштты. Ул арада чәй дә китерделәр.
— Бераз суырылган кебек күренәсең, Галимҗан. Әллә тагын йөрәкме? Рәхим ит, чәйдән җитеш. Лимонын салыгыз. Хәзер кибетләрдә лимон күренми бугай.
— Әйе, күренми,— диде Галимҗан чәен болгата-болгата.— Лимон тәмлесен тәмле дә, чәйнең төсен ала.
Дидаров көлеп җибәрде.
— Ике яхшы бергә килми инде. Лимонның тәме кыйммәтме, чәйнең төсе кыйммәтме? Я, ярый, моны фәлсәфүн иптәшләргә калдырыйк. Безнең генә баш мона җитмәс. Сүзем бар дип әйткән идем бит сиңа. Әйдә, дус, бергәләп эшлик. Хәзер, үзең беләсең, техник прогресс заманы, элеккечә ура кычкырып кына эш чыкмый. Замана, замана...
— Мин бик үк төшенмәдем, Исрафил. Без болай да бергә эшлибез ич. Син ни әйтмәкче идең?
— Миңа, Галимҗан, урынбасар кирәк. Мин сине күптәннән беләм. Син инде яхшы инженер булып җитештең.
— Рәхмәт, Исрафил. Ләкин миңа цехта калырга рөхсәт ит инде. Сәламәтлегем дә артык шәптән түгел. Яшем дә.
— Шулай да, Галимҗан, уйла әле. Цехта сәламәтлек күбрәк кирәк бит. Мин сиңа начар урын тәкъдим итмим.
— Уйлавын уйлармын да... риза булмам шикелле.
Дидаров яныннан чыккач, Галимҗан бик озак тәмәке тартты.

8

Менә шәһәрнең шул төшендә туктасаң, гаҗәп бер нәрсә күрәсең: ишелеп агып килгән мәһабәт таш ташкын кинәт туктый кебек. Очып барган бик зур кошларга охшаган уннарча челтәрле тимер краннар, әйтерсең, бер урында йөзәләр. Инде караңгы төшеп килә, ләкин монда шәһәр яп-якты, көчле прожекторлар яна. Ташкын шәһәр читеннән үзәккә таба юнәлә. Ике-өч ай гына элек монда бер катлы агач өйләр, тәрәзәләрен балкытып, урамга тыныч кына карап утыралар иде әле. Хәзер йөз квартиралы зур таш йортның нигезен салып бетергәннәр, егерме-утыз адымдагы бәләкәй агач йортның коймалары, рәшәткәләре алынган, кешеләре күчерелгән, ишекләре киң итеп ачып куелган. Йорт-

ны, боз кебек агып китмәсен өчен дигәндәй, каршыдагы карт тирәккә бәйләп куйганнар. Күп булса бер атнадан аның эзе дә калмас инде, тик карт тирәк кенә йортның элекке урынын күрсәтсә күрсәтер. Гаҗәп, гомер иткән йортлар күчәләр, бетәләр, ә алар белән бергә гомер иткән агачлар кала. Тагын берничә айдан кешеләр бу урыннарны танымаслар да инде, бу карт тирәк бу мәһабәт таш йорт каршында гомер үсеп тора кебек тоелыр. Ихтимал, моннан чәчәк газоннары үтәр, ихтимал, карт тирәк төбенә урындыклар куярлар, таш ташкын үзәккә таба шактый киткән булыр, тирәк яныннан киләчәккә омтылган хәзерге тормыш кына шаулап узар. Тик кайчак, кичке кояш баеганда яки таң сызылган минутларда, шул тирәк янына кем дә булса килеп туктаса, ул үткәннәрне искә төшерер кебек.

Гәүһәр бу тирәләрдән еш уза һәм шәһәрнең күз алдында үзгәреп баруына шатланып бетә алмый иде. Бүген төзелешләрнең инде таныш йорт янына ук килеп җитүен күргәч, троллейбустан төште. И-и-и! Саубуллашырга туктаган икән лә, тагын бераз кичексә, үкенеп бетә алмас иде. Кайчандыр, Гәүһәр әле бала чакта, бу йортка еш килеп, атналар буе торып китә иде. Монда аның әнисе белән бертуган апасы тора иде. Апасы да, җизнәсе дә олылар. Аларның ике ир балалары булган, икесе дә армиягә киткәннәр дә анда гомергә төпләнеп калганнар, балаларының балалары гына ел саен әбиләренә кунакка кайталар иде. Ул чакта балаларның берсенә җиде, икенчесенә алты, өченчесенә биш яшьләр булгандыр.

Өчме-дүртме елдан соң бу йөрүләр тәмам тукталды. Гәүһәрнең әнисенең әйтүенә караганда, картлар икесе дә гүр иясе булганнар, йортны малайлары саткан. Гәүһәр күп еллардан соң бу йортны эзләп тапмаган да булыр иде, әлеге шул карт тирәк ярдәм итте. Өй каршындагы рәшәткәле бакчада үскән бу тирәк Гәүһәрнең хәтерендә бик утырып калган. Ә аннары тагы күршедә Гәүһәрне бик яхшы хәтерләгән бер карчык бар иде.

Гәүһәр йорт янына якынрак килде, алынган яки каерылып ташланган рәшәткәләргә, коймаларга, ачык ишекләргә, пыялалары ватылган тәрәзәләргә карап торды. Нигәдер йөрәге әрнеп китте. Кире кайтмас яшьлегең хатирәләре белән очрашкач, шулайдыр, күздән яшь чыга торгандыр. Нәкъ бала чагына кайткандай, курка-курка өй эченә керде, обойлары ерткаланып беткән бүлмәләрдә йөрде. Җимерек, ватык, ташландык әйберләр идәндә аунап ята. Әнә тузанланып беткән иске китаплар — дәреслекләр. Күрәсең, монда балалы кешеләр торганнардыр. Гәүһәр китапларны кулына берәм-берәм алып карады. Берсе хәтта гарәп хәрефләре белән басылган. Монысы инде дәреслек түгелдер.

Гәүһәр үзе йоклаган бәләкәй бүлмәгә үтте. Кулын күкрәгенә куеп туктап калды. Бу бүлмәнең дә обойлары купкан. Әнә бер урында ачык бизәкле обой кисәге күренә. Гәүһәр аны шунда ук танып ала: ул торган чактагы обой ич! Хәзер мондый обойлар да юк инде. Гәүһәр якынрак килде, күзләре яшьле, йөзе моңсу. Тиз генә артына борылып карады, шаулашып, кыска ыштанлы малайлар йөгереп килә кебек. Юк, беркем дә юк, күнел алдануы гына. Әнә җил обойларны әзрәк кыштырдата, шул тавышны ишетеп артына борылгандыр инде Гәүһәр.

Залга узды. Монда идәнне дә каерып алганнар инде. Әнә стена буенда, ком эчендә, бармак буе гына курчак. Яшел курчак! Бу бала чакта әбисе алып биргән курчак. Тагарагы да бар иде. Соңыннан тагарагы калды, ә курчагы... югалды. Әй елады, әй елады Гәүһәр. Апалары аңа яңа курчак сатып алдылар, ә ул юк, бу түгел, түгел, дип өзгәләнде. Күрәсең, ярыктан идән астына тәгәрәгән булгандыр.

Гәүһәр курчакны күтәрде дә күкрәгенә кысты.

Өйдән Гәүһәр беркадәр боегыбрык чыкты, ләкин шул ук вакытта кайдадыр күңел тирәнлегендә яшерен шатлык та бар иде. Бала чагына

кайтып килде бит ул. Баштан әллә ниләр үткән, киләчәктә дә үтәселәре бар әле, ә балачак һаман якты бер нур эчендә. Кешенсн аннан да кадерле чагы юк, мөмкин булса, аннан бер адым да китмәс иде. Әнә шул яшел курчакны чүпрәккә төреп күкрәккә кысасы да чабасы иде. Сина бит дөньяның бер нәрсәсе дә кирәкми, бер телем тоз сипкән икмәген булса, шул җитмәгәнме? Үз алдыңа җырлый-җырлый яшел курчагыңны йоклатсаң, әй рәхәт була, әй күңелле була сиңа.

Шул башы да, ахыры да булмаган уйлар эчендә урам буйлап барганда, Гәүһәр, инде онытыла башлаган бер тавыш белән үзенә дәшкәнне ишетеп, шып туктады. Бер дә ялгышмаган икән, бу аның күптәнге танышы — инженер-төзүче Билал Шәнгәрәев икән.

— О, Бил! — дип дәште Гәүһәр аңа, кайчандыр студент чагындагыча итеп.— Кайдан син? Менә очрашу ичмасам!

Алар әле Гәүһәр кыз чакта танышканнар иде. Төзүчеләр институтында укучы берничә студент белән Арча педучилищесында укучы берничә студентка Кама буендагы ял йортларының берсендә очраштылар. Көндезләрен волейбол уйнап, кичләрен Каманың биек ярында утырып, шау-гөр килеп вакытларын уздырдылар. Сөйләнмәгән сүз дә калмагандыр инде, җырланмаган җыр да.

Билал Шәнгәрәев — күзлекле, озын буйлы егет. Карап торырга аңарда нииндидер интеллигентлык сыйфатлары бар иде кебек. Теле дә бик шома, бер вакытта да сүз эзләп аптырамас. Кием-салымы, билгеле, студентларча гына. Аннары, җәйнең эссе вакытлары булганга, киемнең әллә ни кирәге дә юк. Иртән дә, кичен дә майкадан, күлмәктән генә йөрделәр. Шәнгәрәев яхшы гына рәсем ясый иде. Шул нигездә Гәүһәр белән дә бик тиз танышып, бик тиз дуслашып киттеләр. Билал Гәүһәрнең рәсемнәрен һәрвакыт мактады, сездән һәйбәт архитектор чыгар иде дип ничә әйтте. Гәүһәр, билгеле, моңардан көлде генә. И аңамы соң архитектор булырга! Педучилищены яхшы гына тәмамласа, анысына да мең шөкер итәр иде әле.

Гәүһәр егетләрнең муеннарына асылына торган кыз түгел иде. Дус кызлары Билалны мактасалар да, Гәүһәрнең аңа исе китмәде. Ул арада китәр вакытлар да килеп җитте. Дөрес, яшьләрдә адрес алмашу бар нәрсә, Гәүһәр белән Билал да адресларын алмаштылар. Хәтта бер-ике тапкыр бәйрәмнәрдә Билал Гәүһәрләрнең Арчадагы тулай торагына да килеп китте. Аннары ул байтак еллар буе югалып торды. Гәүһәр аны бөтенләй онытты. Дөрес, Гәүһәрнең уйланыр чаклары иде. Әлек әтисе, аннары әнисе үлеп китте. Кыз бер үзе калды. Шуның өстенә тагы, училищены тәмамлау елы. Билгеле, аны кая булса да укытучы итеп җибәрерләр. Ләкин ул чакта Гәүһәр тормышны бөтенләй белми иде, таяныр кешесе дә булмагач, нишләр инде ул? Училищедагы кызлар әкренләп кияүгә чыга торалар иде. Бер дә көтмәгәндә генә Гәүһәрнең дә бәхет капусы ачылды, ул Җәгъфәрне очратты, яратып китте һәм аңа кияүгә чыгып та куйды. Аның күп уйларга вакыты, бигрәк тә киңәшергә туган-тумачасы юк иде. Җәгъфәр аның барлык диярлек мәшәкатьләрен үз өстенә алды, эшкә дә урнаштырды, бик әйбәт итеп киендерде. Гәүһәр үзен бәхетле итеп сизде.

Менә шул елны, көзгә таба, Билал Шәнгәрәев тә Казанга килеп чыкты. Ул, Гәүһәрнең кияүгә чыгуын белгәч, бик күңелсезләнде, Гәүһәр белән очрашып тормышлары турында ике-өч минут сөйләште дә икенче көнне үк тора торган шәһәре — Ленинградка китеп барды. Шуннан берме-икеме ел күренми торды да тагын Казанга килеп чыкты. Хәзер инде Билал Шәнгәрәев бик нык үзгәргән, өс-башы шәп, үз-үзен тотышы югары интеллигентларча төс алган. «Өйләнгән, хатын-кыз кулыннан башка болай шомармас», дип уйлады Гәүһәр аны беренче күргәннән соң ук. Ләкин ул ялгышты. Билал әле дә булса ялгыз икән. Бу юлы инде ул артык яшереп тә тормады, туры килү белән үк Гәүһәргә

үзенең мәхәббәтен белдерде, синнән башка тора алмыйм, синнән башка тормыш миңа тормыш түгел, диде. Гәүһәр моны бөтенләй көтмәгән иде, әллә аптырап, әллә исе китеп калды. Аннары, акылын җыеп, тирән кичереш белән:

— Билал, син акылдан яздыңмы әллә ир хатынына шундый сүзләр әйтергә? Әгәр мин сине белмәсәм, яңагыңа сугар идем. Гомердә иремә хыянәт итәсем юк,— диде.

Шуннан соң да Билал өметен өзмәде, ел саен Казанга килә, ел саен үзенең хисләрен сөйли башлады. «Ахырысы, акылга бераз җиңеләйгәндер. Югыйсә безнең арада нәрсә булган болай тилererлек», дип уйлады Гәүһәр. Билал аны аз гына да кызыксындырмый, араларында да гади танышлыктан башка бер ни дә юк. Ихтимал, башта ук аңа өметенең бөтен канатларын йолкырлык итеп, каты итеп әйтергә кирәк булгандыр. Гәүһәр кызганды. Хәер, ике уйларлык бер нәрсә дә ычкындырмады бугай, киресенчә, йомшак булса да аңлаганга аңларлык итеп әйтте шикелле. Ә Билал, гүя бер нәрсә дә төшенмәгән кебек: «Юк, мин Җәгъфәр белән сөйләшәм, ул мине тыңлар», диде. Гәүһәр бик курыкты, ачуы килеп Шәнгәрәевкә бик әрнүле сүзләр әйтте. «Яңадан синең белән сөйләшәчәк тә түгелмен», дип кырт кисте. Ләкин үзе көн саен бәла көтте. Менә бүген, менә иртәгә Билал белән Җәгъфәр сөйләшер кебек тоелды. Үзе, Шәнгәрәев берничә тапкыр аның юлына чыкса да, аның яныннан сүз катмыйча үтте. Шуннан соң Шәнгәрәев юкка чыгып, бер ел чамасы күренми торды. Гәүһәр акрен-акрен тынычланды. Җәгъфәр ул-бу тавыш кузгатмады, ахрысы, Билал аның белән бөтенләй сөйләшмәгәндер. Менә хәзер аны көтмәгәндә урамда очраткач, Гәүһәр аның элекке дуамаллыгы беткәндер, Билал инде өйләнгәндер, дип ачык йөз белән аңа дәште. Билал эшләпәсен салып аның белән бик җылы күреште дә:

— Мин кул бирмәссез дип уйлаган идем,— диде.— Күрәм, сез үз шәһәрегезгә тәмам гашыйк, башка калалар турында уйлап та карамыйсыз.

— Һәркемгә үзенең оясыннан яхшы җир юк кебек тоела бит.

— Анысы шулай, ләкин Ленинград үзенең матурлыгы ягыннан беренче пайтәхет бит. Анда торуны күпләр мечта диләр.

Гәүһәр көлеп җибәрде.

— Безнең бер укытучыбыз: «Парижда тору — мечта» дип сөйли. Ләкин ул инде китаплардан укып әйтә торгандыр, чөнки үзенең Казаннан чыкканы да юк бугай.

— Париж... Булганым бар анда, матур шәһәр, бигрәк тә акчалы кешеләргә. Ләкин Ленинградны мин аңа гомердә алмаштырмас идем. Ленинград кебек күңелне ашкындыра, дәрт бирә, бөек итә торган икенче бер шәһәр дөньяда юк. Ләкин мин пенсионер түгел, Гәүһәр, тыныч почмак минем өчен мәңгелек йорт була алмый. Тик бер генә нәрсә бар: тар җир уйларны да, дөньяны да тарайта... Мин Казанның бик күп мәктәпләрен карадым. Яңалары да бар, искеләре дә җитәрлек әле. Сезнең мәктәп тә, болай яңа булса да, иске стильдә салынган. Менә Ленинградта бөтенләй яңа мәктәпләр бар. Аларда эшләү, чыннан да, хыял. Мин укытучы түгел, ләкин бер генә сәгатькә булса да ул мәктәпләргә керер идем.

— Мин дә андый мәктәпләр турында хыялланам. Гомумән, укытучылар ул яктан фантазиягә ярлы түгел. Ләкин юрганыңа карап аягыңны сузасың.

Билал тыштан бик сабыр сөйләшсә дә, эчтән үзен бик киеренке тотканлыгы әллә кайдан сизелә иде. Бу тиле үзенең элекке уйларын ташламаган, ахрысы. Гәүһәр яхшы сәгатьтә киту ягын карый башлады. Ул инде Билалга ачык чырай күрсәтүенә дә үкенә иде. Нәкъ шуны

сизгэн кебек, Билал кинэт хислэнеп сөйлэргэ тотынды (дөрес, тыштан ул әле үзен нык тота иде).

— Гәүһәр, әгәр теләсәгез мин сезне Ленинградның шундый ук мәктәбенә урнаштыра алам... һич югында, мин сезгә яңа мәктәп салып бирәчәкмен. Безнең оешма мәктәпләр дә төзи.

— Юк, рәхмәт,— диде Гәүһәр, коры гына.— Бердән, мин татарча укытам, сездә укыту миңа кыен булыр. Ләкин бу... мәсьәләнең бер ягы гына. Мин сезнең тел төбегезне аңлыйм. Мин инде сиңа бер әйткән идем. Аңларсың дип уйлаган идем. Күрәсең... Мин ир хатыны, Билал, аңа хыянәт итәргә уйламыйм. Шуңа күрә бу турыда гомумән бетерик. Ел саен миңа агу эчермәгез.

Билал авыр сулый башлады.

— Гәүһәр ханым, сез минем турыда да бер уйлагыз әле. Мин тилелектән яки башка бер сәбәптәнме әллә? Мин бит сезне...

— Кирәкми, Билал. Югыйсә, хәзер китәм.

— Юк, Гәүһәр ханым, юк. Ленинградта торып, Париж, Лондоннарда йөреп сезнең кебек хатын-кызны очратканым булмады. Ихтимал, мин сукырмындыр, бернәрсә дә күрми торганмындыр, бәхәсләшмим, ләкин мин сезгә гашыйк! Башка миңа беркем дә кирәкми. Мин дәрвиш хәленә калырга риза. Мин ханжа түгел!

— Билал, сез әллә нәрсәләр сөйлисез. Тагын бер мәртәбә әйтәм: мин ир хатыны, аңа хыянәт итүне башыма китермим. Сез яхшы бер кызны табыгыз да аңа өйләнегез. Болай мәсхәрә булып йөрмәгез. Кыз кеше сезгә үзенең барлык яхшы тойгыларын, барлык мәхәббәтен, йөрәген, сөюен бирер. Хатыннар сезгә андый бәхетне тулы килеш бервакытта да бирә алмаслар. Чөнки алар инде... аны туккән, югалткан. Хушыгыз, яңадан минем юлыма чыкмагыз, бу файдасыз.

Гәүһәр китеп барды, сумкасындагы яшел курчакны алып, тагын бер тапкыр күкрәгенә кысты. Ул артына борылмады, Билалны күрмәде. Билал исә юл чатына басып, Гәүһәр күздән югалганчы, аның артыннан карап торды. Ул Гәүһәргә кычкыра да, ачулана да, үпкәли дә алмый иде. Нindидер бер көч белән Гәүһәр аның өстеннән хакимлек итә, Билалны үзенә ихтыярсыз буйсындыра. Каршы торырга һичбер әмәл юк кебек. Алай гына да түгел, моны Билал бөтенләй кирәк санамый, бу — нindидер гайри табигый бер эш кебек.

Гәүһәр инде күздән югалды. Билал, күзләрен йомып, кулы белән йөзен сыпырды. Аннары һичбер максатсыз-нисез юл буйлап атлап китте. Әнә ул ап-ачык итеп Гәүһәрне күрә. Биек яр башында кечке Камага карап утыралар, имеш. Гәүһәр рәсем ясаган, Билал шул рәсемне мактый, ике йөзләләнеп түгел, чын күңелдән мактый; рәсем, Билал уенча, бик яхшы. Гәүһәрнең күзләре очкынланып китәләр... Ник шул чакта Билал үзенең мәхәббәтен әйтмәде икән? Ул чакта алар икесе дә яшьләр, икесе дә тормышта бер нәрсә белән дә бәйләнмәгән иделәр. Дөрес, Билалның ул чакта кайнар йөрәгеннән башка бер нәрсәсе дә юк, ул бары тик студент һәм Гәүһәргә яхшы тормыш бүләк итәргә хыяллана гына иде. Андый нәрсә исә укып бетермичә мөмкин түгел. Һәм Билал, көн саен тел очында йөргән сүзләрен Гәүһәргә әйтмичә, институтны тәмамлау көннәрен көтте. Ә ул арада... Юк, Билал моңа ышана алмый, ничек инде Гәүһәр йөрәген башкага бирсен. Бәлки ул көткән-көткәндер дә... Билал үзе гаепле, башка беркем дә түгел. Ә хәзер инде Гәүһәр әзгә салынган тормышын бозарга курка. Күңеле яратмаса да, иренә турылыклы булып кала. Яңа Татьяна!

Караңгы төшә, урамнарда утлар кабына. Кешеләр көлешәләр, каядыр ашыгалар, кемнәрнедер каршы алалар, кемнәрнедер озаталар. Халык белән шыгрым тулы трамвайлар, троллейбуслар, автобуслар, таксилар үтә. Ә Билал Шәнгәрәев, адашкан кеше шикелле, бер аптырап алга бара, бер кире борыла. Нишләсен соң ул?!

## 9

Гәүһәр укытучылар бүлмәсенә кергәндә, тәрәзәдән кояш көлеп карый иде. Күзләре яктыга камашып, ул башын иде. Кемдер, диванга утырган җиреннән, аягы белән иптәшенең аягына әкрен генә кагылды. Иптәше шунда ук башын күтәрде, Гәүһәр дә карады. Фая Идрисҗанова кинәт кып-кызыл булды. Гәүһәр берни әйтмәде, журналын куяр өчен шүрлеккә борылды. Әйтергә сүзе дә юк иде аның, ул бер нәрсә дә ишетмәде. Инде соңыннан, урам буйлап барганда, минем турымда сөйлиләр иде бугай, дип уйлады. Ул Фая Идрисҗанованың да үзен яратмавын белә иде. Хәер, Гәүһәр дә аны өнәп бетерми. Дөрес, мәктәптә, әдәп саклап, Фаяның исемен телгә алмый, гомумән аңа мөнәсәбәте барлыгын күрсәтми, ләкин бу тыштан гына шулай бит. Фая Идрисҗанованың Дидаровка һәм Кәримовка балдыз булуын белгәч, аңа бөтенләй читсенеп карый башлады. Алай гына түгел, ул алардан ниндидер явызлык көтте. Ул инде Фаяның тырнак астыннан кер эзләвен, туры килгәндә исемен чәйнәвен ишеткән иде. Әле менә Билал Шәнгәрәев белән Гәүһәр арасында нәрсәдер бар дип сөйли башлаган икән. Гәүһәрнең моңа бик ачуы килде. Ул моны Фаягөлнең үзенә дә әйтергә уйлаган иде, аннары бу уеннан кире кайтты, бу сүзләрне йөрәгенә якын алуын күрсәтәсе килмәде. Шунысына бик сөенде: иренә ул Билал Шәнгәрәевнең юләрләнеп йөрүләрен сөйләгән иде. Җәгъфәрнең моңа кәефе аз гына да кырылмады, Бальзак хатыннарын эзли торгандыр, диде. Гәүһәр, ачылып китеп, Билалның студент чакта ук көнбатышка бик нык иярүен, исем-фамилиясен кыскартып, Бил Шан дип йөрүләрен сөйләде. «Монысы инде яшьлек юләрлеге яки шагыйрьләргә иярүе булгандыр», диде Җәгъфәр һәм бу турыда артык сүз озайтмады. Гәүһәр бу сөйләшүдән бик канәгать булып калды. Менә бит ул чын ир нинди була, төрле имеш-мимешләргә борылып та карамый. Хатын-кыз булса, әллә нишләп беткән булыр иде. Юк, ирләр, ни әйтсәң дә, ир инде, шуңа күрә алар янында сулыш алуы да җиңелрәк. Гәүһәр ире белән булган бер зур сөйләшүне хәтерли. Дөрес, бу сөйләшү ир белән хатын мөнәсәбәте турында бармады, әмма үпкәләшер өчен бөтен нигез бар иде шикелле. Көннәрдән бер көнне, өйләнешүләренең икенчеме, өченчеме елында, сүздән сүз чыгып, Гәүһәр шактый кызып алды.

— Җәгъфәр,— диде,— син бит элекке комсомол работнигы. Институтта дүрт ел комсорг булдым, дисең. Соң, биш-алты елда синең комсомол уты бөтенләй сүндемени? Син бит җәмәгать эшенә дә хәзер бөтенләй диярлек катнашмыйсың. Бу бит коточкыч, тамырдан кору.

Җәгъфәр бу һөҗүмне үтә салкын кан белән кире кайтарды.

— Иң элек мин укыйм, Гәүһәр, моны онытма. Кандидатскийны язу, үзең беләсең, җиңел түгел. Аннары еллар туктамый, тормыш туктамый, ә кеше? Ул да үзгәрә, үсә, камилләшә, кичәге үлчәүләр инде аңа ярамый. Диалектика.

Гәүһәр һаман кыза гына барды:

— Үссә, камилләшсә, сүз әйтер идемме, Җәгъфәр?! Син бит шул «диалектика» артына яшеренәсең, әллә нинди купшы сүзләр әйтәсең. Чын, чын. Яхшылап үзеңә бер кара әле. Синең белемең үссә дә, үзең үсмисең, артка тәгәрисең, мещанлык базына шуасың, үзең шуны тоймыйсың. Син бер төрле сөйлисең, икенче төрле эшлисең. Тукта, бүлдермә, көлмә дә. Син эгоистлыкка чума барасың, ә бу безнең тормышта, беләсең килсә, үз үзеңнән качу дигән сүз. Бу, белмим... бу мәртәтлек!..

Менә шушы аерата кызулык белән әйтелгән, билгеле инде, уйлап та бетермәгән сүзләргә каршы да Җәгъфәр күтәрелеп бәрелмәде, аз гына көлемсерәп, шул ук вакытта үзенең дәрәҗәсен тирән саклап:

— Аз гына саграк кирәк, Гәүһәр,— диде.— Ачу килсә, акыл китә ди. Ачулы минутларда бер-береңә ниләр әйтмәссең.

Әлбәттә, соңыннан Гәүһәр үкенде дә, Җәгъфәрдән гафу да үтенде. Бу юлы да Җәгъфәр тантана итмәде, менә әйткән идем бит дип үзен-үзе югары күтәрмәде, көлемсерәде генә.

Ир белән хатын бер-берсен яхшы яклары белән тулыландырырга тиеш, диләр. Күрәсең, бу фикер дөрестер. Кызурак канлы Гәүһәр үзенең кимчелекләрен белә, Җәгъфәрдән бик күп нәрсәгә өйрәнүен дә яшерми. Шулай булмаса, семья тормышының мәгънәсе дә калмас иде. Аннары шунысы да бар бит: семьяда ир кеше, ни әйтсәң дә, баш кеше, төп, авыр йөкне ул тарта, шулай булгач, аның сүзе дә аяк астына салып тапталмаска тиеш, әгәр тапталса, бар да бетә, җимерелә бит. Гәүһәр, билгеле, моны аңлый, үзен бөтенләй тезгенсез итеп сизәргә теләми. Тезгенсезлек гармонияне боза, изге күргән семья тормышыннан бер нәрсә дә калдырмый.

Уйлана, кат-кат үлчи торгач, Гәүһәр Фаягөл Идрисҗанова турында иренә сөйләргә булды. Иртәме, соңмы ул барыбер ишетер, сөйләмәде, димәк, нәрсәдер бар, дип вәсвәсәгә бирелмәсен, үзең сөйләп биргәч, бөтенләй башка була ул.

Гәүһәр кайтып кергәндә өйдә беркем дә юк иде әле. Бүген соңрак кайтыр шул Җәгъфәр, бүген заводта аның лекциясе. Гәүһәр, пальтосын салып, көзге алдында чәчен төзәтте. Салкыннан битләре тәмам кызарган, нәкъ кыз чактагы төсле яна иде. Аңа ничектер рәхәт булып китте, күңелсез уйлары онытылды. Чын, менә биеп, тыпырдап узасы. Әллә рәсем ясарга керешергәме? Күптән инде Гәүһәр мольбертын кулына алганы юк, буяулары тәмам кибеп, корып беткәннәр. Юк, болары калып торсын, әнә тәрәзәдән кичке Казан күренә. И нинди матур, бихисап төтеннәр күтәрелә, зур таш йортлар белән янәшә бер, ике катлы йортлар, кояшта балкып яна торган тәрәзәләр, арырак — челтәрле краннар, урамда әллә нихәтле машиналар, җәяүлеләр.

Гәүһәр тынып калды. Күзләрен кыса төшеп, шул күренешкә карап тора башлады. Кәгазьгә төшерер алдыннан рәсемне күңелгә сеңдерергә кирәк бит, шунсыз кәгазьдә берни дә чыкмый.

Гәүһәр тынычлана башлады, аннары тәмам онытылды. Хәзер инде алдында ап-ак кәгазь һәм төтеннәре чыгып торган шәһәр күренеше генә бар. Тагын художник акылы, художник күзләре, художник йөрәге бар. Болар аерым-аерым да кебек, болар аерылгысыз бергә дә кушылганнар кебек. Бер сызык, ике, өч. Күзләр инде иң кирәклесенә тукталa, карандаш тоткан кул шуны кәгазьгә төшерә. Барысы да ничектер бик тиз эшләнә, гүя бер мәшәкать, бер уй, бер борчылу юк, өлгер генә. Югыйсә әнә буяулар сүнә, тоныклана. Гәүһәр бик ашыкты, карандашы гаҗәп тиз йөреде, карашы үткенләнгәннән үткенләнә барды. Хәзер гүя ара да калмады, Гәүһәр гүя табигать эчендә. Табигать аңа якын, аңлаешлы, үз, сүз кушсаң, сүзне дә төшенер шикелле.

Ниһаять, Гәүһәр эшеннән аерылды, бик җентекләп альбомына карады, әкрен генә елмайды, валлаһи, бик оста төшерелгән, нәкъ чын кебек, төтеннәре чыгып тора кебек, ә кары шундый күперенке, шундый йомшак, учыңа ал да атып җибәр. Гәүһәр үз-үзеннән шундый канәгатьлек сизде, гүя бик әһәмиятле эш эшләп ташлады. Хәлбуки, иртәгә үк ул бик күп кимчелекләр табар, таләпчәнсезлеге өчен үзен орышыр да, әмма бүген ул шат, канәгать, бүген аңа бүтән бер нәрсә дә кирәкми. Ихтимал, чын иҗат эше шушындыйдыр инде, кеше, беренче минутта булса да, үз эшенә үзе канәгатьләнмичә түзми торгандыр. Гәүһәр ише үзешчән художникларга бу аеруча кирәк, чөнки ул үзенең эшен күргәзмәләргә куймый, бүтәннәрнең фикерен барыбер ишетми. Үз алдына да сөенмәсә, аңа тагын ни кала?

Күз бәйләнә башлаган иде, Гәүһәр торып ут кабызды, әмма яңадан дәфтәренә карамады, альбомын шкаф башына куйды да, киемнәрен алмаштырып, өй эшләренә тотынды. Иртән калган савыт-сабаларын

яхшылап юды, аннары өстәл өсләрен сөртте, идәннәрен себерде, сервант, көзге, телевизор өсләренә тузан кунган, шуларны сыпырды, чәчәкләргә су бөркеде. Бала-чага булмагач, куйган әйбер урынында тора, бөтен җирдә тәртип. Шкаф, өстәл өсләрендәге вак-төяк әйберләр дә кузгалмаган. Бу яктан Җәгъфәр дә бик тәртипле, һичбер әйбергә тими, киресенчә, ялгыш этәрелгән әйберне дә үз урынына куя.

Сәгать сигезләрдә Җәгъфәр кайтты. Аның белән бергә Исрафил Дидаров та бар иде. Гәүһәр аның бу вакытта килеп чыгуына бик гаҗәпләнде. Дидаров, нәкъ шуны сизгән кебек, заводтан Җәгъфәрне үз машинасына утыртып алып кайтуын әйтте, ә монда килгәч, Җәгъфәр аны көчләп өйгә алып кергән. Моңа каршы инде Гәүһәр берни әйтмәде, әйдә, өстегезне салыгыз, диде.

Ашыгыч кулдан гына табын әзерләнеп, шәрабе дә килеп утыргач, Гәүһәр бер нәрсәне ачык сизде: ире дә, Исрафил да аның ирләр белән бергә өстәл артында утыруын яратып бетермиләр кебек. Гәүһәр башта тегесен-монысын сөйләштергәләп алар янында бераз утырды да, үзенең эчке сизенүенә тәмам ышангач, ниндидер бер сәбәп белән бөтенләй чыгып китте, берәү дә аны туктатмады, әзрәк утыр димәде, киресенчә, аның китүенә эчтән шатландылар гына кебек. Бәлки ул ялгыша торгандыр, бәлки хатын-кызга хас шикләнү генәдер? Нишләргә, нәрсәгә тотынырга да белмичә, хәлсезләнеп, икенче бүлмәдә урындыкка утырды, йөзен куллары белән каплады. Еламады, үксемәде, ләкин аңа бик авыр иде. Тизрәк Исрафилның китүен, ире белән аңлашуны көтте, бу бердәнбер чара иде. Әмма Исрафилның китәргә исәбе дә юк кебек, тугыз тулды, ун булды, ә алар шыпырт кына сөйләшәләр дә сөйләшәләр. Тавышына караганда, Җәгъфәр дә бераз исергән. Болай бер дә булганы юк иде, нәрсә бу? Әллә чыгып туктатыргамы? Гәүһәрнең дә аңа сөйлисе сүзе бар, болай булгач, кая инде...

— Шулай, Җәгъфәр дус, тормыш дигәнең хикмәтле нәрсә ул,— диде Дидаров, мыгырданып кына,— без әле күп нәрсәне белмибез. Кайчандыр минем хатыным да дипломлы укытучы иде. Мин аңа һәрвакыт әйтә торган идем: пожалысты, укыт, мәктәбеңдә, җыелышларда, киңәшмәләрдә, пожалысты, җаның күпме тели шул хәтле идейный укытучы бул, кирәк икән, пожалысты, хәтта речьләреңне хәзерләшергә могу, любой педагогический киңәшмәдә шартлатып укып чыгарга ярый. Только, пожалысты, өйдә укытучы булма. Булма и все. Өй — өй инде ул, яхшы кешеләр әйтмешли, тынычлык, ял, рәхәтлек урыны. Нигә эндәшми утырасың? Син тормышка туры кара, аның алдында сыгылып төшмә, да, да, кеше бул, гордый бул. Син бит ученый, и вәссәлам! Бот әйт, кеше кайчан булса бер генә тонда яши аламы? Юк, яши алмый, аңа, табигать законы буенча, төрлелек кирәк. Эштә көне буе аның үзен эт итеп сүгәләр, бугазына ябышып, давай, давай, диләр. Кабинетына кайта да ул үзе бүтәннәрне кыздыра башлый — давай, давай. Тыңлыйсыңмы? Тыңла, бу синең кебек укымышлы ир кешегә кирәк нәрсә, моны югары мәктәпләрдә өйрәтмиләр, моны тормышның үзеннән каерып алырга кирәк. И бөтен җирдә җор булырга кирәк, югыйсә хәзер муеныңны сындырасың. Аңладыңмы? То, то. Тәгәрмәч эчендә әйләнгән тиенне күргәнең бармы? Уйласаң, безнең тормышта кеше дә шулай. Ну,— Исрафил кулы белән өстәлгә сукты,— аның бөек акылы бар, ул тиен генә түгел. Эштә — ярамый, аныcын беләбез. Шуннан ул өйгә кайта. Монда инде ул — хуҗа, кечкенә генә патша... Да, да... Кешегә кайдадыр әйберләрне үз исемнәре белән атарга кирәк бит, бөтен җирдә китаптагыча гына булмый ул. Эштә ул ат — тарта да тарта, уйларга вакыты да калмый. Моңа каршы да килеп булмый, бу шулай куелган, закон. Шуңа күрә акыллы башлар, шәһәр квартирасы белән янәшә дача салган кебек, икенче дөнья төзиләр, шауламыйча, купертмичә, басым ясамыйча, конечно, төзиләр. И ул җайлы, матур була.

Картая барган саен бу бик кирәк. Хәзерге вакытта бу — заманга да бик туры килә, халыкның көнкүреше яхшыра бара... Син йоклыйсың бугай, ә мин сөйләп утырам тагы. Уян! Күтәр башыңны! Эх, җебегән. Ну, ну, үпкәләмә, дус күргәнгә генә...

Гәүһәр боларны ишетеп торды, гарьлегеннән кара көеп чыкты. Исерек булмаса, Исрафил да моны сөйләмәс, Җәгъфәр дә тыңламас иде. Исрафил шундый ике йөзле кеше микәнни? Ул бит баш инженер, зур бер заводның җитәкчесе, кешеләр аңа ышаналар, ихтимал, зарларын да сөйли торганнардыр, безнең тормышта бу бик табигый бит. Баш инженер — техник мәсьәләләр буенча гына түгел, кешелек мәсьәләләре буенча да авторитет. Йөзләгән, меңләгән кеше ничек аның эчке буш дөньясын күрмиләр икән? Әллә күреп тә... Шулай ук бу тормыш бик катлаулымы икәнни, аңа гади кешеләрнең башы җитмиме икәнни?

Гәүһәр торган җиреннән тукталып калды, әрләшү белән берни дә чыкмаячак. Ничек тә булса Җәгъфәрне Дидаров тәэсиреннән тартып алырга кирәк, югыйсә ул харап булачак. Гәүһәр аны бу кадәр йомшак дип белми иде, авызына карап, эндәшми тора бит, димәк, уенда әллә нәрсәләр бар. Юк, бу коточкыч, моңа юл куярга ярамый.

— Ну, Җәгъфәр, мин озак утырдым, башка да бераз китте, саласың да саласың... Кайтырга вакыт. Син мин сөйләгәннәр өчен үпкәләмә, аларны мин уйлап чыгармаган. Акылың булса, үзең төшенерсең. Ярый, сау бул.

Кунак киткәч, диванда җәелеп утырган, күлмәк якаларын ычкындырган, чәчен тузгыткан иренә карап, Гәүһәр, өстәл өстен җыештыра-җыештыра:

— Яратмыйм шул дустыңны,— диде.

Җәгъфәр каядыр почмакка карап тора иде, берни әйтмичә, гаҗәп дигән төсле, иңбашларын гына җыерды.

— Ярар, яратканнарын табарсың,— диде ул ахырда,— миңа ятарга кирәк.

— Хәзер җаям. Минем сиңа әйтәсе сүзем бар иде, Җәгъфәр. Син барыбер аны ишетерсең... Сөйләмәде бит дип миңа гаеп тагарсың.

Җәгъфәр сагаеп, башын бора төшеп хатынына карады.

— Мин, Җәгъфәр, сиңа... Фаягөл Идрисҗанова турында сөйләмәкче идем.

Җәгъфәр кызарды, ул кызмача булса да исерек түгел иде, сүзнең нәрсә турында барачагын яхшы аңлады.

— Белмим нигә, мин Фаягөлне яратмыйм, ул да мине...— диде Гәүһәр.— Безнең аның белән ачыктан-ачык талашканыбыз, сүз әйтешкәнебез юк, билгеле. Очрашканда бер-беребез янынннан башны чөеп үтәбез. Мин аңлыйм, бу укытучылар өчен гафу ителә торган нәрсә түгел. Бер көнне Шәриф Гыйльмановичка сөйләгәч, ул да шулай диде.

— Син директорга шуны сөйләдеңме?

— Сөйләмичә, Җәгъфәр. Ике укытучы арасында шундый хәл булсын да яшереп йөр, имеш. Моны барыбер беләләр ич.

— Директорның хатын-кыз гайбәтен тикшерергә вакыты бар ди.

— Бу — гайбәт кенә түгел, Җәгъфәр!

— Мин артыгын күрмим. Аннары мин... исерек тә. Ятыйк... Ул Фая мине аз гына да кызыксындырмый.

Гәүһәр урын җәюгә, Җәгъфәр чишенеп икенче ягына әйләнеп ятты да гырылдый башлады. Ләкин ул йокламый иде, күзләрен йомган булса да, рәхәт тынычлыкка тала алмады.

Гәүһәр утны сүндереп икенче бүлмәгә чыкты. Эченнән ул хәзер беркадәр тынычланган иде. Фаягөлгә булган чын мөнәсәбәтен күпме вакыт иренә әйтә алмый килде, инде хәзер барысы да артта калды. Җәгъфәр моннан нәтиҗә ясармы, юкмы, анысы аның үз эше, әмма Гәүһәр ачык әйтте, Фаягөлне яратмыйм, диде. Ник яратмый? Моны-

сын Җагъфәр белергә тиеш. Шуна күрә тизрәк ятарга ашыкты түгелме?

Фаягөлнең бервакытта да аларның бусагасын атлап кергәне юк, шул ук вакытта ул көн саен диярлек тавыш-тынсыз бирелә йөри кебек. Ярый, ул Гәүһәрнең уенда гына булса, әгәр Җагъфәрнең күңеленә дә чыкмаслык булып кереп утырса? Әллә ничек кенә бу тормыш, Казанда гына йөз меңнәрчә хатын-кыз бар, шуларның тик берсеннән — Фаягөлдән генә Гәүһәр көнләшә, үлеп көнләшә. Нәрсә бу? Хатын кыз күңелендә шундый яшерен бер сиземләү бармы яки бу авыру бер тилелекме? Ахыры, шулайдыр, тилелектер. Ул ирен бик ярата торгандыр, аны югалтудан коты оча торгандыр. Әлек бу тойгы юк иде бит, Гәүһәр тыныч яшәде, ирен дә өзелеп яратты. Соңгы бер-ике ел эчендә генә бу уйлар әллә кайдан чоңгылдан күтәрелде, хәзер төн йокыларын качырып, газаплый. Хәтта шуңа барып житте, вакыт-вакыт Гәүһәрнең ирен бөтенләй куып җибәрәсе килә, аннары бу коточкыч уеннан куркып, иренең күкрәгенә капланып, мин сине ятларга бирмим, бирмим, дип кычкырып елыйсы, кемнәр беләндер канга батып сугышасы килә. Сабый баланың юрганын рәтләгән кебек, иренең юрганын рәтли, аннары иренең җылы аркасына башын куеп тынып кала. «Син минем бер генәм, мин сине беркемгә дә бирмим», дип тавышсыз гына пышылдый ул һәм әкрен генә йокыга тала.

## 10

Кышкы каникуллар алдыннан Гәүһәрнең бөтен теләге балаларның өлгерешен тигезләү иде. Утыз өче яхшы укый, борчылырга урын юк. Ә менә ике малай — Дамир белән Шәүкәт хәзердән үк Гәүһәрне уйландыра. Үткән ел игътибар итмәдеме, әллә, төзәлер әле, вакыт бар, дип киләчәккә өмет багладымы, алар класстан класска ярыйсы җиңел күчтеләр. Быел ел башыннан ук икесе дә аксый. Уку елы башында Гәүһәр әле артык хафаланмады, икесен дә каты кисәтте, өстәмә дәресләр бирде, тактага ешрак чыгарды, ата-аналарын чакырып сөйләште. Әмма көннәр үтте, Гәүһәр балаларның алга китешен күрмәде. Шуннан ул бер нәрсәне ачык төшенде: бу балаларга үгет тә, нәсихәт тә керми, алар белән аерым-аерым шөгыльләнергә кирәк. Тыштан караганда гына балаларның икесенең дә кимчелеге бер төсле сыман, хәлбуки, алар үзләре икесе ике төрле. Дамир син сөйләгәннәрне бик тиз төшенә, ләкин күзләре гел урамда, өстендә тормасаң, дәресләрен бар дип тә белми. Шәүкәт бик тырышкан була, хәтта укытучыдан бик курка, үзе бер нәрсә дә аңламый, сөйләгәннәрне шунда ук оныта. Кайчагында китабына сәгатьләр буе карап тора, сорасаң, берни белми.

Гәүһәр балаларның өйләренә дә барды, ата-аналары белән дә иплән сөйләште, аларны балага бергәләп «ачкыч» табарга чакырды. Дамирның әтисе, кызып китеп, баланы шунда ук «акылга утыртырга» сикереп торган иде, Гәүһәр аны тотып калды.

— Зинһар, балага кул тидерә күрмәгез, ул чагында без аның күнелен укудан бөтенләй биздерәбез. Сез аңа яхшы сүз белән тәэсир итегез, эшләгән эшен һәрвакыт үзегез тикшерегез. Ихтимал, ул урам тәэсиренә бирелгәндер. Кемнәр белән дус булуына аеруча игътибар итегез. Әлбәттә, әнисе белән бер кулга булыгыз. Балага моның әһәмияте бик зур. Сез моны мин әйтмәсәм дә беләсез.

Шәүкәтләрнең өеннән Гәүһәр авыр тойгы белән чыкты. Дамирны ата-анасы ярдәме белән төзәтергә мөмкин әле. Аңа игътибарлы булу, чит тәэсирдән тартып алу — җитеп торыр. Ә менә Шәүкәт... Ул бозылмаган, чит тәэсиргә дә бирелмәгән, аның психикасын имгәткәннәр, ул ниндидер шок хәлендә. Мәктәптән өенә кайткач, беркая чыкмыйча, сәгатьләр буе китабына төртелеп утыра икән. Былтыр бу ничектер күзгә

артык бәрелмәде, әллә Гәүһәрнең игътибары җитеп бетмәдеме? Шулайдыр, ул балага илтифатсыз карагандыр, күп нәрсәне без эш узгач кына аңлыйбыз шул. Шәүкәтнең әтисе «юклыгын», әнисе ялгызак икәнен Гәүһәр элек тә белә иде. Алар ниндидер бер подвалда торганнар, малай көннәрен бер үзе үткәргән, аңа игътибар да итмәгәннәр. Җаны булгач, үскән шунда. Соңыннан аларга бер бүлмә биргәннәр, ләкин ана һаман ялгыз, ахрысы, ул шулай гомер буена калыр да. Шәүкәтнең әтисе кем булгандыр, әнисе бу турыда Гәүһәргә дә, күршеләренә дә сөйләмәде, бары тик: «Зинһар, йөрәгемә ут салмагыз», диде. Шәүкәт, бала булгач, елагандыр да, сыкрагандыр да, чирләгәндер дә. Күрәсең, әнисе аны кечкенәдән үк бик каты кыерсыткан, баланың, әйтерсең, җилекләрен суырып алганнар. Әнисе шуңа канәгать кебек, әллә фаҗигане аңламыймы икән? Гәүһәр килеп йөри башлагач, бик турсайган булды, соңыннан күрмәмешкә салынды. Гәүһәр баланы урамга алып чыккаласа да, бала һәрвакыт куркып әнисенә карый иде.

— Нәрсә бәбәкләреңне мөлтәйтәсең, апаң алып чыга икән, чык. Аңа синең өчен акча түлиләрдер,— ди иде ана чәпчеп.

Билгеле, бу хәтер калдыргыч сүзләргә каршы бик каты әйтергә дә мөмкин иде, малайның әнисе шуны тели дә иде бугай, ләкин Гәүһәр эндәшмәде, баланы тизрәк урамга алып чыкты, әмма Шәүкәт беркем белән дә уйнамады. Укытучы аны башка малайлар белән таныштырды, уйнарга, чабарга кушты. Бала урыныннан кузгалмады. Гәүһәр дә чигенмәде, ире белән сүзгә килеп булса да, бөтен буш вакытын шул балага багышлады һәм бервакыт аның кычкырып көлүен ишеткәч, эченнән иллә сөенеп куйды.

Кышкы каникул алдыннан Дамир дәрестән ярыйсы өлгерә башлады. Гәүһәр класс җыелышларында да, Дамирларның өйләренә барганда да шатлыгын әйтте, ләкин игътибарны йомшартырга ярамый. Шәүкәтнең исә дәрестән әллә ни өлгереше юк, тик үз-үзен тотышында гына беркадәр уянуга охшаган нәрсә сизелә кебек. Әнисе мәктәп җыелышларына йөрмәгәнгә, Гәүһәр аның белән өендә генә сөйләште. Ләкин малайның анасы моңа бөтенләй игътибарсыз калды.

Каникуллар башлангач та Гәүһәр, сирәгрәк булса да, тәрбиягә «авыр» бирелүче балалар янына барудан тукталмады. Балаларның күбрәк саф һавада йөрүләрен, уйнауларын кайгыртты. Бер генә сәгать булса да дәресләрен дә карасыннар. Гәүһәр балаларның һәр икесенә көн саен нәрсә эшләргә кирәген аерым дәфтәр битенә язган иде. Ата-аналарына да шуны бәйнә-бәйнә сөйләде. Үзе хәзер еш килеп йөри алмавын әйтте, чөнки институтта кышкы имтиханнарны тапшырасы бар.

Балалар мәшәкате, читтән торып уку, имтиханнар Гәүһәрнең бөтен вакытын алды. Ул инде иренең үзенә карата аз гына суына башлавын сизгән иде, ләкин моны вакытлы яки узгынчы сәбәпләргә кайтарып калдырырга тырышты. Эше тыгыз булганга, Җәгъфәргә тиешенчә игътибар итә алмады шул, кайнар аш та еш кына булмады, ә Җәгъфәр — токмач корсак.

— Уф, җаным чыга инде,— ди торган иде ул кайчак институттан бик соң кайтып кергәч.

Җәгъфәр бу сүзләргә игътибар итми башлады. Гәүһәр исә, үзенең гаебен сизгәнгә, сүзне куертмады, кухняга чыгып, газ яндырды, чәй куйды, я Җәгъфәрнең керләнгән күлмәкләрен юды. Галим кеше, укытучылар, студентлар арасында адәм хуры булып йөрмәсен.

Гәүһәр гадәттә бик соң ята иде. Ул ятканда Җәгъфәр инде мышнап йоклый торган була. Гәүһәр аның чуалып беткән чәчен сыпыра, өстенә яба. Аннары утны сүндерә. Үзе тиз генә йокыга китә алмый, караңгы түшәмгә карап ята. Кайчак Җәгъфәр турында уйлый, кайчак тапшырачак имтиханнарын. Училищеда да имтиханнар турында бор-

чылгандыр, әлбәттә, әмма хәзер күбрәк баш вата шикелле. Хәер, үткәннәрнең тәэсире әкренләп онытыла, хәзергесенең генә онытылмый шул. Кайчагында мәктәп балалары исенә төшә, күптән бармаган булса, поэшына, яңарак барган булса, күргәннәренә анализ ясый.

Иртә белән ул, кагыйдә буларак, иртә тора, иренең күлмәкләрен үтүкли, иртәнге ашны пешерә. Аннары ирен уятып уята.

— Тор инде, Җәгъфәр, вакыт. Ял көне озаклап аунарсың.

Җәгъфәр сәгатенә карый, аннары тәмле итеп киерелә, тагын берике минут ятагында ауный да торып утыра. Бу вакытта инде Гәүһәр янадан кухняга чыккан була, үзенә хас өлгерлек белән аш әзерли, аннары иренең юынып, киенгәнен көтә.

— Җәгъфәр, күлмәгеңне мин алып куйдым, якасы каралган инде. Менә бу күлмәгеңне ки, юдым, үтүкләдем.

Җәгъфәр кайчагында сөйләнә-сөйләнә киенә, кайчагында кашыкүзе җимерелгән була. Бу хәл бигрәк тә өстәлдә иртәнге аш әзерләнмәгән чакта кабатлана. Гәүһәр моны үз өстенә шелтә итеп алганга эндәшми, нишләсен, өлгерә алмады. Менә бүген иртәрәк кайтырга тиеш, ашны тәмлерәк итеп хәзерләргә тырышыр. Бүгенгесе өчен ире гафу итсен инде. Дөрес, Гәүһәрнең өлгерә алмаган чаклары ешрак була, гафу үтенергә күбрәк туры килә. Менә быелдан соң, тагын бер ел кала, аннары инде алар бөтенләй башкача торырлар.

Ашагач-эчкәч, Җәгъфәр чыгып китә, озакламыйча Гәүһәр дә институтка юнәлә. Кайчагында иренең кырыслыгына әзрәк хәтере кала, куйганын ашады-эчте, биргәнне киде дә китте-барды, Гәүһәренә рәхмәт тә әйтмәде, гүя хатыны аңа гел кирле күлмәкләрен юарга тиеш. Кайчагында Гәүһәр моңа игътибар да итми, институтына ашыга, имтиханын тапшырырга тиеш, шунысы иң мөһиме, калганы бар да узгынчы. Шуңа күрә Гәүһәр чит нәрсә турында бер дә уйламаска тырыша, торабара ул моңа ничектер ирешә дә. Ул дәресләре белән икәүдән-икәү генә кала, дөнья онытыла. Мондый чакта зиһен ачыграк эшли, күп нәрсә искә төшә, аныклана, әйтерсең, шул имтиханнарыннан башка аның бер эше дә юк. Укытучылар кайчагында аны хәтта мактап та алалар, әмма Гәүһәр үзе борынын чөйми, ул сәләтен яхшы белә, күктән бер нәрсә дә умырып алмый, бар белгәне шул китаплардан гына. Кайчагында күбрәк ялтырый икән, ул темасын алданрак, төплерәк үзләштергән була. Шулай да укытучыларның җылы сүзләре аны канатландырып җибәрә, ул авырсынмый укый, армый, талмый, имтиханнарын берсе артыннан берсен вакытында бирә бара. Бары тик институттан чыккач кына Җәгъфәр исенә төшә — күп вакытта караңгы була инде — ул исе китеп тирә-ягына каранып ала. Җәгъфәре инде кетә-кетә көтек булгандыр. Ул өенә ашыга, кайчагында өйдә такыр икәнен уйлап берәр кибеттән ашамлык-мазар ала. Җәгъфәрнең йөзе ачык булса, аның түбәсе күккә тия, кисмен сала-сала ук үзенең уңышлары турында сөйли, кызык хәлләрне дә кыстырырга онытмый, алар икәү көләләр, аннары Гәүһәр урыныннан торып:

— Синең инде тамагың да ачыккандыр. Аз гына сабыр ит, хәзер барысын булдырам,— ди, һәм әгәр Җәгъфәр аның ашын, өлгерлеген мактаса, күктән йолдыз үрелеп алгандай була, алар кичне бик яхшы үткәрәләр. Җәгъфәр үзенең эшләре, дәресләре, лекцияләре яки студентлар, укытучылар турында җитди итеп сөйләми, сөйләсә дә берәр көлке ягын гына кыстыра. Гәүһәр аның юмор сәләтенә кызыга, нәкъ кыз чагындагыча бөтен йөрәге белән бирелеп, сокланып, хәтта гаҗәпләнә төшеп тыңлый, ирендә яңа бер сыйфат ача. «Кара, Җәгъфәрнең шундый сәләте барлыгын белмидер идем», дип эчтән шатлана һәм шатлануын артык яшерми дә, чөнки иренең моңа куанасын гына белә. Киресенчә, иренең кәефсез чагы булса, ул сак кына кылана, тизрәк тамагын туйдырып яткырырга ашыга.

— Мин гаепле шул, озак юандым, беренче булып имтиханга да керә алмадым,— дип куя. Ул шулай кылана, әйтерсең, болар барысы да Гәүһәрнең ихтыярында булган да, ул мена, аңгыра баш, өлгерлек күрсәтмәгән, шуңа күрә генә кичеккән.

Бары тик бик сирәк вакытларда гына Гәүһәр ирендә ниндидер тирән эчке көрәш барганлыгын сизә. Бер карыйсың, Җәгъфәр ниндидер баткаклыкны ерып чыгарга тырыша кебек, хәтта ерып чыга да кебек, ул әүвәлгечә шат, көләч, дөньясыннан канәгать шикелле, берничә көн тоташтан башын югары күтәреп йөри, аннары ничектер җеби кебек, чырае караңгылана, авызыннан рәтле сүз чыкмый, хатынының бер эше белән дә кызыксынмый. Мондый чакта Гәүһәр иреннән:

— Ни булды, Җәгъфәр, синең кәефең юк шикелле? — дип сорый. Җәгъфәр я аңлашылмас итеп мыгырдый, я яхшы ук тупас сүз әйтә, я барып урынына ята. Шуннан соң инде Гәүһәр артык бәйләнми, ләкин эчен нәрсәдер тырный. Иренең кәефе яхшырганчы шулай янып йөри, аннары, иренең баш өстеннән болытлар тарала башлавын күреп, әлеге күңелсезлекнең сәбәбен сорый. Мондый чакта Җәгъфәр мәсьәләне юкбар уенга бора, я эштә канга тоз салалар, дип куя, Гәүһәр үзе дә хәзергә артыгын таләп итмәгәнгә, бик тиз канәгатьләнә, дөнья тагын түгәрәкләнеп китә.

Кеше бит бик катлаулы дөньяда яши, юллар сикәлтәле. Бер нәрсә турында да житди уйланмыйча яшәгән, гел ваемсызлык дулкыннарында йөзгән кешеләр — алар үз-үзләрен алдыйлардыр, юри күзләренә ак сала торганнардыр, чөнки тормыш алай акмый бит. Шуңа күрә Җәгъфәрнең керделе-чыктылы булуына нәрсә гаҗәпсенәсең? Шул уйлардан соң, Гәүһәр беркадәр ачыла төшеп йөри, дөньяга турырак карый, аннары, иренең яңадан күңелсезләнүен күреп, тагын кәефе бозыла. Юк, тормыш юллары сикәлтәле булса да, үзеңне ничектер тигезрәк тотарга кирәк, бертуктаусыз үзеңне камчылаудан файда юк. Гәүһәр үзләренең элеккерәк тормышларын күз алдына китерә. Элек алар бер-берсен аңлашып яшиләр иде, күңелсез минутлар булса да ничектер бик тиз үтеп китә иде. Шуңа күрә аларга әллә ни игътибар да ителми иде. Ә хәзер бөтенләй башка, ниндидер бер система бар шикелле, күңел күтәренкелегеннән соң бер дә шикләнмичә упкын буласын әйтергә мөмкин.

Ниһаять, кышкы имтиханнар да бетте, каникулларның да соңгы көне инде. Иртәгә мәктәп. Гәүһәр аз гына да ял итәргә өлгермәде, хәтта бераз суырылды. Ләкин яшь кешегә моның әһәмияте бармы соң? Менә берничә көннән ул тагын шундый көр булыр, тагын чәчәк атар. Җәгъфәрнең дә кәефе яхшыра башлаган иде. Шуңа күрә Гәүһәр бүген, институттан кайткач, биленә ак алъяпкыч бәйләде дә ит турарга керешге. Җәгъфәрнең яраткан ашын — пәрәмәч пешерергә исәпли иде. Ите, оны, мае бар. Суганы беткән иде, күрше хатыннан әҗәткә алды.

Гәүһәр үз алдына жырлый-жырлый пәрәмәч ясады, аннары чәйнек куйды. Менә Җәгъфәрнең кайтыр вакыты да җитте. Шунысы яхшы, Җәгъфәр һәрвакыт вакытында кайта. Кайта алмаса, телефоннан шалтырата. Бүген телефоннан шалтыратмады, димәк, вакытында кайтырга тиеш. Чыннан да баскычта аның аяк тавышы инде. Әй тиле, нигә инде шулай шыпырт менә. Ярый, юләрләнсен инде.

Гәүһәр кухняга кереп китте, пәрәмәчләрен пешерә башлады. Ул арада ишек ачылды, әнә Җәгъфәр шыпырт кына чишенә, әнә көзгегә карый, әнә аяк очларына гына басып беренче бүлмәгә керде, ак тастымал белән япкан өстәлне күргәч, каш сикертеп елмайгандыр (май исе дә коридорга таралган иде).

Кинәт кухня ишеге ачылды һәм Гәүһәр янына ире килеп басты. Ул

ире әле теге бүлмәдәдер дип уйлый иде, шуңа күрә сискәнеп китте. «Аһ», дип кычкырып җибәрде, чәнечкесен кулыннан төшерә язды.

— Аһ, Җәгъфәр, кайчанга кадәр шулай песи булып йөрерсең икән?! Котымны алдың!

Җәгъфәр көлеп җибәрде, аннары: аһ, пәрәмәч, пәрәмәч, дип, хатынын иңеннән кочып, костюмын салырга китте. Икенче бүлмәдән дә аның шат көлүе ишетелә иде.

— Кара инде юләр, ничек шатлана,— дип уйлады Гәүһәр, ләкин аның үзенә дә күңелле иде. Җитмәсә, пәрәмәчләре тагын нинди килешә, ашамас җиреңнән ашарсың. Аннары икеңче нәрсә дә бар, кайсы хатынга ирен чын күңелдән шатландыру ош... ый. Ул бит моның өчен бөтен осталыгын бирергә әзер.

Җәгъфәр костюмын салып, зәңгәр пижамасын киде дә, ванна бүлмәсендә юына башлады. Гәүһәр иренең ат кебек пошкыруын яратып бетермәсә дә, бүген моңа игътибар итмәде, киресенчә, иренең тавышлануында нинди дер көч, ныклык сизде. Юк, җан сөйгән ирең булуы нинди бәхет. Теге ялгызак ана хәленә калсаң, нишләр идең? Кайчак Гәүһәр ул хатынның баласына мәрхәмәтсез булуын да аңлый кебек. Табигать аны читләтеп үткән, бер матурлык бирмәгән, хәтта әчке матурлыгын да кызганган. Ире дә, якыннары да юк, баласы мәхәббәт җимеше булып түгел, очраклы бәйләнешнең күңелсез нәтиҗәсе булып туган. Шуңа күрә ул әнисенә шатлык алып килмәгән, аны сөендермәгән...

— Булдыңмы, Җәгъфәр? Әйдә утыр.

— Утырабыз.— Җәгъфәр юеш чәчен тарый-тарый ванна бүлмәсеннән чыкты.— Үтертеп ашыйсы килә. Пәрәмәчләреңне чәйнәмичә йотармын, ахрысы.

— Бер генә чәйнәми йотсаң да артыгын бирмим,— диде Гәүһәр, көлеп.— Ашаганың аш булсын өчен, бик тырышып чәйнәргә кирәк. Хәзер шул турда лекция укыйм үзенә.

— Рәхмәт.— Җәгъфәр тәлинкәдән пәрәмәчне алып капты.— Һемм! Телемне йоттым бугай.

— Менә телсез калдың, алай булгач.

Гәүһәр рәхәтләнеп көлә-көлә пәрәмәчләрен бүлмәгә алып керде, аннары өеп ире каршына куйды.

— Алма-Атада мине бишбармак, Ташкентта пылау һәм манты белән сыйлаганнары бар, әмма безнең пәрәмәчкә җитми бугай,— диде Җәгъфәр, пәрәмәчне тәмләп ашый-ашый.

— Һәркем үзенең ашын мактый инде. Казакъка бишбармагы, үзбәккә пылавы, татарга пәрәмәче кыйммәт.— Гәүһәр иренә сөеп карады. Ул ирен шулай шатландыра алуына бик канәгать иде.

## 11

Көннәр күзгә күренеп озынайды. Сәгать дүрттә, биштә түгел, алтыда да якты инде. Якты күп булгач, рәхәт икән, һич армыйсың, күңелең күтәренке, гел эшлисе килеп тора. Дәресләр беткәч, өйгә чабарга ашыкмыйсың, укучыларның әле берсенең, әле икенчесенең өенә барасың, ата-аналар белән сөйләшәсең. Утыз биш бала бит, яхшы укый торганнары да вакыт-вакыт әллә нишләп куялар. Әмма Дамир хәзер иптәшләренең үкчәләренә басып бара. Гәүһәр моңа шатланып туя алмый, класс җыелышларында да аны әледән-әле яхшы яктан телгә ала башлады. Күп борчыган, күп уйландырган Шәүкәтнең дә уңышлары күзгә күренә. Ул нәрсәдәндер котыла, нәрсәнедер җиңә кебек. Яхшы ук активлашып та китте, үзенә турыдан-туры кагылмаган нәрсәләргә дә игътибар итkәли башлады. Монда, билгеле, язның да тәэсире бардыр,

әмма барыннан да бигрәк ул үзенә булган мөнәсәбәтнең үзгәрүен сизә булса кирәк. Гәүһәр аның фаҗигасе тирәнрәк дип уйлаган иде, болай булгач, өмет бар әле!

Бер көнне Гәүһәрне шатланырга да, борчылырга да мәҗбүр иткән шундый хәл булып алды: дәрес яңарак кына беткән, Гәүһәр, гадәтенчә бер-ике минутка тоткарланып, китапларын портфеленә тутыра иде. Күтәрелеп караса, Шәүкәт тәрәзә янына баскан да иптәшен янына чакыра.

— Дамир, кара әле, песнәк килгән. Тсс! Куркыта күрмә!

Дамир, аның белән и пләшмичә, йөгереп килеп тәрәзәгә капланды, песнәк, өркеп, пыр итеп очып китте. Дамир кычкырып көлә башлады, соңыннан иптәшенә

— И-и, күзләрен дә юешләткән,— диде.— Очса соң, аның канатлары бар ич. Менә син очар идең дә, канатың юк.

— Ул очмыйдыр иде, син аны куркыттың. Аның ашыйсы килә, ул ипи сорый.

— Каян белдең? Үзе әйттеме?

— Юк, Гәүһәр апа әйтте.

— Ышан! Кошлар ашамый да тора ала.— Дамир иптәшен колагыннан тартты да йөгереп китеп барды. Ул укытучы игътибар итми дип уйлады, ахрысы.

Гәүһәр аны туктатып: «Нигә кошны куркыттың, нигә иптәшеңнең хәтерен калдырдың», дип сорады. Шәүкәт дөрес әйтә, кошның ашыйсы килгән, шуңа күрә ул безнең тәрәзә янына кунган. Балалар кошларга игътибарлы булырга тиешләр.

Дамир, кызарып, дәшмәде. Аннары башын күтәреп:

— Шаукатка ни б.лә, ул юләр ич,— диде.

Гәүһәр моны һич көтмәгән иде, йөзенә кан йөгерде. Шулай да, үзен кулга алып, Дамирны алгы партага утыртты, аннары Шәүкәтне дә чакырып шунда урын күрсәтте. Үзе дә урындыкка утырды.

— Дамир,— диде,— син иптәшеңә бик тупас сүз әйттең. Син моның өчен хәзер үк аңардан гафу үтен. Ул бик акыллы. Әнә башкалар уйламаган да, ә ул кошларга азык бирү турында кайгырткан. Мин кыш көннәрендә кошлар азыкка бик тилмерәләр дип сөйләгән идем. Кешеләр — кошларның якын дуслары, алар кошларга авыр чакта ярдәм итәләр. Иртәгә тагарак ясап, кошларга валчыклар салыгыз.

— Песнәк яңадан килмәячәк. Ул курыкты,— диде Шәүкәт.

— Килер. Кошлар кешеләргә күңелләрендә кер сакламыйлар. Килештекме?

— Килештек,— диде Дамир.

— Ә Шәүкәт ник дәшми? Син үпкәләдеңме? Үпкәләмә, үпкәләү яхшы гадәт түгел. Ә син, Дамир, иптәшеңнән гафу үтенмәдең бит әле.

Дамир, укытучы үзенең сүзен инде онытказ, дип уйлый иде. Кабат ишеткәч, кызарып башын түбән иде, авыр сулады.

— Я, Дамир, без көтәбез.

Малай кешегә гафу үтенү бик авыр икән. Мөмкин булса, ул үз сүзен һич кире алмас иде. Ләкин укытучы көтә, Дамир боргаланасыргалана, әмма башка чара калмагач, Шаукаткадан гафу үтенә.

— Шаукатка түгел, Шәүкәт. Исемнәрне бозарга ярамый.

— Шәүкәт.

— Менә шулай. Хәзер өегезгә дус булып, яхшы гына кайтыгыз. Иртәгә һәрберегез кошлар тагарагы ясап китерегез. Беләсеңме ничек ясарга?

— Беләбез,— диде Шәүкәт.— Менә шуның шае гына такта аласың да дүрт почмагына дүрт тишек тишәсең, аннары баулар бәйлисең.

— Дөрес. Ә валчыклар җиргә чәчелмәсен өчен нишләргә кирәк?

— Кырыйларына юка гына такта сугарга.

— Дөрес, Шәүкәт. Ә хәзер барыгыз, бер-берегезне мыскыл итмәгез.

Балалар китеп бардылар. Гәүһәр юри бераз соңга калып чыкты. Малайлар, билгеле, болай тиз генә татулашмаслар. Чыннан да, түбәндә энә Дамир инде иптәшен төртеп китте. Ярый әле, Шәүкәт еламады, иптәше төрткәч, үзе дә буш калмады. Әлек ул, җәберсетсәләр, елый гына белә иде. Шуңа күрә малайлар күбрәк аңа «мәми» диләр иде.

Икенче көнне, беренче дәрестән соң ук, алар үзләренең тагаракларын укытучыга күрсәттеләр. Дамирга әле, һич югында, абыйлары да булыша ала, ә Шәүкәтнең беркеме дә юк. Ләкин ул тырышкан, кошлар кунып ял итсен өчен уртага тагын бер аркылы чыбык та беркеткән. Гәүһәр балаларның бу эшләреннән бик канәгать булып калды, икесен дә мактады һәм икесенә ике тәрәзәне күрсәтте. Зур тәнәфес вакытында тагаракларыгызны шунда эләрсез, диде.

Зур тәнәфес вакытында малайлар форточкаларга тышкы яктан тагаракларны асып куйдылар. Башта анда бер кош та кунмады. Аннары, дәрес бетәр алдыннан гына, Шәүкәтнең тагарагына кичәге песнәк очып килде.

— Гәүһәр апа, кара, килде,— диде Шәүкәт, чиксез шатланып. Бераздан кош очып китте. Күп тә үтмәде, алар икәү килделәр, икесе ике тагаракка кунды да валчыкларны чүпли башладылар. Балаларның күзләре песнәкләрдә генә иде. Ярый әле, звонок шалтырады. Дамир кулын күтәреп:

— Т-сс! — дип кычкырды.

Бөтенесе тәрәзәләргә үрелеп песнәкләрне күзәттеләр. Кызык булды, кошлар курыкмады, тамаклары туйгач кына очып киттеләр. Ә укытучы Шәүкәт белән Дамирны күзәтте. Кисәтүләрне хәзер Гәүһәр бик сирәк ясый иде. Малайлар үзләре дә сизмәстән бер-берсенә якыная башладылар. Бер көнне Дамирны Шәүкәтләрдә очраткач, Гәүһәр бөтенләй шатланып китте. Шул көнне баланың анасы да укытучыга җылырак күз белән карады шикелле. Хәзер инде чынлап торып Шәүкәтнең укуына тотынырга кирәк иде. Әле берничә ай вакыт бар, тырышканда Шәүкәт классны яхшы тәмамлый алыр.

Шундый көннәрнең берсендә, Шәүкәтләрдән чыгып, бакчага таба борылганда, Гәүһәр, һич тә көтмәгәндә, алтын күзлеклене очратты. Ул үзе шикелле урта яшьләрдәге бер ирне култыклап килә иде. Гәүһәр инде елмая башлады, ләкин алтын күзлек кинәт башын читкә борды, һәм алар Гәүһәр яныннан сүзсез генә үтеп киттеләр. «Ахрысы, танымады», дип уйлады Гәүһәр, аңа ничектер күңелсез булып китте, кич белән иренә дә шул турыда сөйләде. Җәгъфәр башта бик күңелле итеп көлде.

— Исең киткән икән,— диде бераздан,— исәнләшмәвенә хәтерең калган. Кем син аңа ул хәтле?

— Ничек инде кем? Бездә кунакта булды лабаса ул.

— Булса. Ихтимал, ул атна саен берәр җирдә кунакта була торгандыр. Барысын хәтерләп бетерсенме?

— Ничек инде хәтерләмәскә? Мин бер җирдә кунакта булсам, хуҗаларны гомер онытасым юк.

Җәгъфәр башын артка ташлап тагын көлеп җибәрде.

— Кайчак, син, Гәүһәр, бөтенләй балаларча сөйлисең. Балалар белән дә балаларча сөйләшергә ярамый торгандыр. Син елына ничә тапкыр кунакка барасың, кемнәргә барасың?

— Күп булмаса да барабыз, я синең дусларыңа, я минем.

— Менә шул шул, без дусларга кунакка йөрибез, анда да ничә бәйрәмдә бер, ә ул атна саен кунакка бара, күбесенең, ихтимал, исемнәрен дә белми торгандыр.

— Мин моны аңламыйм.

— Аңламассың шул, чөнки без башка кешеләр, ә аның өчен...— Җәгъфәр көлеп җибәрде.— Ә син ул кеше сәнгатьне тирән аңлый дигән буласың. Аңлый, пычагым.

— Җәгъфәр, тукта әле. Әгәр ул шундый икән, син ни өчен аны кунакка чакырдың? Җитмәсә, аның алдында...

— Шулай да син бөтенләй бала икәнсең, Гәүһәр. Һәйбәт квартирда торасыңмы? Торасың. Идел буенда дачаң бармы? Бар. Машинада выжлатып йөрисеңме? Йөрисең. Ике җирдә ике холодильнигың бармы? Бар. Болар әллә күктән төшкәнме? Аңа бер стакан чәй эчермә, имеш. Берне түгел, унны эчсен, шартласын, аннан мин бөләммө?

— Тукта, син боларны үз акчаңа сатып алдың ич?

— Акча әле мәсьәләнең бер ягы гына. Акчаң булып та бер нәрсә дә ала алмавың мөмкин. Син теләгән нәрсә кибеттә әле тулып ятмый.

— Мин аңламый торадыр идем, болай булгач, төшендем. Әле моннан ике-өч ай элек театрда алтын күзлекленең хатынын күргән идем. Каршымда сөйләшеп тора, үзе миңа борылып та карамый, соңыннан янымнан борынын күтәреп узып китте. Ул чакта гаҗәпләнгән идем. Хәзер булса...

— Ул күрми икән, син дә күрмә. Без аларга дус түгел, алар безгә, эше бетте китте. Төшенгәнсеңдер?

— Юк, аларны...

— Бик батыр булмассыңмы? — Җәгъфәр хатынына кинәт усал итеп карап алды.— Моны синнән акыллыраклар да белә, ләкин кирәк чакта телне тыялар.

Гәүһәр берничә көн буена гел шул турыда уйланып йөрде. Ул үзенең ялгышуына, һәр ялтыраганны алтынга санавына бик үкенде. Баксаң, тормыш бер дә алай түгел икән. Тыштан бик шома күренгән кешеләр дә чынында әллә нинди була.

— Гәүһәр апа, песнәкләр хәзер көнгә бер-ике тапкыр гына килә-ләр,— диде Шәүкәт, иртән мәктәпкә килгәч.

— Хәзер юлларда да, урманда да азык күбәйде. Әнә юллар ничек каралган.

Дамир песнәкләрне бөтенләй онытткан иде булса кирәк, ә Шәүкәт әле һаман күзәтә икән. Песнәкләрнең көнгә бер-ике генә тапкыр килүләренә дә игътибар иткән. Бәлки, бу кечкенә нәрсәдер, тик шушы кечкенә нәрсәләрдән дә Гәүһәр үзенә нәтиҗә ясый иде. Хәзер Шәүкәт тирә-ягындагы әйберләргә берни күрми торган буш күз белән карап тормый, ул аларның үзгәрешләренә игътибар итә. Шуның белән бергә, дәресләрен дә онытмый, бик күбесен үти, үти алмаганнары өчен борчыла. Мондый чакта ничек инде аңа ярдәмгә килмисең?

Шәүкәтнең көннән-көн үзгәрә баруы Гәүһәрне шатландырды, аның күңеле күтәрелеп китте. Иренә дә ачыграк күз белән карый башлады.

— Җәгъфәр, нигә синең бу арада сөмсерләрең коелып йөри? — диде.— Яз көне дөнья белән сөзешергә ярамый.

— Хәзер март кына әле, яз апрельдә башлана.

— Юк, апрельдә аның уртасы. Кайчагында яз гомумән бик иртә килә бит.

— Миңа калса, һәр нәрсә вакытында килә. Юләрләр генә шаяруны чынга ала.

— Акыллылангансың икән, Җәгъфәр.— Гәүһәр көлеп җибәрде.— Сораганым юк иде, болай булгач, сорыйм инде: алтын күзлек турында чын дөресен сөйләп бирдең, Исрафил Дидаров та шундыймы әллә?

Җәгъфәр хатынына озак кына карап торды. Бу сорауны тиктомалга бирмәс, әллә бер-бер нәрсә сизәме? Гәүһәрнең йөзе аңык кына бер нәрсә дә әйтми иде бугай.

— Мин күрәзәче түгел,— диде Җәгъфәр, сүрән генә.— Син берәр нәрсә беләсең икән, үзеңдә сакла, кирәге булыр.

— Мин үпкәләрсең димәгән идем. Җавап бирмисең икән, бирмә. Телемә килгәннән генә сораган идем. Исрафил абый мине бик кызыксындырмый.

— Алайса бик яхшы,— дип, Җәгъфәр читкә борылды.

Гәүһәр мәгънәле генә итеп көлемсерәде. Кызык бу Җәгъфәр: юк кына нәрсәләрдән хәтере кала, үпкәли. Шул ук вакытта ул хатын-кызның кызыксынуын арттыра. Моны Гәүһәрнең Исрафил Дидаров турында кайта-кайта сорауларыннан да күрергә була иде. Җәгъфәр Гәүһәрнең уйлары кай якка таба акканын чамалады бугай, ул йоннан төргән түгел ләбаса.

Гәүһәр бер ваемсыз кеше кебек әкрен генә җырлап җибәрде. Җырлый-җырлый ниндидер рәсемле журнал карады, аннары үзенең рәсем дәфтәрен алды. Эшләнеп бетмәгән рәсемен күздән кичерде, аннары альбомын читкә куйды, тәрәзәдән тышка, карт тирәккә бакты, әмма уе аңа да тукталмады. Күрше урам чокыр төбеннән уза. Анда бер-ике катлы йортлар гына, күбесе агачтан. Түбәләрен калын кар баскан. Кемдер Гәүһәргә сөйләгәне бар, бу урамда элек ярлы студентлар гына торган, имеш...

Гәүһәрнең карашы бик йөгерек, уйлары таркау иде. Бераздан ул карлы йорт түбәләрен дә, чокыр төбеннән үткән студентлар урамын да онытты. Ул авыз эченнән җырлавын гына дәвам иттерде.

## 12

Яз җитә башлагач, Гәүһәрнең бер «котырып» ала торган гадәте бар. Мондый көннәрдә күңеле гүя чыгырыннан чыга, әллә ниләр эшлисе килә, тотынса, теләсә нәрсәне булдыра алыр кебек, мөмкин булмаган бер нәрсә дә юк шикелле. Үзе дә, киемнәре дә мамык кына кебек, көчлерәк җил иссә биеккә-биеккә очып китәр төсле.

Менә шулай яки шуңа охшашлырак итеп каршы ала торган иде Гәүһәр кар астыннан чыккан нәфис язны. Быел да вакытында яз килде, кар сулары акты, тау битләрендә, калкурак урыннарда җир ачылды, күңелне кытыклап, борынны рәхәтләндереп, черегән яфрак өеме өстеннән җылы бу күтәрелде, яз хәбәрчеләре — кара каргалар, сыерчыклар килде, агач башларында үткән елдан калган ояләр тирәсендә чыр-чу, талаш башланды. Малайлар көне урамда гына, мәктәпләрдә дәрес барганда да әледән-әле зур, якты тәрәзәләргә омсынып карыйлар, ә дәрес бетүгә, дөньяларын онытып, шаулаша-шаулаша урамга атылалар.

Гәүһәр боларны күрә, тоя, вакыты белән үзе дә дөньясын онытырга хәзер, шул ук вакытта быел нәрсәдер аны чабуыннан та тотадыр кебек. Ул кабатланмас тамчылар җырын тыңлый, сихерләнә, күзенә яшь килә, башын ия, әле генә балкыган киңлек, сафлык болганчык томанга әверелә, җанны өшетә, ниндидер билгесез нәрсә белән яный шикелле. Гәүһәр шакката, болай шомланырга бер дә сәбәп юк шикелле. Хәлбуки, соңгы вакытларда аның борчулары бермә-бер артып китте. Моны үзе белән бергә эшләгән иптәшләре дә күрә башлады. Болай әйтерлек сәбәп булмагач, әллә укуында берәр тоткарлык килеп чыктымы дип уйладылар алар. Башка елларда Гәүһәр имтиханнарын җиңел тапшыра, укуы турында адым саен кирәккә дә, кирәксезгә дә сөйләми, зарланмый, өстәмә яллар алмый иде. Аның укуын мәктәптә сизмәделәр дә. Хәзер Гәүһәрнең эчтән сызуын күргәч кенә, анда да аптыраганнан гына, укуын телгә алдылар.

— Юк, укуларым быел да яхшы бара,— дип җавап бирде Гәүһәр

мондый сорауларга каршы.— Дөрес, укуның үз мәшәкатьләре бар, Шәриф Гыйльманович. Тик алар үз җаенда хәл ителә.
— Классында, миңа калса, эшләр шулай ук җайлы бара шикелле. Дамир белән Шәүкәт янадан борчымыйлармы?
— Юк, Шәриф Гыйльманович. Әлбәттә, алар минем игътибар үзәгендә, ата-аналары белән дә һәрвакыт элемтә тотам. Уку елы башындагы кебек зарлана алмыйм.
— Бик яхшы, бик яхшы. Сәламәтлегеңнән дә зарланмыйсыңдыр инде?
— Юк, Шәриф Гыйльманович. Бу яшьтән зарлана башласаң...
— Кайгы агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, Гәүһәр. Тик кайгы килсә, аны күтәрә белергә кирәк... Иптәшеңнең сәламәтлеге ярыйсыдыр? Әшендә ул-бу юктыр бит?
— Юк шикелле...
Нәкъ менә шунда Шәриф Гыйльманович Гәүһәрнең тавышында нәрсәдер сизеп, сүзне башкага күчерде. Яз бит, күңел җилкенә, яшьлек еллары искә төшә, мәхәббәт яңара, диде.
— Яшь өлкәнәйгәч, шулайдыр,— диде Гәүһәр, тыйнак кына.— Әмма безнең яшьлегебез белән бүгенгебез бер шикелле. Аерманы күп вакытта сизмисен дә.
— Анысы, шулайдыр да, яшь чакта тойгылар күбрәк дулый. Елга да бит ташу вакытында каты ага, аннары үзеннән-үзе басыла.
Әллә кайдан томан эченнән Билал Шәңгәраев күтәрелде. Гәүһәрнең борчылуларының бер башы аңарда түгелме? Моннан атна-ун көн элек Гәүһәр төш күрде. Билал Җәгъфәр белән сөйләшкән, имеш. Җәгъфәрнең йөзе чөгендер кебек кызыл, ул әрли, сүгенә, мине алдадылар, дип кычкыра. Шунда каяндыр Фаягөл килеп чыга, Җәгъфәргә сыенып, нәрсәдер аның колагына пышылдый, каядыр алып китәргә маташа. Гәүһәр җибәрми, имеш. Фаягөл каһкаһа белән көлә. Җәгъфәр әле Гәүһәргә, әле Фаягөлгә карый. Күзләре киңрәк ачылганнан-ачыла бара...
Әллә шуны Шәриф Гыйльмановка сөйләргәме? Ул бит Гәүһәрнең күңелендәге үзгәрешләрне сизде, шуңа күрә сүзне юри яшьлегенә, мәхәббәткә күчерде. Ә ояты ни тора? Бер-бер нәрсә булса, бер хәл иде. Югыйсә шикләнүләр генә бит. Боларны тыңлагач, Шәриф Гыйльманович нәрсә уйлар? Гәүһәр аның каршында бик түбән төшмәсме? Ул күрә булыр, Гәүһәр яшь, матур, ирләр сокланмаслык хатын түгел. Ул әле тормыш арбасыннан төшеп калмаган, Җәгъфәр янында башын әнә ничек югары күтәреп атлый, башкаларның яшерен кызыксынуы аны кимсетми, киресенчә, канатландыра гына.
Гәүһәр урам буйлап уйланып кайтты. Кичкә таба гөрләвекләр тагын да көчәйде. Бөтен җирдә су ага. Алар җир йөзен юалар. Бәлки, Гәүһәрнең дә кайгыларын юарлар.
Кинәт Гәүһәргә ире бик кызганыч булып тоелды. Гәүһәр үзе дөресен белә, бу дөреслек аңа авыр чакта көч бирә, ә Җәгъфәргә?
Җәгъфәр эштән бик соң кайтты һәм... кызмача иде. Гәүһәрнең моңа исе китте, чөнки күпме торып та ирен мондый аяныч хәлдә күргәне юк иде. Өйдә булса бер хәл, кеше күрмәс иде. Кешеләрнең бит төрлечә юраулары бар.
— Җәгъфәр, кайда болай булдың, берәрсе күрмәдеме? — диде Гәүһәр, борчылып.
Җәгъфәр нидер мыгырдап кулын гына селекте, эшләпәсен шүрлеккә ыргытты, пальтосын урындык башына ташлады. Шуннан ул икенче бүлмәгә узды, кинәт көлеп җибәрде, аннары, көлүеннән туктап, диванга килеп утырды да ике кулы белән башын кысып тотты.
Гәүһәрнең ачуы кызгану белән алмашынды. Ул ире янына утырды, иңбашыннан кочты.
— Җәгъфәр,— диде ул йомшак кына тавыш белән,— чәй эчәсең

килмиме? Чәем кайнар... Булмаса, чишенеп ят, башың авырта торгандыр.

Җәгъфәр хатынының кулын иңеннән алды, читкәрәк елышты. Гәүһәр аңа аптырап карап торды.

— Җәгъфәр, кара инде... Җәгъфәр, болай бер дә килешми бит. Чын, булмаса, ят, ял ит.

— Юк, син мине кума, кума! — диде кинәт Җәгъфәр, хатынына туры карап. Аның йөзе агарган, ирennәре кыйшайган иде.— Ял ит, имеш. Юк, ял бетте инде миңа. Крепость җимерелде, җилгә очты, тузан булды.

— Җәгъфәр, әллә нәрсәләр сөйләмә әле... Әйдә, яткырам... Я инде, карышма, бәгырем. Бераз эчкәнсең икән, башка чакта тыелырсың. Кара, төсләрең ничек киткән, бер дә болай булганың юк иде бит.

— Булганым юк иде, менә булдым... Ә ни өчен булдым? Белмисеңме? Ә? Белмисең. Ә мин беләм!

— Кирәкми, Җәгъфәр, әллә нәрсәләр сөйләмә. Ни сөйләгәнеңне үзең дә белмисең.

— Беләм, бик яхшы беләм. Әллә синең юмалавыңны сизмиләр дисеңме? Сизәм! — Җәгъфәр бер кулы белән йөзен каплады, аннары күзләрен чекерәйтеп хатынына карады.— Халыктан куркасың, мин курыкмыйм. Мин башкалар белән йөрмәгән бит.

Гәүһәр агарынып китте. Ул бу сүзләрне инде күптән көтә иде иреннән, әмма Җәгъфәр бу сүзләрне йөзенә бәреп әйтмәс дип уйлый иде, чөнки аннан соң ни кала? Бүген аны беренче тапкыр базга баткан итеп күрде, аның беренче омтылышы ирен аннан тартып чыгару булды. Ул акылы белән аңлаудан бигрәк, йөрәге белән сизде: әгәр хәзер тартып чыгармасаң, Җәгъфәр тагын да тирәнрәк батачак, аннары инде аны чыгарып та булмас.

— Җәгъфәр, чыннан да син ни сөйләгәнеңне белмисең. Әйдә, ят, иртәгә айнык баштан барысын да сөйләшербез, аңлашырбыз.

— Аңлашырга! Җитте, аңлаштык инде. Мин монарчы да юләр булганмын, шуңа күрә... Синең тәмле сүзләреңә карап... Үзем ятлар белән йөрмәгәч...

— Башкалар әллә йөргәнме? Телеңә ни килсә, шуны сөйлисең.

— Минем бер сүземә каршы бишне әйтмә. Үзең барысын да бик яхшы беләсең.

Гәүһәр җан ачысын җыеп:

— Бу ялган, ялган, Җәгъфәр, әгәр сиңа бер-бер нәрсә сөйләгән булсалар, ышанма,— диде.— Мин сиңа үзем аңлатырмын...

— Кирәкми, мәшәкатьләнмә. Син инде миңа бер түгел, ун сөйләгән идең. Мин сиңа ышанып килдем һәм... үз-үземне җәзага салдым. Хәзер инде беркемгә дә ышанмыйм. Рәхмәт, күземне ачтылар.

Җәгъфәр, оста уйнаучы кебек, карталарын берәм-берәм генә чыгара иде. Инде сүз юк, кемнәрдер Гәүһәр хакында Җәгъфәргә нәрсәдер сөйләгәннәр, аны ышандырганнар. Җәгъфәр кешегә тиз генә ышанмый, әгәр ышанса, аның сүзен бик югары куя, аны инде бу уеннан кайтаруы бик кыен. Гәүһәр моны күптән белә иде. Шуңа күрә бик куркып:

— Кем, Исрафил абый күзеңне ачтымы? — дип сорады.

— Анысы мөһим түгел. Үземнең башым җитмәгән икән, кешеләрнең аңлатуы кирәк булган, рәхмәт аларга.

Гәүһәр инәлеп, ялварып, күз яшьләре белән диярлек:

— Җәгъфәр, ышанма башкаларның ялган сүзләренә. Мин сиңа турылыклы, мәңге шулай...— диде.

Җәгъфәр аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмичә:

— Сөйләмә... Мин инде синең бер сүзеңә дә ышанмыйм,— диде.

Бу кичтәге сөйләшү озак дәвам итсә дә, Җәгъфәрнең: «Мин сиңа артык ышанмыйм инде», Гәүһәрнең: «Бу ялган, ялган», дигән мәгънәдәге сүзләреннән ерак китмәде. Гәүһәр беренче тапкыр үз өендә ят өйдә кунган шикелле кунды, чишенмәде, урынына ятмады, каядыр почмакка караган килеш уйланды да уйланды, дөресрәге, уйлары юк иде аның, әгәр ни турында уйландың, нинди фикергә килдең? дип сорасалар, ул, билгеле, бер ничек тә җавап бирә алмас иде, күзләре ачык булса да, берни күрмәде, үзе йокламаса да, уйлары кузгалмады, аның башы каткан иде. Син якын, үз күргән, син чиксез ышанган, сулышын өзеп бирердәй кешең, авыр минутта арка терәгең булган юлдашың кинәт шулай үзгәрсен әле... Юк, бу коточкыч, мөмкин түгел бу, моңа ышанып булмый.

Иртә кичтән хәерлерәк, диләр. Бүген таң бик әкренлек белән туды. Өстәл лампасы һаман янып утыра иде. Көн яктысы арта барган саен аның нуры кимеде, ахырда ул беркемгә дә кирәксез җемелдәвек булып калды. Нәкъ шул лампа яктысы кебек, Гәүһәрнең йөзе дә сүлды, күз кабаклары шеште, ирен почмакларында тирән-тирән сызыклар барлыкка килде. Җәгъфәр мышнап йоклап ята. Уятырга вакыт. Хәзер уятыр. Мәктәпкә барыр вакыт та якынлаша. Ничек барыр Гәүһәр! Балалар бит бер караштан аның йокламавын сизәрләр. Алар ике йөзләнә белми, күрмәмешкә дә салынып үтмәсләр, «Гәүһәр апа, сезгә ни булды?» — дип сорарлар. Гәүһәрнең бервакытта да аларны алдаганы юк иде, инде алдашырмы? Алар бит моны гомер буена хәтерләрләр, телдән әйтмәсәләр дә күңелләреннән Гәүһәр апаларына рәнҗерләр, син безгә дөресен сөйләмәгәнсең, син һаман ялганлагансың икән, диячәкләр. Иң яхшы теләкләр белән башкарылган хезмәтеңә, ахыр килеп, шундый бәя алу мөмкинлеге Гәүһәрне тетрәтеп җибәрде. Ул ыңгырашып куйды. Юк, бу иртә Гәүһәргә җиңеллек китермәде, киресенчә, барысын бутады гына. Ул бик авырлык белән генә урыныннан торды, кухняга чыкты, гадәтенчә юынды, чәйнек белән чәй кайнатырга куйды. Ул арада Җәгъфәр дә торды, ләкин хатынына дәшмәде, юынып, чәчен тарады да берни әйтмичә чыгып китте. Гәүһәр нишләргә белмичә бераз торды да, кайнаган чәйнекне сүндереп, киенә башлады.

Урамда бөтен кеше аның төн йокламавын беләләр иде кебек, бер төрлесе аңа кызганып, бер төрлесе тантана белән карады шикелле. Гәүһәр башын иеп, узып баручыларга карамаска тырышып, тизрәк мәктәбенә ашыкты. Тик монда да аңа җиңеллек юк иде, укытучылар да, балалар да бер карауда аның хәлен сизделәр кебек. Ул тизрәк укытучылар булмасеңә кереп журналны алды да үзенең классына ашыкты.

Гәүһәр барысын да көндәгечә эшләде кебек, укытты да, яздырды да, балаларның дәфтәрләрен дә җыйды, өйгә дәресләр дә бирде. Тәнәфес вакытларында укытучылар белән дә сөйләште, ләкин эчендәге чиксез күңелсезлеген берничек тә яшерә алмады. Ярый әле, бүген Фая Идрисҗанова очрамады. Бүген Гәүһәр үз-үзенә ышанмады, әллә нәрсәләр әйтеп ташлар иде кебек. Башка укытучыларның сорауларына гадәти сүз белән генә җавап бирде: «Нигәдер кәефем юк», диде. Ул әле нәрсәдер өмет итә, барысын берьюлы чишеп салырга ашыкмый. Кешеләр аңа ышаналар идеме, юкмы, анысын ул тикшереп тормады, дәресләре бетүгә, тизрәк өенә кайтып китәргә ашыкты.

Өй буш, караңгы иде. Җәгъфәр бик соң кайтты. Гәүһәр аны гадәттәгечә каршы алды, чәй кайнатты. Җәгъфәр бер сүз дәшмәде, ашамады, эчмәде, чишенде дә йокларга ятты. Әзер табын шул көенчә калды. Гәүһәр бик озак уйга калып утырды. Җәгъфәр аңа кычкырмады, өйдән чыгып кит, дип сөрмәде. Бу бәлки аның хатасын төшенә башлавыдыр. Берьюлы ялгышын танырга ирлек горурлыгы кушмас аңа, шуңа күрә вакытны суза торгандыр. Шулай булсачы!

*(Дәвамы бар.)*

## Роберт Әхмәтҗанов

### Ильич дивары

Мәйдан буйлап киләчәккә агыла бөек чират.
Мин торам гасыр каршында тик бер минут сорап.
Ни котәләр ак чыршылар, шул кадәрле тынып?
Керәм дигән идем, Ильич,— диварында ремонт.
Мәркәз ябык, керми китәм, карыйм янган утка,—
җир хәстәре онытылды миндә бу минутта...
Александр бакчасында — алма-алма карлар;
утка карый — дөнья белән алышы-биреше барлар.
Карыйм яшь-яшь чыршыларга, ак кар бөртекләре...
Тибрәндерми тыңлый алар зәңгәр керфекләрен.
Карыйм Мәскәүнең диңгездәй төпсез һавасына,—
а, ул ничек биекләнгән еллар авазына!
Александр бакчасында уйный нарасыйлар,—
алар әле синең юлдан ерак барасылар...
Авызы белән алма тота берсе,— кигән олы бүрек.
Үсә яшьлек илдә синең игелекне күреп.
Исемеңнең биш хәрефен җил һәм яңгыр ялар...
Хәреф таный белмәсә дә сине таный алар.
Диварлар да туза җирдә, алар — бары символ.
Безнең белән мәйданнарда кыл уртада — син бул!
Дөрбәләр бар, пантеоннар, гротлар бар җирдә.
Сине йөрәктән алмыйлар — төшермиләр гүргә.
Диварлар буйлап тезелгән батырларның җаны.
Арта илнең күкрәгендә үлмәс утлар саны.
Дөрли ялкын,— йолдызлар һәм кояш күрә аны,
мәңгелек утка берләшкән үлемсезләр җаны.
Аларны шушы мәйданнан дәшкән галәм яры;
калган аларның юлыннан утлы сызык бары,—
яшен ташы булып төшкән җирнең икарлары...
Кайберләре изге чиктә, көрәш сафларында
ракетадай янган чорның тыгыз катламында.
Аларның исемен югалтмый хәтер тора сакта.
Югалмый синең улларың, һәрберсе — исәптә.
Үз тирәңә аталарча син туплаган барын.
Ил аларның йөзләрендә синең йөзне таный.
Килгәннәр синең янына Сен-Симон һәм Жорес,
утка карый Фурье, Оуэн, Кампанелла, Маркс...[1]
Җыелганнар бер ялкынга — уртак байрак төсе...
Мәңге шулай йөрәгендә сине барлар Кеше.
Без — хисапсыз. Бар континент ни көтәбез туңып?..
Араларда бер сүз тора: «Мавзолейда ремонт».
Нинди ремонт?! — сәгать суга, часовойлар сакта,
изге тынлык. Керфекләрдә кар тибрәнми хәтта.
Нинди ремонт? — Курант суга, гүли таш диварлар.
Җир әйләнә. Җирдә — мәхшәр. Уйнап йөри балалар.
Александр бакчасында — алма-алма карлар...

[1] Александр бакчасындагы обелискка уелган исемнәр күздә тотыла.

Аклы-каралы Мәскәү —
декабрь полотносы:
ак түбәләр, кара җир,—
кемнәрне каратмасын?

. . . . . . . . . .

Ак бакчалар — кар туе...
Ике яклап җир — мәхшәр
Әйләнә кәне буе.

Фирүзә күз, ак муен,
уза йөзләр — нәкъ чуен,
рафинадтай ак тешләр
аңлатмыйммы кеше уен?

Ут-муенсалар тагып,
Элеп ак фонарьларын,
күпкәме кавыштырган
бу дөнья балаларын?

Карасына, агына
Мәскәү тигез караган.
Әйтә килгән: тик эштә
аер акны карадан!

Мәскәүленең күңелендә
африкалы кояшы,
африкалы Мәскәүдә
декабрьны тоймасмы?

Күзгә карап серләшкән
Метролары җилендә,
Күгәрчендәй гөрләшкән
Останкино күгендә —

кемнәр алар?
капкасын
киң ачып соң
кем дәшкән?..

Безнең күңел киң, иркен,—
барыбызга —
бер Мәскәү.

Шундый дуслыкны кем соң
үз итеп яратмасын?..

Аклы-каралы Мәскәү
Декабрь полотносы.

## Яшьлек кырлары

*Новелла*

Салкынча таң.
Офык сызыгына тияр-тимәс,
ахак төсле,
калтыранып балкый
салкын йолдыз.
Таң атканда
шул йолдыз астында
ялгыз тракторның
сукалавы ишетелә.
Аның гөре
яңгырап кайта гүя
йолдыздан.
Ул актара туган кырларымны,
ул җәйге басуларның битен
камыл сызыклары белән бергә
кире каплый
язга чаклы.
(Ул кырларның йомшак туфрагына
йолдыз кумсәң,
кояш шытар иде!)

Гади кешеләр инде йоклап арды.
дөнья җилкәсендә бер нокта
тынгы белми...
Ул — трактор,
һаман йокламаган.

Кинәт әнкәй төште исемә.
Без йоклыйбыз,
ә ул кыштыр-кыштыр,
онын или,
нидер пешерә;
ә йөзенә
кызыл шәүлә төшә учактан...

Газиз ана,
шул трактор сыман,
сөрә
сөрелмичә калган ызаннарын,
кайта-кайта сөрә
үткәннәргә,
яшьлегендә
чиерәк калган клиннәргә
кайта бугай...
Тире белән юа
үкенеч тузаннарын —
улларына чи калмасын...

Сизә, тоя күңеле:
аның йөрәге
инде тигез гөрелдәми.
Менә шуңа
алган җирен
сөреп бетерергә ашыга ул...

Салкын йолдыз,
калтыранып,
чыклы басулар өстендә
янып калыр...
Ак диңгездәй
карабодай кырларында
төклетура гөжләр,
таң җиленнән килер
арыш исе.
Тик
күңелем
Тормыш буразналары арасыннан
туган кырларымның
гөрелтесен эзләр...

Таң зәңгәре йөзә камылларда,
иңнәремнән коча июнь җиле.
Инде көз.
Каеннарым — язга китте.
Җир кыйгачлап очты
карлыгачтай,
шуды кырлар —
офык сызыгына.
Килеп чыгар алар яз каршына,
Кыңгыраулы ызаннарга.

Ул чак булыр баш очында
                    тургайлар гимны,
язгы йолдызлар мириадасы
чакырып янар
гашыйк йөрәкләрне
югарыга.
Тик әлегә
басуларым таң ягына
төн зонасын кичеп килә;

Офык сызыгына тияр-тимәс
калтыранып яна
салкын йолдыз.

Нәкъ шул йолдыз турысында,
ялгыз тракторның
яшьлек кырларымны
сукалавы
ишетелә.

●

Кырларда җил.
        Җитен кырларында,
җитен диңгезендә — бүген җил.
Җитен җилли.
Зәңгәр дулкыннарда
кыр тургае йөзә...
Туган җир!

Җитен җилли
        офыкларга тулып,
ишелеп-ишелеп кайта юлларга...
Бала тургай. Таныйм!
                    Ул тумыштан
пропискада
безнең кырларда...

Тугрылыклы.
Нәни метеор сыман
кыр өстендә риза янарга.
Яшел кыяклардан — камылгача
басуда ул,
төшә
камылга...

Яшь тургайлар менә,— яңа буын,
туган ягым күгенә, алмашка.
Күгем тулы тургай!
Яздан көзгә...
Мөмкин түгел җырда янмаска!
Карт игенче, соң кат «хуш!» дигәнче,
һаваларга карар иң элек:
зыңлап калыр
        гомер иткән дөнья
күк юлына биек чөелеп.

## Июнь иле

Баш очында — кояш,
Җирдә — июнь иле.
Яфрак арасында
Яшелләнә җиле.

Шау чәчәктә юкә,
Алкалары — сары.
«Очам» диеп тора
Тузганаклар шары.

Ул су өсте! Тып-тын,
Шома көзге генә...
Шуып-шуып үтә
Су чебене генә.

Кояш елмаюы
Яшел яр читендә.
Балкып тора елга
Яшел рам эчендә...

Мин үзем дә шуннан,
Июнь иле ямьле...
Гашыйк балачагым
Шунда калды мәңге.

Инде еллар йөге
ике иңне баса...
Мин «Ау!» диеп дәшәм
утыз июнь аша.

«Ау!» дип җавап бирә
усак урманнары,
«Ау!» дип җавап бирә
февраль бураннары.

Флейта җыры кебек,
Сызып-сызылып кына,
тавышы кайткан сыман,
аннан сүнеп тына.

Урман сәгатьләре
уникене суга.
Гаҗәпләнә бугай
нәни малай шуңа.

Күке тавышларын
бармак бөгеп саный...
Аңа адашса ни...

Минем адаш —
сабый!..

Мин «Кайт»,— диям аңа —
Монда иркен, рәхәт!
Кайт син бу елларга
йөгереп кенә җәһәт.

Сугыш күптән сүнде,
(Син үзең дә белдең.
Капка төбәсенә
Кызыл яулык элдең!)

Кибетләрдә йөртәм,
(Ялган сөйләмәмен),
Сайла да ал үзең
Җаның теләгәнен!

Таяк атың ташла,
Уенчыклар — дөнья!
Ул чакка үч итеп,
бер туйганчы уйна..

«Ау!» дип җавап бирә
болын, зәңгәр таулар...
Бер-беренә суза
ал кояшлы таңнар.

...Бил тиңентен үлән,
Күбәләкләр хоры.
Табигатьнең гүя
Кияү көткән чоры...

Шау үлән эчендә,
җәеп ике кулын,
гашыйк күзләр белән
ята
урман угылы...

Июнь җиле исә
үләннәрне тарап.
Ята балачагым
кошлар юлына карап.

Гаҗәпләнгән күккә,
алмый гүя тын да...
Чакырма да —
кайтмас.
Ул бәхетле —
шунда!

## Әхсән Баянов

# Дөньяга ялвару

Заманыбыз — могҗизалы.
Заманыбыз —
Ясалма җепләр заманы,
Ясалма йон,
Ясалма күн,
Ясалма ефәк заманы.

Җирне, айны,
Венераны
Һәм кояшны
Урап йөри
Бәхетле ачышлар,
Бәхетле язмышлар даны.

Заманыбыз —
Ясалма юлдашлар заманы.
Заманыбыз могҗизалы.

Могҗизалар океанында батмадым мин,
Рәхмәт язмышыма.
Үги ата кулы белән сөймәдең син,
Үги ана әчесе миңа бирмәдең син,
Рәхмәт, Дөнья, сиңа.

Яшәүне мин яшьләй танып белдем —
Кысыр кайгы түгел,
Чын кайгылар,
Чын шатлыклар күрдем.
Рәхмәт, Дөнья, шуңа.

Үпкәм дә бар ләкин:
Тугачтан ук, белмим ничек,
Сынаргамы теләп —
Мин сөт сорап үксегәндә
Каптыргансың
Имезлек дип исемләнгән
Буш резинка — ялган имчәк...
Ә соңыннан...

Ә соңыннан,
Туйдым,
Ах, шул чаклы туйдым ялган нәрсәләрдән!
Янгын күргән төсле
Килә кычкырасым —
Кычкыралмыйм, үрсәләнәм.

О дөнья!
Сакла мине ялган нәрсәләрдән:
Ялган дустан,
Хәйләкәрдән,
Әләкчедән сакла.
Сакла мине
Елан телле ялагайдан,
Ялган шөһрәт,
Ялган даннан сакла.

Күрсәтмә син купшы парад, тантаналар,
Кыйгылдашып юха фанфаралар
Тондырмасын колагымны.
Сакла,
Сакла
Тиле шау-шулардан.

Дөнья,
Мин ялварам:
Сакла мине
Барлык ясалма бизәктән:
Барыннан да бигрәк
Ялган сөю,
Ялгыз наздан сакла.
Барыннан да бигрәк,
Сакла
Ясалма йөрәктән.

Сакла,
Еллар сүндералмас
Ялган нәрсәләргә
Йөрәгемдә янган нәфрәт утын.
Шушы туфрак,
Шушы һава,
Су шикелле,
Сиңа булган хак сөюем төсле,
Ул — чын.

Никадәрле кыралмасам
Ялган сүзләр,
Ялган речьләр, вәгъдәләрне —
Мин яратам сине шулкадәрле.

Бу чаклы да мәхәббәткә
Син түләсәң ялган сөю белән —
Мәхрүм ит син, Дөнья, мине
Шушы һава,
Шушы җирдән,
Үзеңнән.

Юк, сатылмый бу мәхәббәт.
Миңа кирәк бары чын мәхәббәт.
Һәм чын бәхет кирәк.

Юк, кирәкми имезлекләр миңа,
Чын сөт кирәк,
Бары чын сөт кирәк.
Һәм син куйма, куйма миңа
Металл йөрәк.

1968

Урман.
Яңгыр көн-төн юа торгач,
Бәллүр төсле иткән һавасын.
Чал табигать карлы душта тагын
Коендыра җәнлек баласын.

Ә бу төштә җуя кан эзләрен...
Әллә аккош, әллә акчарлак —
Тик каурыйлар ята күген сагынып,
Очар булып — ике як канат.

Ерткычы кем аның — этме, кошмы,
Оста мәргән башта атканмы?
«Очкан кошка тидердем бит!» диеп,
Бәлки берәү йөргән мактанып...

Урман шул бу — җитми монда үлән,
Кирәк тагы кан, ит кайсына...
Төн һәм урман — чаршау, юрган бары
Гүзәллек һәм вәхшәт кавышуга.

Дөнья, шулмы синең гармонияң?
Юк, кач, кайгым, кырык чакрым:
Таңка кардай оча,
Ылысларда
Шаулап йөри әнә шатлыгым!

Агачтан ул сикерә агачларга,
Әверелгән дә никтер тиенгә.
Боз өстендә чыр-чу... Минем шатлык
Нидер сөйли бала телендә.

Мондый шатлык җиргә Лорка җаны,
Җәлил каны төсле кадерле.
Юк, уйлыйсы килми,
Кемдер бу дөньяда
Сата алыр диеп шагыйрьне,
Ата алыр диеп шагыйрьне...

1967

## Сентябрь

Артта калган сусау, яну,
Тулгак, дау, ыңгырашу.
Котылган ана баладан:
Сентябрь —
Күзгә басу —
Талып рәхәткә,
Сулышын
Шундый тигез алып,
Йоклый.
Ята таралып —
Тып-тын.

1968

Гомер — биек тау бугай ул.
Көннәргә баса-баса,
Елларга ябыша-ябыша,
Урап мең үлем аша,
Үрмәлим өскә мин һаман:

Үрмәлим картлык дигән
Шыксыз биеклеккә табан.

Зураеп алда офыклар,
Мәхәббәт, бәхет рәхәтен,
Зәһәр җимешен нәфрәтнең,
Егылу, җую хәсрәтен —
Һәммәсен татый күңел.

Тик менүем һич үземне
Күрсәтер өчен түгел.

Менгән саен мин ачыграк
Сизәм, ачыграк күрәм:
Гөмбәзен күкнең кул белән
Сыйпый алмам, тотынып калмам,
Йолдыз булып кабыналмам.

Күгендә җирнең янмам.
Тик барам һаман, барам...

Никтер юк курку, тукталу.
Альп чәчәген кыңгырау
Итәрмен дип ашкынам.
— Чың-чың-чың-чың чыңлатырмын,
Дөньяларга тыңлатырмын.

Һәм шунда тик сикерермен...
Берәр метеор артыннан.

1968

## Җырлый белсә елан...

Юк, килми күз алдына һич
Еланның җырлаганы.
Мәңге мәхрүм тавыштан ул:
Җырламый, ыслый бары.
Шуышып йөрү кирәк шул:
Кемдә юк бәгырь, йөрәк,
Бирмәгән моң, бирмәгән көй —
Табигать әңкә зирәк.
Табигать әңкә зирәк.

Җырласа елан, җир буйлап
Нинди чың китәр иде!
Нинди агулы тавышлар
Тантана итәр иде дә —
Телсез калып барлык кошлар,
Саранча сыман, җирне
Көл итеп, җыен хәшәрәт
Парадка чыгар иде.

Шаулар иде дала, кала.
Тутырып мәйдан, ялан,
Хунвейбин, я бүтән хайван
Исеме йөрткән шам-шалан
Барлык сыннарын Рафаэльнең,
Чый-чи килеп яман,
Сөйрәр иде башларыннан
Үзләре яткан караңгы
Баз, чокырларга табан...

Ярый әле качып, шуышып,
Ул «твист» бии бары:
Ярый әле юк дөньяда
Еланның җырлаганы.

Җырламый, ыслый бары...

1968

●

Була сүзләр —
Тыныч, йомшак сүзләр,
Яфрак сулышына охшаган.

Кычкырмыйлар тамак карлыкканчы,
Мин ишетәм ләкин, ышанам.

Була сүзләр —
Ничек сөйләсәң дә
Оят түгел — изге, гөнаһсыз.
Заман, мәйдан, эшләр, гөрелтеләр
Капламый һич — барысы зыянсыз.

Була сүзләр —
Чәнечкеле еллар
Аша карый безгә миллион күз:
Җәлил кебек ирләр... Мин ышанам,
Кычкыралар алар тавышсыз...

Була сүзләр —
Кычкырсаң да, ләкин
Мин ышанмыйм яман сүзләргә.
Сөйлә, дустым, мин ишетәм сине,
Мин ышанам сөйгән күзләргә.

1968

## Җиңәргә тиеш

Рәнҗеттеләр сине тупас куллар —
Җавап кайтармадың.
Тупас телләр рәнҗеттеләр тагы —
Җавап кайтармадың.

«Гаделлек бар — бөек судья,— дидең,—
Ул барыбер җиңәр!» —
Ә судьяга, киләчәккә барып
Кемнәр нәрсә сөйләр?

Заманнарның чиген булмый узып,
Булмый эшсез, көчсез.
Җиңгән көчләр — гүзәл, зирәк, бөек.
Ә җиңелгән — телсез.

Белә тарих: гадел — җиңүчеләр!
Сүзләре хак, дөрес.
Изге яшәп, гадел үлим дисәң,
Син җиңәргә тиеш.

Син җиңәргә тиеш!

1968

## Элегия

Тукталмый һич тә — башымда эссе, коры җил исә.
Исә җил — соңгы яфрак-сабакларның гомерен кисә.

Хыяллар безнең алда, дустым, тау-тау иде кичә.
Очырдың-киттең бүген ком тауларын, сиздермичә.

Чишмәләр юк, болытлар узды, явып өлгермичә.
Саклыйм күз яше сибеп тик гыйшкымны шиңдермичә.

1968

Мөсәгыйть Хәбибуллин

# ЧЫН ТӨШ

хикәя



Өй каршындагы урам эскәмиядә, бөкрәя төшеп, Гыйлаҗ карт утыра. Аның бар күткәне югары очта күренгән бозау көтүе булса кирәк, чөнки борылмада көтү күренү белән ул аягына басты, кулын каш өстенә куеп, шунда таба карап тора башлады. Аннары зур эш кырырга җыенган кеше сыман, җил капканы ачты да, аягын сөйрәп кенә атлап, өйгә таба китте, бозауга дип, килене хәзерләп куйган ашлы суны алып чыкты. Ул арада, мөгри-мөгри, йортка бозау кайтып керде. Карт аны эчерде, абзарга ябып, сарыкларны каршыларга китте. Күп тә үтми сарык көтүе, аңа тагылып диярлек сыер көтүе кайтты. Сыер кайтып кергәч, Гыйлаҗ карт өсте каплап куйган ләгәнне ачты. Сыер кыстатып тормады, күзләренә кадәр олы ләгәнгә тыгылды, талымсызланып, ашлы суны лапыр-лопыр чөмерә башлады. Гыйлаҗ карт аны сабыр гына көтеп торды. Аннары сыерның мөгезенә бау элде дә абзар кырындагы имән баганага китереп бәйләде. Сыер, әрсезләнеп, багана төбендәге тозны яларга тотынды.

Нәкъ шул чак кече капка шыгырдап куйды. Гыйлаҗ карт күтәрелеп капкага карады. Капкада әле булса кызлар сынын югалтмаган килене Мәфтуха күренде.

— Эткәй, үзем,— диде Мәфтуха этисенә, каударланып, казык башындагы чиләген алды.

Гыйлаҗ карт кулына чыбык тотты да кунакчага менми калган чуар тавыкны куып китте.

— Көш, көш, ләгънәт, бар кунакчана мен, көш! Тавык түгелдер бу, ярканаттыр, мур кыргыры...

— Суярга кирәк аны, эткәй,— диде Мәфтуха килене,— симергәндер ул, шуңа кунакчага менә алмыйдыр, чын әгәр.

— Шулай итәсе булыр, мур алгырын, кияү килгәч пешерербез...

— Эти,— диде Мәфтуха килене,— Таймас кайтмадымы?

Гыйлаҗ карт килененең соравын ишетмәде, ахрысы, өйгә таба атлады. Хәер, аның бар эше шул: булган мал-туарны каршылау иде. Калган эшләр, әйтик, барысы да Мәфтуха килене белән Әхтәм кияве җилкәсендә иде. Әхтәм кияве дим, чөнки Гыйлаҗ картның малае Вәли сугыштан кайтмады. Килене Мәфтуха бер балалы Әхтәмгә кияүгә чыкты. Дөрес, Әхтәм әле булса үз йортында тора. Бик сирәк керә ул бу йортка. Мәфтуха картны ашата-эчертә дә Әхтәме янына барып куна. Әхтәмнең өе бер йорт аша гына, мал-туарлары Гыйлаҗ картта. Әнә шулай килене дә, кияүле дә, мал-туарлы да булып китте Гыйлаҗ карт.

Мәфтуха килене сыерын савып кергәндә, Гыйлаҗ карт такта җәй-

гән караватында намаз укып утыра иде инде. Караватның йомшак сиртмәсен алдырып, тактаны үзе җәйдерде, үзенчә сәке итте ул. Килене сөтне плитәгә кайнатырга утыртты да самовар куеп җибәрде. Гыйлаҗ карт намазын бетергәч, караватына бөкләнеп утырып, тыйнак кына чәй көтә башлады.

— Әти, Таймас кайтмадымы? — дип сорады янә бер тапкыр килене.

— Күренмәде әле ул, килен, чәй эчкәч барып аласы итәрмен, азрак уйнасын инде,— диде Гыйлаҗ карт һәм, тәрәзә төбендәге китабын алып, карчыга борынына күзлеген элде.

Мәфтуха түр тәрәзә каршына басты да уйга чумды. Тышта энгер иңеп килә. Баеп барган кояшның соңгы нуры авылның иң калку җирендәге клуб тәрәзәсенә төшкән һәм шул мәлдә тәрәзәгә ут капкан кебек иде. Мәфтуха үзенең тормышына һәм Әхтәменә булган мәхәббәтен әнә шул кояш нурларына охшата. Әйе, аның йөрәге беркайчан да тынгылык белмәде. Әллә Әхтәмен артыгы белән яратуыннан инде ул? Һәм ул йөрәгенең ешрак кага башлавын тойды. Урамны иңләп, протез аягын шыгырдата-шыгырдата, Әхтәме кайтып килгәнне күрде. Әхтәм Гыйлаҗ картның тәрәзәсенә күз ташлап алды да, карават өстендә сөмсерәеп утырган картны күреп, үз өенә таба үтте. Ә бит бу өй дә аныкы, бу өйдә дә аның гаиләсе тора. Ләкин кияү белән карт арасында үзләре генә белгән ниндидер салкынлык бар иде кебек. Килене Мәфтуха да моны сизә. Ни сәбәптән туган салкынлык икәнен генә белми иде. Болай үзләре бер-берсе өчен үлеп торалар кебек тә бит...

Әхтәмнең аяк тавышын Гыйлаҗ карт та ишетте, күрәсең. Укыган китабын читкә куеп, аяк тавышына колак салды. Әхтәм киявенең кая таба атлавын чамалый иде кебек ул.

— Кияүгә дәшәр идең,— диде ул килененә,— чәй эчеп китәр иде. Өлгерер иде әле укуына да...

— Анда тоткәй көтә аны. Җәмилә тоткәй килгән...

Гыйлаҗ карт яңадан сүз катмады, тамак кыргалап янә кулына китабын алды.

Ул арада самовар да кайнап чыкты. Мәфтуха чәй табыны хәзерләде. Гыйлаҗ карт, ике урындыкны рәткә куеп, өстәл артына кереп утырды.

— Кибеткә сәйлүн чәе килгән диләр, эткәй...

— Иртәгә барасы итәрмен,— диде Гыйлаҗ карт, эшлекле кыяфәт белән.

Чәй эчә башласа, ике-өч чәшке белән генә калмый Гыйлаҗ карт. Самоварны екканчы эчә, тирләп-пешеп чыга, күлмәк сәдәфләрен ычкындырып җибәрә, карчыгыннан калган чигүле сөлге белән бер өзлексез бит-муенын сөртеп тора.

Ниһаять, ул чәй эчеп туйды. Озын итеп амин тотты. Озак утырудан катып калган аякларын ыңгырашып язды. Моны ул, һичшиксез, килененә иркәләнүдән генә эшләде. Аннары караватына барып ятты. Шунда гына Мәфтуха килене киенә башлады.

Гыйлаҗ карт бер ялгызы калды. Ул моның өчен бераз килененә рәнҗи. Ләкин бер хәл дә кыла алмый. Ә бит заманында кырт Гыйлаҗ кушаматын йөрткән шушы кеше өйдәгеләргә күз агын актарып бер генә карый торган иде. Әмма бик күптәнге хәл иде инде ул.

Җир шарын иңләп 1941 ел атлый иде. Гыйлаҗның егерме ике яшьлек улы Вәли Бөгелмәнең укытучылар училищесын тәмамлап кайтты. Заманасына күрә белемле кеше иде ул. Әнә шул яңалыкның сукмагына бер аягы белән генә басып алган Вәли көннәрдән бер көнне, атасы Гыйлаҗны таң калдырып, күрше авылдан ятим үскән Мәфтуханы алып кайтты. Һәм култыклап кергән уңайга, бик үк тәкәллефләнеп тормыйча:

— Менә, әти-әни, сезгә килен, минa кәләш, бүгеннән ул бездә торачак. Үз итегез, үз балагыз кебек күрегез,— диде.

Әүвәлтен үз сүзле, каты куллы Гыйлаж, сөзешергә җыенган үгез кук, башын иеп, малаена һәм булачак киленәнә каш астыннан гына тасраеп карап торды. Күренеп тора: бу җегәрле ир уртасы кеше ни булса да әйтәчәк һәм аның сүзе кайсы якка булса да тик бер генә булачак. Шуңа күрә булса кирәк, карчыгы Гөлҗәннәт авыз ачып нидер әйтмәкче иткән иде, карты шундый итеп күзен актарып карады, Гөлҗәннәт апа, ачкан авызын ябып, алъяпкыч итәген бөтәрли башлавын сизми дә калды.

Әмма кырт Гыйлаж күтәрелеп бәрелмәде. Җилләнеп улы белән килене каршына килеп басты да фатихасын бирде, аннары бер кәлимә сүз әйтмичә, каядыр чыгып китте. Бераздан ул авыл мулласын ияртеп кайтып та керде. Әмма әтисенең хәйләсен аңлап алган Вәли, Мәфтухасын җитәкләп, әнисе белән бертуган апаларына китеп барган иде инде. Шулай да Гыйлаж карт югалып калмады, алай-болай дигән булды да, мулла каршына карчыгы белән үзе басып, балаларына багышлап никахны укытты. Вәгазь беткәч, мулланы сыйлады, уч тутырып акчасын бирде. Карт-корылар сораганда, кем баласы — аның баласы дигән дәрәҗә өчен эшләде ул моны. Шулай итеп, Вәли белән Мәфтуха, законлы загслары янына, ялган никахлы да булып киттеләр.

Ләкин мулланы озаткач, Гөлҗәннәте белән сөйләшүеннән үк күренеп тора, кырт Гыйлаж малаеның бу кыланышына рәнҗегән һәм ул аларның кайтуларын гына көтә иде. Өйдә җил-давыл кубачак иде әле...

Мәгәр алай булмады. Шул көннең икенчесендә сугыш чыкты. Вәли йөгереп кайтып, әтисе белән әнисен кочаклады да, Мәфтухасын үз балалары кебек карауларына вәгъдә алып, Бөгелмәгә китте.

Мәфтуха аны Бөгелмәгә кадәр озата барды. Их, үкенечле булды да соң аерылулары! Оялды ул. Бөтен тәне белән тартынды. Кеше хатыннары кебек, иренең муенына сарылып, сулыгып-сулыгып елый да алмады. Хәтта күтәрелеп туры карарга да оялды. Ә бит күпме үкенде ул соныннан шул кыланышы өчен, күпме яшь түкте! Әле булса күз алдында: поезд кузгалыр алдыннан Вәли аның яңакларыннан учлап тотты да яшь белән һәм яшьлек мәхәббәте белән мөлдерәп тулган кара күзләренә карады.

«Я, Мәфтуха, җаным, хуш!..»

Һәм гомерендә өченче тапкыр иреннәреннән суырып үпте. Мәфтуханың, әйтерсең, кул-аякларын бәйләп ташлаганнар иде. Авыз ачып сүз дә әйтә алмады, кымшана, коча да алмады Вәлиен, таралды да төште. Ничектер бу хәл, бу тамаша аңа төш кебек кенә тоелды. Ә ул төш булмаган, чын булган икән. Моңа Вәлие китеп ике-өч ай үткәч, үле хәбәрен алгач кына ышанды. Ышанды, әмма яшьлек дусты, бер төнлек ире, тәүге тапкыр җан җылысын биреп, ташып торган мәхәббәтен тоеп сөйгән дусты юк иде инде.

Әнә шулай сугыш елларын Гыйлаж карт белән аның карчыгы янында үткәрде Мәфтуха.

Сугыш елларында колхоз фермасын сөйрәргә туры килде аңа. Өе дә, эш урыны да, күңел юаткычы да булып китте Мәфтуха өчен ферма. Монда нибарысы утыздан артык сыер бар иде. Савучы да, мөдире дә, ветврач та, зоотехник та үзе иде ул фермада.

Сугыш беткәч, авылга ир-ат кайта башлады. Дөрес, өмет итеп, Бөгелмә ягына карап елаучылар да күп иде. Әллә инде кеше шатлыгы кайгыларны җиңеләйтә иде, әллә тынычка калу юаныч бирә иде. Фермада шактый үсте, терлекләр саны йөзгә җитте. Савучылар артты. Ферманы да идарә киңәше, председатель теләге белән дигәндәй, бер аягын фронтта калдырып кайткан Әхтәмгә тапшырырга туры килде Мәфтухага. Нәкъ шул айларда улын көтә-көтә әнкәсе Гөлҗәннәт тә дөнья куйды. Мәфтуха җитмешне куып барган әтисе Гыйлаж белән икәүдән-икәү генә калды. Ләкин җегәрле карт иде әле кырт Гыйлаж. Шул сәбәпле

булса кирәк, карт белән киленс «арасы» турында авыз чайкаучылар да булды. Әмма бу дөрес түгел иде. Мәфтуха Әхтәмгә гашыйк булды. Дөрес, Әхтәм зрә дә эре кыланды. Күкрәге тулы орден да медаль — кыланырлыгы да бар иде шул. Авыл тулы кызлар булса да аллә нигә ул Мәфтухага бәйләнде. Әүвәл баш Мәфтуха ана кырт кисте. «Әхтәм, без бит бергә эшлибез. Син — егет кеше, мин — хатын. Болай да тел кашучылар күп, йөрмә, кирәкмәс...» — диде.

Ләкин моның белән ул Әхтәмнең йөрәгенә ут кына өстәде. Әхтәм Мәфтухадан башка эшли дә, хәтта уйлый да алмады. Бәлкем, моңа Мәфтуханың эш дигәндә чаткы сыман атылып торуы да сәбәп булгандыр. Савучы кызлар аны тыңлыйлар, яраталар, ихтирам итәләр иде. Ә бит кешенең абруе коллектив үстергәндә генә тулы була ала. Моны яхшы аңлый иде Әхтәм. Мәфтуханың ярдәме кирәк иде ана. Бик кирәк иде. Ләкин әнә шул ярдәм, бергә җигелеп эшләү ике арага кызыл җеп сузар дип күз алдына да китермәгән иде ул. Мәфтухасыз торалмый башлады Әхтәм. Ятса — Мәфтуха, торса — Мәфтуха булды күз алдында.

Һәм көннәрдән бер көнне ул ана чишелде. Яратуы, ансыз, Мәфтухасыз торалмавы турында әйтте.

Печән өстендәге җәйге җылы кыска төн иде. Алар җәйләү яклап дымлы печән чабып салган арбада кайталар. Авыл өстенә эңгер иңеп килә. Туры бия, дилбегә какмауларына тынычланып, пошмый гына атлый бирә. Әхтәм аксак аягын арба буйлап сузып салган да янәшәсендә утырган Мәфтухага карап кайта.

— Мәфтуха!..

— Әү, Әхтәм!..

Әхтәм борсалана, кесәсеннән кисетын чыгарып, тәмәке төрә. Һәм тирән итеп эчкә алып, авыз-борыны тишекләреннән сыгаеп калган төтен чыгара. Авыл ягыннан урманга таба каргалар, жим эзләп сонга калган саесканнар очалар. Выжлап үткән канат тавышлары гына ишетелеп кала.

— Мәфтуха, кайтмыйк бүген?.. Куныйк шушында, урман кырыенда?..

Мәфтуха дәшми. Әллә нинди уйлар килә аның башына. Вәлис кайтып төшсә? Ләкин кара кәгазь күз алдына килдеме, тагын йөрәге талпынып куя. Әхтәм белән тора алырмы ул? Ә бит Әхтәмнең аны алдап куюы да бар. Ләкин Әхтәмнең кайсы ягы беләндер сөтле кофены хәтерләткән күзләрен күрдеме, булган шиге чәлпәрәмә килә: әйе, ул аны ярата, бик ярата.

Әхтәм атны урман читендәге имән каршына туктатты да кисәк Мәфтуханы кочып алды. Мәфтуха бер аяклы Әхтәмнең тәмәке исе килеп торган кайнар сулышын, көчле кулларын беренче тапкыр үз тәнендә әнә шунда тойды.

Мәфтуха бәхетле иде. Соң күпме кирәк кешегә аны бәхетле итү өчен?!

Кайтавазлы мәхәббәт һәм җаны теләгән эш. Калганы аның барысы да үз кулында.

Килененең Әхтәм белән «уралуын» Гыйлаж картка да житкерделәр. Карт капыл үзгәрде. Килененә әдәм рәтле дәшмәде, сәламен алмады, ясаган чәен эчмәде.

Мәфтуха килене картның хәлен яхшы аңлады. Әмма кул гына селекте: «Үз җаең гына уйлап, юләрләнеп йөрмә әле, ясаган чәем эчмәсәң, үзең көйләрсең дә эчәрсең... Житәрлек карадым инде мин сезне»,— дип фикер йөртте. Әмма Гыйлаж картка явыз ният тотмады ул. Карт эндәшмәсә дә, сәламен бирде, чәен куйды, ашын пешерде, мунчасын якты. Әйтерсең, картның ачуын да күрмәде. Һәрхәлдә, күрмәскә тырышты.

Ләкин картның нияте олыдан иде. Бер көнне шулай кич белән идарә яклап кайтып килүче Әхтәмгә каршы чыкты бу. Һәм бала башыдай йодрыгын күтәреп, күкрәген Әхтәмнең түшенә терәде дә:

— Күрше булсаң, кеше бул, аздырма киленне! Ишетәсеңме, ниятең әшәке синең, Әхтәметдин... Бел аны, егет, инбалит дип тормам, икенче аягын сугып сындырырмын! Әйтте диген, колагыңа нык ал!!.— диде.

Әхтәм дәшмәде. Сул кулы белән картны этеп җибәрде дә, күкрәгенә тулып барган ярсуын баса алмыйча, йөгерә-атлый китеп бармакчы итте. Ләкин икенче мәлдә тыела алмады, кулындагы таягын күтәреп:

— Кит юлымнан, карт җен! Әллә үзең өйләнмәкче идеңме киленеңә?!.— диде һәм читкә тайпылып калган картка борылып та карамыйча, титаклый-титаклый китеп барды.

Икенче көнне үк вакыйганы Мәфтухага сөйләмәкче булды Әхтәм. Әмма Мәфтуха, күрмәмешкә салынып, аның яныннан үтеп китте. Ашыгуы идеме? Кая таба? Бит һәр көн тукталып, бер-ике авыз сүз әйтеп китә торган иде. Әхтәм оялды. Оялды һәм гарьләнде. Күңеленә шом төште? Әллә чынлап та?..

Ләкин Мәфтуханың ни өчен эндәшмәвен анык кына белмәде ул.

Шул ук кичне менә нинди сөйләшү булган иде Гыйлаҗ карт белән килене арасында. Мәфтуха кайнатасын ул көнне танымады. Картның башы-күзе тонган, йөзе кәбестә яфрагыдай яшәргән иде. Өйгә керде дә ишек катынннан үтмичә:

— Килен, хакмы бу, гайбәтме? — дип сорады.

— Хак, эткәй... Алса, мин аңа барырга булдым...

Гыйлаҗ карт кисәк сөрлегеп киткәндәй булды, ишек янагына тотынып, мич буендагы эскәмиягә утырды. Мәфтуха курка калды. Йөгереп мич артыннан чүмеч белән су алып килде. Гыйлаҗ карт чүмечкә күтәрелеп карамады, эчәм-эчмим димәде, сыңар кулы белән каршындагы чүмечне этеп җибәрде дә бөтен ярсуын берьюлы тыярга теләп:

— Вәлине кайтмас дисеңме? — диде.

Мәфтуха Вәли сүзен ишетү белән агарынып китте.

— Эткәй,— диде ул, кулындагы чүмеченең суы түгелүен тоеп,— эткәй, алай димәсәнә...

һәм буш чүмечен өстәлгә куйды да мендәренә барып капланды.

— Кешеләргә кара язу килгәләде бит. Әнә кайта торалар, хәбәрләре ишетелә тора,— дип ашыгып сөйләргә тотынды Гыйлаҗ карт, әйтер сүзен әйтеп бетермәстәй булып,— син дә көт бераз... Кем белә бит, бәлкем, ризыгы калгандыр әле...

Мәфтуханың кыланышын ни дип юрарга да белмәде Әхтәм. Җыелышларда да сабырланды ул. Булган киңәшләрен әйтте дә активлашмыйча гына утыра бирде. Әнә шулай кыш житте. Әхтәм дә ферма эше, дөнья мәшәкате белән буталып, онытылып йөрде. Еш кына салган баштан эшкә килүен дә күрә башладылар.

Кибеттә Бөгелмәдән килгән бер чибәр эшли иде, шуның янында урала диделәр савучылар Мәфтухага. Алар Мәфтуха белән Әхтәм арасында булган хәлләрне бик яхшы беләләр иде.

Мәфтуха кайтарып сорамады һәм үзе дә эндәшмәде. Ниндидер мәзәк сөйләп ташлады, күрәсең, сиздермәскә тырышуы иде. Ләкин йөрәгенең кысыла баруын, күкрәк түрендә барысы өчен дә үкенү, ярсу ялкыны үсә баруын тойды ул. Чынлапмы?!

Әмма кызлар белми сөйләмәгәннәр икән. Яңа елга Әхтәм чынлап та кибетче кызга өйләнеп алды. Тату гына тора башладылар. Эшкә дә Әхтәм үз вакытында килде. Мәфтуха белән берни дә булмаган кебек, иптәшләрчә сөйләшергә тырышты.

Яңа эссе, жылы жәй килде. Әхтәм хатынын бала табу йортына илтеп куйды. һәм шул төнне үк, протезына каз мае сөртеп, Мәфтуха жәй йоклый торган келәткә килде.

— Синнән башка торалмыйм, Мәфтуха. Бәхетсез мин,— дип өзгәләнде ул, башын Мәфтуханың күкрәгенә салып. Мәфтуха эндәшмәде. Булган жан жылысын бирде. Башка куанычы калмаган иде аның. Әмма

вөжданын нидер кимерде. «Намус кулмәк кебек икән ул, кигән саен бәрәкәте, кадере бетә»,— дип фикер йөртте ул. Шул ук вакытта ташып китәргә торган хисен Әхтәмнән башка берәүгә дә бирә алмый иде ул. Юк, юк, берәүгә дә. Ә Әхтәм бүген әнә үзе килгән.

Ләкин элекке кайнарлыгын тоймады Мәфтуха Әхтәмнең. Хатын-кызларга хас бер сиземләү белән анлады: Әхтәм анык түгел. Өшегән һәм сүрелгән җанын эретергә генә килгән. Хатыны кайту белән эзен суытачак бу тирәдән. Әхтәмнең өзгәләнүен ялганга санады, ышанмады. Бу хәлнең күңелле бетмәвен аңлатып:

— Моннан бүтән килмә инде, Әхтәм җаным. Семьяң бозылмасын, тату торыгыз,— дип үгетләде.

Әнә шулай көннәр, аңа ияреп атналар, айлар үтте. Мәфтуха да, Әхтәм хатыны бала күтәреп кайткач, йөрәк дәртен тыярга өйрәнде, сабырланды. Аңа ничектер вөҗданы кушмады моны эшләргә. Юкса, Әхтәм жай килгән саен сугылгалап та карады. Әмма Мәфтуха кырт кисте:

— Бусагамны атлап керәсе булма, Әхтәм. Ачу тотып йөрмим, әмма яңадан керәсе итсәң, үпкәләмә,— диде.

Ире белән хатын арасындагы мөнәсәбәтне үз хатыны иң соңыннан ишетә торган булса да, иренең Мәфтуха белән «буталуы» турындагы яман хәбәр иең хатынына да килеп житте. «Димәк, буш сүз булмаган»,— дип уйлады яшь хатын. Аның әти-әнисе Бөгелмәдә яши иде.

Әхтәмгә ул болай диде: «Тагын кабатлана икән, баланы калдырам да китәм, яшә теләгән кешең белән»,— дип янады. Әхтәм каршы бер сүз дә катмады. Кызгылт чәчен йөзенә төшерде дә утыра бирде. Соңгы айларда тагы да сала-төшерә башлады ул. Сәбәбе дә табылды — машина алды. Инвалид машинасын алгач, ул көн чамасы баш күтәрми «юды», эшкә йөрмәде. Аның урынына Мәфтуха эшләп торды. Ул гына да аз тоелды Әхтәмгә, көн аралаш хатынын машинасына утыртты да Бөгелмәгә кунакка чапты. Фермадагы бөтен эшне янә Мәфтуха сөйрәде. Ул Әхтәм өстеннән дәгъва итмәде, идарәгә җиткермәде. Булдыра алган кадәр үзе башкарды. Әмма Әхтәмнең бу эшенә председатель һәм идарә членнары түзеп килсәләр дә халык чыдамады.

— Нәрсә, бер кешегә ике камыт кигертәсез! Нигә үзе эшләми, көн туса, Бөгелмәгә чаба. Эчмәгән көне юк, сукмагән кешесе калмады. Бозылды Әхтәм. Юлдан язганчы, алыгыз фермадан үзен,— дип, идарәгә үк килеп әйтә башладылар.

Һәм йөри торгач үзләренекен иттеләр. Чираттагы идарә җыелышы Әхтәмне фермадан алырга һәм вакытлыча фуражир итеп куярга булды. Ләкин бер шешә юлына баскан Әхтәм анда да озак эшли алмады. Фураж сатып эчкәләде. Сизделәр, белделәр дә аннан да чыгардылар.

— Миңа эш кирәкми, ике кулыма бер машинам бар, ашарга пенсиям житә, ялынмыйм мин сезгә,— диде соңгы сүзе итеп Әхтәм. Һәм шуннан соң бөтенләй юлдан язды. Көн эчте, төн эчте. Читән, ихата буйларында кем ауный дисәң, ул, Әхтәм, исереп ятты.

Бу тамашаны күреп торган Мәфтуха йөрәге сыкрап елады. Әллә нигә җәлләде ул Әхтәмне. Ә бит күрә алмаска тиеш иде. Юк, алай итә алмады. Ялынып сораган чакта акчасын бирде, үз туганыдай итеп кызганды. Һәй, Вәлие исән булса, шул көнгә калыр идеме ул! Ниндидер Әхтәм белән язмышын бәйләр идеме! Вәлие турында уйлады мы, Мәфтуханың ин нечкә хисләре уяна. Ләкин шунысы гаҗәп, ул аны төшендә күргән итеп кенә хәтерли иде.

Әнә ничек изге иде аңа Вәлинең мәхәббәте!

Ләкин ул ике аягына нык басып чын тормышта яши, кулы, зиһене белән эш башкара, дөнья көтә. Хезмәт хакын ала, бәйрәм көннәрендә теттереп ял итә, күңел ача. Кеше күңеле — дәрья ул, онытылып, шашынып аласы килә кайчак. Мәфтуха да әнә шундый уй-хискә бирелеп, япа-ялгызы урман-кырларга чыгып китә. Әнә шунда җегәрлеге, кайнар-

лыгы ташып торган табигый бер хис уяна аңарда. Ә нигә аңа шул вакыт ярсыган йөрәген басып, тулып торган хисне урнына куеп, кемнеңдә булса көчле күкрәгенә сыенмаска! Нигә аңа шунда бер селкенеп, иркәләнмәскә?! Кем сөйми иркәләнүне? Һәркемнең моңа хакы бар лабаса!

Ләкин әнә шулай дип уйласа да, һичкайчан алай эшләмәде Мәфтуха. Бөтен көч-җегәрлеген эш-хезмәтенә бирде. Алай-болай үтсен-китсен дип кенә эшләмәде, юк, бөтен җанын-тәнен биреп эшләде. Тотынган эшендә, башкарган хезмәтендә һәрвакыт шатлык, күңел юанычы тапты. Кайчак төнлә белән дә фермага килеп китә торган иде. Шунда бер төнне Әхтәмне очратты ул.

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн иде. Ферма утары уртасындагы бердәнбер лампочка тирә-юньне тонык кына яктырта. Абзардан чыгып килгәндә Әхтәмнең күптән таныш булган протезы шыгырдавын ишетте Мәфтуха. Ишетте дә йөрәге талпынып куйды. Әллә ялгыш ишеттеме? Кага башлаган йөрәген басарга теләгәндәй, кызу-кызу атлап, капкага таба китте.

Колагы ялгышмаган икән, капка баганасына сөялеп Әхтәм басып тора. Багана башындагы лампочка яктысы аның сөяп куйган алюминий таягын яктырта. Мәфтуха күрмәмешкә салынып үтеп китмәкче итте. Ләкин күкрәк түреннән чыккан, гитара кылыдай калтырап киткән тавыш аны туктарга мәҗбүр итте.

— Мәфтуха!..

— Сез нишләп йөрисез монда, Әхтәм? Төн ич!..

Әхтәм өмсенеп куйды, бер адым ясап, яктыга чыкты.

— Мәфтуха, сиңа бер сүзем бар иде...

— Я соң, әйт! — диде Мәфтуха, бераз тынычлана төшеп.

— Мәфтуха,— Әхтәм үрелеп сөяп куйган таягын алды,— нишләргә инде миңа, хатын китәм ди?..

Мәфтуха дәшмәде, авылга таба кузгалып китте. Әхтәм аңа иярде. Менә ул адымын кызулата төште дә Мәфтуханың җиңенә кагылды.

— Мәфтуха, нишләргә инде миңа?.. Син минем бердәнбер кешем... Башка кешегә әйтә алмыйм...

— Әхтәм,— диде Мәфтуха, җемелдәп торган йолдызлар белән мыжгып тулган күк гөмбәзенә карап,— син нигә минем янга киләсең? Бит мин сиңа ничә тапкыр төнлә кермә дип әйттем инде! Ишетәсеңме, Әхтәм, мин вөҗданыма тап төшерергә теләмим... Булды — үтте, китте. Һәр нәрсәнең бер чиге булырга тиеш... Без синең белән ир һәм хатын түгел. Алдың — тора бир. Ир — баш, хатын — муен. Барысы да үзеңнән. Эчмә. Үз чамаң бел!

Һәм тиз-тиз китеп барды. Авыр иде бу сүзләрне әйтү Мәфтухага, һай авыр иде! Әмма башкача булдыра да алмады ул. Аны халык хөрмәт итә, абруен төшерәсе килми иде. Янә бер гайбәт таралсынмы?.. Юк, юк, тагын бер тапкыр юк. Ул аңа килергә рөхсәт итмәскә тиеш!

Ләкин ике көн дә үтмәде, имчәк баласын күтәреп, Мәфтухага Әхтәм килеп керде.

— Китте,— диде ул, шаккатып торган Гыйлаҗ картка һәм өнсез калган Мәфтухага карап,— баланы да калдырып китте...

Гыйлаҗ карт белән Мәфтуха аптырап калдылар. Карт бер балага, бер йөзе-күзе шешенеп беткән Әхтәмгә карады да Мәфтуха килененә ым какты.

— Баланы ал, килен!.. Утыр, Әхтәметдин!..

Мәфтуха баланы алды да ишекле-түрле йөреп китте.

— Ии... Әхтәм җаным, тагын ни тамаша кылуыгыз инде?! Кеше ни әйтер?.. Мин нишлим бу бала белән?.. Имчәк баласы гына бит әле ул!..

Әхтәм дәшмәде, бакыр чәчен сипкел баскан йөзенә төшереп утыра бирде.

Гыйлаҗ карт шыңшып торган балага, мескенләнеп киткән Әхтәмгә аптырап карап торды. Карап торды-торды да:

— Килен, ни, әллә бүгенгә кунсынмы?.. Кеше башына бәла төшкәч, күршегә керми, кемгә керсен. Туганың килсә, кунак ит, күршең керсә, туган ит, дигәннәр картлар,— диде.

Ләкин Мәфтуха карт ягына әйләнеп тә карамады.

— Әхтәм,— диде ул, каядыр почмакка төбәлеп,— бар син аның артыннан, китсә этиләренә киткәндер... Ялын, ялвар, итмә баланы ятим!..

Әхтәмнең күзләрендә яшь ялтырады, ул башын тагы да ия төште.

— Бармыйм мин анда, килмәячәк ул!

— Юк, син барасың, Әхтәм, бармаска хакың юк. Ишетәсеңме, хакың юк! Ата син, бала атасы. Ә ул аның анасы!

Әхтәм акрын гына торды да, башын-күзен күтәрмичә, чыгып китте. Бераздан аның машина тавышы ишетелде.

— Китте,— диде Гыйлаҗ карт. Йоклаган баланы үз караватына салырга кушты.— Синекеннән егылыр ул, тимәс борын селкенеп тора бит...

— Әткәй, син ят, ял ит. Мин аны үзем карармын...

Мәфтуха баланы караватка салды да исе китеп аның нәни йөзенә карап торды. Бала, суеп каплагандай, әтисенә охшаган иде. Хәтта очлаеп килгән ияге дә, каш-колаклары да, кылган башы кебек ап-ак чәче дә Әхтәмнеке иде. Шул мәлне Мәфтуханы Гыйлаҗ картка әйтергә түгел, күңел тутырып уйларга да курыккан бер хис уянды.

«Әгәр бала чынлап та аңа калса? Әхтәм аларга күчеп килсә?»

Һәм үз уйларыннан үзе үк куркып, Гыйлаҗ карт ишетмәдеме, белмәдеме дип, әткәсенә таба карап алды. Гыйлаҗ карт намазына утырган иде. Дөньясын онытып намаз укый иде. Мәфтуха көзге алдына килеп басты. Һәм капыл әллә ниләр уйлап ташлады. Яшь түгел иде инде ул. Һай, яшь түгел иде! Әйе, аның йөзенә тормыш нужасы эз салмыйча калдырмады. Маңгай өстен, күз төпләрен җыерчыклар ермаклаган. Кыз чагында елмайганда барлыкка килә торган бит очындагы мөлаемлык чокырлары да тирәнәйгәннәр, ияк асты җыерчыкларына килеп кушылганнар. Ләкин җете кара күзләр, сирәк-мирәк агара башлаган чәчләр бөтен бит-йөзенә төкәнмәс мөлаемлык өстәп торалар иде әле. Беренче карауга шактый яшь күренгән чыраенда тагын әллә нинди картаю галәмәтләре күрде Мәфтуха. Юк, яшь түгел инде ул, яшь түгел иде.

Менә бала уянып китте. Намаз укып утырган Гыйлаҗ карт тиз-тиз генә амин тотты да:

— Карале, килен, әллә ашыйсы килә микән? — дип сорап куйды.

— Шулайдыр да бит, әткәй...

— Әллә мәйтәм, иске өйгә чыгып сөт кайнатып алып керимме?

— Бар сон...

Бала көйсезләнә башлады, башын уңлы-суллы борып, имчәк эзләде. Аннары нәүмизләнеп йөзен чытты, әче итеп елап җибәрде. Мәфтуха кисәк таралып, каушап калды. Кулга алып та, идән буйлап селкеп йөреп тә туктамады бала, үкерүен генә белде. Мәфтуха шулкадәр дулкынланды, каушады, шыбыр тиргә батты. Ахырда чыдар әмәле калмагач, буш имчәген чыгарып салды да бала авызына каптырды. Үкереп елаган бала бер мизгелгә туктап калды. Мәфтуханың ярсып типкән йөрәге, уч төбенә эләккән кош кебек, калтырана башлады. Анарда үзе дә аңламаган ана булу хисе уянды. Гүя ул аның баласы, гүя ул чынлап та үз баласын имезеп утыра. Һәм ул, талымсызланып, үз итеп баланың нәни йөзенә карый. Карый да башына килгән уеннан, үз шәүләсеннән курыккан карак кебек, куркып китә.

Юк, бәхетле булмады ул. Язмыш ана һәрчак аяк чалды. Табып үстерә алмады ул бала. Валидән узмады... Ә менә хәзер, кулына нәни бала алгач, ана булу теләгенең үсә баруын тыю бик тә кыен иде аңа. Әйе,

юкка, юкка Әхтәмнән бала тапмады. Явыз теләрдән, гайбәттән коты алынды. Барысына да төкерәсе дә табасы булган да бит.

Һәм кайдадыр йөрәк түрендә өмет чаткысы кабынып китүен күргәндәй булды ул. «Әхтәмнең хатыны баласын алырга килмәсә, Әхтәм белән алар тора башласалар?»

Уеннан, хыялыннан үзе үк куркып китте. Ләкин бер туган уй-хыялны тиз генә күңелдән алып ташлап булмый икән ул. Менә ул Әхтәм белән кинога бара. Юк, менә ул Әхтәм белән урам эскәмиясендә утыра, ә яннарында Таймас уйнап йөри... Шушы Таймас, кулындагы Таймас!..

Ләкин чын тормыш һәрчак усал була. Бала, сөт килмәгән коры имчәккә риза булмыйча, янә елап җибәрә. Мәфтуха аны күкрәгенә кыса да идән буйлап йөреп китә.

— Җыламасана, нәнием... Җылама. Хәзер бабаң сөт кертер...

Ул арада чүмеч белән кайнаган сөт алып, Гыйлаҗ карт килеп керде.

— Әткәй, бик кайнар түгелме соң?

— Суыттым...

Гыйлаҗ карт килененең йөзе буйлап яшь агуын күрүгә тетрәп китте. Чүмеч тоткан куллары калтырый башлады.

— Сабыр ит, килен... Мин карт кешегә рәнҗемә инде син... Менә калак белән эчереп тор булмаса. Шешәсе бар да бит, имчәге юк... Бозау имезлеге ярамас инде?..

Мәфтуха яшь тулган күзләре белән әтисенә карап алуга ук төшенде, карт шаярып сөйләми. Карт нигәдер рәнҗи, үкенә...

— Әллә үзләренә кереп аласыңмы, әткәй? Ишекләренә калак кына тыгып йөриләр бугай алар...

— Әйе шул...

Резин имезлек каптырып ярты шешә сөт эчергәч кенә бала йокыга китте. Гыйлаҗ карт өй түбәсенә менеп дөбер-шатыр килеп чормада йөрде. Бераздан ул киндере уңып беткән бишек күтәреп төште.

— Хәзер мин аны рәтлим, килен... Бала бишек ярата ул... Тирбәттең исә, оеп йокыга китә... Вәли мәрхүмнең бишеге иде...

Һәм Вәли сүзен әйтүгә агарып киткән киленен күрде дә ялгыш ычкындыруына үзен-үзе тиргәп алды. Сүзне тизрәк икенчегә борды.

— Кай тирәгә элим, синең караватың янынамы? Юкса, үзем дә карар идем... Барыбер күзгә йокы керми минем...

— Үзем карармын инде мин аны, әткәй. Менә монда эл, минем караватат янына...

Мәфтуха елаудан туктаган, тынычлана төшкән иде инде. Гыйлаҗ картның ду килеп, балага сөт кайнатып, бишек элеп, мендәрләр салып йөрүе аңарда әтисенә карата кызгану хисе уятты. Беренче тапкыр, күп еллар бер өйдә торуга беренче тапкыр, үз әтиседәй итеп күрде ул аны. Кисәк картка нәрсәдер әйтәсе, җылы итеп сөйләшәсе килеп китте. Ләкин карт аңар ятарга, бала йоклаганда черем итеп алырга кушты.

Ятса да күзләренә йокы кермәде Мәфтуханың. Йокыга китсә шунда ук саташып уянды, кемгәдер янады, кемнедер орышты. Әллә елап арыганга, әллә күп итеп сөт эчкәнгә, бала тыныч йоклады.

Тик таң алдыннан гына тынып йокыга китте Мәфтуха. Күпме йоклагандыр, анысын хәтерләмим. Ул уянып киткәндә, түр тәрәзәләрдә таң нуры уйный, ярсып-ярсып әтәчләр кычкыра иде.

Мәфтуха, күзләрен йомган килеш, бала өстендәге кулы аша нәнинең тигез сулыш алып йоклаганын тойды. Һәм кисәк сискәнеп китте. Аның кулына эре сөякле салкын бармаклар тиеп китте ләр. Мәфтуха күзләрен ачты һәм бакыр башын иеп, бала бишеге янында утырган Әхтәмне күрде. Күрде дә бу хәлнең өнендәме, төшендәме икәнен белергә теләгәндәй, эре сөякле таныш кулны тотып карады.

Һәм сөякчел бармакларның үз кулын кысуын сизүгә, күңел түреннән бәреп чыккан кайнар яшьләренә ирек биреп:

— Кайттыңмы? — дип сорады.

## Фәнис Яруллин

### Кешелек якыная Ильичка

Яктылыкны сөйгән кешеләр
Биегенә менә кыянын;
Дөнья бора йөзен Ильичка,
Анда күреп иң зур хыялын.

Гаделлекне сөйгән кешене
Туктаталмый аны бер көч тә;
Дөнья укый безнең Ильичны,
Якыная кешелек Ильичка.

### Ике елга

Икебез ике елга идек,
Икебез ике юлда идек;
Бер булганга агышыбыз
Очраштырды язмышыбыз.

Тирәнәйде суларыбыз,
Көчебез дә артсын инде.
Бер кушылган гомер-елга
Аерылмыйча аксын инде.

### Төсләр

Күңелдә төсләр күп минем,
Яшеле, зәңгәре бар;
Зәңгәр томанга төренгән
Яшьлекнең ямьнәре бар.

Күңелдә төсләр күп минем,
Сарысы, көрәне бар;
Башларымның бик күп кенә
Сагышлар күргәне бар.

Күңелдә төсләр күп минем,
Кызылы, аллары бар;
Ал төсләр сибеп кабынган
Мәхәббәт таңнарым бар.

Күңелдә төсләр күп минем,
Агы бар, карасы бар;
Шул төсләрне һәр шигырьгә
Аралап аласы бар.

## Клара Булатова

# Мөмкиндер дә кебек...

Карлыгачтай кыйгач кашкайлары,
Йөзе аның алсу таң сыман...
Тик шаян хис җиле кагылмастай
Бер салкынлык анда бар сыман.

Шуңа бездә аңар шаян караш
Салмый хәтта иң шук егетләр.
Нигә соң, и, ана шулай саксыз
Елмайдың син бүген, секретарь?

Аның да бит йөгерек җилдәй чагы,
Күбәләктәй чагы бар иде.
Дүрт ел көткән, йөрәгендә йөрткән,
Көтеп алган яры бар иде.

Коңгырт күзләр иртән көлгән иде,
Ул күзләргә кичен яшь тулды.
Ул ярына иртән кәләш иде,
Кәләшлектән кичен тол булды.

Үлде Рәис. Үлде —
Урамнарга
Тәңкә карлар яуган бер кичтә.
Вахтасыннан кайта алмады ул...
Иртәгесен Сара ишетә:
— Авария «өч йөз егерме»дә,
Мастер үлгән.
Хәбәр иттеләр...
...Ничә тапкыр инде урамнарга
Тәңкә карлар явып үттеләр.

Ничә тапкыр алар эределәр,
Эремәде сагыш һич кенә.
Чигә бөдрәләрен җыйды Сара,
Көрән күлмәк киде өстенә.

Тыныч кына яши кебек шулай,
Тыныч кына тәртип өендә,
Тыныч кына йөри эшендә дә,
Юктыр кебек тыштан берни дә.

Тик күзләре җиргә төбәлгәннәр,
Бер-берсенә кашлар тартылган.
Шаян хисләр җиле кагылмастай
Бер салкынлык анда бар сыман.

Шуна бездә ана шаян караш
Салмый хәтта иң шук егетләр...
Нигә соң, и, аңар шулай саксыз
Елмайдың син бүген, секретарь?
Күрденме син шуны: Сарага бит
Үз яшен дә килми бирәсе.
Тик яктырак көлмәк киясе дә,
Бөдрәләрен ингә сибәсе.
Елмаясы... Ләкин күзләрдәге
Тирән сагыш ничек югалсын?
Ул кайгысын кем соң оныттырсын,
Кем коткарсын аннан, кем алсын?
Яшьлектәге ярсу дулкыннарны
Кабатларга тагын йөрәктә,
Мөмкиндер дә кебек, түгелдер дә,
Кирәкми дә кебек, кирәк тә...
Юк, кирәкми! Юк, юк, кирәк түгел,
Үткәннәргә тугры ул хисләр,
Тик шулай да аңар болай саксыз
Ник елмайдың бүген, секретарь?..

## Сөйләр сүзләр әле никадәр...

Ерак юлга чыгар көннәреңдә
Әллә инде вакыт җитмәгән,
Башларымны салып иңнәреңә
Сөйләр сүзләр әле бетмәгән.

Юл төенеңә авырттыра торган
Авыр йөкләр бүген төйнәмим.
Тик ул якка юл алганда сиңа
Юлдаш булсын якты теләгем.

Җырлар белән алып кайт син чорның
Һәркайдан да яңа сулышын,
Илкәеңә сакла көчле җырың,
Сөйгәнеңә — йөрәк җылысын.

Җырлар сузам кайтыр көннәреңә,
Бәлки, сиңа барып җитәрләр.
Башларымны салып иңнәреңә
Сөйләр сүзләр әле никадәр!..

Яфрак-яфрак булып кар яуганда
Урый идек карлы юлларны.
Урамнарны ялгыз ураганда
Бер исенә төшер шуларны.

Киң урамнар безгә тар иде дә,
Нинди якты, матур чак иде.

Юлларыбыз ап-ак кар иде дә,
Уйларыбыз кардан пакь иде.

Шул елларның юлга яткан кары
Эремәгән кебек һаман да.
Бер исенә төшер шул чакларны
Яфрак-яфрак карлар яуганда.

## Кайда булдың, дисең

Кайда булдың,— дисең,— моңа кадәр?
Ничек сине таба алмадым?
Белмим, синме үзең ашыккансың,
Белмим, минме соңга калганмын.
Хәзер инде синең тормышыңда
Яратсам да юлдаш булалмам.
Миннән алда чөнки язмышына
Башка берәү кереп уралган.
Очрашканда йөрәк еш типсә дә,
Тартылабыз, ахры, шунлыктан.
Кайчак синең кыюлыгың җитми,
Ә кайчакта никтер мин куркам.
Күңелдәге телдән әйтә алмый,
Кайнар хисне тыеп киләбез.
Шуңа ул да, мин дә, син үзең дә,
Өчебез дә газап чигәбез.
Күзләреңнән күрәм: яратасың,
Миннән башка яши алмыйсың.
Хисләреңне сынап карамыйча
Ник ул чакта аны алдың соң?
Юк, ташлама миңа андый караш,
Кысылса да сулыш аңардан.
Кушылмаган кебек ай һәм кояш
Кавышулар безгә язмаган.
Файда бирмәс инде очрашулар,
Көчәйтсә дә йөрәк янганын.
Белмим, синме үзең ашыккансың,
Белмим, минме соңга калганым.

●

Сукмакларга сары келәм түшәп,
Каен яфрак коя.
Яфрак коеп көзге җилләр иссә,
Җаным сыкрап куя.

Яфрак коеп көзге җилләр иссә,
Туйлар чоры керер.
Көз җиттеме — авыл бәйрәм көтә,
Туен көтә кемдер.

Көз җиттеме, авыл бәйрәм көтә,
Туен көтә бар кыз.

Пары белән бар да, яры белән,
Бер мин генә ялгыз.

Пары белән бары, яры белән,—
Туйлы көзләр җитсә...
Сукмакларга сары яфрак түшәп,
Көзге җилләр иссә.

Сукмакларга сары яфрак төште,
Өзгәләнә күңел,
Җан яраткан, күңел тарткан кешем
Үземнеке түгел...

## Айдар Хәлим

### Кайсыгызны юатыйм?

I

Мин сине бик көттем, әти!
Кичләрен, өемдәге өчле лампаны
сукырайтып,
Күктә якты йолдызлар кабынганда,
Ялан аяк болдырдан торып,
Үткән самолетларга
оран сала идем:
— Әтине кайтарыгыз!
...Мине зарыктырган ал парашют
менә-менә ачылыр,
Чыгар аннан, шатлыгыннан шашып,
Хәрби киемле иң изге кеше,
Уң кулында — автомат,
Сул кулында бер түтәрәм
ап-ак икмәк тотып...
Дип көтеп торганда,
Шыксыз таулар,
Зиһенемне чуалтып
Кабат-кабат:
— Кайт-та-рыгыз!.. та-ры-гызз!..
Миңа хәзер — 26. Бөдрә солылар
чәчемнән көнләшге,
Баш очымда алтынланып,
бер уч кылган калды.
Күзләремдә үрсәләнеп,
трагедия җан бирде.

2

Мин сине бик яраттым, әни!
Калмык далаларына комсомол чакыргач,
бер хат яздым:
«...Улан-Холлдан Каспийгача
бер йотым суга сусап,
Дуслар белән чакрымнар санаганда,
бархан төбәсендә
ал яулык кебек бер пар мәккә тап булдык.

Алар ялгыз үсми,
Гаҗәпләндек, әни...»
Үтте еллар...
Сабырлыкларын яфрак итеп койган
Тирәкләр юлы буйлап,
Мине язмыш бер җиргә алып килде,
Һәм күрсәтте
Кабер...
Суынмасын сукмак, туганнар,
бу изге йөрәккә,
Узгынчылар, ял итеп, чәчәкләр салыгыз.
Тауларда калган тавышым
сезне куәтләр:
— Кайт-та-рыгыз! Кайт-та-рыгыз!

3

Гомерлек республикам — тауларым, урманнарым,
Сезгә сәлам!
Читтә кышларын кышлап, туган телен
онытмаган кошларым,
Сезгә сәлам!
Бөек халкым, синнән башка уйларым
сап-салкын,
Сиңа сәлам!
Килəм мин яшәргән җир буйлап,
Мәһабәт бер ятим,
Сагындым, бик сагындым үзегезне.
Я, кайсыгызга җылы сүз әйтим,
соң кайсыгызны юатыйм?

## Матурларым минем

Кызлар, кызлар! Берегез суырып үпте,
Икенчегез егете белән үтте,
Өченчегез урман сукмагында
Чык кипкәнен көтте — кичекте.

Карап тордым... Солыларда күрдем
Таң сарысы кебек бәсәрү.
Сагынсам да, нишлим, саргайсам да
Килмәс миңа кабат яшәрү!

Җир ваклыклар белән тулы әле!
Ялгыз йөрәгеңне биш итеп
Яндырчы кыз кеше!
Төн чигенсен,
Артка ятсын шәүлә уч итеп!

Кызлар, кызлар, матурларым минем!
Телим сезгә бәхет-сәгадәт.
Сез басасы бусаганы үпсен
Пар балдаклы тигез мәхәббәт.

## Тол ана сүзе

1

Төн. Томан керфекләремдә куерып,
Тормыш белән бәхилләшәм дигәндә,
Дөньяга бала таптым.
Хәлсез кулларым белән,
Сабыем астына өметемне түшәп,
Өстенә йолдызлар корамасыннан
Юрган яптым...
Таңны зарыгып көттем. Әнә... күкшелләнә таулар...
Бу мизгелне балам аңлар...
Балам аңлар...

2

Күл сөлегем, таулардагы яктылыгым,
Җир улы булып, үлгәнче җирне яратсаң иде.
Балам, балам!
Бәгыремдә төенләнгән кайгыларны
Чыкта чайкатсаң, таратсаң иде.

3

Җир-ана алдында
Сине тапканыма бер шатланам, бер оялам...
Вакытлымы, балам?
Вакытсызмы, балам?
Бәхеткәме, балам?
Ләхеткәме... балам?
Аңламый беркем — ялгызым янам мин.
Ялгыз ана мин...

4

Бигрәк өзелеп, сөенеп, көенеп яраттым шул!
Язны көтми сандугачым сайраттым шул!
Көн сөюемне кияү итеп бирде,
Көн үзе үк кире алды.
Йөрәгемә кайгы-моңын салды...
Кайгы түгел!
Шалкан кебек таза улым калды.
Туй капкасына сөлгеләр чиктем мин!
Һич зарланмыйм...
Су буеннан сызгырганга чыктым мин!
Һич гарьләнмим...

5

Очраттым да сине, егет, аллам иттем.
Ә соңыннан... үз алламны үзем
утка тоттым...
Кирәкми, мәхәббәткә аклану кирәкми!
Һәрбер хистән
Бәхет эзли күңел.

Әй, җир-ана,
Яратуы өчен
Кызың гаепле түгел!

## Дуска

*Гетедан*

Онытма, син дә кеше бит!
Уйлан син дикъкать белән:
Бүтәннән өстен түгелсең,
Түгелсең түбән — беләм!

Шатлыкларын да күп күрдең,
Кайгыларына түздең,
Юк, дустым, син башың имә,
Бәхетләр алда безнең.

## Экспромт

*Заһит Хәбибуллинга*

Җирдән, күктән куәт алып
Ташкан кеше,
Матурлыкны, телен табып,
Ачкан кеше.

Күп илләргә хуш киләсең,
Маэстро,
Күгең кояш, баш өсләрең
Аяз тора.

Скрипкаң дүрт кыллы икән,
Исән булсын.
Өстә безнең йөрәк кылын,
Бишәү булсын.

## Рифгать Закиров

### Өермә

Авыл урамында бер ду килеп,
Әйлән-бәйлән уйнап ала да
Аннан кинәт кенә бөтерелеп
Ташлана ул иркен далага.

Ә урамнар тынып һәм бушанып,
Моңсуланып кала бер мәлгә...
Мин дә шулай булам хисләремнең
Иң кайнарын җырга биргәндә.

### Моң

...Әтидән хәбәр килми торганда,
Йөрәккә кайгы-сагыш тулганда,
Килә идем мин безнең урманга,
   Күке моңнарын тыңларга.

...Йөрәккә ургып шатлык тулганда,
Керфеккә шунын чыгы кунганда,
Мин киләм һаман таныш урманга,
   Күке моңнарын тыңларга.

...Куйсам да канат дәртле
                     җырларга,
Урын калдырмый сагыш, моң-зарга,
Килермен барыбер шушы урманга,
   Күке моңнарын тыңларга.

### Онытылган кайгым булсаң да...

Шундый сөйдем сине!..
Хәтта алай
Сөймәгәндер Мәҗнүн Ләйләсен...
Кавышмасак, бер онытыр диеп,
Уйладыңмы, бәгырем, әллә син?

Уйладыңмы:
Вакыт — доктор диеп,
Шул төзәтер, диеп, ярасын...
Тик ул аны төзәтә дә барды,
Һәм өсти дә барды яңасын.

Әйе, шулай...
Күпме вакыт үтеп
Табалмадым дәва бу җанга:
Чөнки син бит һаман йөрәгемдә,
Онытылган кайгым булсаң да...

## Бер күңелдә...

Бер күңелдә һәрчак ике төрле
Урын барын тоеп яшисең:
Аның берсе булса шатлык өчен,
Икенчесе — кайгы-яшь өчен.

Тик шунысы: авыр кайгы килгәч,
Күпме генә кайнар яшь койма,
Аның шул яшь өчен дигән ягы
Тулу түгел,
      булмый ярты да...

Ә икенче ягы...
Бәхет әле
Килеп җитмәс борын, җай табып,
Тик аз гына шатлыктан да тулып,
Түгелергә тора чайпалып...

## Күк гөмбәзе

Күк гөмбәзе кайда да бер инде —
Кояшы шул аның, ае шул;
Җир үзе дә авыш булгангадыр,
Күрер күзгә бераз авыш ул.

Тик шулай да
Никтер шушы гөмбәз
Туган илдә бүтән төрлерәк:
Түбәсе дә гүя биегрәк,
Киңлеге дә аның киңрәк!

Мөдәррис Мостафин

# ЕЛЛАР ҺӘМ ЮЛЛАР

ОЧЕРК



Сугыш хәбәре Сарман районы, Иске Дөреш авылы крестьяны Шәех Закиров семьясына да кара кайгы булып беренче көнне үк килеп керде.

Мәликә апа Хәйбрахманны иртүк йокысыннан уятты.

— Улым, этиең сугышка китә, күрешеп кал,— диде ул, елаудан карлыккан тавыш белән. Унбер яшьлек малай этисе кочагына сыенды. Солдат Шәех күңеленнән һәркайсы белән хушлашып, берсеннән-берсе кечкенә уллары күз йөртеп чыкты. Төпчеге, әле ае да тулмаган Фәез, бишектә имезлек суырып ята иде. Ата ишек бусагасында озак туктальп торды.

— Сиңа авыр булыр инде, Мәликә. Нишлисең бит, сугыш. Хәнифне дә өйдә озак тотмаслар,— диде, тышта атасын көтеп торучы олы улына таба ишарә ясап.

Мәликә, яулык чите белән күз яшьләрен сөртә-сөртә, ирен озата чыкты. Хәйбрахман, тәрәзәгә капланып, урамнан күзен алмады. Бу аларның соңгы тапкыр күзгә-күз карашулары булды. Солдат туган ягына әйләнеп кайтмады, шул ук елны Мәскәү янындагы сугышларда һәлак булды.

Үлем кәгазе килгән көнне Закировлар өендә ананың әледән-әле әрнеп елавы тирән тынлык белән алышынып торды. Нарасыйлар ил өстенә, үз гаиләләренә нинди авырлык төшүен бөтен тирәнлеге белән аңламыйлар иде әле. Тик Хәйбрахман гына ара-тирә балавыз сыгып алды.

Озакламый Хәнифкә дә повестка килде.

— Ни хәлләр итәрбез, улым? — дип, әнисе аны кочагына кысты.

Хәйбрахман, әнисен юатырга теләп, чәчләреннән сыйпады һәм:

— Борчылма, әни, мин дә эшли башлармын,— диде.

Ул чагында әйткән сүзләренең мәгънәсен, бөтен җаваплылыгын аңлагандырмы, юктырмы Хәйбрахман, ләкин ана чыннан да кул арасына керергә, башта өйдә бала карап, аш-су әзерләп торырга, йорт эшләрен карашырга, соңрак колхоз эшенә кушылырга, кушылырга гына түгел, җигелергә, балалыгыннан аерылырга, вакыт җитми олы

кешегә өйләнергә туры килде. Шулай итеп, Хәйбрахман дошманны жиңү хакына үзләрен аямыйча эшләүче тыл солдатлары сафына, мылтыксыз сугыш алып баручылар армиясе сафына басты.

1943 елның язы аның хәтеренә нык сеңеп калды. Хәйбрахман бу язда сабанга чыкты. Әле буыннары да ныгып житмәгән яшүсмер өчен жир сөрү, әлбәттә, авыр хезмәт иде. Ләкин сугыш кешеләрдән мөмкин булмаганны эшләүне дә таләп итте. Һәм кешеләр кинәт үзгәрделәр: кырысландылар, батырайдылар, үзләрендә теләсә нинди авырлыкларны жиңәрлек көч таптылар. Башта Хәйбрахман Харис һәм Хәкимулла агайлар буразналары арасында йөрде. Монысын инде, картлар күзколак булыр, дип председатель шулай оештырган иде. Жир сөрү бик гади эш булып күренсә дә, авыр һәм четрекле, зур осталык таләп итә. Тырнап барып кына уңыш алып булмый. Ул чагында бүгенге кебек куәтле тракторлар да, юньле аты, сабаны да юк иде. Хәйбрахманга пар ат, ике төрәнле сабан бирделәр. Башта камыт кидерә алмыйча аптырап бетте: буе житми, атлар чөяләр дә жибәрәләр иде үзен. Камытны түмәр өстенә басып киертә торган булды. Аннары кирәк чагында сабанны күтәрә алмыйча йөдәде — күзеннән яшьләр атылып чыга иде. Тора-бара күнекте.

Буразналар тасма булып сузылды, шул буразналар саны арткан саен, егет күңеле сөендә, беләгендә көч, күкрәгендә илһам арткандай булды. Ә Харис карт: «Апаем, тирәнрәк алдыр, тирәнрәк, сай сөргән жирдә эрем генә үсә»,— дип, әледән-әле аның исенә төшерә торды. Ул олы абыйлары әйткәненә күндәм булды.

Игеннәр өлгергәч, Хәйбрахман лобогрейкага утырды. Киң кырларда бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр иген урдырды. Урак өсте авыр булса да күңелле һәм рәхәт иде. Яңа икмәктән авыз итәргә, туйганчы ипи ашарга мөмкин. Көр күңел белән сахраларда бер жырлап жибәрүе үзе ни тора!

Закировлар өенә тагын кайгы тәрәзә чиертте: Хәнифнең үлүе турында язу килде. Хәйбрахман ул көнне дә эшен ташламады. Өй эчендә — тагын кабер тынлыгы һәм елаш. Аз булса да юанырмын, дип тотты да, атларын жигеп, гадәттәгечә лобогрейкасы белән басуга чыкты. Ләкин машинаның ганыш, күнелле келтерәвен ишетмәде, яңа ашлык исен тоймады, басу өстендә дулкыннарның йөгерешүен күрмәде...

Көннәр бер-бер артлы үтте. Кышын ул парта арасына утырды, күршедәге Теләнче Тамак авылына йөреп, жиденче классны тәмамлады.

Озак дәвам иткән, халыкларны интектергән, күп корбаннар алган, ничәмә-ничә ел тынычлап йокларга ирек бирмәгән сугыш та бетте. Жиңү хәбәре Дөреш авылында да яшен тизлеге белән таралды. Шатлык өй борынча йөрде, урамнарга, басуларга юл алды. «Исәннәр кайтыр, безнекеләр генә бу көнне күрә алмадылар»,— дип, Мәликә апа көн буе өзгәләнеп-өзгәләнеп елады.

Ел ахырында Хәйбрахманны бригадир итеп куйдылар. Аңа әле уналты яшь тә тулмаган иде, өстенә тау кадәр жаваплылык алды. Бригадирның мәшәкатен әйтеп, хезмәтен бәяләп бетерергә мөмкин түгел. Ул чагында бит нәрсәгә тотынсаң, шул юк иде. Сугыш бетсә дә, авылда эшләр жиңеләймәде: халык йончылган, жир йончыган иде. Иген уңышы капчыклап кына жыеп алмалы — гектарыннан 5 центнердан артмый. Хужалыкны өр-яңадан күтәрергә кирәк. Менә шундый житди вакытта бригада кадәр бригадага житәкчелекне уналты яшьлек егеткә ышанып тапшырдылар. Тырышты Хәйбрахман, кирәк урында тәмле сүзен кызганмады, колхозчыларның хезмәтен дөрес исәпкә алды, хәленә керә белде. Кайчакта аның ягымлы карашы, йомшак тавышы һәм сүзсез генә туры итеп карап торуы кешеләрне буйсынырга мәжбүр итә иде.

Бригадир булып эшли башлавының беренче көннәре. Кайчандыр

үзен җир сөрергә өйрәткән Хәкимулла абзыйга урманга утынга барырга әйтте ул.

— Мә, апаем, юкә аркан белән атынны җигеп, үзең бар,— диде Хәкимулла.— Юкә бау бозау мунчакларга гына ярый, ә син монда ат җигеп утын алып кайтырга тиеш!

Хәйбрахман аптырап калды. Шактый шулай күзгә-күз карашып торгач, тынлыкны агаебыз үзе бозды:

— Хәер, бу арканнарда синең гаебең юк. Барырмын,— диде.— Кыен эшләве, кыен. Юкә дә булдымы аркан! Син әле каешын да күрерсең, тракторын да йөртерсең! Башың яшь әле. Ә шулай да кыю тотындың, улым, рәхмәт. Тик игене уңсын, ипие күбрәк булсын иде...

1946 елның урак өсте иде. Кешеләр җитми. Хәйбрахман бармаклары белән дә санап карый, счет төймәләренә дә сала, ләкин җитми генә бит. Бервакыт өендә ашап утырганда ишек алдында кечкенә энеләрен җитәкләп йөрүче Габденурга күзе төште. Һәм, нәрсәдер хәтерләгәндәй, җил-җил атлап, энекәшләре янына чыкты.

— Апаем, Габденур, кил әле бирегә.

Тегесе йөгереп килеп, абыйсы каршына басты.

— Сиңа ничә яшь хәзер, беләсеңме?

— Унике.

— Әйе шул, унике. Апаем, сиңа җәйге айларда колхоз эшендә катнаша башларга да вакыт. Хәзер кызу урак өсте. Иртәгә дворга мен, ат җик, басудан ашлык ташырсың, я су китерерсең. Синең кебек егеткә болай уйнап йөрү килешми инде.

Ул соңгы сүзләрен шаяртыбрак әйтте. Хәер, уены-чыны бергә иде. Абыйсының сүзен күндәм тынларга һәм үтәргә өйрәнгән Габденур каршы килмәде. Ул үзе дә ат җигеп, арбага аягүрә басып, бөтен кеше күз алдында чаптырып узарга хыялланып йөри иде.

Хәйбрахман иртәнге якта басуларны, ындыр табагын йөреп чыкты. Эшкә чыгасы кешеләр барысы да килгәннәр. Ә Габденур күренми. Нәрсә уйларга да белмичә, ул атын колхоз дворына таба куалады. Энекәшен бик нык тиргәргә, «акылга утыртырга» исәбе бар иде. Ләкин ат җигә алмыйча җәфаланучы Габденурны күргәч, ачуы басылды. Үзенең беренче тапкыр сабанга чыккан көнен исенә төшерде.

— Нәрсә, апаем, камыт киертә алмыйсынмы?

— Әйе,— ди Габденур, учы белән маңгаендагы тир бөртекләрен сөртеп.

— Син, апаем, я арба читенә бас, я аяк астыңа берәр нәрсә сал. Мин дә шулай өйрәндем. Курыкма, иләшкәч атың үзе башын иеп торыр. Бераз яшел үлән каптыргала үзенә. Ат, хайван булса да, назлаганны тиз аңлый.

Хәйбрахман әйтеп кенә калмады, җигеп тә күрсәтте. Һәм: «Арбаңа ашлык төяярләр, экрен генә келәткә алып кайт, ә монда бушатырга булышырлар»,— дип озатып калды. «Яланда уйнап йөрер чагы да бит... Әйдә, чыныга торсын», дигән уйлар узды аның башыннан бу минутта. Менә энекәше дә булыша башлады.

Арбасына басып, ындыр табагы кырыена килеп туктаган Габденурны күргәч, көрәк белән җилгә каршы чөеп ашлык җилгәрүче хатын-кызлар Мәликә апага:

— Кара әле, күзгә күренәме, Габденур ич! — дип мактау сүзләре яудырдылар.

Мәликә апа күтәрелеп улына карады, Габденур да авызын ерып, күзен әнисеннән алмады. Батыр иде ул бу көнне!

Күпме ямьле язлар узды, күпме алтын көзләр, буранлы кышлар узып китте. Гомер агым судай акты да акты. Хәйбрахман, яше җитеп, армиягә алынды, анда авиомеханик һөнәренә өйрәнде. Хәкимулла абзыйның әйткәне рас килде, туган авылына әйләнеп кайткач, тракторчы





Закировлар арасыннан иң өлкәне Хәйбрахман һәм аның тормыш юлдашы Әржүдә.

булды, күпме буразналар сызды, шоферлыкка укыды, машина йөртте һәм, курслар оештырып, уннарча колхоздашларын шоферлыкка өйрәтте. Ул укыткан егетләр хәзер үзләре оста шоферлар, басу киңлекләрендә аның белән бер тракторда прицепщик булып йөргән малайлар хәзер үзләре корыч айгырларны үкертеп эшләтәләр. Юкка гына яшәми Хәйбрахман жир йөзендә: кеше күңелендә дә, туган авылының бәрәкәтле туфрагында да ул чәчкән орлыклар күр шытым бирәләр.

Менә аның гаилә тормышы кору турында уйлар вакыты да житте. Хәйбрахманның күзе төшеп, күңеленнән сөеп йөри торган кызы бар. Ул — ферма мөдире Әржүдә. Бик тырыш кыз. Аның тыйнаклыгы, гадилеге дә ошый егеткә. Ләкин ничек сүз башларга? Ничек итеп күңелендәгене белдерергә? Өч ир малай үсеп килә, әнисенең кулыннан көч китеп бара, килен кеше, өстенә тау кадәр мәшәкать алып, Хәйбрахманнар өенә килергә риза булырмы соң?

Әржүдә риза булды. Аш-суга оста, йорт эшләренә кулы ятып тору өстенә, ул олы жанлы, киң күңелле кеше иде. Үзе белән бергә Хәйбрахманнар өенә нур алып килде. Гаилә тормышының авырлыгын, мәшәкатен күтәреште, карт ананың, үсеп килүче малайларның шатлыкларын үз шатлыгыдай кабул итте.

Хәйбрахман энеләре язмышы өчен жаваплы булуын бер вакытта да исеннән чыгармады, аларны хезмәт сөючән, олыларга ихтирамлы, әдәпле итеп тәрбияләргә тырышты. Дөрес, хезмәт ярату Закировларның каннарына балачактан ук сеңгән. Әтиләре ыңгырашмыйча-нитмичә теләсә нинди авыр эшне башкарыр иде. Әниләре әлеге дә баягы авыр сугыш елларында кулына урагын алып, таң белән иген кырларына китәр иде, ут алгач кына кайтыр иде, балаларын ашатыр-эчертер, йорт эшләрен карар иде, төнлә, сукыр ут яктысында фронттагы кызылармеецлар өчен жылы оекбашлар бәйләр, бәрәңге киптерер, ә таң белән тагын уракка китәр иде. Аның сугыш чорындагы һәм аннан соңгы авыр еллардагы батыр хезмәте Хәйбрахман өчен дә, энеләренә дә якты үрнәк булды.

Хәйбрахманның колхозда шофер булып эшләгән еллары иде. Берзәнбер көнне ул төпчек энесе Фәезгә әйтте:

— Апаем, минем машинада йөкче булып эшләрсең, машина йөртергә өйрәтермен. Ә кышын курста укырсың да, хокук алып, үзең рульгә утырырсың.

Әмере, киңәше бергә иде. Фәез бер кавым дәшми-тынмый торды. «Ризалашыргамы, юкмы?» дип уйлады, күрәсең. Һәм: «Ярар», диде.

Бер кабинада утырып, шофер тормышынын рәхәтен һәм михнәтен бергә татып, бер җәй, бер көз, бер кыш эшләделәр алар. Көннәр аяз торганда, юллар әйбәт булганда шоферның кәефе яхшы, эше дә гөрли. Тәгәрмәчләр күз ияргесез тизлек белән тәгәри, машинаның кызу чабуыннан көнләшкәндәй, җил сызгырып кала. Ярый ла мотор һәрвакыт гөрләп эшләп торса, юллар коры һәм сикәлтәсез булса?! Кыенын да хәтсез күрергә туры килә шул. Бервакыт алар каты яңгырга эләктеләр һәм урман юлында сазга баттылар. Тәгәрмәчләр төтеннәр чыгарып, әче сызгырып, бер урында әйләнеп торалар гына бит. Хәйбрахманның да, Фәезнең дә кул-битләренә, киемнәренә ләпек чәчрәп, тәмам мунча төнлегеннән чыккан төсле булдылар. Тәгәрмәч асларына күпме үлән йолкып ташладылар, күпме чыбык-чабык тондырдылар. Этләнә торгач, машина урыныннан кузгалды.

— Ай-ай, абый, болай батып ятырга язмасын. Кыен икән. Машина үзе дә еламый гына бит.— дип куйды Фәез.

Хәйбрахман энесенең нәрсә әйтергә теләвен аңлады: яңгыр астында пычрак ярып йөрүдән бераз кәефе киткән иде аның.

— Начаррак хәлләр дә булгалый, апаем. Эш майлы ботка ашау түгел ул... Менә без батып яттык, автомашинаны саздан тартып алгандай алдык. Ә бер кузгалып киткәч, нинди рәхәт, тау актарган кебек, мәйданда җиңгән кебек хис итәм мин үземне. Ә син?

— Мин дә.

— Өйрәнә тор, апаем. Төрлесен күрергә туры килер.

Юлларның озыны да, кыскалары да, авырлары һәм җиңелләре дә күп булды. Ниһаять, Фәез тормышын машинадан башка күз алдына да китерми башлады. Хәйбрахман правление тәкъдиме белән яңадан бригадир постын кабул иткәч, үзе йөрткән, турылыклы иптәше «ГАЗ-51»не Фәезгә тапшырды.

Хәйбрахман, мөстәкыйль хезмәткә керешүе белән тәбрикләргә теләгәндәй, энесен җилкәсеннән какты, ә Фәез селкенмәде дә.

— Кара син аны, абайламыйча да калганмын, нинди таза булып үскәнсең. Иман төбемени! Ә бит, беләсең килсә, бала чагыңда бик чирләшкә идең син. Хезмәт кешене ныгыта ул. Я, бир, кулыңны, хәерле юл телим үзеңә!..

* * *

Мәликә апаның дөнья куйган елы иде. Нәкъ сабан туе алдыннан Габденур армия хезмәтеннән кайтты. Туган-үскән йортта, түр башында газиз әнисенең булмавы аның бәгырен өзгәләде. Габденур үзенә урын, яраткан авылыннан ямь таба алмады. «Китәм, ил зур, кая да булса яңа төзелешкә китәм»,— дип әйтеп салды ул бер көнне. Хәйбрахман аның бу сүзен җавапсыз калдырды, дөресрәге, кайгы эчендә янучы энесенә капылт кына нәрсә дип әйтергә белмәде.

Сабан туе көне килеп җитте. Халык гөрләтеп бәйрәм итте. Ләкин Габденур һаман боек иде. Закировлар, җыйнаулашып, күршедәге Шыгай авылына мәйдан карарга, ат чабышларын күрергә киттеләр. Шыгай шактый зур авыл булып, анда сабан туе да шәбрәк уза. Халык та күбрәк җыела. Габденур карап-карап утырды да, ярсыган йөрәген басарга теләп, көрәшкә керде. Мәйдан читендә тезләнеп утырган Хәйбрахман баштарак: «Бирешмә, апаем, әйдә, әйдә, сынатма!» — дип тәмле сүз белән энесен дәртләндергәләсә дә, соңрак, Габденурның болай да көндәшләрен җиңел алып салуын күргәч, тынып калды. Габденур сабан туенда җиңеп чыкты, комиссия членнары бирелче батырга билгеләнгән сарыкны аның җилкәсенә китереп салдылар. Габденур биредәге гадәт буенча, сарыкны күтәргән килеш түгәрәк мәйданны бер



Менә ул районның кыр батыры һәм сабан туе батыры Габденур.

әйләнде. Барысы да кул чаптылар, ә Дөрешнекеләр, шатлыкларын яшермичә, «Молодец, Габденур!» дип кычкырдылар.

Алар машина кузовында бергә кайттылар. Унда да, сулда да күз күреме җитмәслек киң басуларда өлгереп килә торган игеннәр дулкынланып утыра иде.

— Шушы басуларны ташлап кайда китәм дисең син, юләр. Юк, бер кая да җибәрмим мин сине. Телисең икән, әнә тракторга утыр, анысын теләмәсәң, комбайнга. Синең кебек батырлар үзебездән дә артмый, апаем,— диде Хәйбрахман.

Габденур абыйсына елмаеп карады, ләкин бер авыз сүз әйтмәде. Чөнки ул үзе дә икеләнә иде. Өйгә кайтып, бәйрәм табынына утыргач, Хәйбрахман барлык гаилә члennары алдында шул ук сүзне кабатлады:

— Габденур, туган авылны ташлап, аяк та атламыйсың! Әйе, мин риза түгел!

...Кояш байый. Офыкта — кызыл ялкын. Шул ялкынның алсу нурлары өй түбәләрендә, тәрәзә пыялаларында, агач башларында — бөтен нәрсәдә чагыла. Шундый моңсу һәм тантаналы эңгер-меңгердә зиратта ялгыз тополь үсеп утырган кабер каршында башын түбән иеп, тын да алмыйча бер кеше басып тора. Менә инде караңгылык та канат җәйде. Шомлы тынлык урнашты. Кеше, зираттан чыгып, авылга юнәлде. Колхоз правлениесе урнашкан бина тирәсе Ильич лампалары нурларыннан ялт иткән. Шунда Тукай исемендәге колхозның Бөек Ватан сугышында һәлак булган кешеләре хөрмәтенә обелиск куелган. Балкыган ут яктысы астында күктә очучы самолет канатыдай ялтыраган көмеш сыман обелиск янына килеп туктады ул. Уйларга күмелеп, тагын бик озак шунда басып торды. Аннары әкрен генә кузгалып китте һәм Закировлар капкасына кереп югалды.

Бу Фәез иде. Ул әнисе үлемен аеруча авыр кичерә. Сагышы ташыган чакларда, зиратка килеп, әнисе кабере янында уйларга чумып басып тору аның гадәтенә кереп калды. Ул гүя әтисе һәм әнисе белән киңәшә, уенын дөреслеген тикшерә иде. Фәез кайтып кергәндә, өйдәгеләр бәйрәм табыны янында һаман гәпләшеп утыралар иде әле. Фәез Габденур янына барып утырды, һәм, абыйсының кулын шытырдатып кысып тотып, көндез барган бәхәскә йомгак ясагандай:

— Бергә яшәүгә ни җитә, абый. Уеңны башыңнан чыгарып ташла,— диде.— Әни мәрхүмә дә үләр алдыннан: «Бергә-бергә туган авылыбызда гомер итсәгез, мин һәрвакыт риза-бәхил булырмын»,—дигән иде. Онытма, бу — әнинең васыяте!

Фәезнең күзләрендә яшь күренде, ә Габденур күңеле тулуын сиздермәс өчен читкә борылды.

* * *

Август кояшы кыздыра. Кырларга чыксаң, күңел сөенеп туя алмый: тук башаклы иген диңгезе өстендә дулкыннар йөгерешә. Әле басу түрендә, әле юл кырыйларында комбайн тавышы яңгырый. Басу юлларында, ут уйнатып, тузан өермәсе куптарып, ашлык төягән машиналар чаба. Ындыр табагына килеп керсәң, машиналар гөрелтесенә күмелеп каласың.

Урып-жыю элек-электән үк бөтен көчне үзенә буйсындыра торган вакыт булды. Ә игениәр яхшы уңган 1968 елда ул аеруча күп көч куюны таләп итте. Җитмәсә, бу вакытта никадәр эш бергә төенләнә, берсен дә читкә куярга ярамый. Хәйбрахман бу өермә эчендә ел саен җан-фәрман килеп бөтерелә. Кылны кырыкка яра торган чак. Шундый көннәрнең берсендә без аны авылдан ерак түгел басуда, арыш чәчә торган җирдә очраттык. Төшке аш вакытына туры килдек. Механизаторлар яшел чирәм өстенә җәелгән ашъяулык тирәсенә тезелешеп утырганнар, кайсы берсе сузылып яткан. Тирә-юньгә итле борчак ашының хуш исе таралган. Кыска вакытка туктаганнары күренеп тора: тракторларның моторлары сүндерелмәгән. Басу читендә берничә ат утлап йөри. Механизаторлар арасында утыручы чандыр гәүдәле Хәйбрахман, сикереп торып, безнең янга килде. Һәм: «Мактап йөрисез икән», дип ашарга кыстый башлады. Колхоз председателе Әүхәт Мөхәммәтов белән ашъяулык тирәсенә җайлап утырдык. Болай да тәмле аш, сахрада ашагангадыр, телләреңне йотарлык иде. Барыбыз да аш пешерүчене мактадык.

Тамак туйдырып алгач, тракторчылар, чәчкеч машинистлары эш урыннарына юнәлделәр. Менә мотор тавышлары көчәйде. кара җир өстенә зәңгәрсу төтен бөркелде. Өчәр чәчкеч һәм туфракны бастырып, тигезләп баручы авыр тросслар таккан куәтле тракторлар әкрен генә кузгалдылар. Кызу йөрергә ярамый: эшнең сыйфатына зыян килә. Арыш бөртекләре сошниклардан җир куенына төшеп бара. Башта буйга чәчәләр, аннары аркылыга. Дөрес, бу ысулның кыен яклары да бар: вакыт күбрәк таләп ителә. Турысын гына әйткәндә, икe кат чәчү дигән сүз ул. Аның каравы ышанычлы, игеннәр тигез һәм көчле булып тишелә.

Басу йөзе — игенче йөзе, диләр. Шушы басуларда Закировның, Рәфис Хәлиуллин, Мөҗәһит Хафизов, Александр Аксаков кебек тракторчыларның кемлеге ачык күренә. Туфрак йомшак, яхшы эшкәртелгән. Шулай булмыйча мөмкин түгел, чәчүгә керешкәнче бу җирләрне лущить итеп, сөреп, дискылап, ничәмә-ничә тапкыр тырмалыйлар. катоклар белән бастыралар. Барысы да туфракны йомшарту, анда дымны саклап калу өчен эшләнә. Менә хәзер дә чәчү машиналары тигез эзләр салып узалар, ә аларга тагылган авыр тросслар туфракны бастырып баралар.

— Отлично! Шулай эшләвегезне дәвам иттерегез, егетләр,— диде председатель, механизаторларның эшен хуплап. Чыннан да тел-теш тидерерлек кечкенә генә кимчелек тә очрамады.

Хәйбрахман, чирәмгә барып утыргач, уракның ничек баруы, ашлыкның кайсы участокта гектардан күпмешәр төшүе турында сөйләде. Салмак кына, уйлап кына сөйли ул. Бригадир яхшы орлыктан яхшы иген үсүе турында бик күп дәлилләр китерде.

Менә алты ел инде биредә орлыкны калибрлап, эреләрен генә сайлап, беренче һәм икенче фракциясен генә чәчәләр. Хәйбрахман машина белән калибрланган орлыкка гына риза түгел, узган язны борчакны мөмкин кадәр кулдан бөртекләп чүпләтүне дә оештырган. Мондый орлык чәчелгән участокларда борчак гектардан 33 әр центнер чыккан. Туфракка бер генә зәгыйфь орлык та кермәскә тиеш. Начарын чәчеп, нигә үзеңне-үзең алдарга? Ул я тишелми, яки зәгыйфь, көчсез үсенте бирә, аны чүп басып китә. эссе җилләр көйдерә.

Әңгәмә әнә шул хакта һәм агротехникага бәйләнешле башка нәрсәләр турында барды.

Бу көннәрдә Тукай исемендәге колхоз дәүләткә ашлыкны икенче план хисабына сата иде. Ә урасы-сугасы тау кадәр әле. Кесәсендә йөреп, тышы ялтырап беткән блокнотын тез башына куйды да, председатель андагы саннарга күз йөртеп:

— Ике план белән генә дә чикләнмәбез әле, мөгаен,— дип, сүзен йомгаклагандай итте.— Бодай да, тары да әйбәт төшә. Ярый, күзгә лыйк булмаса.

Хәйбрахман ындыр табагына барырга булды, атын җигә калды. Ә без икенче бер басуга юл тоттык. Кырларның йөзе шактый үзгәргән иде инде. Камылы гына тырпаеп калган басулар сөрелгән җир белән алышына, әледән-әле стенадай утыручы иген кырына, я һәр яфрагы олы әрекмән хәтле чөгендер җиренә барып чыгасың. Биредә шикәр чөгендереннән дә югары уныш һәм зур керем алалар.

Озак барырга туры килмәде, еракта бер комбайн күренде.

— Ул әнә шунда булырга тиеш,— диде Әүхәт Мөхәммәтов.— Егет әйбәт. Сабан туйларында да җиңеп чыга, иген кырларында да. Узган ел икеләтә батыр калды. Сарманда сабан туенда бөтенесен селтәп салды, районда иң күп уручы һәм иң күп ашлык суктыручы да ул булды. Асыл егетләр күп бит хәзер. Шулар арасында мәйдан тотып кара әле син! Комбайнны да әллә нәрсәләр кыландырып бетерә ул, яңалыклар кертә. Шуңадыр инде, машинасы яхшы көйләнгән скрипка кебек: сызлыра гына.

Сүз белән юл кыска булды. Без кояшта җилләп, коңгырт сары төскә кергән борчак теземнәрен ялмап баручы кыр корабы белән тигезләштек. Борчак суктырганда комбайн штурвалында утыруы бик кыен— саламыннан өермә булып тузан чыга. Комбайнчылар, әледән-әле туктап, саф һава сулыйлар. Тузан пәрдәсе каплагангадыр, мөгаен, Габденур үзенә ияреп баручы председатель «Волга»сын тиз генә күрмәде. Ә күргәч, комбайнның барышын әкренәйтте һәм, штурвалны ярдәмчесенә биреп, җиргә сикереп төште. Габденурның күзләрендә шат елмаю балкый, тешләре ялтырап тора иде.

— Исәнмесез! Эшләр уң булсын! — дибез.

Ул уңайсызланып кына майланган кулын суздры. Шул кытыршы, көрәктәй олы куллар бит инде бер башак үскән урында икене үстерүче!

— Эшләр әйбәт бара, торкарлык юк, бүген төнге унбер-уникеләрсез туктамаска исәп,— диде ул.— Көн әйбәт чагында алдырып калырга кирәк.

Күп уру гына җитми, тир түгеп үстерелгән, дүрт күз белән көтеп алынган уңышны түкми-чәчми җыеп, амбарга салырга кирәк. Ашлыкның һәр бөртеге кадерле. Кем кем, ә Габденур иңи бәясен белә! Аның барлык уйлары ашлыкның бөртеген дә югалтмау турында. Борчак суктырганда подборщик пружинасы артына калай фартуклар куйган ул. Салам, калайга бәрелеп, ныграк селкенә, бөртек калмый. Бу — Габденур кертикән күп җайланмалардан берсе. Габденурның гадәте шундый: җир өстендә урак тешенә эләкмәгән берәр кузак яки башак күзенә чалына икән, ул аны атлап яки таптап узмый, комбайн авызына алып сала. Тамчылардан күл җыела дигәндәй, бөртекләрдән көшелләр хасил була бит.

Без сөйләшкән арада комбайн бер әйләнеш ясап килеп тә җитте. Габденур, саубуллашып, басмалардан тиз-тиз атлап, югарыга — штурвалга менде. Кыр корабы, канатларын җәеп, юлын дәвам итте. Җилләр уйнатып, комбайнга таба килүче йөк машинасы күренде. Ул килеп тә җитте, барышлый ук кузовын бункер торбасы астына куйды. Аннан, кояшта ялтырап, чишмәдәй булып борчак акты. Кузов бик тиз тулды, машина шунда ук авылга таба чапты.

— Беләсезме,— диде председатель,— әлеге машинаны Закировларның төпчеге Фәез йөртә. Кем әйтмешли, икесе бер агрегат. Абыйсы суккан ашлыкны берүзе ташып өлгерә. Шайтан булса, ул да куып житә алмас үзен. Әле кайчагында төнлә Чаллыга элеваторга да юллап кайта. Тынлаучан, эшчән булганы өчен авылда «Ярар Фәез» дип йөртәләр аны. Шундый кешеләр инде алар, Закировлар.




Рәсимә белән Фәйзерахман.

* * *

Басулар буйлап йөри торгач, без чәчәкләргә күмелгән түгәрәк урман аланына барып чыктык. Борынга бал исе бәрелде. Ялгышмаганмын. Шунда, урман эчендә, колхозның умарталыгы урнашкан икән. Умарта оялары алдында күч булып бал кортлары безелди. Сакчы эт тавыш бирде. Шул тавышны ишетеп, умартачы үзе дә урманнан килеп чыкты. Шатлыклы йөз белән, авыз эченнән нәрсәдер мыгырдана-мыгырдана, безнең каршыга таба атлады ул. Әүхәт тамак кибүен әйтеп, мәтрүшкә чәе кайнатырга кушты. Чыннан да, көн буе диярлек кояш астында йөреп, шактый сусаган идек. Таганга аскан корымланган кара чиләктә чәй кайнаганчы без әңгәмәбезне дәвам иттек. Әүхәт бик ачык кеше, сүзгә дә күршегә керә торганнардан түгел. Әле һаман шул Закировлар турында сөйли:

— Шундый кешеләр күбрәк булсын иде менә. Фәйзерахманнары ун ел инде көтү көтә, кышын фермада маллар карый. Көтүче дип әйтергә генә җиңел, җаваплылыгы, мәшәкате зур аның.

Киленнәре дә үзләренә охшаган, хезмәт сөючәннәр. Әрҗүдә сыер сава. Фәйзерахман хатыны Рәсимә дә сыер савучы. Нинди генә әле! Гәүдәгә бәләкәй булса да, бик уңган, ут кебек. Фәезне зоотехник кыз Ольгага өйләндердек. Минзәлә техникумын тәмамлап, безгә эшкә килгән иде. Үзем баш кода булдым. Бәбиләре дә бар инде. Шау-гөр килеп, хезмәттән тәм, тормыштан ямь табып яшиләр Закировлар.

Умартачы алдыбызга, муллыгыбызны күрегез дигән сыман, табагы белән кәрәзле бал китереп куйды. Хуш исле яшькелт чәйне кружка артыннан кружка бушатып барабыз. Нинди хозурлык! Ләкин сүзебезнең җеп очын югалтмыйбыз.

— Язгы чәчү вакыты иде,— ди Әүхәт.— Без төнлә дә эшләдек. Фаралар, фонарьлар белән яктыртабыз да чәчәбез. Яз соңарып килде, чәчүне кызурак тотарга кирәк иде. Төнге сменага без гадәттә тәҗрибәлерәк механизаторларны билгелибез. Габденурга да әйттек. Карап кайтыйм, дип, басуга киттем. Габденур чәчү машинасына баскан. «Әһә, мин әйтәм болай булгач, бодай бөртекләренең туфракка дөрес ятуына шикләнмәскә мөмкин». Киттем. Икенче төндә амбарга килдем, чәчүлек орлык озатуда тоткарлык-мазар юк микән, дим. Габденур күземә күренә дип торам, капчыкларга бодай тутырып, озатып тора. Гаҗәпләнүемне сизде булса кирәк. «Минем, ди, берсекөнгә физикадан имтихан тапшырасы бар, шуңа күрә монда гына калдым. Машина

басудан әйләнеп килгәнче, аз булса да укый торам», ди. Болай укып, мин әйтәм, нәрсә чыгара алыр икән бу. Ләкин чыгарды, физикасын да, башка фәннәрен дә яхшы билгеләренә генә тапшырды, кулына өлгергәнлек аттестаты алды. Шундый кешеләрне ничек мактамыйсың инде, ә? Хәйбрахманы да, Фәезе дә укый...

Көннең сүрәнләнгәне сизелә башлады. Тагын «Волга»ның утыргычларында тирбәләбез. Басуда йөрү өчен бик җайлы машина булмаса да, коры көнне «газик»ларга бирешми ул.

Менә яңадан Иске Дөрешкә кайтып кердек. Авылның башында үзенең төзеклеге һәм зурлыгы, күккә сузылган телевизор антеннасы белән бер яңа өй күзгә ташланды. Мин ирексездән аның кемнеке булуын сорадым.

— Габденурныкы ул,— диде председатель. Эченә керсәң, хәйран калырсың, курчак өе кебек. Бүләкләр музее дисәң дә ярый аны. Нәрсәгә күз салма — Габденурның бүләге. Суыткыч, телевизор, радиоалгыч, тегү машинасы, кер юу машинасы, гармун, ишек алдындагы мотопеды, велосипеды — барысы да бүләк. Вагы-төяге санап бетергесез.

Мин күңелдән генә уйлыйм: була бит, дим бәхетле кешеләр. Бәхет! Ләкин бәхет үзе генә килми. Аны кеше үз куллары белән яулый. Бәхетнең шундые кадерле. Габденур бәхетен хезмәттә, туган туфрагында тапты. Иген кырлары, киң болыннар, авылының якты күге, саф һавасы — аның шатлыгы, аның бәхете.

Кичен хәл алырга урамга чыктым. Күктә йолдызлар җемелдәшә, талгын җил исә. Уйларга чумып, хәтсез вакыт басып тордым. Закировлар һәм аларның гыйбрәтле тормышы күз алдымнан узды. Хәйбрахман, Әрҗүдә, Фәйзерахман һәм шомырт кара күзле, сызылып киткән кара кашлы Рәсимә, барысы, барысы... Дүрт Закиров, дүрт өй, дүрт капка. Әнә шул капкалардан язын-көзен, җәен-кышын, көн саен таң беленү белән, ирле-хатынлы Закировлар колхоз кырларына, фермаларга юл тоталар. Коеп түккән яңгырлар да, эче, салкын җилләр дә аларның юлларына киртә була алмый.

Хәйбрахман белән Әрҗүдә берсеннән-берсе матур өч малай үстерәләр. Олысы Хәниф алтынчы класста укый инде. Авыл хатын-кызының йорт эше бетмәс-төкәнмәс. Ләкин Әрҗүдәгә әлегә өйдә утырырга туры килми. Бердән, ул тормышын җәмәгать хезмәтеннән башка күз алдына да китерә алмый, икенчедән, колхозда хәл итәсе бурычлар шул хәтле күп, тормыш үзе ирләрнең генә түгел, хатын-кызларның да эштә актив катнашуын таләп итә. Әрҗүдә заман йөкләгән әнә шул вазифаны менә күпме еллар инде намус белән үти. Сыер савучы хезмәте җиңел түгел. Әмма Әрҗүдә сыкранмый, ялкынланып эшли. Фермада да, өйдә дә җитешә. Өе һәрвакыт чиста, балалары пөхтә һәм яхшы киенгән булыр.

Хәйбрахман ял иткән сәгатьләрдә, газета-журналлар караштырганда яки телевизор экраны алдында утырганда, Әрҗүдәнең йөгерә-йөгерә аш-су әзерләвен, өй җыештыруын, икенче бүлмәдә балаларның үзара киңәшә-киңәшә дәрес карауларын мыштым гына күзәтә һәм тормышының тулы, түгәрәк булуына сөенеп бетә алмый. Кием-салымның ниндиен теләсәң, шуны алырга мөмкин, табында итле ашы, балы, мае, кабарып пешкән бодай күмәче — җаның нәрсә тели шул бар. Колхоздан акчасын, ашлыгын җитәрлек бирәләр. Эшләве дә, яшәве дә күңелле. Их, менә этисе Шәех белән әнисе Мәликә исән булсалар, шушы өйнең түрендә утырсалар иде. Авырлыкларны күп күрделәр, мәрхүмнәр, ә бүгенге мул тормышта яшәү насыйп булмады үзләренә. Әнә шундый уйлар, сугыш елларындагы һәм аннан соңгы чордагы авыр көннәр бер җепкә тезелеп Хәйбрахманның күз алдыннан уза. Мондый уйлардан аның бугазына төер утыра. Эче-эчкә ябышкан атлар белән җир сөргән чаклары бар иде бит аның. Колхоз кырларын хәзер әнә нинди куәтле




Бу кин җилкәле егет — Закировларның төпчеге Фәез, монысы — аның хатыны зоотехник Ольга.

тракторлар сөрәләр, кирәк булса, төп чыкканчы бөтен басуыңны актарып ташлыйлар. Автомашинасы, комбайны күпме! Елый-елый аг җиккән энекәшләре техниканың сыртына менеп атландылар. Әйе, замана үзе дә, кеше дә үзгәрде. Тагын ун-унбиш елдан нәрсәләр генә булмас! Әлегә сирәк-мирәк булса да салам түбәле иске өйләр күренгәли торган Иске Дөреш авылы, мөгаен, үзе дә бөтенләй башка сурәткә керер. Бәлкем, исеме дә Яна Дөреш булыр?!

...Төнге тынлыкны бозып, басулардан тонык кына булып әле трактор, әле комбайн тавышлары ишетелә. Аларның берсендә, әлбәттә, Габденур утыра. Ара-тирә, фара нурлары белән юлны капшап, ашлык төягән автомашиналар уза. Иске Дөреш авылы аша Чаллыга илтүче олы юлга күз салсаң, машиналарның кыр казлары кебек тезелешеп баруларын күрәсең. Бәлкем, Фәез дә шулар арасындадыр. Фидакарь хезмәт төнлә дә тынып тормый.

* * *

Көзен тагын Сарманда булырга туры килде. Районның уңыш бәйрәме көне иде. Беренче кар төшкән көн. Һавада кар бөртекләре оча, җирдә җәяүле буран себерә, ә күңелләрдә җәй. Культура йортына районның алдынгы игенчеләре җыелган. Хәйбрахман һәм Габденур Закировлар да шулар арасында. Хәйбрахман кара-зәңгәр төстәге яна костюмын кигән, әйбәтләп кырынган, яшәреп киткән. Күкрәгендә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе медальләре ялтырый. 1968 елда аның бригадасы зур мәйданда һәр гектардан 23,5 әр центнер бөртекле ашлык үстереп алуга иреште. Партиянең район комитеты секретаре Мөгаллим Сәгыйров югары уңыш үстерүче бригадирлар арасында беренчеләр рәтендә коммунист Хәйбрахман Закиров исемен атады. Габденурны 1968 елның кыр батыры дип игълан иттеләр һәм җилкәсенә яңып торган кызыл хәтфәдән «Батыр» тасмасы астылар. Тукай исемендәге колхоз гектардан 22 шәр центнер ашлык үстереп, дәүләткә ике планнан арттырып ашлык сатып, район күләмендәге ярышта җиңүче булып чыкты һәм хрусталь «Алтын башак» кубогын яулап алды.

...Халык залга узды. Сәхнә түрендә зур рәсем — көләч йөзле, таза беләкле, чөеп яулык бәйләгән колхоз кызы кулларын алга сузган. Тук башаклар салынып төшкән, басу һәм башаклар фонында алтын хәрефләр белән шундый язу язылган: «Ватаныбызга 4 миллион 812 мең пот Сарман ашлыгы бирдек!» Бу миллионнарда — районның барлык хезмәт ияләренең йөрәк җылысы, сәләте, хезмәте. Ватаныбызга нинди олы бүләк! Бер ярым план дигән сүз. Сарманлыларның ил алдында йөзләре

ак. Бригадир Хәйбрахман, комбайнчы Габденур һәм шофер Фәез Закировлар да бу җиңүне яулау өчен ел буе ару-талуны белмичә эшләделәр.

Райком секретаре кыр батырларын тантана белән тәбрикләде һәм барысына да корычтай сәламәтлек, шәхси бәхет теләде.

Бер төркем кыр батыры, оркестрның тантаналы тавышы астында, сәхнәгә узып, авыл хуҗалыгы алдынгыларын тәбрикләргә һәм хөрмәтләргә килгән Уңыш бабайга символик бүләк — ипи белән тоз тапшырды. Кабарып пешкән бодай күмәче. Ул Сарман игенчесе кадерләп җир куенына салган бөртекләрдән шытып чыккан, аның маңгай тире тамган туфракта үскән. «Рәхмәт сезгә, улларым, киләсе елда да шушы залда шатланышып очрашырга язсын!» — ди Уңыш бабай, аларның кулларын кысып.

Залның түреннән тыгыз һәм зур бодай көлтәсе күтәргән таза гәүдәле ике ир атлый. Беренчесе — Габденур. Эре алтын башаклы көлтәләрне сәхнә алдына бастырып куйдылар. Аларның берсенә сарманлылар үстергән ашлык күләме, икенчесенә дәүләт амбарларына озатылган кадәресе язылган.

Аннары иң көчлеләр, иң алдынгылар парады дип атарга лаеклы тамаша башланды. Кызыл байраклы колхозларның җитәкчеләре һәм алдынгы кешеләре, мактаулы бүләкләрен югары күтәреп, Сәйдәш маршы ритмына горур атлап, сәхнәгә уздылар һәм байракларны сәхнә түренә утырттылар. Сәхнә ал байраклар нурына күмелде. Тукай исемендәге колхозның юбилей елы ярышында яулап алган республика байрагын Габденур һәм колхоз председателе Әүхәт Мөхәммәтов күтәреп алып бардылар.

Кинәт быргы тавышы яңгырады. Барабаннар сугып, кызыл байракларны җилфердәтеп, залга пионерлар керде. Яшь ленинчыларны — булачак тракторчыларны, укытучы һәм инженерларны — залдагылар аягүрә басып каршыладылар. Аларның көмеш чыңыдай яңгыравык авазлары, тәбрикләү сүзләре күңел кылларын тибрәтте. Игенчеләрне алар: «Алтын куллы бөек кешеләр», дип атадылар. Габденур исеменә дә мактау сүзләре яуды. Аны почетлы пионерга кабул итеп, муенына кызыл галстук тактылар. Зал дәррәү кул чапты. Иген кырларында ул батыр, кыю — ничә ел рәттән инде тугызар мең центнер ашлык суктыра, җилкәсе киң — әле күбрәген дә күтәрер, тик комбайн бункеры гына чыдасын, ә менә мактау сүзләрен бик күтәрә алмый ул. Президиум өстәле артында һаман башын иеп, күтәрелеп карарга курыккан кебек утырды. Дулкынланудандыр, күрәсең, бит очлары кызарган. Бу истәлекле көнне, бу хөрмәтне онытмас ул!

Тантана тәмамланып, Габденур сәхнәдән залга төшкәч, Хәйбрахман халык арасыннан энесен эзләп тапты.

— Рәхмәт, апаем! — диде ул, аны кочаклап. Аталарча горурлык, аниләрчә җылылык белән чын күңелдән әйтелгән гади генә бу ике сүз төбендә тирән мәгънә ята иде. Габденур аны бөтен тәне белән тойды. Һәм үз чиратында яуланган уңыш белән абыйсын котлады.

Алар урамга чыктылар. Кар һаман ява иде. Авыл, урамнар ак юрган ябынып, яктырып киткәннәр. Багана башларында электр лампалары җемелди. Күбәләктәй кар бөртекләре, тирә-юньгә гаҗәеп бер матурлык биреп, шул ут яктысында очып йөриләр. Очалар, очалар да өй түбәләренә, агач башларына, җиргә кунаклыйлар. Хәйбрахман белән Габденур шушы сихри күренешкә хәйран калып, уйларга чумып, тавышсыз-тынсыз гына озак басып торалар. Каршыда, район Советы башкарма комитеты бинасы янында, нурларын еракка чәчеп, зур кызыл йолдыз яна. Бу дан йолдызын районда урнашкан традиция буенча тегеяки бу эштә иң зур нәтиҗәгә ирешкән хезмәт алдынгысы хөрмәтенә кабызалар. Ә бүген ул 1968 елда районның кыр батыры исемен яулап алган Габденур хөрмәтенә кабызылган иде.

# ӘКИЯТ БУЛЫП КҮТӘРЕЛӘ КАЗАН

*Интервью*

*Узган елның җәендә «Советская Россия» газетасы журналистлары үткән илле еллыкта бөек Идел буе шәһәрләрендә һәм авылларында нинди үзгәрешләр булганын карау һәм алар турында укучыларга сөйләү өчен бу елганы башыннан ахырына кадәр йөреп чыктылар. Алар язган очерклар, репортажлар «Советская Россия» нәшриятында аерым китапта чыгачак.*

*Без укучыларыбызга «Советская Россия» газетасының Татарстан буенча үз хәбәрчесе Марсель Зариповның шушы китапка кергәчәк язмаларын тәкъдим итәбез.*

**Теплоход, безне кунакчыл каршы алган Чувашстанны калдырып, Татарстан ярлары буйлап бара башлаган чакны сизми калдык.**

**Иделдә чик буе баганалары юк. Бу елга һәр сәяхәтче өчен үзенеке, якын. Шуңа күрә дә Калинин, Ярославль тирәсеннән — гомумән, башланган урыннан алып Каспийга кадәр, аның яр буйлары сәяхәтче-туристларның кояшта төсе киткән палаткалары белән тулы. Әле анда, әле монда, әле уңда, әле сул якта шәһәрләр, поселоклар, авыллар күренеп кала, дулкыннар өстендә маяклар чайкала, көймәләрдә балыкчылар «зарыгып» утыра. Белеп кара син аларның кайсы кайдан икәнен!**

**Казанга килеп җиткәндә, без палубада идек. Иске белешмәләрдәге: «Казан шәһәре Иделдән җиде чакрымда», дигән сүзләрнең хәзер инде дөрес түгеллеген белсәк тә, гаҗәпләнми булдыра алмадык: шәһәр кинәт су астыннан калкып чыккандай күз алдына килеп басты.**

**Кояш чыгып кына килә иде. Утлы шар, әйтерсең лә, гүзәл Сөембикә манарасының очына тәрәлгән. Капитан теплоходны нәкъ шул шарга таба юнәлдерде...**

**Без ак палубалы туристлар теплоходына терәлеп туктадык һәм, бер төркем туристларга ияреп, көне буе шәһәр карап йөрдек.**

**Чын-чынлап сокланырлык шәһәр!**

**Борынгы Кремль... Революциянең давыл хәбәрчесе Максим Горький пешекче ярдәмчесе булып үзенең университетларын үткән пекарня, беренче курс студенты Лев Толстой чәче кырылган татар солдатын чыбыклаганны карап торган Арча кыры... Татарстан партия оешмасының тәүгесе — Н. Е. Федосеевның марксистик түгәрәге, Владимир Ульянов укыган ак колонналы Казан университеты... Баш имәс Радищевлар, Чернышевскийлар, декабристлар үткән Себер тракты...**

**Сәлам сиңа, борынгы һәм яшь Казан! Исәнме, Татарстан!**

# Яңару

Беренче адымны ясауга ук бу җирнең яңаруын күрәсең. Иделнең текә ярында буровой вышкалары. Казан порты янында — маяк, шәһәрне яртылаш боҗралап алган яр буе култыксалары. Арырак ак ташлы кварталлар, завод трубалары, чал Кремльнең башняләры мәгърур калкып торалар. Шәһәрнең борынгысы бүгенге белән тыгыз бәйләнгән.

Туристлар шау-шулы Казан урамнарында белешмәләр эзлиләр, музейга чират торалар. Алар бу кызыклы крайның тарихын гына түгел, бүгенгесен дә белергә һәм төшенергә телиләр.

Без дә шул максат белән Татарстан буйлап сәяхәткә чыгып киттек. Ләкин безнең сәяхәт башка төрлерәк иде. Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә сирәк кульъязмалар бүлеге бар. Борынгы әйберләрне саклаучы яшь фәнни хезмәткәр Вячеслав Аристов безгә берничә кызыклы документ күрсәтте. Без алардан файдаландык һәм бүген Татарстанда яшәүче һәм эшләүче кешеләрдән бу иске документларны аңлатып бирүләрен үтендек. Шулай итеп, биш аңлатма, биш тарих килеп чыкты.

Без аларны туристлар эзли торган белешмәләргә өстәмә итеп тәкъдим итәбез. Белешмәләр бик тиз искерәләр бит алар.

**БЕРЕНЧЕ АҢЛАТМА**

## Сабын патшалыгыннан— нефть энҗесенә

«...Бертуган Крестовниковларның стеарин-сабын заводы беренче урында торырга тиеш, аннары 2 пар тегермәне, 14 күн заводы, 2 аракы заводы, 3 тире эшкәртү заведениеләре китә...»
Профессор Н. П. Загоскинның «Казан турында белешмә»се, 1895 ел.

Ә белешмәләрнең берсе бу арифметиканы тагы да образлы итеп: «Астрахань балык патшалыгы булган кебек, Казан да сабын патшалыгы дип атала ала»,— дигән иде.



Без республикада иң мәгълүматлы кешеләрнең берсе белән — Татарстан АССРның Госплан председателе урынбасары К. Н. Мөхәммәтҗанов белән сөйләшәбез. Ул республиканың үткәнен һәм бүгенгесен генә белүче түгел, бәлки иртәгәге горизонтны да башкалардан алданрак күзаллый. Әңгәмә бик эшлекле, тоташ саннардан гына тора, ләкин пошынып утырырга туры килмәде.

— Иске шөһрәт яңаны ярата инде ул,— дип сөйли Мөхәммәтҗанов.— Элекке белән чагыштырганда бүген никадәр ерак киттек без! Тиз оча торган пассажир самолетлары, турбокомпрессорлар, вакуумлы, ышанычлы техника, синтетик каучук, этилен, полиэтилен, сыйфатлары буенча искиткеч булган модификаторлар, кинопленка, сәгатьләр, төгәл үлчәү приборлары, йөзләрчә, меңнәрчә төрле башка әйберләр — Татарстанның бүгенге горурлыгы.

Шунысын да әйтергә кирәк, продукцияләрнең күп төрләре буенча без илдә төп урынны алып торабыз. Мәсәлән, бишьеллыкның соңгы елында илебез алачак 345—355 миллион тонна «кара алтын»ның 100 миллионын безнең промыселлар бирәчәк. Татарстанны илебезнең нефть энҗесе дип бер дә юкка гына атамыйлар. Моннан тыш медикларга кирәкле бөтен кетгутны, кино һәм фотопленканың 60 процентын,

машина төзелеше продукциясенең дүрттән бер, мехның биштән бер өлешен без бирәбез. Югыйсә, территориясе буенча республика илебез мәйданының өч йөз җитмеш дүрттән бер өлешен генә алып тора бит.

Ярты гасырлык биографиябезнең иң төп нәтиҗәсе булган тагын бер үзгәреш бар: революциягә кадәр Казан губернасындагы эре предприятиеләрнең күбесе чит ил кешеләренеке иде. Мех фабрикаларына немец фабриканты Луи Зальт хуҗалык итте. Англиянең «Казан ойл филд лимитед» фирмасы нефть эзләде, Швейцария промышленниклары — бертуган Рамнар машина төзелеше белән шөгыльләнделәр. Фабрика һәм заводларның бүгенге хуҗалары — үз эшләрен яхшы белүче, элекке промышленникларның төшенә дә керә алмаган уңышларга ирешкән эшчеләр, инженер-техниклар. Хәзер Татарстан маркасын дөньяның 50 илендә, шул исәптән Америка Кушма Штатлары, Англия, ГФР кебек капиталистик илләр дә беләләр.

Без үзгәрешләргә, чорыбызның ритмына күнектек инде. Шулай да көн саен булып тора торган яңалыклар шаккатыргыч. Борынгы Казан яшәрде. Авылларны танырлык түгел — колхозлар культура йортлары, китапханә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү биналары салалар. Республика картасында көн аралаш диярлек чираттагы үзгәрешне билгеләргә туры килә. Соңгы елларда крайда яңа промышленность үзәкләре — Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Азнакай, Баулы, Җәлил үсеп чыкты.

Киләчәк индустриясе — зур химия бигрәк тә тиз үсә. Кама елгасында минераль ашламалар, автомобиль шиннары, каучук җитештерә торган химия гигантлы корпуслары калкып чыга. Алар нык үскән чимал базасы — нефть промыселлары, Казан органик синтез заводы белән берлектә Европада тиңдәше булмаган бердәм нефтехимик комплексы булачак.

Колач — ифрат зур, бурычлар — катлаулы, авыр, ләкин Татарстан кешеләренең көченнән килерлек.

## Саннар һәм фактлар

★ 1913 ел белән чагыштырганда республиканың эре промышленносте тулай продукциясе 259 тапкыр, машина төзелеше һәм металл эшкәртү 3 377, төзү материаллары эшләп чыгару 388 тапкыр артты.

★ 1940 ел белән чагыштырганда 1966 елда кеше башына электр энергиясе җитештерү 23,2 тапкыр, бельё трикотажы 120, өске трикотаж 13,3, ит 6,3, колбаса әйберләре 10,2, терлек мае 5 тапкырга арткан.

★ Татарстанда нефть табылуга 25 ел тулды. Бу елларда республика промысел эшчеләре илгә 700 миллион тоннадан артык иң арзан нефть бирделәр.

ИКЕНЧЕ АҢЛАТМА

## Басуларның үзгәрүе

«Шулай дәвам итсә, ашлыкның уңмавы (бу — һәрвакыт булырга мөмкин) ачлык афәтенә китерергә мөмкин...»

Чит илләр министрының махсус йомышлар буенча чиновнигы барон Икскуль фон-Гильдебандт даими булып тора торган ачлыкның сәбәбен белү өчен Казан губернасына килгәч, үзенең донесениесендә шулай дип язган.

Бу хәл 1884 елның язында, Идел буенда бер-бер артлы булып торган ачлык елының берсендә була. Дөресен әйтергә кирәк, Икскуль фон-Гильдебандт бик тыңлаучан чиновник булып чыга. Немецларга хас төгәллек белән ул ачлыктан җәфа чигүче авылларда була, администрация, земство, шәһәр, биржа, җирле матбугат вәкилләре белән киңәшмәләр үткәрә. Мәскәүгә кайткач, без югарыда китергән күзәтмәләрен яза, хәтта практик әһәмияте булган эшлекле берничә киңәш бирә. Иң мөһиме менә монысы: «Энергияне, хосуси эшчәнлекне арттырырга, гомумән, крайның муллыгын күтәрергә кирәк». Өйрәтүе бик җиңел, яхшы теләкләрне тормышка ашыруы гына кыен.

Җирле дворяннар ачлыкка каршы нинди чаралар күргәннәр, бер дә туенып тормаган крайга ничек ярдәм күрсәткәннәр соң! М. Рыбушкин төзегән «Казан шәһәренең

кыскача тарихын актарабыз. Анда болай дип язылган: «Ашлыкның уңмавы сәбәпле, афәтне бетерү максатыннан чыгып, игелекле Казан сословиесе мохтаж кешеләргә өләшү өчен шактый сумма җыюда ярдәм итте: кыш дәвамында дворян сословиесе вәкилләре берничә спектакль куйды. Алардан җыелган көмеш белән 10 000 сум акча икмәк сатып алу өчен ярлыларга өләшенде».

Нинди капма-каршылык: берәүләр өчен — афәт, икенчеләр өчен — күңелле спектакльләр!!

«Безнең шәһәр әле беркайчан да быелгы кебек кәеф-сафа корырга бай түгел иде, күптән инде без болай шатланып күңел ачканыбыз юк иде,— дип язган бу уңай белән «Казан вестнигына өстәмә»нең хроникеры.— Җыелышлар, баллар, маскарадлар, театрлар, ачлар файдасы өчен спектакльләр бер-бер артлы булып кына торалар, хәтта бу ләззәтләрнең кайсын сайлап алырга да кыенсынасың...»

Без кайчандыр барон Икскуль фон-Гильдебандт үткән Казан арты басулары буйлап барабыз. Басулар шундый ук, республикада табигать тарафыннан иң «рәнҗетелгәне», тирә-якта кызгылт-сары комсу һәм балчыклы туфрак, бер генә гектар да кара туфрак юк. Ә ашлык яхшы, башаклар эре, авыр, тук. Мондагы ягымсыз кырларны уңыш бирергә мәҗбүр итү өчен игенче күпме хезмәт һәм тырышлык куярга, күпме кайгыртучанлык күрсәтергә, ниһаять, хуҗалыклар күпме техника һәм машина белән тәэмин ителгән булырга тиеш!!



Безнең гид һәм комментатор Социалистик Хезмәт Герое Н. Б. Бариев — экономикасы нык үскән, югары культуралы «Үрнәк» колхозы председателе.

— Ярдәм күрсәтү спектакльләреннән килгән сәдакага хәерче, ач авылларны туйдырып буламыни! — дип сөйли Нургали Бариевич.— Шуңа күрә дә Казан арты кешеләре эш эзләп читкә киткәннәр, алтын приискаларында һәм шахталарда эшләгәннәр. Башка юл калмаган, чөнки сука белән комсу туфракта уңыш үстереп булмаган. Ашлыкны чәчкәнгә караганда ике яки өч тапкыр гына артык җыеп алганнар. Мужик табигать алдында көчсез булган, теләсә кайсы елда да көндәлек ризыксыз калган.

Дөрес, хәзерге вакытта да игенче һава торышына бәйле, язның яхшы булуын, җәй көне яңгырның вакытында явуын, көзнең коры килүен тели, ләкин уңышның барыбер булачагын белә ул.

Мин дөньяда 50 ел яшәдем, мин Октябрь яшьтәше, илле икенче елдан үз колхозымда председатель. 16 елда уртача уңыш 10,5 центнер булды. Бу — борын-борыннан игенчене туйдыра алмаган кырлардан шундый уңыш. Ә Кама аръягында, Ык һәм Агыйдел елгаларының уңдырышлы ярларында һәр гектардан 20—23 әр центнер уңыш җыеп алалар.

Ашлык — безнең төп табыш. Былтыр колхоз миллион сум табыш алды. Кешеләр хезмәтенә түләргә дә, авылларны төзекләндерергә дә җитә. Хәзер хезмәт көне 3 сум тора. Бөтен фермаларны да яңабаштан салдык, өч бригадада клуб булдырдык, больница төзибез.

Хәзер авыл икмәк белән генә канәгать түгел, тормышны ничек яхшырак һәм матуррак итәргә дигән уйлар кешеләргә тынычлык бирми.

## Саннар һәм фактлар

★ Революциягә кадәр Казан губернасында барлык җирләрнең 40,3 проценты алпавытлар, сәүдәгәрләр һәм монастырьлар кулында иде.

★ Республикабыз кырларында 40 мең чамасы трактор, 90 мең тирәсе бөртекле ашлык, 2,1 меңләп силос уручы комбайн һәм башка күп төрле машиналар эшли.

★ Республика ашлыкка булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә һәм соңгы сигез елда дәүләткә ашлык сатуны 719 меңнән 1 миллион 500 мең тоннага җиткерде.



## Республиканың өлгергәнлек аттестаты

«Мәдрәсәләр һәм мәктәпләр өчен программалар һәм исемлекләр бил-геле бер кагыйдәгә катгый буйсындырылган булырга һәм бөтенләй гомуми белем характерында булмаска тиеш».

(Идел буе краенда татар-мөселман йогынтысына каршы тору чаралары эшләү өчен җыелган киңәшмәнең карарыннан. 1910 ел).

Арча дигән кечерәк кенә район поселогында (илебездә андый поселоклар йөзләрчә һәм меңнәрчә) без башлангыч мәктәпләрдә, шул исәптән милли мәктәпләрдә, эшләү өчен кадрлар хәзерли торган урындагы педучилищеның татар теле һәм әдәбияты укытучысы, ТАССРның атказанган укытучысы Р. Г. Вәлитова белән очраштык. Утыз ел буе ул мәктәпкә барачак, балаларга миһербанлык, белем өләшәчәк кешеләрне укыта. Аның биографиясе — караңгылыктан, наданлыктан яктылыкка, белемгә атлаган бөтен бер халыкның биографиясе ул. Ул балалар йортында үскән, педучилище, аннары институт бетергән. Педучилищеда ук эшли торган ире белән бергә беренче класслар өчен әлифба төзеде. Бергәләп тагын бер дәреслек — татар мәктәпләре өчен туган тел һәм ана теле дәреслеге хәзерләделәр һәм нәшриятка тапшырдылар.



— Безгә шундый кайгыртучанлык булса иде! Математика урынына алла законы, грамматиканы һәм орфографияне корьән алмаштыра иде,— дип елмая Рәмзия Гыйлаҗевна.

Сүз уңаенда шуны да әйтик: корьән, башка дин китаплары кебек үк, беренче битеннән соңгысына кадәр алдый. Бохарада аксак Тимер оныклары салган иске мәчеткә: «Белем ирләр һәм хатын-кызлар өчен мәҗбүри»,— дип уеп язылган. Ләкин эш лозунгтан ары китмәгән, тормышта бөтенләй башкача булган. Кешеләр үзләренең догаларында алланы һәм Мөхәммәтне искә алып килгән меңнәрчә ел дәвамында ир мөселманнарның да, хатын-кызларның да укый-яза белгәннәре бик аз булган.

Патша хөкүмәте вакытында Казан губернасында 1438 кабак, 680 чиркәү, 1890 мәчет булган, 6 дин әһеленә бер укытучы туры килгән, мәгариф эшенә бер елда һәр кеше башына 12,5 тиен тотылган. Татар югары белем турында башына да китерә алмаган. Дөрес, рәсми тыю булмаган. Мәктәпне бетереп, арифметиканың дүрт гамәле турында ишеткәнең дә булмагач, ничек итеп фән сараена керәсең, ди.

Ә без һәркемгә урта белем бирмәкче булабыз. Урта белем! Күз алдына китерәсезме: ликбездән, алифбадан башлаган республика җидееллык мәктәпне тәмамлады һәм өлгергәнлек аттестаты алырга җыена.

Балалар — җәмгыятьнең киләчәге. Алар турында кайгыртудан да мөһимрәк һәм җитдирәк нәрсә юк һәм булырга да мөмкин түгел. Республикада мәктәпләр челтәре яңадан диярлек төзелә. Аларны дәүләт тә, колхозлар да сала. Соңгы биш елда гына да безнең районда 53 мәктәп төзелде, мәгариф эшенә 2 миллион сумнан артык акча тотылды.

Балалар үзләре теләгән теләсә нинди телдә укыйлар. Безнең район башлыча татар районы, мәктәпләрдә ана телендә укыталар...

Р. Вәлитова аңлатмасына безнең ике генә өстәмә булачак. Усал хроникерларның берсе 1883 елда чыккан иллюстрацияле «Идел календаре»нда: «Университетлы Казан

шәһәреннән ерак түгел Арча шәһәрчеге бар. Биш елда управаны асрауга анда 8 667 сум, ә халыкны агартуга нәкъ 50 сум тотылган», дип язган ул.

Бүген Татарстан үзенең табышын менә ничек бүлә: 1966 елда мәгарифкә чыгым 115 миллион сум, ягъни бөтен чыгымнарның яртысы кадәр диярлек булган.

## Саннар һәм фактлар

★ Революциягә кадәр урта һәм югары уку йортларында татарлар берән-сәрән генә булган. Хәзер югары уку йортларында 20 меңнән артык татар укый.

★ Сугыштан соңгы чорда колхозлар гына да 80 мең урынлык мәктәпләр салганнар.

★ Бүгенге Татарстан — эре фәнни үзәк. Анда 11 вуз, 55 фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык учреждениеләре бар. Аларда 1 610 фән докторы һәм кандидаты эшли.

**ДҮРТЕНЧЕ АҢЛАТМА**

«Россиядә, киң мәгънәсендә алганда, татарларның... үз культурасы юк һәм булуы да мөмкин түгел».

Казан губернаторы Галиҗәнап сарае камергеры М. В. Стрижевский хатыннан.

1912 ел.

Совет Татарстанының бүгенге культурасы турында Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре язучы Гариф Ахунов сөйли:



— Бу аңлатманы бәлки өлкән буын язучыларының берсе бирергә тиештер. Республиканың культура эше белән җитәкчелек иткән компетентлы берәр иптәш бирсә дә начар булмас иде. Мин бүгенге Татарстанда культура үсешенең барлык өлкәләренә дә кагыла алмам дип шикләнәм. Шуңа күрә, аңлатманың тулы булуына исәп тотмастан, республикабыз турында «Канатлар кая илтә!» дигән очерклар китабы язганда очраткан кайбер фактларны әйтеп үзү белән генә чикләнәм. Республикабызның бүгенге рухи дөньясы турында фикер алышканчы, Тукайның 1906 елда «Хиссияте миллия» мәкаләсендә язган сүзләрен искә төшерик.

«Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйларына сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга... яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаҗ».

Без менә ике шәхеснең ике төрле карашы белән очраштык. Табигый хәл. Берсе — үзенең бурычы итеп патша политикасына хезмәт итүне санаган, халыкны физик һәм рухи яктан изүне алга сөргән дәүләт чиновнигы карашы; икенчесе — үз милләтенең үсүендә, тәрәккый итүендә, аның аң-белемле, культуралы, иректә булып җитүендә үз бәхетен күрергә теләгән гражданин, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе карашы.

Тукай үзе хыялланган якты көннәрне күрү бәхетенә ирешә алмады. Патша заманының котылгысыз юлдашы — туберкулез аны «дөнья читлегеннән» алып китте.

Язлар килгән саен, апрель аенда, шагыйрьнең туган көнендә, Татарстан шагыйрьләре вакытсыз һәлак булган бөек Тукайның һәйкәле янына җыелып, яңа шигырьләрен укыйлар, хезмәт Татарстанының нинди уй-тойгылар белән яшәвен, шагыйрь хыялланган нәрсәләрнең республикабызда бүген өзлексез тормышка аша баруын сөйлиләр. Октябрь алып килгән азатлык нурларында Тукай һәм Фатих Әмирхан, Каюм Насыйри һәм Шамил Усманов кебек әдипләр, алдынгы җәмәгать эшлеклеләре хыялланганнар чынга әйләнде.

Әдәбият гөрләп үсә, зур колачлы профессиональ музыка туа, рәссамнар яңадан-яңа әсәрләре белән халык алдында зур имтихан тоталар.

Бездә 120 ләп Язучылар союзы члены бар, шул кадәрле үк яшь язучылар беренче китапларын, шигырь җыентыкларын бастырып чыгардылар, театр сәхнәләрендә беренче пьесаларын куйдылар. Сугыштан соң кулына каләм алган яшь буын барлык әдәби жанрларда актив эшли.

Татар язучыларының хикәяләре, повестьлары, романнары Мәскәүдә һәм чит илләрдә басыла. В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан республикасының төзелүенә 50 ел тулу уңае белән, Мәскәү нәшриятлары безнең язучыларның 52 китабын чыгаруны планлаштырды. Өч ел эчендә алар чыгып бетәчәк. 1968 елда инде 18 китап басылып чыкты. Казанның үзендә исә һәр ике-өч көн саен яңа бер китап дөньяга чыга тора.

«Казан утлары» журналының тиражы быел 85 меңгә, «Азат хатын» журналы 220 меңгә җитте. Димәк, халыкның культурага булган ихтыяҗы да көннән-көн арта дигән сүз.

Музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә дә ирешкән уңышлар байтак.

Шәригать сурәт ясауны, «әргән уйнауны», биеп-җырлап йөрүне тыйган. Шул сәбәпле бездә революциягә кадәр милли опера, балет, рәсем сәнгате үсә алмаган. Хәзер Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бар. СССР халык артисты Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсы, Бөек Ватан сугышында һәлак булган гаять талантлы композитор Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты Советлар Союзының күп кенә сәхнәләрен әйләнеп чыктылар, чит ил театрларында уңыш казандылар. Татар совет музыкасының нигезен салучы, Татарстанның халык артисты Салих Сәйдәшев җырлары илебезнең барлык өлкәләрендә яңгырый.

В. И. Качалов исемендәге Казан рус драма театры, Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәләрендә классикларның һәм бүгенге көн драматургларының җитди зур әсәрләре уйнала. Югары профессиональ осталык, идея һәм сәнгать югарылыгы ягыннан өлгергәнлек таләп итүче бу әсәрләр бездә инде сәхнә осталары — зур актерлар, рәссамнар, режиссерлар үсеп җитүен раслый. Мәсәлән, опера театрының Бөек Октябрьның 50 еллыгы алдыннан тамашачыларга күрсәткән «Катерина Измайлова» спектакле Идел буе иҗат коллективлары конкурсында иң яхшы спектакль дип бәяләнде.

Моннан тыш Татарстанда Республика дәүләт күчмә театры, Әлмәт драма театры, Минзәлә драма театры эшли. Соңгы елларда бу театрлар профессиональ осталыкларын нык кына үстереп, Советлар Союзының төрле шәһәрләрендә гастрольләрдә булдылар.

Әдәбиятта, театр һәм рәсем сәнгатендә без үзебезне В. И. Качалов, Ф. И. Шаляпин, М. Горький, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Камаллар нигезен салып калдырган реалистик культура традицияләрен дәвам иттерүчеләр дип саныйбыз.

Әдәбият белән сәнгатьне, культураны, җанлы әдәби процессны халыкның гомуми мәдәни үсешеннән аерып карау мөмкин түгел. Бүгенге Татарстан ирешкән культура үрләре республикабызның гомуми үсеше, алга китеше белән бәйле. Язучылар, рәссамнар, композитор һәм актерлар иҗатының бетмәс-төкәнмәс чыганагы — эшчеләребез, колхозчыларыбыз, интеллигенциябез башкарган зур эшләр: завод-фабрикаларда, колхоз-совхоз кырларында көн саен хезмәт һәләре тудырган материаль байлыклар. Ә халыкка хезмәт итүнең тоеп эшләү безнең иҗатыбызда нык тудыра һәм яңа илһамнар өсти.

**БИШЕНЧЕ АҢЛАТМА**

## Күрәләтә тап төшерергә маташу

«Рудниклар башында да, тау промышленносте идарәсендә дә иделураллылардан (татарлар һәм башкортлар күз алдында тотыла) инженерлар да, референтлар да, геологлар да, галимнәр дә юк...»

Бу — сирәк кульязмалар фондыннан алынган нәрсә түгел, киресенчә, хәзерге заман буржуаз пропагандасының иң үтемле продукциясе. Ул Анкарада Ай-йолдыз

Енишехир нәшриятында басылган. Безне бу китап белән Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыев таныштырды. Без аннан бу китапка аңлатма бирүен үтендек.



— Ялган һәрвакытта да чирканыч, үзенең асылы белән җирәнгеч. Ә мин бу китапны канәгатьләнеп укыдым,— диде Салих Гыйлемханович, елмаеп.— Философ тормыштагы хакыйкать урынына ялганны өстен күрә икән, димәк, аның мактанырлык урыны юк. Бу — иң ышанычлы билге.

Автор күп нәрсәләрдән хәбәрдар. Китапта Идел буе нефтенең үсеше турында саннар шактый төгәл китерелгән. Безнең промыселларда русларның, украиннарның, әзербәйҗаннарның, башкортларның, татарларның зур бер гаилә кебек яшәүләрен һәм эшләүләрен бу китапның авторы Г. Акыш белмидер дип әйтеп булмый. Илебезнең иң бай нефть ятмаларын эшкәртүче орденлы «Татнефть» берләшмәсенең күп санлы коллективында 94 мең татар эшли. 2 мең инженер һәм техник — татар милләте вәкилләре. Сүз уңаенда әйтеп үтик: берләшмәгә Әгъзам Вәлиханов җитәкчелек итә, Ренат Мөслимов — баш геолог. Җитди, ачык фикерле инженерлар: Ришат Булгаков, Галимҗан Әхмәдиев, Әкълим Мөхәммәтҗанов илебездәге иң эре нефть предприятиеләре җитәкчеләре дәрәҗәсенә үсеп җиттеләр. Мондый кыйммәтле кадрлар исемлеген тагын да дәвам итәргә мөмкин.

Тулы характеристика бирү өчен моны өстәп әйтергә мөмкин: Ә. Вәлиханов илнең иң югары парламентында татар нефтьчеләре вәкиле булып тора, Г. Әхмәдиев республиканың Верховный Советына сайланды, меңнәрчә «кара алтын» чыгаручылар орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. Ә яхшыларның да иң яхшылары — участок начальнигы Корбан Вәлиев, нефть чыгаручы Фәсхи Шәрәфетдинов, скважиналар ремонтлау мастеры Әхәт Гобәйдуллин, төзүче Рәшит Саттаров, газ эшкәртүче Мәгъсүм Миңнекәев һ. б. лар илебездәге иң югары исемгә — Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булдылар.

Хәер, Г. Акышны аңларга була. Элек милли республикаларның ирекле союзы урынына берләштерелгән Себер, Бөек Төркстан, Кавказ федерациясе, самостийный Украина һәм «ирекле» Урал-Идел штатлары турында хыялланып йөргән буржуаз милләтче идеологы бит ул.

Идел һәрвакыт үзенең суын Каспийга койган, елга тамагын су башы итеп булмый. Илебез Конституциясе Октябрь революциясенең законлы нәтиҗәсен — Совет Социалистик Республикалар Союзын юридик яктан рәсмиләштергәч, милләтчеләр фашистик Германиягә зур өмет багладылар. Икенче бөтендөнья сугышының ни белән беткәнен тарих белә. Г. Акыш та үзенең лекцияләрендә «өмет кояшы сүрелде» дип саный.

Бүгенге Татарстанның экономик һәм культура үсеше буржуаз милләтчеләргә аз гына да иллюзия калдырмый. Ленин вахтасының бер көнендә Татарстан элекке Казан губернасы бер елда җитештергән кадәр продукция эшләп чыгара. Уңышлар үзеннәнүзе генә килмәде. Алар — эшчеләр, крестьяннар, галимнәрнең зур, фидакарь хезмәте нәтиҗәсе, милләтләрнең һәм халыкларның экономик, культура һәм политик якынаюы нәтиҗәсе.

Мондый шартларда Акышка һәм буржуаз дөньяның бөтен идеологларына нәрсә эшләргә кала! Бер генә хәл — дөреслекне бозып күрсәтергә, фактларны бармактан суырып чыгарырга, кыскасы, Совет строена күрәләтә тап төшерергә генә кала.

Хәер, пропаганданың мондый ысулы буржуаз идеологлар арасында популяр була бара. Күптән түгел Вашингтонда Дортмут колледжы профессоры Майкл Чукасның зур күләмле китабын бастырып чыгардылар. Ул: «Пропаганда җитлеген килә» дип атала да. Хәзерге заман пропагандасының җитлегүен профессор ничек аңлата соң! Кайбер өзекләрен китереп үтим: «Һәртөрле пропаганда эшчәнлегенең максаты алдау булырга мөмкин», «Пропагандистның бурычы — алгыш юлга кертү», «Белә торып фактларны бозу...».

Тагын да аңлатып торуның кирәге юк.

Фатих Хөсни

# КАЙДА СЕЗ, ОЛЫ ЯЗМЫШЛАР?[1]

Күп кенә кимчелекле яклары, җитешсезлекләре, күңелгә хәвеф сала торган тирән чокырлары булуга да карамастан, тоташ бер хәрәкәт-хәзинә итеп алып караганда, әдәбиятыбыз бик тә сәламәт, гел үсүгә, камилләшүгә бара. Соңгы елларда әдипләребез сафына күп кенә яңа исемнәр өстәлде, алар үзләре белән яңа сулыш, яңа бизәкләр, яңа ачышлар алып килделәр. Тема диапазоны киңәйде, тормышның моңа хәтле каләм тимәгән яңа кырлары әдәбиятыбызда чагылыш таба башлады. Моны, аерым алганда, узган 1968 ел прозасы мисалында да күрергә мөмкин.

«Социалистик Татарстан» газетасында, яшьләр һәм балалар газета-журналларында әледән-әле чыгып килә торган хикәяләрнең уңай һәм кимчелекле якларына аерым-аерым тукталып тормастан, тик шуны гына әйтеп үтәсем килә: бу газета-журналлар, проза жанрында уңышлы парчалар килеп торса, урынны кызганмыйлар. Ләкин, гомумән алганда, редакцияләр проза әсәрләренә карата кирәгеннән артык таләпчәнлек күрсәтәләр, дип зарланырга урын юк.

Узган ел дәвамында «Социалистик Татарстан» газетасында басылган хикәяләрдән Габдрахман Минскийның «Туй чәе», Барлас Камаловның «Кетмәгәндә» дигән хикәяләрен, аннары тагы почмагына «эшче» дип пичәт басылган Кәрами иптәшнең «Кара малай» исемле хикәясен, ничектер, хәтердә тотып калганмын. Дөресен әйткәндә, «Кара малай» дигән хикәяне мин бик сагаеп, авторы эшче булганлыгы өчен генә урнаштырылган берәр чиле-пешле нәрсә түгелме дип укый башладым һәм ялгышканымны шундук сизеп алдым. Кечкенә генә мәйданчыкта яшь автор бик оста биеп күрсәтте. Хикәядә гаять тормышчан, күңелне ышандыра торган вакыйга бар һәм ул вакыйганы оста гына алып чыга ала торган җанлы кешеләр-персонажлар да сурәтләнгән. Ишетүемә караганда, Кәрами иптәш хәзер университетка укырга кергән, имеш. Университет белеме алгач, бу иптәшнең әдәбиятта ныграк төпләнеп калуын теләргә кирәк. Заманасында бик шәп хикәяләр биргән һәм соңыннан әдәби фондыбызга кереп калган повестьлар авторы талантлы каләмдәшебез Рафаил Төхфәтуллинның шул ук «Социалистик Татарстан» газетасының ике номерына сузылган «Бер савыт катык» хикәясен бу авторның мөмкинлекләреннән бик түбән дәрәҗәдә торган, юк кына нәрсәләрдә татар халкының — аз да түгел, күп тә түгел — милли характерын билгеләргә тырышып язылган уңышсыз хикәя икәнлеген әйтеп үтәм. Шундый ук уңышсыз хикәяләрнең берсе итеп бу газетада басылган «Катыклы җәннәт» (Касыйм Фәсәхов) хикәясен күрсәтеп үтәсе килә.

«Азат хатын» журналында ел дәвамында барлыгы егермедән артык хикәя басылган. Һәр номерга ике хикәя диярлек туры килә. Хикәя кытлыгы үзен сиздергән бер дәвердә юка журнал өчен зур гына казаныш бу. Хикәяләр белән журналда Гомәр Бәширов, Габдрахман Минский, Атилла Расих кебек танылган язучылар да, урта буын вәкилләре дә, яшь каләмнәр дә катнашканнар. Әдәби сыйфатлары ягыннан хикәяләр тигез түгел. Минем үземә, мәсәлән, гыйбрәтле проблемасы белән Атилла Расих хикәясе, аннары тагы Шәриф Хөсәеновның «Генеральная үборка» дигән көлке хикәясе

[1] Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта сөйләнгән доклад.

һәм байтактан «яшь язучы» исәпләнеп йөртелеп тә, әлегә хәтле ничектер ачылып китә алмаган Әхәт Фазылҗановның «Тәрәзәләр ут ала» исемле хикәясе ошады. «Ошады» дигән сүз эстетик критерий була алмый. Берәүгә ошап та, икенче берәүләргә ошамаска мөмкин. Ни өчен һәм кай яклары белән? дигән сорауларга җавап бирергә кирәк. А. Расих хикәясе турында әйттем дә кебек инде. Анда безнең кайбер яшьләребез арасында яхшы ук нык таралган җилбәзәклек, иркәлек, әдәбиятта тик маҗара эзләү карашыннан чыгып кына язылган фальшь әдәби әсәрләр йогынтысына бирелеп, кызыклы «романтика» эзләү һәм бу ялгыш адымнарның нинди кыенлыкларга төшерү мөмкинлеге гыйбрәтле генә итеп тасвир ителгән. Акылга утырмаган җилбәзәк кыз Кадрия, маена чыдый алмыйча дигәндәй, өйдән качып китә, якындагы зур шәһәрләрдән берсенә барып, тиз генә эшкә урнашмакчы, үзенчә яшәмәкче, үзе теләгәнчә тормыш кормакчы була. Ләкин тормышның аның үзенең законнары бар: анда кайда булса да борын төртер өчен «прописка» дигән нәрсә дә кирәк, аның өчен документларың да кирәк, күзеңне ертып иртә тора белергә дә кирәк һәм башка, һәм башка бик күп нәрсәләр кирәк... һәм шул «һәм башкалар» янына тагын бер җайга салынганчы кесәңдә аз-маз гына акча булуы да кирәк. Әммә тормышны уен гына итеп күз алдына китергән Кадриянең кесәсендә өйдән кыстырып киткән акчасы бик тиз тәтен булып оча, пропискага керә алмый, эшкә урнаша алмый, вакытлыча якты чырай күрсәткән кешеләрдә генә озак тамырланып калырга мөмкин түгел һәм, шулай итеп, эчә безнең кадерле Кадриябез «лаеш шулпасын»... һәм тәмам аптырагач, ничек кирәк алай кайтып, тавышсыз-тынсыз гына тагын шул йомшак күңелле әти-әнисенең канаты астына килеп сыена. Миңа калса, андыйларны әле әйләнеп кайтканнан соң да ишек төбендә бераз «сайратып тотарга» иде һәм шул яшькә җиткәнче балаларын тормышка өйрәтмичә, «өф» итеп кенә үстергәннәре өчен әти-әниләре үзләре дә, нинди генә телдә булса да, «сайрарга» тиешләрдер кебек. Югыйсә, «сыр-бор» уйналды, шуннан тормыш тагы үз ерганагы буенча агып китте. Монда, минемчә, Расихны либераллыгы җиңгән.

Журналистика өлкәсендә күп эшләп тә, әдәби иҗаты белән сирәк күренә торган Әхәт Фазылҗанов «Тәрәзәләр ут ала» хикәясендә табигый ага торган әйбәт тел белән әйбәт кешеләр — кешелекле кешеләр турында яза. Бер караганда, телгә алып сөйләрлек әллә нәрсәсе дә юк кебек. Үзенә тапшырылган эшне намус белән башкара торган Әнвәргә, гаиләсенең дә ишәя төшүен искә алып булса кирәк, поселокның икенче очында узган ел гына салынган, үзәктән җылытыла торган өйдән фатир бирәләр. Әнвәрнең хатыны Гөлфиянең башыннан утын кайгысы берьюлы очты, хәзер инде, «утын! утын!»» дип, иреңне игәп торасы да түгел. Ләкин шунда Гөлфиянең башына икенче хәсрәт төшә: ай, ходаем, монда бит аның күршеләре адәм фәрештәләре иде, бары бергә — югы уртак иде, бер-берсенә туганнарча булышып торалар, ничек аерылмак кирәк андый күршеләрдән! Ләкин, бактың исә, кысыр хәсрәт кенә булып чыга Гөлфиянең бу кайгысы. Яңа йортта аларны шундый ук яхшы кешеләр, ярдәмчел кешеләр каршы ала. Бәлки, Гөлфиянең дә күңеленә шундый уй килә торгандыр, ә укучы буларак миңа килә дә килә: күп тә соң бездә яхшы кешеләр! Кыскасы, әнә шул яхшы күңелле кешеләр белән очрашудан күңелдә сөенеч тойгысы кала. Димәк, хикәя үз эшен башкарды дигән сүз.

Шәриф Хәсәенов, «Генеральная уборка» дигән хикәясендә, шундый ук сөенечне икенче яктан, икенче чаралар — юмор чаралары белән алып килә. һәр йортта диярлек шулай булганы кебек, ике-өч буын кешеләре бергә оешып яши торган Фуат Кәримовичлар йортында да, бер-берсенә бик үк туры килми торган интереслар нәтиҗәсендә, әледән-әле эреле-ваклы, кирәкле-кирәксез чүпләр җыйнала һәм семья башлыгы Фуат Кәримовичның, олыдан кубып, «киләсе ялда — генеральная уборка!» дип, бар тавышына игълан итүен китереп чыгара. Китә өйдә ыгы-зыгы, китә җыештыру, сүзгә килешү һәм берсе алып ташлаганны икенчесенең шыпырт кына яңадан элеккеге урынына алып куюы... Ләкин болар барысы да бер стакан суда давыл уйнату булып кала. Әйләнеп карарга да өлгермисең, үзенең әлеге шул вак-төяк чүп-чарлары белән тормыш Фуат Кәримовичлар өенә яңадан әйләнеп кайткан... Ай, ачы торма да соң бу тормыш дигәнең!

Гомәр Бәшировның «Кыл өстендә» дигән хикәясендә моңа хәтле берәүнең дә кул-аягы тимәгән мәсьәлә — дөнья хәлләре белән мәйханә килеп, туганлык-кардәшлек хисләрен әкренләп суыта, тупасландыра барыбыз мәсьәләсе, язучының шуның өчен

борчылуы һәм безнең бу кимчелегебезне кисәтергә тырышуы сурәтләнә. Ни әйтәсең, бу да бер проблема! Эшлекле булу — кешелекле булуга һич тә каршы килми, югыйсә.

...Балта остасы Биккенә агайны ашыгыч рәвештә почта бүлегенә — телефонга дәшәләр. Аны каты авыру, хәле кыл өстендә калган өлкән апасы чакырткан. Менә шуннан башланып китә ыгы-зыгы: Биккенә агайдан «пичәтле кәгазь таптыру, аннары ат табу, сбруй җыю һәм картның моңарчы бөтенләй диярлек оныткан алмапасын өзгәләнеп искә төшерүләре, моның өчен кызарып, уңайсызланып калулары... Житмәсә тагын барып җиткәч, күңелгә шом сала торган икенче бер «Сары сакал» пәйда була. Бу «Сары сакал» Биккенә агайдан бер эштә аты белән чак кына ярдәм итүен үтенә. Бу «чак кына йомыш» дигәне — шуннан, аяк астыннан килеп чыккан икенче бер фаҗига, имеш. Туган-тумачалары, бертуган энеләре тарафыннан шулай ук онытылып калган ялгыз бер карчыкның мәетен озатышырга ат кирәк булган, имеш. Монда безнең хөрмәтле Гомәр агаебыз артык тартып китермиме, дигән шик туа күңелдә. Биккенә абзабыз да шундыйрак бер борчылу белән кайтып бара. Биккенә абзабыз да (һәм аның энеләре дә) апаларын оныткannар, әлеге мәхрүмә карчык белән дә нәкъ шундый ук хәл. Монда без, район үзәге хәтле район үзәгендә, станциядә, электә үз эшен ярыйсы гына башкарып килгән карчыкның мәетен озатырга, шушы очраклы рәвештә килеп чыккан аттан башка, транспорт тапмаган булуларын, бу хәлнең бернинди киртәгә дә сыймаганлыгын әйтеп тә тормыйбыз инде.

Кыскасы, куертты язучы буяуны. Алайга киткәч, инде ахырына хәтле шулай барырга иде. Фаҗига икән — фаҗига! Оныткан икәнбез «алмапаларыбызны», аның ачысын дә үзебез татыйк, барып керсен иде Биккенә-сакал әлмапасының салкын мәете өстенә. Ә юк, үлгәне әлегә Биккенәнең апасы түгел икән, үлгәне әлеге бүтән бер карчык икән. «Йа хода! Коткардың!» дип җиңел сулап куйгандай була Биккенә карт. «Күрдегез, хәйләсен таптым бит! Туганнарны актык минутларында таки сөйләштерергә, бәхилләштерергә булдым!» дигән канәгатьләнү белән, учын-учка сугып куйгандай итә язучы. «Ничава! Җиңел котылдык! Ике мәет озатканчы бер генә мәет озатабыз. Арифметикасы ук башка!» дип, без дә җиңел сулап куябыз. Хәлбуки, эш арифметикадамы соң монда? Керешкән икәнсең куркытырга — ахырына кадәр куркыт! Гыйбрәте үтемлерәк булыр. Югыйсә, без еш кына очракларда кәҗә тәкәсе хәлендәрәк калабыз: тотынабыз сөзмәкче булып, ныграк китереп төрттерергә ниятләп, артка таба чигенешләр дә ясап карыйбыз, ләкин сөзәргә вакыт җиткәч, мөгезебезне иплэп кенә тидереп кую белән чикләнәбез. А. Расихның югарыда телгә алынган хикәясендә дә сиздем мин бу «мөгез тидереп кенә куюны».

Еллык әдәби продукциябезнең иң зур күпчелеге, әлбәттә, «Казан утлары» журналында урын алган. Монда безнең повестьларыбыз, монда безнең хикәяләребез, монда безнең ел дәвамында денья күргән бердәнбер романыбыз. (Әйтеп утик, ел азагындарак икенче роман — Эдуард Касыймовның «Томан аша» дигән романы да аерым китап булып басылып чыкты.) Монда безнең көчебез, монда ук безнең зәгыйфь якларыбыз да. Журналда ел дәвамында барлыгы тугыз повесть, бер роман, тәрҗемәләре-ниләре белән тартып-сузып уникеләп хикәя басылган. Бу уңайдан, чаң сугып, тагын бер мәртәбә хикәя жанрының әле һаман да тернәкләнеп җитә алмавын билгеләп үтәсе килә. Сыекланы сыйфат ягыннан гына түгел, сан ягыннан да. Калын журналда елга уникеләп хикәя, аның да икесе-өчесеме тәрҗемә хикәяләр — ай-һай ла, бер дә очынырлык факт түгел бу. Монда мин редакцияне гаепләүдән ерак торам. Һәр яктан камилләшкән хикәяләр килсә, редакция сотрудниклары аларны асларына салып утыру өчен яшереп калдырмыйлардыр дип уйлыйм. Мин үзем, мәсәлән, ел дәвамында журналга дүрт хикәя тәкъдим иттем, шуларның өчесе басылды, берсе басылмыйча калды.

Журнал редакциясендә хикәяләр турында сөйләшү вакытында редакция сотрудникларына карата кайбер дәгъва белдерүчеләр булды. Әллә без, кайбер хәлләрдә үтә четерекләнеп китеп, кайбер иптәшләрне өркетеп җибәрәбез микән? Һәр яктан камилләшкән әсәрләр яавып торса, әйтәсе дә юк, бик шәп булыр иде кана! Кызганычка каршы, гел генә алай булмый бит. Моннан инде редакциядә эшләүче иптәшләр өчен стенага лозунг итеп язып куярлык бер кагыйдә килеп чыга: «сизгер күңелле бул, чүп арасында ялтыраган энҗе бөртеге барын күрсәң, моны чүбеннән арындыру өчен авторга булыш. Аның өчен үзең эшләп утырма, ә авторны эшләтә бел!» Редакция-

дә эшләүнең төп асылы, минемчә, нәкъ әнә шунда. Ләкин бу — без язучыларның ялкаулыгын һич акламый. Мин үзем, мәсәлән, гомер буе яхшы хикәяләр язып килгән Гариф Галиев, Мирсәй Әмир, Рафаил Төхфәтуллин кебек язучыларның ел буена берләнбер калын журналыбызда һич югы бер генә хикәя белән булса да тавышларын ишеттерми калуларын аңлый да, аклый да алмый. (Гариф дус гафу итсен, соңыннанрак күземә чалынды: журналның бер номерында «Юмор-сатира» бүлегендә «Минем Мәликәм» дигән кызыклы гына бер хикәясен күрсәтеп алган икән!)

Бер уңайдан, журналда «Язучының күңел дәфтәреннән» рубрикасы астында, хикәягә тартым, асылда хикәя кысасына утырып ук җитмәгән, ләкин үзенең кысан гына калыбында язучының эчке кичерешләрен, иҗади процесска, үзе тудырган образга мөнәсәбәтен, табигатькә, тормышның аерым чагылышларына үзенчәлекле карашын сәнгатьчә чагылдырып үтәргә ярдәм итә торган парчалар басылгалауны мин уңай бер күренеш дип табам. Башкорт язучысы Кирәй Мәргән һәм Ибраһим Гази узган елда бу яктан үзләренә бертөрле ялтырау белән ялтырап алдылар. И. Газиның бу циклга кергән «Профессорда кунакта» дигән парчасы кайбер чиле-пешлерәк хикәяңне бер якка орып салырлык. Элекке кетүче малае, хәзерге кендә фәннәр докторы, профессор Гыйлемхан Ямангулович дигән башкорт агаебыз бәләкәй генә мәйданчыкта биепме бии: чак кына кегеп тә алган, Казаннан килгән кунакка байлык та күрсәтәсе килә, «Волга»сын да үзе йөртә. Әле ничек кенә йөртә! Безнең болай да, үлемнән куркып, алманы юмыйча ашамый торган авторыбызны кызмача баштан очырыпмы очырта. ГАИ инспекторлары да сүз әйтмиләр икән үзенә, тәмам белеп бетергәннәр инде. Тотсалар да, «Так нельзя, Гыйлемхан Ямангулович, надо тише, убъетесь» дип, шаян гына бармак яныйлар да шундук җибәрәләр. Кыскасы, бәләкәй генә парчада шаулап яшәүче җанлы кеше, аның шатлыгы, аның кунакчыллыгы, аның юморы, аның кызмача кешеләргә хас бәйләнчеклеге нәкъ тормыштагыча койган да куйган!

Моңа хәтле сөйләгәннәргә дә, әлбәттә, кагыла, ә моннан соң тукталачак әсәрләрдән, миңа калса, аеруча калку булып, борчулы бер сорау — «кайда сез, олы язмышлар?» дигән сорау туа. Һәм алдан ук ачык әйтеп керешәм: моннан соңгы бөтен сүземне — аерым әсәрләр турындагы уңай фикерләремне дә, тәнкыйть сүзләрен дә — мин, барыннан да элек, әнә шул сагыш — «кайда сез, олы язмышлар?» дигән сагыштан чыгып әйтәчәкмен.

Аерым повестьларга керешкәнче иң элек шатлыклы гомуми бер күренешне билгеләп үтмичә булмый. Әдәбиятыбызның тема диапазоны киңәйгәннән киңәя бара: узган ел язылган проза әсәрләрендә без, мәсәлән, тагын бер кат нефтяникларыбызны да, шәһәр төзүче архитекторларыбызны да, укытучыларыбызны да, сугыш һәм сугыш арты елларында катып-өшеп булса да яшәргә, эшләргә, укырга тырышучы үсмерләребезне дә һәм зур эштә чыныгып, балачага үстергән, «олы оста» дәрәҗәсенә күтәрелгән Лотфулла Дияровларны, Митрофан Зозуляләрне дә, художникларны да һәм студентларны да күрдек. Эш һәм хәрәкәт мәйданнары да төрлесеннән-төрлечә.

Профессиональ осталыгыбыз да чарлана бара. Әдәби геройны коя белү, сюжет һәм фабула мәсьәләләрендә безнең прозаикларыбыз биткә кызыллык китерер дәрәҗәдә түгел дияр идем мин. Әлбәттә, сәнгатьчә бөтенлекне, кирәкне артыктан аера белү осталыгын тулысынча үзләштердек дип булмый әле. Шулай да Сабирҗан булып егылып та Галимҗан булып сикереп тора торган персонажларны хәзер инде күрмәссең, бер-берсенә чабата киндерәсе белән генә тагылган су буе озынлыгы таркау-таркау главалар да сирәк очрый. Телебезнең эчке егәрен тулысынча файдаланып җитә алмасак та, урыны-урыны белән публицистика, газета теле йогынтысына бирелеп киту өянәкләрен, урынсыз калькаларны очратсак та, тулаем, бүгенге әдәби телебез тигез яңгырашлы матур, чын сәнгатьчә тел дәрәҗәсенә күтәрелде.

Шуның да өстенә узган берничә ел эчендә безнең прозабызга Мөхәммәт Мәһдиев, Вакыйф Нуруллин, Мәдинә Маликова, Роберт Батуллин кебек өметле яшь каләмнәр өстәлде. Болар барысы да күңелне шатландыра, артыбызның буш кыр түгеллеген раслый.

Әйберләрне исемнәре белән атап, тәртип белән анализлый башласак, иң элек Эдуард Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» исемле повестена тукталырга туры килә.

Әсәр, башлыча, яшьләр турында. Әле яңарак кына югары уку йортын бетереп чыккан яшь белгечләр, аларның җилкенү катнаш хәвефләнү белән тулган беренче

адымнары, аларның эш урыннарына китү алдыннан җыелып бер «тузан коеп» алулары, аларның билгеләнгән урынга барып җитеп, әкренләп эшкә керешүләре, чын тормыш белән очрашкач, беркадәр таркалып калулары әсәрдә яхшы ук кызыклы һәм тулы чагылдырылган. Язучының теле дә, тулаем алганда, тигез ага, чын әдәби тел дияр идем мин. Образларны тормыштагыча күңелне ышандырырлык итеп коя белү ягыннан да Эдуард Касыймовны көчсез кеше дип булмый. Әченчеме, дүртенчеме повесте, кулы ышанычлы йөри аның. Шулай да «Бир кулыңны, дустым» әсәре миндә канәгатьләнү тойгысы калдырмады. Киресенчә, сөенүдән бигрәк аптырап калу хисе кузгатты ул миндә. Моның сәбәбе: барыннан да элек, әсәрнең төп персонажларыннан булган Әлбинә белән Әхсән язмышыннан, дөресрәге, бу язмышларның артык чәрексез һәм какшау булуларыннан килеп чыга. Шуларга ук соңыннан авторның, яхшы күңел белән, ак канатлы фәрештә итеп трактовкаларга тырышкан өченче бер персонажы — Роберт та килеп кушыла.

Таркалмас өчен, схематик рәвештә генә булса да, әсәрнең сюжет җебен тәшкил иткән вакыйганы кыскача күздән кичерик. Институтны бетергән бер төркем яшьләр, соңгы бер истәлекле эз калдыру өчен, кичкә каршы Идел буена — пикникка чыгалар. Әлбәттә, уен-көлке, яшьләрчә шаярулар, берсен-берсе үртәшүләр һәм, шул шау-шу белән аралаштырып, бокаллар чыңлатып эчеп алулар... Әлбинә белән Әхсәннең үзара якынлыгы электән үк аз-маз кузгалган булса кирәк, әсәрдән моны чамача гына сизенләргә мөмкин. Ләкин Әхсән аерылышу алдыннан бу «аз-маз»ны тирәнәйтергә уйлый. Шул мәкерле ният белән ул Әлбинәне, иптәшләреннән аерып, көймәгә утыртып икенче бер аулак утрауга алып китә. Һәм китә купшы сүзләр, китә төчеләнүләр, әгәр бик теләсә, Әхсән бу кечкенә һәм матур утрауны хәтта Әлбинәнең үзенә үк багышламакчы...

— Әйдә, без аны синең исем белән атыйк, Әлбинә... Изге Әлбинә атавы... Русчасы бигрәк матур: остров святой Альбины,— дип сайрарга тотына мәкерле егет.

Элекке аралашулардан бер нәрсә дә сизмәгән икән, тенгә каршы иптәшләреннән аерып алып китеп, бу аулак атауга алып килергә тырышуыннан да ни дә булса сизмичә, нирен килгән икән — ярый, мәхәббәт диган йогышлы чир кызның күзен сукырайткан, ди,— соң менә хәзер, егетнең менә шушы купшы, сару кайнаткыч төче сүзләреннән дә Әлбинә нәрсәдер сизенергә, итәген-җиңен җыя төшәргә тиеш иде ләбаса! Юк, Әлбинәнең сагаюын күрмибез без. Киресенчә, ул Әхсәннең купшы сөйләнәсөйләнә аның тирәсендә бөтерелүеннән бөтенләй эреп китә. Һәм шул эрегән күңелгә әлеге егет тәкъдим иткән коньяк пары да керәп урнашкач, Әхсәнгә инде артык тырышлык күрсәтүнең кирәге дә калмый...

Монда башта ук шундый мәкерле ният белән йөргән Әхсән гаепле булса, аның җәтмәсенә ансат кына эләккән беркатлы Әлбинәнең гаебе шулай ук кечкенә түгел. Димәк, еларга, соңыннан кемне булса да каргарга аның әллә ни хакы юк. Ләкин автор мәсьәләне алай кырыс төсендә куймый. Ул, аңлапмы, аңлап түгелме, Әлбинәнең гаебен бөтенләй күрмәскә, аны хөкем итмәскә тырышып, үзе тулысынча, янәсе, имеш, җәберләнгән Әлбинә ягына баса, аның белән бергә елаша, комедияне трагедиягә әйләндерергә маташа. Дөресен генә әйткәндә, шулай ансат бирелергә, тугарылырга, күккә карап ятарга риза булган кыздан Әхсәннең соңыннан кул селтәвен, гәрчә гафу итеп булмаса да, беркадәр аңларга да мөмкин. Ник соң ул шундый җебегән, ихтыяр көче булмаган, күбек сүзләрдән алдана торган кыз белән үзенең гомерен бәйләсен! Ул хатынның икенче урында икенче кеше авызыннан чыккан шундый ук төче сүзләрдән алданмаслыгына гарантия бармы?

Соңыннан, авылга барып, укыта башлагач, Әхсәннән йөккә калуын белгәч һәм әлеге шома егет тарафыннан кире кагылгач, Әлбинәнең, ихтыяр көчен бөтенләй югалтып, тәмам әчегән йонга әверелүе («...Дәрес бирүләре авырайды. Дәфтәр тикшергәндә уйга бирелеп, төпсез караңгы упкыннарга чумуларны әйтәсе дә юк... Йөрәгенә кайнар агулы хәнҗәр (!) тыгып бутагандай тоелды һ. б. һ. б.) аның йомшак, җебегән, характерсыз бер кеше булганлыгын әллә кайдан күрсәтеп тора. Димәк, монда Әхсәнне яклап булмаган кебек, Әлбинәне дә һич аклап булмый. Әлбинә безнең чорның мактауга һәм үрнәк итеп куелырга лаек кешесе түгел. Ә менә автор аны барлык чаралар белән якларга, аның йомшак якларына күз йомарга тырыша. Алай гына да түгел, автор шундук Әлбинәгә кулын һәм үзен багышларга әзер торган «рәхмәт фәрештәсе»ндә уйлап чыгара. Ул — аларның студент чактагы иптәше Роберт.

Киң күңелле, су кергәндә күзлеген салырга онытa торган һәм гомумән йомшак табигатьле бу мәми авыз шулай да кеше ташлап киткәнне әләктереп алырга әзер, имеш. Автор моны да, үзенчә, бик гуманлы бер акт, бәладә калган иптәшеңә кул сузу дип аңлатырга тырыша сыман. Ләкин ул бер нәрсәне күздән ычкындыра: Робертның болай «рәхмәт фәрештәсе» булып кылануы шундук икенче ягы — тискәре ягы белән әйләнә. Димәк, Робертның егет буларак һич кенә дә горурлыгы юк икән! Ул, яхшылык эшләү сылтавы белән, юлдан табылган һәрнәрсәне алып кесәсенә салырга әзер торучы талымсыз бер әрвах икән! Кыска гына итеп әйткәндә, повестьта чагылган өч яшь кешенең өчесе дә бик вак җанлы бәләкәй кешеләр — лилипутлар булып чыктылар. Дөрес, дөнья булгач, кызганычка каршы, андый яшьләребез дә бар, андыйларны әдәбиятта чагылдыру — шулай ук язучы эше. Ләкин инде ул вакытта аларга ниндидер «рәхмәт фәрештәсе» маскалары кидереп торуның кирәге юк, әйберләрне (һәм шулай ук кешеләрне дә) үз исемнәре белән атау яхшы. Димәк, бу очракта без үзебез көткән зур язмышлар белән очрашмадык. Әсәрнең бер җирендә Әлбинә язмышына карата автор үзе әйтеп үткәнчә, әсәрнең «трагедиясе көтмәгәндә комедия төсен алды». Әмма бу трагикомедия бер Әлбинә язмышына гына карамый. Журналда басылган укучылар хатларында да әсәрнең, аерым алганда, Әлбинә белән Робертның бу йомшак якларына игътибар юнәлтелгән иде. Моннан тагын бер мәртәбә, безнең укучыларыбыз уңай якны кимчелектән аера беләләр икән, дигән нәтиҗә ясарга кала.

Аннары журналның ике санында Мәдинә Маликованың «Казан каласы — таш кала» дигән повестен укыдык. Бу да яшь белгечләр тормышыннан алынып язылган. Мәдинә Маликованың әдәбияттагы бу зур «дебюты», тулаем алганда, күп яктан игътибарны үзенә җәлеп итә. Беренчедән, әсәр моңа хәтле берәүнең дә кул-аягы тимәгән тормыш материалын кузгата: анда шәһәр төзелеше мәсьәләләре, төзүче инженерлар, архитекторлар, художниклар гәүдәләнә. Ничек һәм ни дәрәҗәдә тирәнлектә? Анысы икенче мәсьәлә. Ләкин яшь язучының шундый җитди материалга тотынуы, ничек тә булса үз сукмагын салырга тырышуы мактауга лаек факт. Икенчедән, автор тормыш-көнкүреш «вaклыкларына» — детальләргә игътибарлы. Димәк, анда художник өчен иң кирәкле сыйфатларның берсе — сизгер күзәтүчәнлек бар. Өченчедән, Мәдинә Маликова кеше күңеленең «карурманнарына», психологик нечкәлекләренә үтеп керүдә дә уңышлы гына адымнар ясый. Хатын-кыз язучы буларак, ул бигрәк тә хатын-кыз табигатен, аның көчле һәм зәгыйфь яклары белән, ачуда игътибарга лаеклы күзәтүләр ясаган.

Әнә шулай өмет баглаткыч яклары булуга да карамастан, «Бир кулыңны, дустым» повестена хас кимчелекләр бу әсәр өчен дә уртак. Бигрәк тә нәрсәдә чагыла бу уртаклык? Әлеге дә баягы: әсәрдә сурәтләнгән яшьләрнең вак характерлы булуында, эре, үрнәк булырлык язмышларның юклыгында. «Үрнәк булырлык язмыш», «Олы характер» дигәннән, тәрләчә аңлатып бутауларга урын калдырмас өчен, бу урында бер нәрсәне ачыклап үтик. Олы язмыш, үрнәк характер дигәнебез, әлбәттә, үзмаксат була алмый. Әгәр бер язучы, тормыш катлаулылыгын бер якта онытып калдырып, башта ук үзенә «Тукта, мин менә олы язмыш, шәп кеше турында язып, шаккатырыйм әле сезне!» дигән максатны куеп, безгә конфет кәгазьләре ябыштырып бизәгән «үрнәк характер» бирә икән, яхшы ният белән әзәләнгән бу «кырып-юнып» ясаудан схематик бер курчакган бүтән нәрсә чыкмас иде. Кызганычка каршы, безнең әдәбиятыбызда моның кайбер «үрнәкләре» булгалый тора. «Олы язмыш» дигәннән без, барыннан да элек, халыкның каршылыклар белән тулы олы тормышын күз алдында тотабыз. Бары тик әнә шундый олы тормышта һәм шул тормышта актив катнашып яшәгән чагында гына олы язмышлар чарлана ала.

Яңадан үз темабызга кайтып, Мәдинә Маликованың әлеге повестена күз салыйк. Әсәрдә яхшы ук озакка сузылган һәм чәбәләнеп беткән мәхәббәт уены бар. Ләкин таза нигезгә корылган һәм күңелгә яктылык, нур сибә торган ныклы мәхәббәт юк. Мондагы яшьләр мәхәббәткә, семья кору мәсьәләләренә гаять дәрәҗәдә җиңел карыйлар һәм шунлыктан ул мәхәббәтләр, ул семьялар комнан оештырган уенчык өйләр кебек шундук таралып га төшәләр. Мәсәлән, әсәрнең баш героинясы Мәрьям Закирова художник Шәүкәт Аитов өчен авыз суларын корытып йөри. Ләкин әсәргә кирәкерешкә үк купшы сүзләр сөйләп, үзен дөньядан өстен куеп, янәсе, имеш, «үз Джокондасын» булдырырга омтылган, оригинальлек артыннан койрык чәнчеп йөргән бу шома егетне башында чак кына акылы һәм кешеләрне таный белү сәләте булган

кеше шундук танып алырга тиеш иде ләбаса. Аның коры куык икәнлеген, ижат иткән беренче картинасының ук уңышсызлыкка очравы, Мәрьям авылга китү белән аны онытып, икенче мавыгулар белән китүе үк ачык күрсәтеп тора. Ләкин Мәрьям һаман сукыр килеш кала бирә — бу аның йомшак характерлы, дөресрәге, характерсыз бер кеше икәнлеген раслаучы факт.

Шәүкәт белән бер авызы пешкәч, икенче мәртәбә ул инде, әлбәттә, өреп кабарга тиеш иде кебек. Сәламәт логика шуны сорый. Хәлбуки, Мәрьям, сәламәт логикага каршы килеп, моның киресен эшли. Шундый ук җиңеллек белән, хәтта Шәүкәткә булган җиңел мөнәсәбәтеннән дә җиңелрәк рәвештә, әйтерсең лә, юлдан тапкандай, шугалак шуып йөргәндә Вилдан атлы икенче бер егетне табып ала. Бер-ике көн очрашкалап йөриләр, өченчеме-дүртенчеме көнендә Вилдан Мәрьямне, кулларын җылытып чыгару сылтавы белән, үзенең ялгыз өенә алып кайта. Кызны җиренә җиткереп пешерелгән чәй белән сыйлый, Мәрьям Вилданның аз сүзле егет икәнлеген һәм детектив китаплар укырга яратканлыгын белә һәм шул җитә... озакламыйча ул Вилдан белән, әллә ни мәхәббәт уены уйнап тормыйча гына, семья корып җибәрә.

**«Барыбер түгелменни! Кем өчен сакларга тиеш соң мин үземне! Кемгә кирәгем бар минем!»** дип хөкем йөртә Шәүкәтеннән колак кактым (ә мин аны «котылган!» дияр идем!) дип уйлаучы Мәрьям. Һәм автор моны тагын да ялангачландыра төшеп, үзеннән:

«һәрхәлдә, **ул Вилданга кирәк иде—һәм ул калды»** дип өсти. Семья коруга моннан да җавапсыз, моннан да «беткән баш»ларча карауның булуы мөмкинме!

Шулай ансат корылган бу гаилә «крепосте», һичбер рәтле-башлы сәбәпсез, шундый ук ансатлык белән җимерелеп тә төшә. Ләкин җимерелеп төшкән урында коры хәрабәләр өеме генә торып калмый, шул хәрабәләр арасында атасыз бала — бәләкәй Фәйрүзәкәй утырып кала...

Семьяның җимерелүе «рәтле-башлы сәбәпсез» дидек, ләкин Мәрьям логикасыннан чыгып караганда, аның үзенә күрә чәрексез генә сәбәбе дә табыла. Күпмедер вакыт үткәннән, Мәрьям ир хатыны һәм һәм бала анасы булганнан соң, кеше белән дыңгычланган тыгыз автобуста бу чибәр апа үзенең яшь вакыттагы «романын» — Шәүкәтне очрата. Соңгы мәртәбә, Шәүкәтнең хыянәтен чамалаганнан соң, күпер өстендә аны яңаклап җибәргәч, еллар үткәннән соң булган очрашу бу. Игътибар итегез: «Мәрьям сумка тоткан уң кул аркасы белән Шәүкәтнең сул кулына орынып китте. Ул кулның кайнарлыгы аның бөтен тәнен көйдереп алгандай булды».

Арырак:

«Аларның күзләре бер генә секундка очрашты... Шәүкәтнең яшькелт күзләре үзгәрмәгән, алар аңа элеккечә үк якын итеп, сокланып карыйлар, аларда ялвару да бар иде. Мәрьям нәкъ бу ялварулы караш алдында, бу сихри елмаю алдында үзен яшь вакыттагыча көчсез итеп сизде».

Тагын да арырак, ире Вилдан Таганрогка, командировкага киткәч...

Алар шәһәр читләрендә, дамба буйларында тагын һәм тагын очрашалар, Мәрьямнең нәфис кулы Шәүкәтнең кайнар учында әледән-әле эреп, югалып калгандай була.

Ә иң ахырдан Шәүкәт тасма теленең «Яңа Джоконда» дип сайраулары да, институтка керергә дип хыялланып йөрүләре дә сабын күбеге булып чыккач, кыскасы, Шәүкәт чибәр егет тәмам пессимистка әйләнгәч, шул җөмләдән, Мәрьямнең үзенең дә «яңа кала», һич югы яңа микрорайон төзәргә дип сөйләнеп йөрүләре «Чулпан» кинотеатрының интерьеры өчен тартышудан һәм индивидуаль проект буенча нибары бер йорт салдырудан ары китмәгәч, алар нечектер үз юлларын үзләре табалар. Шәүкәт шул бөҗәк хәлендә сәхнәдән югала. Ә Мәрьям, мотоцикл катастрофасына эләгеп, больницага озатылган элекке ире Вилданның аяк очына барып тезләнә. Семьяны яңадан тергезергә теләүдәнме бу? Башта арыслан тотардай булып йөргән Шәүкәтнең соңыннан шиңеп калуын күрепме? Әллә, ике куянны куып, берсеннән дә коры калмыйм тагы, дигән расчеттанмы? Ул турыда берникнди дә ишарә юк, укучы үзе баш ватсын. Бер нәрсә ачык: һәрхәлдә, яратып түгел. Кызганып булуы мөмкин, әмма яратып кайтуга һич ошамый.

Монда да шул ук «сыр-бор» гына килеп чыкты. Кешеләр вак, мәхәббәт дигәне вак, укучыны чын ихластан дулкынландыра алырлык язмышлар булмады. Аннары тагын бер нәрсә бик нык эчне пошыра: әсәр күбесенчә мәхәббәт, семья конфликтына гына корылган. Без анда персонажларны гына күрәбез, геройларны түгел. Ә бит әсәрдә героик күтәрелешкә менәрлек мөмкинлекләр ачылып-ачылып куйгалады: әлеге шул индивидуаль проектлар буенча берсе икенчесеннән матуррак йортлар салу һәм стан-

дарт-типовой проектлар буенча берсе икенчесенә ике тамчы су кебек охшаган ямьсез таш капчыклар бастырып кую һәм шушы ике идеяне яклаучылар арасында менә дигән тормышчан конфликт ятмыймыни! Әлбәттә, Мәрьям дә, башка берәү дә моның беренчесен бер селтәнү белән генә законлаштыра алмас, чөнки ул, барыннан да элек, экономикага бәйләнгән. Ләкин мин үзем, мәсәлән, тәзүче-инженер Мәрьям Закированың очынып-очынып бу конфликтка ташлануын бик-бик теләр идем, анда аның — гәрчә конфликтны үзе теләгәнчә чишә алмаса да — гражданлык йөзе ныграк чагылыр иде. Ә болай ул күбесенчә мәхәббәт флирты һәм купшы романтика артыннан чабучы булып кына калган.

* * *

Тукта, чү! Тагын бер адашкан кыз һәм тагын бер «рәхмәт фәрештәсе!» Бу юлы инде сүз яшь язучы Азат Ганиевның «Янәшә» дигән хикәясе турында барыр. Дәгъва юк, иптәшнең каләме бар, аның кулыннан тотып яздырасы түгел. Урман яланы читендәге яңа утыртылган яшь чыршыларны тотаклашып беренче класска мәктәпкә баручы балаларга охшатуы белән үк ул үзенең дөньяга художникларча карый белгәнлеген күрсәтә. Хәер, автор профессиясе белән дә художник икән, моны мин Гариф Ахуновның хикәя алдыннан биргән кереш сүзеннән белдем.

Ләкин, минемчә, әлегә аңарда чын сүз художникларыча җитди итеп уйлый белү җитми. Художникларча уйлый белү дигән сүз ул: образлы уйлануны — тормышча ышандыра торган итеп уйлау белән органик куша белүдән гыйбарәт. Ә Азат Ганиевның «Янәшә» хикәясендә мине, укучы буларак, күп нәрсә ышандырмый. Кыскача гына булса да хикәягә күз йөртеп үтик:

...Зилә атлы кыз Исфат исемле физкультурник егеткә мәҗнүннәрчә гашыйк. Йокы күрми бичара, иптәш кызларыннан аерылган, егете урамнан узганда аның артыннан ияреп йөри — атлавына карап йөрсә дә күңеле була. Хәтта шул дәрәҗәгә барып җиткән ки, Исфат спортзалга кереп, өстен алыштырганда, тышкы яктан фундамент ташына басып, тәрәзәдән аны карап тора. (Егет кызны карап торса, әле ул беркадәр ышандырыр да иде!) Алай гына да түгел, егет аңарга үзенең һичбер омтылышы-мәхәббәте булмаганны белдергәч, кыз серкә кислотасы эчеп, үзенең бөтен эчке газапларына берьюлы нокта куймакчы була. Серкә белән эш барып чыкмагач, суга батып үләргә җыена...

Хәзерге заманда андый мәҗнүн гашыйкларны эзләп табу бик алай ансат булмаса да, ярый, ышандык, шундый бер диванасы табылды, ди. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы бар: инде син ул кызның гыйшык дәрәҗәсен алай «кырык градуска» җиткергәнсең икән, рәхим итеп, моны чишә дә бел. Хәлбуки, хикәядә ул гаять ансат чишелә. Очрый кызның юлында этюдник күтәреп йөрүче Дамир атлы икенче бер егет. Тотына ул кызны матур сүзләр белән юатырга. Кыз серкә эчеп больницага кергәч, аның хәлен белергә бара. Кыз, больницадан качып, батып үлү нияте белән көз азагындагы салкын суга ташлангач... Аллага шөкер, батмый кала кыз, янәсе, имеш, тормышка мәхәббәте аны өскә калкытып чыгара. Юк, хикәянең бу трагикомедияле ахырын телдән сөйләп кенә аңлатып булмас, өзек китерик:

«...Дулкын түгәрәкләре бер-берсен куыша-куыша, ярга таба йөгерәләр. Дамир, ике бармагын авызына кабып, сызгырып җибәрә. Зилә аңа борылып карый: ак күлмәктән, кара чалбардан булганга, Дамирны танымый тора. Таныгач, аңа кулын изәп:

— Хэлло! Әйдә су керәбез,— дип кычкыра».

Судан чыккач, алар янәшә атлап урманга кереп китәләр. Карагыз әле, никадәр җүләр булган «Гроза»дагы Катерина. Батам дип суга ташланганнан соң «Хэлло!» дип кенә кычкырасы икән дә, сикереп чыгып, Борисы белән урманга кереп китәсе икән! Нишләмәк кирәк, ул чагында шул бәлагә тарыган кешеләрне хәзерге кебек ак канатлы «рәхмәт фәрештәләре» сагалап тормаган. Уены-чыны бергә: мәхәббәт кебек олы хис белән болай шаярмыйк, иптәшләр!

Гомумән алганда, өметле бу яшь каләмнә болай сискәндерү, бәлки, кирәк тә булмагандыр. Ләкин әдәбиятта чәч агарткан кайбер өлкән агайларның, журналны чираттагы тикшерү вакытында, тырышып-тырышып бу хикәяне мактаулары, башка яшь язучылар өчен үрнәк итеп куярга маташулары мине бу фактны читләтеп узмаска мәҗбүр итте. Юк, яшь каләмнәрне коры иркәләү белән әллә ни үстерә алмабыз, ә менә дәреслеккә курыкмыйча карарга өйрәтсәк, үстерербез.

Рафаил Төхфәтуллинның «Агымсу» повесте әлегә бетеп җитмәгән, шунлыктан аның турында нинди дә булса тулы бер фикер әйтү кыен. Әмма басылган хәтлесе кайбер каршылыклы фикерләргә китерә.

Болай үзе тигез әдәби тел белән язылган бу повесть яшел Тегәрҗеп урамында аунап, каз бәбкәләре саклап үскән алты малай турында сөйләүдән башлана. Соңыннан, үсә төшкәч, бу егетләр төрлесе төрле яры таралышып бетәләр, Исламгәрәй белән Хәйдәр исемлесе нефть эшендә төпләнеп кала. Әсәр асылда бер кеше — Хәйдәр Рафиков авызыннан хикәя кылына һәм нигездә аның тормышына багышланган. Ләкин алдан ук шуны әйтеп үтәргә кирәк, бу алты малай тормышының берсе дә, шул җөмләдән баш персонаж Хәйдәр Рафиков тормышы да, бөтен бер язмыш дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Персонаж тормышы бөтен һәм түгәрәкләнгән әдәби язмыш дәрәҗәсенә күтәрелсен өчен аның турында озын һәм җентекле детальләре белән сөйләп чыгу гына җитми, барыннан да элек, аның үз эчендәгеме, кешеләр белән мөнәсәбәттәгеме драматик каршылыкларны җиңеп, җитди тормыш конфликты аша чыныгып чыгуы мотлак. Дөресен әйтергә кирәк, Хәйдәр Рафиков хәзергә андый җитди каршылыклар аркылы үткәрелмәгән, тормыш аны йоны уңаена гына сыпырып тора.

Әсәр, бераз сүлпәнрәк акса да, тулаем алганда, табигый тормыш картиналары сурәтләүдән башланып китә. Фронттан малайның этисе кайтып төшүе, шомарган солдат капчыгыннан чыккан юк кына күчтәнәчләре, шикәр күрмәгән малайның шикәр шакмагын акбур дип кабул итеп, язып караулары, дүрт-биш ел чит-ят җирләрдә йөргән солдатның җирне сагынып кайтуы, ләкин монда да нефть казылмалары, трактор гусеницалары белән бозылгалап беткән урамнарны, басу читләрен күреп, аптырап калулары, соңыннан сельпо эшчесе булып китеп, бармагының әкренләп үзенә таба кәкрәя башлавы, тагын да соңыннанрак, шешә тишелеп, төрмәгә эләгүе, аннары малайның нәкъ күз алдында йорт җанлы өтинең, уңнан керсә — уңнан, сулагайдан сугыла икән — сулагайдан йортка дип җыйган бүрәнәләреннең, шифр, калайларының һәм башка эрерәк әйберләреннең суд башкаручысы ярдәме белән озатылуы бик-бик тормышча табигый сурәтләнгән. Үсмер егетнең нефтькә китеп, эшкә керү җаен таба алмый йөрүләре дә кызык һәм табигый. Күңелне ышандырмый торган фальшь ноталар шул табигый картиналар арасына әкренләп, үзләрен бик ыржайтмаска тырышып, керә баралар. Керә баралар, куера баралар, күңелне шомландыра баралар. Иң элек Чагыл тавында инженер-геолог Владимир Петрович Керчинский һәм аның, янәсе, имеш, «нурлы итеп, йогышлы итеп көлә торган» бик сөйкемле, бик матур, соңыннан Мәскәү консерваториясендә укыячак үтә нечкә табигатьле Надясы белән шикәрне акбурдан аера белмәүче, кырылмаган-юнылмаган гап-гади авыл малае, ялан тәпиле Хәйдәр арасында бик нечкә, бик эмоциональ мәхәббәт җепләреннең сузылырга тотынуыннан башланып китә. Ышанып булмый бу нечкәлеккә. Я, балалык тилелеге белән бер кабынып алгандыр да, беткәндер, онытылгандыр, дисең. Алай түгел икән шул менә. Бераз соңыннан, аптыраган-йөдәгән һәм нужасы авызыннан күренеп торган Хәйдәр, эш эзләп, нефть якларына барып чыга. Шул тирәдә буталып йөри торгач, тагын әлеге Керчинский белән очраша. Керчинский хәзер нефть эшенең зур бер җитәкчесе, олы начальник. Һәм, әлбәттә, язучының ихтыяры буенча, кайчандыр Чагыл тавында бер мәртәбә күзенә чалынган малайны шундук танып ала, аны шундук эшкә һәм тулай торакка урнаштыра. Алай гына да түгел, кызы Надяның да әледән-әле малайны искә төшергәнлеген әйтә. Алай гына да түгел, әлегә рәтләп борының да сөртә белмәгән йомыкый авыл үсмерен, янәсе, имеш, кызы Надя белән дә күрештерү өчен өенә кунакка алып китә. Менә шуннан китә инде Хәйдәр өстендә күк капусы ачылып!

Ай-һай ла! Кыз да бик сагынган икән! Китә очрашулар, китә бергәләп киногa йөрүләр, китә өйгә кунакка чакырулар. Өйдәгеләр дә бик шат — «тукта, сабыр... безнеке зур инженер кызы, унынчы классны бетерә, скрипка күтәреп музыка мәктәбенә йөри, киләчәктә консерватория бетереп, олы музыкант булырга хыялланучы безнең ул Надябыз... авызыннан бәрәңгесе күренеп торган һәм әле яңа гына ничек кирәк алай оператор ярдәмчесе булып эшли башлаган кара сөяк татарчонокка тиң килерме?» дип як-якка карап та тормыйлар.

Ә анда, як-якта Хәйдәр белән Надя кыздыралар гына. Гади итеп кенә түгел, прямо, Александр Гриндагыча, романтикалап кыздыралар. Кавышу урынында шартлы билге: буяу карандашы белән зәңгәр җилкән рәсеме ясалып куелган. Ах, бу зәңгәр җилкәнне! Соңыннан кабат-кабат килеп чыгып, ул безнең персонажларыбызның да, хәтта безнең — укучыларның да тәмам башын әйләндерә... Тик автор бу символның Александр Гринда моннан күп еллар элек, күп мәртәбәләр мавыктыргычрак бу-

лып инде җилфердәгәнен генә онытып җибәрә. Аерма тик шунда: Гринда ал җилкән булса, Төхфәтуллинда зәңгәр. Яхшы тормыштан түгел булса кирәк бу литературщина, авторның үзе яза торган тиреләкне тиешенчә белмәвеннән килә булса кирәк.

Гомумән, җил гел уңай яктан исә безнең Хәйдәребезгә: акчасы юкта аңарга этәтөртә акчасын да биреп торалар, мастеры да адәм фәрештәсе Борһан абзый туры килә. Тиз генә курс аша үткәзеп, оператор итеп тә куялар... икенче урынга күчкәч, ул инде — аз да түгел, күп тә түгел — мастер булып та алган. Җитмәсә тагын, шунда, аяк астында гына диярлек авылдашы, шулай ук күз карашы белән «сихерле» ала торган чибәр кыз Айсылу чуалып йөри. Анысының күңеле шулай ук Хәйдәргә төбәлгән. Ләкин әсәрнең юл араларыннан аңлашылганча, анысын әле автор киләчәк өчен саклый булса кирәк. Ирексездән, халык телендә йөри торган шук бер җырның азагы искә төшә:

...Ярны сөйсәң сөй икене,
Берсе торсын запаска!

Ләкин бит халык моны шаярып җырлый, ә безнең хөрмәтле язучыбыз үзенең персонажын чын күңелдән «запас яр» белән тәэмин иткән.

Шактый озынга сузылган күп сүзле бу повестьның киләчәген автор тагын ни белән тутырыр, басылган хәтлесе, дөресен әйтергә кирәк, тегеләйрәк булып чыккан. Уен кебегрәк чыккан. Ә бит беләбез, бу язучының таланты җитди һәм ул талантның бик татлы булып өлгергән җимешләрен дә татып күргән кешеләр без.

Нефтьчеләр тормышыннан булгач, шушы бер уңайдан Гариф Ахуновның «Хуҗалар» романын да, бик тәфсилләп булмаса да, күздән кичерик. Гариф Ахунов бу романын сизелеп торган претензия белән язган. Ягъни, күп яздыгыз вак кешеләр турында, менә мин сезгә тормышны әйдәп баручы кешеләр турында — хуҗалар турында язып күрсәтим әле, дигән теләкрәк тотынган. Хуҗалар һәм хезмәтчеләр төшенчәләренең бик иске төшенчәләр булуы, мондый төшенчәләрнең безнең социалистик чынбарлык нормаларына сыеп-сыймаулары турында бәхәс ачмастан, әсәрнең асылына килик. Сүз дә юк, әсәрнең нефть темасына багышланып язылган булуы һәм бу авторның үз темасына турылыклы буларак, шул темага моннан элек язган һәм инде русчага да тәрҗемә ителеп, билгеле бер дәрәҗәдә рус укучысына да танылып өлгергән «Хәзинә» романы белән уртаклыгы, һава берлеге игътибарны үзенә нык җәлеп итә.

Шулай ук нефть эшенә гомерләрен багышлаган, тыйнак күңелле, эшләрендә таләпчән Лотфулла Дияров, Митрофан Зозуля кебек ветераннарны күрсәтүдә, аларның яшь буын нефтьчеләрен тәрбияләп үстерүдәге тырышлыкларын тасвирлауда да авторның истә калырлык табышлары, уңышлары бар.

Исеме җисеменә муафыйк буларак, әсәрдә күп кенә җитәкче кешеләр, аларның эш стильләре, аларның үз кул астындагы кешеләргә мөнәсәбәте турында байтак кына сөйләнә. Алынган вакыйгаларның масштаблары да зуррак — монда сүз завод салу, кала кору турында бара. Монда шулай ук партия демократиясе, аны бозарга омтылыш моментлары, мондый омтылышларны вакытында кисәтеп, чын демократик принципларның җиңеп чыгулары кебек җитди мәсьәләләр күтәрелә. Намуслылык, җаваплы эшче исеменә, гомумән, кеше исеменә кер кундырмау мәсьәләләре кузгатыла. Әсәрдә Таҗи Вилданов, шофер Атнабай, Сәгыйдә, шәһәрдән практикага кайткан ике егет — сакаллы һәм сакалсыз егетләр — кебек шактый җанлы язылган, характер дәрәҗәсенә күтәрелгән персонажлар бар. Шулай ук кызыксыну белән укыла торган эпизодлар, аерым главалар ялтырап-ялтырап китәләр. Шулай да, тулаем алганда, хуҗалар һәм аларның кешелекле, эшлекле яклары турында бөтенлекле һәм әчкә динамикалы роман килеп чыкмаган.

Нәрсәләрдә соң әсәрнең җитди кимчелекләре?

Барыннан да элек, авторның төп герое Арслан Гобәйдуллинны баштан ук почмакка икона итеп бастырып, аны һәртөрле конфет кәгазьләре белән бизәп, безне — укучыларны аның шәп кеше икәнлегенә ничек кенә булса да ышандырырга тырышуында. Игътибар гына итегез. Арслан сугыш елларында Белоруссия урманнарында партизан булып йөргән. Арслан — әрәм янган нефть газын файдалану юлында бердәнбер кайгыртып йөрүче. Арслан — менә дигән семьянин. Арслан көчле, каты куллы — ул кысып күрешкәндә чыдап кына тор. Арслан кирәгеннән артык гадел һәм ул үзенең бу гаделлеген башкалар алдында демонстрацияләүдән дә качмый. Ниһаять, Арслан аракы эчми. Алай гына да түгел, безнең ул Арслан әле сүгенә дә белми икән. Ни ачуын китерде аның Кожанов дигән Мәскәү кешесе. «Арслан... сүгенә белә

торган кеше булса, ул бәлки Кожановка бирәр усал сүз әйтүдән дә тартынмас иде, ләкин сүгенә белми иде шул», дип ышандыра автор. Кем уйлаган шул хәтле бөтен җире килгән кеше булыр дип, ниһаять, безнең ул Арсланыбыз көрәшче дә икән бит әле. Сарман сабан туенда ничек шакматырды кешеләрне!

Менә шул сөттән ак, судан пакь җитәкче Арслан Гобәйдуллин әйләндерә башлый инде эшне. Ничек әйләндерә? Менә күрербез. Иң элек нефть газыннан файдалану өчен завод салу нияте белән янып-көеп (искә алыгыз: завод салу нияте белән!), ләкин мондагы өлкә оешмалары белән һич киңәш-табышсыз, гомуми план белән шулай ук әллә ни килештереп тормастан, турыдан-туры Мәскәүнең үзенә чаба. Егетлек күрсәтергә тырышып, ут алгандай болай чабып йөрүдән, әлбәттә, берни дә чыкмый. Хәлбуки, эшнең җаен белеп, мондагы кешеләр һәм җитәкчеләр белән киңәшләшеп, шул эшнең җитдилеген һәм кирәклеген гомуми төшенү нигезендә план буенча эшләгәндә, Мәскәү завод салырга һич каршы түгел. Әйтик, горком секретаре Корбанов кебек җитәкчеләр һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты, перспективаны күздә тотып, мәсьәләне бөтен җитдилеге һәм зарурлыгы белән куйгач, аерым кешеләрнең, койрыгы пешкән мәчедәй, чабулап Мәскәүгә барып йөрүләренең кирәге дә калмый. Завод салу гына түгел, заводта һәм промыселларда эшләүче кешеләрнең һаман үсә барган ихтыяҗын исәпкә алып, шул тирәдә хәтта кечерәк кенә бер кала корып җибәрү дә алга килеп баса!

Күрдегезме, үзен бик шәп хуҗа итеп тота торган акыллы баш Арсланыбызның бер очкосы шундук югалды.

Шуннан тагы арага сүзе-өне бик озакка киткән һәм ахырдан сөреме горком бюросына чаклы үсеп җиткән келәм мәсьәләсе килеп кысыла. Мәсьәлә моннан гыйбарәт: Арслан Гобәйдуллин Мәскәүдә чакта, аңарга 40 яшь тулып килүне искә алып, сәүдә системасында эшләүче Ислам Гозәеров диген берәү аның өенә келәм китертә. Логикасы да юк түгел үзенчә: «Ул бит болай,— ди Гозәеров, Арсланның тел төбендәге киренекне сизә башлап,— сезгә кем генә килми, авторитет дигән нәрсә бит ул акыллы булудан гына килми, яши белүдән дә килә. Мәскәүдән дә, Казаннан да түрәкара килми тормас. Аларны бит контора-да гына түгел, өеңдә дә кабул итәсе була. Келәмсез йорт бит ул, ничектер, нурсызрак». Җитмәсә тагы келәм Арсланның хатыны Сәгыйдәгә дә бик ошады, ябышып ята Сәгыйдә келәмгә. Я, ярый, Арслан әлеге Гозәеровның мәкерле хәйләсен фаш итте, бүләк итеп китерү дигән сүз бетте, моның өчен ул Гозәеровны яхшы гына кызартты да... Шуннан Гозәеров келәмнең тиешле бәясен әйтте. Аңлатыгыз ходай өчен, шуннан соң келәмнең тиешле бәясен биреп һәм, һич югы, хатынының күңелен күреп, шул ук вакытта үзеннән күп яшькә олы Гозәеровны да тупас рәвештә рәнҗетмичә, келәмне алып калса, ни булган? Революциягә ни зыян моннан? Юк шул, Арслан Гобәйдуллинга кешеләр күзенә чәчрәп күренердәй гаделлек күрсәтеп уйнарга кирәк. Белмәссең, югыйсә, кеше теленә керүең, начальник кешенең укасы коелуы бар. Ә аңарга хатыны Сәгыйдәнең соңыннан «төне буе елап чыгуы» яки өлкән яшьләрдәге Гозәеровның «үртәлеп һәм соң дәрәҗәдә рәнҗеп, келәмне күтәреп чыгып китүе» берни түгел. Бу фактта Арсланның гаделлеге тары бөртеге хәтле булса, соңыннан ул-бу булмагае дип куркуы һәм эгоистлыгы поты белән.

Шулай ук өстән тәкъдим ителгән Гәрәйшинны «аудару» да, Арслан Гобәйдуллин белән горком секретаре Мөстәкыймов арасында калкып килеп чыккан «бәрелешләр» дә, моның астында яткан «су асты ташлары» да, партия демократиясен яклаудан да бигрәк, ничектер, күптән сакланып килгән эчке наразыйлыкларның тышка бәреп килеп чыгуы кебек тәэсир калдыра.

Гомумән, Гарифның бу романында кыю булып кылану, үткен мәсьәләләр күтәрергә тырышу урыны-урыны белән үзен нык кына сиздерә. Шул ук партия демократиясен саклау мәсьәләсе, яки Булат Дияровның Кырым курортларында йөреп, Мәскәүдә зур театрлар күреп кайткач башкаланы һич кирәксезгә «провинция» белән сөзештерергә тырышып уйланулары — болар, бер карагаңда, «кабыргасы белән куелган» мәсьәләләр кебек күренәләр. Ләкин Гариф бу күтәргән мәсьәләләрне логик азагына кадәр җиткерми, мәсьәлә үткенәя башлагач, әлеге эшне үз агымына калдырып, яки административ юл белән чиштереп, үзе тизрәк башка — «куркынычсызрак» коллизияләр артына поса.

Романның иң зур кимчелеге хәтта аларда да түгел, романның иң зур кимчелеге — романда роман юк! Ул төрлесе төрлечәрәк язылган, арада, әлбәттә, игътибарны нык җәлеп итәрдәй кызыклылары да булган

очеркларадан тора. Роман роман булсын өчен, анда, барыннан да элек, башыннан азагына хәтле үрелеп, бер эпизоды икенче эпизодны тудырып, бер эпизоды икенчесен көчәйтеп, ә тулаем бер фарватердан һич чыкмыйча ага торган бөтенлекле, әзлекле зур вакыйга кирәк. һәм шул зур вакыйганы урыны белән иңнәренә күтәреп баручы, урыны белән вакыйгага кушылып, ләкин шул ук вакытта үзләренең эчке драмаларыннан да аерыла алмыйча, үзләренә тагылган «хәсрәт төеннәрен» газап белән, шатлык һәм әрнү белән ахырына хәтле алып чыгучы эзлекле һәм **ялкынлы характерлар**, персонажлар гына түгел, нәкъ менә **характерлар** кирәк. Шуның да өстенә тагын, бәлки алардан да әүвәлерәктер, әлбәттә, язучы-художникның мөстәкыйль, эзлекле һәм башыннан азагынача бөтен булган карашы — **үз карашы** (мировоззрениесы) булу һәм аның шул карашына чын-ихлас күңелдән иман китергән булуы шарт. Укучының сүрелмәс мәхәббәтен яулаган мәшһүр зур романнарга нәкъ әнә шул сыйфатлар хас та инде. «Тын Дон» романыннан Григорий Мелехов белән Аксинья язмышын яки язучы-художникның революция язмышына тулаем бөтен һәм азагынача нык булган ышанычын-иманын алып ташлап карагыз. Нәрсә калыр икән? «Күтәрелгән чирәм»дә без Давыдов та Давыдов дип авыз суларыбызны корытабыз. Дөрес, Давыдов романның һәм художникның төп идеясен алып килүче зур фигура. Ләкин шуннан сез Нагульновны, аның элекке хатыны Лушканы һәм Тимофей Рваный «өчпочмагын» ташлап карагыз. Романнан ни дәрәҗәдә роман калыр икән? Яки «Война и мир»дан Андрей Болконский, Наташа Ростова һәм Пьер Безухов язмышларын алып ташлап калдырыгыз. Кутузов та калсын романда, Багратион да калсын, Бородино сугышы да калсын, эпопея дип зурлап атарлык әсәр булыр, әмма роман булмас.

Ә бездә соңгы вакытта ансат кәсепкә тотындылар: берсе икенчесенә төкерек белән генә ябыштырылган һәм укучыны боргычлап алып баручы эчке пружинасы булмаган сыек кына эпизодларны, төссез генә персонажларны өсте-өсте өяләр дә, әгәр дә шуны өч-дүрт йөз биткә сузып, «метражын» тутыра алсалар, өстенә чабата хәтле итеп «Роман» дип язып куялар һәм беркатлы укучы шуны чынлап та «роман» дип кабул итәргә тиеш була. Бу саташуга бер чик куярга вакыттыр, минемчә.

Тукта, чү! Тагын бер ватылган семья да, тагын бер «рәхмәт фәрештәсе!». Бу очракта без Ләбибә Ихсанованың «Ана күңеләлеге» дигән повесте турында сүз алып барачакбыз. Бик ук тәфсилләп торырга туры килмәс, чөнки озынгарак сузылуымны үзем дә сизеп торам. Әсәрдә мактап һәм укытучылар тормышыннан алынган, яшүсмерләр һәм алар арасында әле тик береләнә генә башлаган гөнаһсыз мәхәббәт яралгыларын сурәтләгән кызыклы һәм гыйбрәтле генә аерым эпизодлар бар. Атасыз үсүче баланың язмышы турында борчылып яшәүче ялгыз ананың җылы күңеле бар. Әсәрнең төп героиняларыннан берсе Фәһимә Шабаева, гомумән алганда, акыллы, тотнаклы хатын тәэсире калдыра. Ләкин менә шушы акыллы дигән хатынның да семьясы барып чыкмаган. Сәбәбе нәрсәдә? Сәбәбе бик үк ышанычлы түгел шул. Дөресрәге, сәнгатьчә мотивлаштырып җиткерелмәгән. Югыйсә, Фәһимә Фәйзи Шабаев дигән егетне бик яратып чыккан булган, башта алар яратышып яшәгәннәр дә. Малайлары Рөстәм туган. Кыскасы, үзләре өчен генә түгел, әнә шул бәләкәй гражданинның язмышы өчен дә җаваплылыклары артасы бервакытта семья кинәт, комнан өйгән уенчык өй кебек, ишелеп төшә.

«Бик матур яшәргә тиеш иде бит алар. Бер-берсен сөешеп туймас еллары иде. Фәйзи **китеп барды**, ә Фәһимә **тотып калмады. Тотарга теләмәде.** Әйткән сүзе бар иде шул: Фәйзи мин сине бик-бик яратам. Ләкин белеп тор, башкаларга карасаң, бер вакытта да, беркайчан да кичермәм», дигән юлларны укыйбыз без әсәрдә. һәм бу юллар семья җимерелүнең сәбәбен аңлауга беркадәр ачкыч хезмәтен үтиләр. Кыскасы, әлеге шул татлы хыяллар белән очынып, авторның ышандыруына караганда, әлбәттә, сөешеп туймыйча яшәп ятканда, кичләрдән бер кичне алар өенә чәрелдек тавышлы һәм яхшы ук зәһәр бер хатын килеп керә дә, кинәт «куырылып киткән Фәйзигә карап: «Я, нишлибез, судлашабызмы, бергә яшибезме? Безнең балабыз булачак», дип ультиматум куя. Димәк, Фәйзи, Фәһимә белән әлеге шул «бик яратышып» яшәгән арада, кайдадыр читтә, икенче берәүне «кабып карарга» өлгергән икән шул. һәм гомумән, аерылышканнан соң шул ук шәһәрдә шәп кенә яшәп, янәсе, имеш, медицина өлкәсендә танылган бер доктор булып, Фәһимәдә калган улының язмышы белән җиде-сигез ел буена, ичмасам, бер генә тапкыр да кызыксынмавы, хәтта ул җиде-сигез елдан соң улы Рөстәм, үтә эз-

гәләнгән бер минутында, әти кешедән кинәш эзләп, өенә барып кергәч, калтырап төшүе бу шома карьеристның кем икәнлеген һәм кай якка таба тәгәрәргә тиешлеген бер чама белән төсмерләргә алдан ук азмы-күпме азык биргәндер диясе килә. Автор бит Фәһимәне бик акыллы, сизгер хатын итеп тәкъдим итте безгә. Юк, нәрсәдер очы-очы ялганмый монда. Баштан ук нык булмаган аларның мәхәббәте. Яки Фәһимәбез безнең, автор биргән характеристикага каршы буларак, тормыш һәм семья кору мәсьәләләренә бик җиңел караган, тышкы шомалыкка, тасма телгә алданучы юләр бер кыз булган. Хәер, аның юләрлекләре, беркатлылыгы соңыннан да үзен сиздерел-сиздерел куйгалый. Беренчедән, үзе шулай уйламый-сорашмый таякны кинәт сындырып ташлаган бик катгый безнең ул Фәһимәбез, соңыннан, Фәйзи белән араны өзгәннән соң да, озак вакытларга хәтле шул ялангач шалапайны күңеленнән чыгарып ташлый алмый. Икенчедән, янәсе, имеш, үзенең үтә горурлыгы аркасында, бала үстерү, бала тәрбияләү мәсьәләсендә Фәйзине бөтенләй борчымый, бөтен авырлыкны һәм җаваплылыкны үз җилкәсенә ала. Повестьта хәтта аның Рөстәм өчен әлеге «медицина өлкәсендә чәчәк атучы» Фәйзи Шабаевтан алимент алуы турында да ишарә юк. Нәрсә дигән сүз бу? Чуртанны яңадан суга җибәрүме, йөгәнсез ирне җәлләүме? Әллә мораль мәсьәләсендә маниловчылыкны яклаумы?

Хәер, бер караганда, Фәһимәнең бу мәсьәләдә үзен үтә тыныч тотуының үзенә күрә бер логикасы да бар: узган ел басылган башка повестьларда һәм хикәяләрдәге кебек, аның баш очында да «рәхмәт фәрештәсе» — укытучы Хәсән очып йөри. Олы яшькә хәтле кысыр йөргән, ләкин үзе соң дәрәҗәдә шәфкатьле бу Хәсән агай Фәһимәнең әтисез үсү аркасында бераз «чатлы-ботлырак» чыккан Рөстәме турында да бик кайгырта, бигрәк тә ул... Фәһимәнең үзе турында кайгырта түгелме икән? Хәзергә «рәхмәт фәрештәсе» булып ялгыз тол хатынның тирә-юнендә генә чуалып йөргән Хәсән, авторның тулысынча хәер-хаклыгы белән, әсәр азагында инде максатка бөтенләй ирешә яза: «Шул вакыт Хәсән аңар (Фәһимәгә — Ф. Х.) бик якын, бик үз булып тоелды, менә хәзер үк аны күрәсе, аның янында буласы килде. Тик уйлаганын минуты, сәгате белән эшләрлек ашкынулы яшьлеге узган инде, күрешәчәк көнне сабыр гына көтеп торырга кушкан айнык акылы хуҗа хәзер аңа», дигән юлларны укыйбыз без повесть азагында. Бер ирне югалтты, икенчесе менә-менә табылырга тора — димәк, бернинди трагедия дә юк, бары тик чаршаулар ворып, аннан-моннан гына этмәлләнгән сәхнәдә һәвәскәр артистлар тарафыннан уйналган гап-гади спектакль генә бар.

Узган ел «Казан утлары» журналында басылган проза әсәрләре арасыннан игътибарга лаеклы итеп кабул ителерлек ике әсәрне — яшь язучы Вакыйф Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» повестен, аннары тагын әдәбиятта шулай ук соңгы елларда гына күренә башлаган Мөхәммәт Мәһдиевның «Без — кырык беренче ел балалары» дигән әсәрен күрсәтер идем мин. Темалары ягыннан берсе икенчесенә яхшы ук охшаган һәм, әйтергә кирәк, бик үк яңа да булмаган бу ике әсәр — сугыш һәм сугыш арты елларын балалар рыясызлыгы белән чын дөреслегендә һәм каршылыкларыннан курыкмыйча сурәтләүләре ягыннан мине үзләренә җәлеп иттеләр. Шул яхшы сыйфатлары өстенә тагын Мәһдиев повесте үзенең җылы һәм гаять кешелекле юморы белән дә аерыла. Бик кадерле һәм безнең әдәбиятта бик алай ташып та тормый торган бу сыйфатны аның моннан элекке кечкенә-кечкенә парчаларында да сизәргә туры килгән иде. Вакыйф Нуруллинны да бу сыйфаттан бөтенләй мәхрүм кеше дип әйтмәс идем мин. Күбесенчә автобиографик мотивларга корылып язылган — җылысы, җиле шуннан килә торган бу әсәрләрдә үзләрен сиздергән бу башлангыч уңышлар шул башлангыч хәлләрендә генә калмасыннар, алга таба тормышның зуррак картиналарын чагылдырганда үсә-көчәя барсыннар иде, дигән теләк белдерәсе килә. Аннары тагын В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар»ында үсмерләр сөйләменең интонациясен табып җиткезә алмау, аларга «һәм», «чөнки», «ләкин» кебек теркәгечләрне — китап сүзләрен тагу кебек кимчелек тә бар. Балалар һәм үсмерләр авызыннан хикәяләнә торган тасвирда бу аеруча «чит тән» булып күңелне тырный. Сакланырга кирәк бу «китапча» шомалыктан!

Һәм, ниһаять, узган елның нәкъ азагында Әмирхан Еникиның «Вөҗдан» дигән повесте басылды. Бу язучының һәрбер башка әсәрен укыгандагы кебек, зур ләззәтләнү белән, бик кызыксынып, яратып укыдым. (Бу, әлбәттә, автор тасвир иткән хәл-әхвәлләр белән тулысынча килешеп, барысына да имзамны басып бардым дигән сүз түгел —

бәхәсле яклары турында алда сүз булыр).

Әсәрдә бик җылы күңелле, укучыда матур тойгы калдыра торган сөйкемле кешеләр — коммунистлар һәм партиясез активлар бар. Болар рәтеннән мин цех начальнигы Васильевны, Вафаны, Мостафаны, үз эшләренең белгечләре булган һәм һәртөрле демагогиядән ерак торган тәҗрибәле мех осталарын — мишәр агай-энеләрне күрсәтер идем. Шулай ук, кайбер искәрмә белән, беркатлы кыз Хафазаның үзен дә, бигрәк тә кешенең борчулы минутларында килеп, «җан өрергә» йөрүче саф күңелле Бибинур белән Сараны шундук күреп аласың, яратасың. Әйе, мондый кешелекле кешеләр әсәрдә бар. Ләкин, шундыйлар белән рәттән ук, шактый гына сволочьлар да бар. Бу яктан Әмирхан Еникины тормыш каршылыкларын сылап-сыйпап күрсәтүдә берәү дә гаепли алмас.

Әсәрдә, икенчедән, кешелек намусы, вөҗдан кебек «четерекле мәсьәләләр», аларны тап төшермичә саклый белү, аларны арзанлы ләззәтләргә алыштырмау, гомумән, вак җанлылык белән килешмәү мәсьәләләре күтәрелә һәм күп урында уңышлы гына хәл дә ителә. Әлбәттә, әсәрдә олы язмышлы чын герой дәрәҗәсенә күтәрелгән кешеләр юк. Авторның тел төбендә Хәбиб Юлдашевны яклау, урыны-урыны белән аны гаделлек эталоны, башбаштаклык корбаны итеп күрсәтергә тырышу сизелсә дә, дөресен әйтергә кирәк, Юлдашев андый көчләп тагылган «ука эполетлар»ны күтәреп йөри алырлык кеше түгел. Әсәрдә ул вак җанлы, куркак, ихтыярсыз бер кеше булып чыккан. Ләкин, безнең фикеребезчә, әсәрнең бөтен тозы да шунда: ул — тасвирлана торган чорда шактый зур урын алган гаделсезлек, кешегә ышанмыйча карау, кешедән шикләнү, хәтта вакыты һәм урыны белән кешеләр арасындагы иң газиз мөнәсәбәтләрне дә какшатып, баланы атага, гашыйк кызны сөйгән егетенә каршы оскыту элементлары булуын, һәм шуның нәтиҗәсендә, олы язмышлы зур кешеләребез белән беррәттән, Хәбиб Юлдашев кебек мескен җаннар да талкыга эләккәнлекне, ышандыргыч сәнгать чаралары аша, гыйбрәтле, әмма кабатларга ярамый торган бер «тарих» итеп хикәяләп бирә.

Ниһаять, әсәр чын оста кулы белән язылган. Бер укый башлагач аны өзелә алмыйча укыйсың. Әдәби телебезне бөтен эчке егәре, күңелне һәм колакны иркәли торган эчке музыкасы белән яңгырата алуы ягыннан Әмирхан бу әсәрендә дә Әмирхан булып калган, аны башка кем белән дә бутап булмый.

Шулай да... шундый күркәмлекләре булуына да карамастан, әсәр, тулаем алганда, күңелдә ниндидер билгесезлек, сәбәпсез пошыну юшкыны калдыра. Бу, минемчә, автор башбаштаклык корбаны, гаделлек эталоны итеп күрсәтергә тырышкан Хәбиб Юлдашевның хәрәкәтләре, үзе куелган четерекле хәлләрдән чыгу өчен алып барган көрәше (әгәр моны көрәш дип әйтергә ярача?) гаҗәеп дәрәҗәдә вак, кирәгеннән артык кысан, кирәгеннән артык интим шартларга корылган булудан килә булса кирәк. Дөресен әйткәндә, Юлдашев урынсыз җәберләнгәне өчен почмакта яки аерым кешеләр алдында зарланып-елап йөрүдән узмый. Үзе укыган, яшьләгән уздырган, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «үз шәһәре, туган-туфрагы кебек якын, кадерле» булган Казанына соңыннан, еллар, ун еллар узганнан соң да кайтмый йөрүе, кайтса да озак тора алмавы үзе үк безне шиктә калдыра. «Казанга минем ниндидер үпкәм бар икән, дип уйлый күрмә» дип тозәтергә тырышуы да бары тик куркаклыгыннан, үзенә-үзе туры әйтергә йөрәге җитмәүдән генә. Югыйсә, Казаннан китү алдыннан ышанычлы дусы итеп, киңәш сорап барган кешесе Вафа аңарга бик акыллы һәм бик тормышчан киңәш биргән иде бит! Ул хәтта аның киңәшен дә тотмады, янәсе, имеш, «бөгеләсе» килмәде. Димәк, гап-гади логика килеп чыга: гаеп ташланган җирдә, үзең хаксыз дип санаган шул ялган гаепләрне аударып ташларга, үзеңне акларга көчең җитмәгән икән, димәк, син ул гаепләрне өстеңә алдың дигән сүз. Моннан да соң нинди ул «бөгелә алмау» кебек купшы сүзләр белән уйнап торырга!

Хәбиб Юлдашевның Хафазага булган мәхәббәтенә әсәрдә кирәгеннән артык зур урын бирелә. Һәрхәлдә, алар арасындагы дуслык-мәхәббәт мөнәсәбәтләренең уен гына булганлыгы турында башка китерергә мөмкин түгел. Хәтта Хәбиб Юлдашев Казаннан китүенең яки мехбаза җитәкчеләре алдында акланырга теләмәвенең сәбәпләреннән берсе итеп, соңыннан Хафазага авырлык килмәгәе, дип курыкканлыгын сәбәп итеп куя. Менә нинди галиҗәнап кеше ул Хәбиб Юлдашев автор ышандыруы буенча. Ләкин шушы «галиҗәнап» кешенең, әсәр буена бик озак һәм бик ихлас күңелдән яратып йөргән Хафазасын, бары тик пычрак куллы кешеләр тарафыннан гына тозакка эләккәнлеген чамалап торганы

хәлдә һич аңлашмыйча ташлап китүе бер генә дә башка сыймый. Соңыннан, Хафазасы-мескенкәй, аңлашу һәм, бәлки, гафу үтенү нияте беләндер, моның фатирына килә, ике-өч сәгать көтеп утыра, әмма егетне очрата алмыйча китеп барырга мәҗбүр була. Хәбиб тәти егетнең аның артыннан куа чыккан булуы... һәм, имештер, кызны куып җитә алмавы һәм, шулай итеп, сөйгән кызына кул да бирмәгән килеш, аның белән һич аңлашмыйча, китеп баруы — бу инде һич кенә дә егет файдасына сөйләми. Мин шундук егетнең повесть буена «Хафаза! Хафаза!» дип өтәләнеп йөрүләренә, кызның кечкенә йомшак кулларын үз учында эретүләренә, дөресрәге, боларның чын-ихластан булганлыгына ышанмый башладым. Хәтта Хафазаның бутауларын гафу итә алмаган тәкъдирдә дә, Юлдашев, әгәр ул чынлап та галиҗәнап булса, кызны күреп, сөйләшеп, аңлый алган чаклы аңлашып китәргә тиеш иде кебек.

Әллә ни зур геройларны күтәрмәсә дә, шулай да кабатланмаска тиешле гыйбрәтле хәлләр турында хикәяләүче, оста каләм белән язылган «Вөҗдан» повесте, тулаем алганда, әнә шундый «тумыш таплар»дан шулай да азат түгел.

* * *

Югарыда бер әйтелгәнчә, мин монда, түмгәктән түмгәккә сикереп оча торган саескан кебек, фактган фактка сикереп, барлык фактларны кочарга омтылган универсаль күзәтү юлына басмадым. Мин үзем куйган берничә аспект тирәсендә генә биедем. Әлбәттә, татар совет әдәбиятының, шул исәптән татар прозасының да, үсешләре бар. Ул, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да, күтәрелешкә бара. Ләкин шул ук вакытта соңгы елларда прозабызның күңелдә хәвефләнү хисе кузгата торган авышулары да бар.

**Беренче авышу:** без бик вак язмышлар, хәтта «язмыш» дип әйтергә тел дә бармый торган вак көнкүреш маҗаралары белән мавыга башладык. Бу бигрәк тә мәхәббәт һәм семья мәсьәләләрен тасвирлауда үзен сиздерә. Без уңышсыз мәхәббәтләрне, комнан өелгән корылма кебек ишелергә торган семьяларны, әйтерсең лә, юри эзләп йөрибез. Хәтта Мәдинә Маликова югарыда күзәтелгән повестенда, аңлапмы, аңсыз рәвештәме, моны теория дәрәҗәсенә үк күтәрергә тырышып, «кызганычка каршы, күп очракларда гаиләдә тыныч тормыш — кызыксыз тормыш була шул» дип, персонаж исеменнән генә дә түгел, үз исеменнән раслап та утә. Яңа ачыш түгел бу. Үз вакытында Л. Н. Толстой да «Анна Каренина» романын: «Барлык бәхетле семьялар бер-берсенә охшаган, һәрбер бәхетсез семья үзенчә бәхетсез», диган сүзләр белән башлап киткән булган. Бу әле бәхетле семьялар юк диган сүз түгел — берден. Икенчедән, «бәхетсез семья» дигән төшенчәне Толстой тирән мәгънәсендә ала. Анна Каренинаны, мәсәлән, аның бәхетсезлегендә баш очында «рәхмәт фәрештәсе» каравыллап йөрми, ул бәхетсез икән — логик ахырына кадәр, ягъни поезд астына ташланганчыга кадәр бәхетсез. Бу, элеккерәк термин белән әйткәндә, рок. Бу — трагик язмыш.

Бездә дә мәхәббәт һәм семья мәсьәләләрендә җиңел караш, шуның нәтиҗәсендә килеп туган бәхетсезлекләр бар. Алар турында, әлбәттә, язарга кирәк. Ләкин үткен почмакларын уратып узып түгел, уенга әйләндереп түгел, бөтен фаҗигале җитдилеге белән, сәбәпләрен һәм мотивларын чын-чынлап ачып язарга кирәк.

**Икенче авышу:** соңгы вакытларда без әсәрләребездәге персонажларны, күпчелек очракта материаль-хезмәт, иҗтимагый эшчәнлек атмосферасыннан бөтенләй диярлек аерып, гел әдәп-әхлак, дуслык-мәхәббәт, семья-көнкүреш маҗаралары сферасында гына сурәтли башладык. Бу — моннан элек күтәрелгән һәм рәтле бер нәтиҗә дә бирмәгән ялангач «производство» темасын яклап чыккан берьяклы өянәкка антитезис рәвешендә башланды булса кирәк. Теге якка сөрлегү хата булганы кебек, бу якка сөрлегү дә хатадан бүтәнгә алып бармый. Кеше гел «эшләп чыгарып» кына тора алмаганы кебек, кеше, иҗтимагый хезмәт сферасыннан аерылып, гел көзгегә карап, гел үзе белән үзе мавыгып кына да яши алмый. Кешенең хезмәт эшчәнлеген аның ук көнкүрештә үзен тотышы белән гармоник бәйләп тасвирлау — менә бу безнең икенче төп бурычыбыз.

Әлбәттә, һәр жанрның үзенә хас табигатенә ригаяле булу, форма мәсьәләләрендә пехтәлек, инде бик күпкә үскән әдәби телебезнең кагыйдәләрен, эчке аһәңен, музыкасын тоеп язу ягыннан да бездә әле урынына утырып җитмәгән яклар бар. Ярый, алары инде башка вакытка, башка иптәшләргә калсын.

## Рафаил Төхфәтуллин

# ҖЕПЛӘРНЕ НЫГРАК ТӨЙНИСЕ БАР[1]

Игенчеләр һәм нефтьчеләр иле Татарстан узган ел ике зур җиңүгә иреште: республика нефтьчеләре илдә 300 миллион тонна кара алтын чыгаруда лаеклы өлеш керттеләр, ә игенчеләребез моңарчы булмаганча мул уңыш үстерделәр. Бу җиңүләр олы бәхетебезнең нык нигез ташлары булып ятты. Бу җиңүләр Бөек Ленинның 100 еллык һәм туган республикабызның ярты гасырлык олы юбилейларын якты йөз белән каршылау өчен көрәштә ышанычлы нигез булулары белән тагы да куанычлырак.

Җиңүләр күңелләрне шатландыра. Ләкин безнең күңелләр бары шатлык-куаныч белән генә тулмаган. Борчулар һәм хәвефләр, тынычсызлык һәм әрнүләр дә җитәрлек әле. Одер якларыннан һаман да корал чыңнары ишетелә. Хәсрәтле Вьетнам күгендә һаман да сугышның кара сөреме таралып беткәне юк... Тагы да карарак сөрем — идеологик диверсия белән мәкерле империализм безнең олы ышанычыбызны какшатырга, якты өметебезгә күләгә төшерергә көннән-көн тырышлыгын арттыра... Дөнья бөек фәнни ачышлар, зур җиңүләр һәм дәһшәтле тетрәнүләр алдына күзгә-күз диярлек килеп басты. Тулысынча әзерме без бу сынауларга? Ышанычыбыз һәм өметебез булган яшь буынның йөрәкләрендә ата-бабаларыбыз мирасы — революцион ялкын җитәрлек дәрлиме? Бөек Ленин революциянең иң явыз дошманы дип атаган бюрократизм һәм карьеризм безнең арабызда нигә әле һаман да яши? Мораль тотнаксызлык, хулиганлык һәм эчүчелек чирләре нигә тормышыбызны һаман да ямьсезли?... Әнә шундый һәм тагын, тагын бик күп сораулар безнең күңелләрне туктаусыз борчый, тынычсызлый һәм әрнетә дә.

Татар совет прозасы да үткән елда илһамлы һәм тынгысыз, куанычлы һәм борчулы сораулар белән тулы иҗади чор үткәрде. Әйтергә кирәк, бу иҗади ел шактый мул җимешле булды. Моны басылып чыккан проза әсәрләренең аннан элекке елларга караганда сан ягыннан күплеге генә расламый, билгеле.

Үткән елда «Казан утлары» журналында һәм аерым китап булып ике роман, 13 повесть басылып чыкты. Димәк, күләмле 15 әсәр. Аларның һәркайсының үз темасы, укучыларга әйтер сүзләре бар. Э. Касыймовның «Томан аша» романы татар әдәбиятында «авыру урын» булып килгән эшчеләр сыйныфы темасына якты нур өстәсә, М. Маликованың «Казан каласы — таш кала» повесте әдәбиятыбызда әле бөтенләй яктыртылмаган архитекторлар һәм художниклар тормышын тасвирлый. Г. Ахуновның «Хуҗалар» романы, М. Хәсәновның «Очар кошлар» повесте татар әдәбиятында инде күтәрелеп килгән чирәм булган нефтьчеләр темасына тагын яңа буразналар сыза. Л. Ихсанованың бала тәрбиясенә багышланган «Ана көндәлеге», Э. Касыймовның әхлак-намус мәсьәләләрен күтәргән «Бир кулыңны, дустым!» повестьлары да темаларының яңалыгы белән куандыра. М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» һәм В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» повестьларының темасы яңа түгел. Авыр сугыш елларындагы чыдамлы һәм батыр тыл сурәтләнә ул әсәрләрдә. Ләкин һәр ике автор шушы кабатланган темага моңарчы кабатланмаганча итеп, һәр икесе үз әйтер сүзләре белән матур әсәрләр иҗат иткәннәр. М. Шәрифуллинның колхоз авылының бүгенге көненә багышланган «Җир хуҗасы» повесте яшь замандашыбыз образы — яңа тип колхоз председателе белән истә кала. М. Хәсәновның узган ел чыккан икенче бер повесте — «Җирән кашка» ат ямьмышы аша халкыбыз тормышының кызыклы гына сәхифәләрен

[1] Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта сөйләнгән доклад.

ача. Ш. Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» повесте комсомолның Ватан сугышындагы героикасына матур сәхифәләр өстәсә, Р. Хафизованың «Таң билгесе» повесте безне ерак Себердәге мәктәп тормышы белән таныштыра.

Прозабызның авыр артиллериясе — өлкән буын язучылар, аннан элекке елларда фундаменталь әсәрләр белән сизелерлек залплар биргәннән соң, үткән елда тынычрак тордылар. Шулай да һөҗүмнең зур икәнлеген, һаман да киеренке икәнлеген искә төшереп, авыр артиллерия дә гөрселдәп-гөрселдәп куйды. Киң катлам укучылар һәр яңа әсәрен түземсезлек белән көтеп ала торган олы сүз остасы Әмирхан Еники үзенең «Вөҗдан» исемле яңа повестен бирде. Повесть утызынчы еллардагы катлаулы тарихи чор вакыйгалары аша безне җәмгыять һәм шәхес язмышы турында җитди уйландыра. Укучыларның хаклы ихтирамын казанган Габдрахман ага Әпсәләмов совет яшьләренең Ватан сугышындагы үлемсез батырлыгына дан җырлаган «Миңа унтугыз яшь иде» повесте белән шатландырды. Ничәмә еллар татар совет прозасын фидакарь төстә төпкә җигелеп алга сөйрәп барган, армас-талмас иҗади дәртле Габдрахман аганың, мәкерле авыруны да батырларча җиңеп, шул ук тынгысыз иҗат дәрте, шул ук искиткеч өлгерлеге белән яңадан әдәбият мәйданындагы үз урынына басуы — әдәбиятыбыз өчен, меңләгән укучылар өчен үткән елның зур куанычы.

Әлбәттә, әсәрләрнең нинди профессия кешеләре турында язылуы гына әдәбиятыбызның тематикасы киңәюдә төп билге түгел. Ләкин безнең чорда эшче, колхозчы, интеллигенция образын аның профессиясеннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Хәзерге чорда эшчеләрнең, интеллигенциянең профессия төрләре йөзәрләгән булса, колхозчыларның профессия төрләре дә дистәләп санала. Тагы да әһәмиятлесе — безнең чорда һәр профессиянең коммунистик төзелештә уртак максатка юнәлгән үз бурычлары, үз каршылыклары, үз көрәше бар. Әнә шуның өчен дә әдәбиятта никадәр күбрәк профессия кешеләренең образлары чагыла икән, бу инде безнең тормышыбыз һәм көрәшебез дә шулкадәр киңрәк, тулырак чагыла дигән сүз. Әнә шуның өчен дә күп төрле профессия ияләре булган укучылар һәркайсы язучыларга «Нигә безнең турыда да язмыйсыз?» дигән таләпләр куялар икән (гәрчә без бу таләпкә әле кына өлмәебрәк карасак та), бу сүзләрдә, һичшиксез, хаклык бар. Һәм менә шуның өчен дә узган ел прозасында профессияләр штаты шактый киңәйгән икән, мин моны әдәбиятыбызның тематикасы киңәюдә бик куанычлы билге дип саныйм. А. Расихның «Ике буйдак» романы белән башланган мондый киңәю киләчәктә дә яңадан-яңа мәйданнар яуласын!

Узган ел прозасында күзгә күренеп торган икенче күңелле күренеш ул — повестьларның күплеге. Әйткәнемчә, былтыр укучылар хөкеменә 13 повесть бирелгән. Элегрәк елларны бу сан 3—4 тән артмавын искә алсак, повесть жанры үсешендә былтыргы сикерешнең шактый биек икәнлеге күренә. Шунысы да игътибарга бик лаеклы: былтыргы повесть авторларыннан дүртәү — М. Маликова, М. Мәһдиев, В. Нуруллин һәм Р. Хафизова — бу жанрда беренче әсәрләре белән чыктылар.

Болар барысы да — үткән ел прозасының күләм ягыннан үсүе һәм тематикасының киңәюе дә, повесть жанрының саны һәм авторлары сизелерлек артуы да, факт буларак, күңелле нәрсәләр. Тагын шунысы бик куанычлы: прозабызның яңа биеклекләр яуларга тулысынча сәләтле икәнлеген күрсәтүче, шул биеклекләргә сикерергә былтыр мәйданның тагы да киңәюен күрсәтүче матур күренешләр болар.

Республикабыз игенчеләре җитди уңышларга ирешкән үткән елда, димәк, әдәбиятыбызның, аерым әйткәндә, прозабызның йөзенә кызыллык килерлек түгел. Игенчеләрнең һәм нефтьчеләрнең былтыргы уңышлыкларының иң беренче сере — аларның профессиональ осталыклары артуда. Гомумән, үз эшеңнең чын остасы булу — бүгенге чорда һәр профессия иясе алдына заман үзе куйган бик мөһим таләп. Язучылар алдына исә заман бу таләпне икеләтә кискенлек белән куя.

* * *

Былтыргы проза күләм-сан ягыннан шактый мул икән, осталык-сыйфат турында сөйләшү аеруча зарури. Бу сан-күләм сыйфат ягына зыян китермәгәнме? Китапларыбыз су-дым белән генә бүртеп калынаймаганмы? Күңелгә әнә шундый борчулы сораулар килә.

Аннары, тагын бер кызыклы факт. Үткән ел «Казан утлары» журналында повестьлар саны сигез булса, хикәяләр саны, тәрҗемәләр һәм кыска юморескаларны исәпкә алмаганда, җиде генә. Элегрәк елларны мондый хәлнең булганы юк иде. Һәрхәлдә,

журналда хикәяләр саны повестьларга караганда 2—3 тапкыр артыграк була иде. Былтыр исә повестьләр хикәяләрне дә уздырып җибәрде. Хикәялек киндердән тартып-сузып повесть тегәргә керешмәдек микән, дигән хәвефле уй да күңелне тырнап ала. Повестьлар белән җентекләп танышып чыккач, мондый шик-шөбһәләрдән күңел бераз айный, ләкин һич тә тулысынча тынычланып җитми. Нигә? Чөнки әле повестьларда, шулай ук романнарда да кирәкмәс озынлыклар, очы-очка ялганып җитмәгән сюжет җепләре һәм композицион таркаулык һаман да үзен сиздерә.

Әйткәнемчә, М. Маликованың «Казан каласы — таш кала» повесте безне архитекторлар һәм художниклар дөньясына алып керүе белән кызыклы. Чыннан да, повестьта без бу дөнья белән шактый тулы танышабыз, иҗади интеллигенция кешеләре борчуы белән борчылабыз, алар алдындагы проблемалар белән дулкынланабыз. Бу яктан повесть, югарыда әйткәнемчә, образларының профессиясе белән үк әдәбиятның тематикасын киңәйтә. Ләкин шунда ук мәсьәләнең икенче ягы килеп баса. Образ буларак та әдәбиятка яңалык өстиләрме соң алар? Әйе, повестьта андый образлар да бар. Моратны һәм Шәүкәтне без, чыннан да, архитектор, чыннан да художник итеп күрәбез. Гәрчә Шәүкәтнең таланты чамалы булса да, ул — нәкъ таланты чамалы булган художник образы. Ләкин менә повестьның төп герое Мәрьям турында моны әйтә алмыйбыз. Эш урыныннан киттеме, Мәрьям архитектор булудан туктый, эшеннән аерылдымы, Мәрьям шактый җилбәзәк бер хатынга әйләнә дә кала. Ә буш вакыты, эшеннән тыш вакыты, аның бөтенләе белән диярлек мәхәббәт маҗараларыннан гыйбарәт. һәм менә нәкъ шул урыннар повестьның композициясеннән бүлтәеп-бүлтәеп чыгып торалар.

Әлбәттә, мин әсәрдә образның хезмәтенә фәлән кадәр, шәхси тормышына һәм мәхәббәтенә фәлән кадәр урын бирелергә тиеш дигән примитив караш әйтергә җыенмыйм. Биредә сүз образның әдәби бөтенлеге, тормышчанлыгы турында бара. Образда шәхеснең хезмәте, көнкүреше, мәхәббәте, омтылышлары бөтен каршылыклары белән логик эчке бәйләнештә бирелергә тиеш бит. Әнә шул эчке бәйләнеш аз гына таркауланса да, образның бөтенлегенә зур зыян килә һәм бу, үз чиратында, әсәрнең композициясен боза. «Казан каласы — таш кала»дагы композицион таркаулык та нәкъ менә төп герой Мәрьямнең образ буларак бер бөтен итеп уйланып җиткерелмәвендә, минемчә.

Бу яктан караганда, Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым!» повестендагы Әлбинә образы — шактый уңышлы. Әлбинә турыдан-туры эш өстендә, ягъни дәрес биргәндә бик аз күрсәтелә. Ләкин һәр эпизодта аның укытучы һәм нәкъ менә яшь укытучы икәнлеген сизәсең.

Г. Ахуновның «Хуҗалар» романындагы Арслан образы да шактый бөтен. Арслан эштә дә, өендә дә, хәтта үзенең беренче мәхәббәте Мөнәвәрә белән очрашканда да шул ук акыллы җитәкче булып кала. Ләкин автор акыллы җитәкче образын тудырам дип артыграк та тырышып җибәрә. Арслан эчми дә, тартмый да, үтә гадел дә. Ул хәтта, кулында йөзәрләгән машина була торып, хатынын да шәһәрдән ерактагы бакчасына җәяү генә йөртә һ. б. Геройны бу рәвешчә, тырышып-тырышып, үтә уңай итәргә омтылу, беренчедән, аның ышандыру көченә зыян итсә, икенчедән, аны үсүдән мәхрүм итә. Арслан образы белән дә шундый ук хәл. Ул әсәргә акыллы җитәкче булып килеп керә, әсәр ахырында да шул ук дәрәҗәдә кала. Геройны, бигрәк тә төп геройны үсүдән мәхрүм итү, үз чиратында, «Хуҗалар» романының композицион төзеклегенә дә зыян китергән. Романдагы вакыйгалар берсе-икенчесеннән үсеп чыкмыйлар, күп вакыйгалар аерым-аерым туалар. Сабан туе вакыйгасы һәм ахырдагы янгын вакыйгасы әнә шундыйлар. Бу вакыйгалар берсе дә әсәрдәге эчке динамика һәм характерлар көрәше нәтиҗәсе түгел. Шунлыктан алар, гәрчә аерым-аерым бик матур язылсалар да, романның гомуми тукымасына органик төстә бәйләнмиләр. Буянов образына кагылышлы бер пот алтын вакыйгасы, шофер Атнабайның «ашыгыч ярдәм» машинасында йөргәндәге маҗаралары романның композициясенә табигый үрелмиләр.

«Социалистик Татарстан» газетасында (29 декабрь, 1968 ел) чыккан мәкаләсендә «Хуҗалар» романының мондый композицион таркаулык күренешләренә Х. Сарьян да игътибар итә. Ләкин ул болар турында бик өстән-өстән, «гафу ителердәй җитешсезлек» дигән формада гына әйтеп үтә. Сүз әсәрнең композицион кимчелекләре турында бара икән, бу инде аның сәнгатьчә дәрәҗәсенә беренче бәя дигән сүз. Ә әсәрнең әдәби эшләнеш дәрәҗәсе турында, әдәби осталык турында без болай сүз

уңаенда гына түгел, уртага салып, тулы тавышка сөйләшергә тиешбез.

Композицион бөтенлеккә зыян китерә торган кимчелекләр Э. Касыймовның «Томан аша» романында да бар. Г. Ахунов романында аерым-аерым вакыйгалар композициянең уртак җебенә зәгыйфь бәйләнсәләр, Э. Касыймов романында аерым геройларның язмышы бу уртак җепкә тиешенчә төйнәлеп җитми. Фоат образы белән нәкъ әнә шулай. Роман зур бер химия заводы коллективы турында, ә Фоат бу коллективтан гел читтәрәк йөри. Хәтта аның эше дә заводтан читтә — ул машина белән станциядән заводка чимал ташый. Ә бит Фоат романда төп геройларның берсе һәм ул төп вакыйганың уртасында булырга тиеш иде. Ләкин алай түгел. Фоатның характерын ача, язмышын билгели торган вакыйгалар да — суга батучыны коткару, караклар шайкасына юлыгу хәлләре дә коллективтан читтә, завод тормышына һичнәрсәсе белән бәйләнмәгән шартларда үтә.

Сюжет киеренкелеге, ягъни әсәрнең соңгы битенә кадәр укучыны «кулдан ычкындырмау» — композициянең бик мөһим һәм кыен таләбе. Бу яктан караганда, былтыргы прозада сюжетның ул арка җебе тиешенчә тартылмаган әсәрләр байтак. Сюжет киеренкелеге дип мин, әлбәттә, җеп очларын чуалта-яшерә баш әйләндергеч маҗаралар коруны күз алдында тотмыйм. Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда, мәсәлән, үзәк бер сюжет җебе бөтенләй дә юк кебек. Ләкин повестьның һәр бүлеген, һәр битен аерыла алмыйча укыйсың. Чөнки «Туган ягым — яшел бишек»нең һәр бүлеге, һәр бите безгә халкыбыз тормышының кызыклы һәм гыйбрәтле, моңсу һәм горур сәхифәләрен ача бара, повестьның һәр бите теленең гаҗәеп нәфислеге, гүзәл бизәкләре белән үк укучыга куанычлы эстетик ләззәт бирә. Бирелә сюжет маҗарасының бөтенләй кирәге юк, андый маҗара укучыга әсәрнең һәр битендәге халык күңеле җәүһәрләре белән ләззәтләнергә комачаулар гына иде. Димәк, «Туган ягым — яшел бишек» халык тормышының матур сәхифәләре, халык күңеле җәүһәрләре белән укучыны ахыргача тотып тора икән, бу инде үзе сюжет киеренкелеге дигән сүз. Былтыргы прозада мондый эпик-этнографик киеренкелеккә корылган әсәрләр юк. Былтыргы проза әсәрләрендә сюжет вакыйгага киеренкелегенә корылган.

М. Хәсәнов, гадәттә, үзенең роман, повестьларында сюжетны мондый вакыйгага киеренкелегенә шактый оста кора. Ләкин аның былтыргы «Очар кошлар» повестенда бу як шактый йомшак. Повестьның уртасына кадәр киеренкелек әле бар. Бораулау мастеры Хаҗины, бер бораулаучысы авариядә фаҗигале һәлак булгач, каты гаепкә тарталар. Хаҗи өстендә кара болытлар куера, җиде төн уртасында аны милиция кулга ала. Мәсьәлә райком бюросына куела. Бюро утырышында республика прокуроры сөйли башлау белән сюжет киеренкелеге шунда ук бетә. Чөнки Хаҗины аклаячаклары шунда ук ачыклана. Хәтта Хаҗиның яңадан эшенә кайтачагы да, разведка скважинасының, һичшиксез, нефть бирәчәген дә укучы сизеңли. Повестьның калган яртысын шушы сизеңләүнең дөреслеген күреп, теләр-теләмәс кенә укыйсың. Бәлки, повестьның калган яртысында вакыйгага фәлсәфи яктан тирәнәер дип көтәсең. Андый өмет тә акланмый. Ә бит әсәрдә вакыйгага киеренкелеге әнә шул фәлсәфи нигезе булса гына кыйммәтле. «Очар кошлар» повестенда нәкъ әнә шул фәлсәфи нигез шактый йомшак. Мастер Хаҗи җитәкчелегендәге нефть разведкасы бригадасы Кама буена яңа горизонт ачарга килә. Нинди каршылыклар, нинди көрәш көтә аларны бирелә? Эшкә башлау белән кинәт авария һәм бораулаучы Инсафның фаҗигале үлеме. Төп каршылык шушы. Вакыйга шул уңай белән куерып ала да, Хаҗи акланугa, эшләр тагын гөрләп бара башлый.

Ә авария һәм Инсафның үлеме повестька нинди мәгънә, нинди фикер өстәде соң? Автор бу турыда җитәрлек уйламаган, повестьта авария һәм геройны гаепләү барысы тик коры вакыйга гына булып калган.

Сюжет киеренкелегенең ярты юлда йомшап калуы Р. Хафизованың «Таң билгесе» повестена да хас. Надан һәм эгоист мәктәп директоры эшеннән алынгач, повесть шактый зәгыйфь үрелгән мәхәббәт җебе белән генә дәвам итә. Гомумән, мин бу повесть турында шуны әйтер идем: узган ел М. Маликова, М. Мәһдиев, В. Нуруллин беренче повестьлары белән үк әдәби процессның уртак агымына үз тавышлары белән бик матур кушылып китә алсалар, Р. Хафизова повесте әле ул дәрәҗәгә җитмәгән. Әсәрдә портрет, характер детальләре булсын, пейзаж күренешләре булсын — барысы да әзер бизәкләр, әдәбиятта инде күп кабатланган буяулар белән генә бирелә. (Кирәк тип икән — ул гел шыксыз, уңай икән —

гел сәйкемле). Авторның үз табышларын, үз күзәтүләрен повестьта сирәк очратасың.

Әсәргә вакытында нокта куймау шулай ук композицион бөтенлекне бик нык боза. Мондый чир үткән елгы повестьларда да әле үзен сиздерә. Л. Ихсанованың «Ана көндәлеге» повестенда сюжет җепләре җиденче бүлектә үк инде түгәрәкләнгән, геройның язмышы ачыкланган иде. Ләкин повесть шуннан соң да әле тагын ике бүлеккә сузыла.

Үткән әдәби елдагы романнарның, повестьларның сюжет-композиция якларын күздән кичергәч, түгәрәкләп шуны әйтәсе килә:

— Җепләрне ныграк төйнисебез бар!

* * *

Әйе, җепләрне ныграк төйнисе бар... Ләкин нәрсә өчен дип төйнибез соң әле без ул җепләрне? Әгәр дә повестьның, романның сюжет-композиция җепләре бик оста төйнәлеп тә, укучы күңелендәге кыл-җепләр аз гына да кыймылдамыйча, төйнәлмичә калса, мондый тәти җәтмәнең нигә кирәге бар? Бөтен хикмәт тә шунда шул — әсәрнең ул җепләре укучының күңел кыллары белән ныграк килеп бәйләнсен. Моның өчен ул җепләр тормышның үзеннән һәм мөмкин кадәр тирәннәнрәк суырып алынсын. Мәгълүм ки, шундый әсәрләр генә укучыны дулкынландыра һәм уйландыра ала.

Миңа калса, былтыргы прозаның тормыш җепләре белән иң нык бәйләнгән әсәрләре дип, мин Ә. Еникинең «Вөҗдан» повестен һәм М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» белән В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» повестьларын атар идем. Бу өч повесть үзләренең нәкъ менә тормышчанлыклары белән укучы күңелен биләп алалар. М. Мәһдиев һәм В. Нуруллин повестьларының уңышы, беренчедән, талантлы каләм белән язылуларында булса, икенчедән, аларның әсәрләрендәге вакыйгаларны үз башларыннан кичерүләре белән дә аңлатыла булса кирәк.

Ә. Еники повестенең уңышында, боларга өстәп, минемчә, тагын өченче сәбәп тә бар. Ул — повесть материалы һәм повестьта чагылган чор турында тирәнтен һәм, ихтимал, газаплы төстә уйлану нәтиҗәседер. Чөнки йөрәктән чыккан гына йөрәккә җитә диген кебек, уйланып язсаң гына укучыны уйландыра аласың. Ә «Вөҗдан» повесте укучыны уйландыра. Җәмгыять һәм шәхес язмышы турында да уйландыра ул, кеше күңеленең серле тирәнлекләре турында да уйландыра.

Шушы уңай белән моннан 7—8 ел элекке бер әдәби бәхәс хәтергә төшә. Фатих ага Хөсни «Литературная газета»да теманың актуальлеге артыннан куып, тормыш материалы турында җитәрлек уйланмау һәм мондый уйлану өчен вакыт дистанциясе кирәклеге турында язып чыккач, аның башына әйбәт кенә кундырганнар иде. Янәсе, язучы тормыш койрыгында сөйрәлергә тиеш түгел, бәлки, алданрак та атларга тиеш. Әйе, тормыш койрыгында сөйрәлергә тиеш түгел язучы, әйе, алга карый белергә тиеш. Ләкин койрыкта сөйрәлмим дип, бүгенге көннең бик актуаль мәсьәләләренә әсәр язып та, ул әсәрең иртәгә үк үлеп калса... Бу инде алга карау буламы соң? Әлбәттә, алга таба үтә зирәк карасаң, үтә алдан күрүчән булсаң, бүгенге актуаль әсәрең иртәгә дә яшәр. Ләкин соңгы еллар практикасы, рус әдәбиятында булсын, милли әдәбиятларда булсын, бүгенге көн турында бүген үк туган андый үлмәс күләмле әсәрләрне белми. Заманында шаулаган һәм үз бурычларын шактый уңышлы үтәгән В. Овечкинның «Районные будни», В. Кочетовның «Секретарь обкома» әсәрләре бүген инде укучыны алай дулкынландыра алмыйлар. Ә менә вакыт дистанциясе аша тирәнтен уйланып, күңел түрендә тәмам җитлегеп туган әсәрләр үлмиләр, еллар үткән саен аларның яңадан-яңа мәгънәсе, яңа матурлыгы гына ачыла бара. Соңгы елларның иң уңышлы әсәрләре: И. Газиның «Онытылмас еллар», Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», А. Расихның «Ике буйдак», Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» һәм башкалар шулай ук моны раслый түгелме? Инде килеп, үткән ел прозасының югарыда әйткән өч повесте да шушы турыда уйландыра. Әлбәттә, мин бүгенге көн турында язарга кирәкми, үткән көннәр турында гына язарга кирәк, диярга теләмим. Әмма бүгенге көннең актуаль мәсьәләләре турында язуны иң сугышчан жанрлар — очерк, хикәяләргә күбрәк тапшырып, повесть, роман жанры өчен әлегә вакыт дистанциясе хокукын яклыйсым килә. Әлбәттә, бу вакыт дистанциясенең кыскарак булуы һәм тагы да мөһиме — киләчәге көнгә бүгенге күзлектән карап, иртәгеге көнгә якты нур сирпә белү дә бик зарури. Былтыргы проза менә шушы турыда да уйландыра.

Ә түгәрәкләп әйткәндә, әдәбиятка заман таләбе, халык таләбе һаман да шул ук: тормышчан тирәнлек һәм югары осталык!

Нурмөхәммәт Хисамов

# МАТУРЛЫК ХАКЫНА

Ике кат яшәмәс берәү дә,
Чәчәкләр бирегез кешегә!

Лирик шигырьләренең берсендә Гамил Афзал әнә шулай ди. Шагыйрь иҗатының олы мәгънәсе — кешегә, аның хезмәтенә, акылына гимн җырлауда, җирдә кешене бәхетле итәрлек шартлар даулауда һәм кеше бәхете өчен көрәшче үзенең байрагы иткән җәмгыятебез, туган илебез белән горурлануда. Гамил Афзалның иҗат кредосы ил өчен, кешеләр өчен шатлык һәм матурлык раслаудан гыйбарәт.

Мин чәчәкләр җыям ил түенә,
Мин матурлык эзлим гомергә! —

ди ул үзенең икенче бер шигырендә.

Шагыйрь иҗатындагы сатира һәм юмор турында сүз алып барырга җыенганда, ник әле без аның лирикасына кереп киттек! Хикмәт шунда ки, Гамил Афзалның сатирасын лирик героеның тормышны раслаучан фәлсәфәсеннән аерып карау мөмкин түгел. Шагыйрь һәр ике жанрда үзен бердәй көч белән танытты. Тормыштагы матурлыкны якын күргәнгә, мәһабәт төзелеш белән рухланып, үзе дә шунда гражданин буларак катнашканга, аның иләмсез күренешләргә тәнкыйте дә үткен. Бу урында Сибгат Хәкимнең бер фикере белән килешеп бетәсе килми. Г. Афзалның сатира-юмор шигырьләреннән тупланган соңгы җыентыгына[1] язган сүз башында ул: «...сатираның берүзе хәл итә торган үз темасы бар. Аның лирика белән компромисска барасы килми»,— ди.

Икенче җөмләдәге фикер Г. Афзал иҗатына карата төгәл үк булмас. Чөнки, югарыда әйткәнебезчә, шагыйрьнең лирикасы, бер яктан, авторның сатира пафосын төшенергә принципиаль ачкыч бирсә, икенче яктан, лирика элементлары, аның сатирасына үтеп кереп, аерым бер художество функциясен башкара һәм Г. Афзал сатирасының үзенчәлекләреннән берсен тәшкил итә.

Шагыйрьнең сатирасы бүгенге поэзиябездәге сатира-юморның аерылгысыз бер күренешенә әверелде. Без хәзер, хаклы рәвештә, Гамил Афзал сатира-юмор мәктәбе турында сүз алып бара алабыз. «Өф-өф итеп» дигән яңа җыентыгы шагыйрьнең бу жанрдагы иң яхшы шигырьләрен бергә туплый.

Гамил Афзалның сатира мәктәбе дигәч тә, ул үз алдына тора торган аерым бер күренеш түгел, әлбәттә. Аның үзенчәлеге үзенең элгәрләре белән уртаклыгыннан башлана. Сибгат Хәкимнең югарыда телгә алынган кереш мәкаләсендә бик хаклы рәвештә болай диелә:

«Гамил Афзал лирикада да, юмор, сатирада бигрәк тә, турыдан-туры Тукайдан, Бабичтан килә. Дөресрәге, аның үсеп чыгуы да шушы ике шагыйрьдән... Кайвакытта

[1] Г. Афзал. Өф-өф итеп. Татарстан китап нәшрияты. 1968 ел.

бер-берсеннән заман белән аерылган шагыйрьләр рухындагы уртаклыкны тоТЕП күрсәтүе дә читен. Ә күңел нидер сизә. Син аны фикер, җөмлә сөрешендә, ритмик агышында, шигырь юлларының сулышында тоясың».

Шагыйрь классик әдипләребез Кандалый, Тукай, Бабич, Такташларның шигъри казанышларына һәм халык иҗаты байлыгына таянып эш итә, аларны үзенчә трансформацияли. Тукайдан килә торган тәэсир исә аеруча көчле, күп яклы. Бу, барыннан да элек, Г. Афзал шигырьләрендәге сатира алымында сизелә, ягъни шагыйрь үзенең көлке типларын сөйләм — монологлары аша ачып бирә. Моның Тукайдагы классик мисалларын Кисекбаш монологында һәм «Ысулы кадимче» әсәрләрендә күргән идек. Гамил Афзалның «Минем сакал», «Сайладым, их, сайладым», «Шәрифулла күршем белән», «Сәләхетдин бабай сүзләре», «Сабитның Советка сайланасы килә» һәм башка күп шигырьләрендә шушы алым бик уңышлы файдаланыла. Бу алым укучыны үзенең «объективлыгы» белән ышандырып куя, авторга героеның иҗтимагый-әхлакый йөзен аның үз сүзләре аша ачып салырга ярдәм итә. Туктаусыз эзләнә барып, шагыйрь бу алымның сатирик мөмкинлекләрен киңәйтүгә, төрләндерүгә ирешә. Монда, үлчәм-строфика төрлелеге белән беррәттән, көлү объектының, вакыйгалар чишелешенең һәм шигъри чараларның төрлелеге билгеле бер роль уйный.

Г. Афзал үзенең сатирик «кадрларына» конкрет якын килә белә. Менә аның «Минем сакал» шигыре. Анда бүгенге тормышыбызда очраган аерым кимчелекләргә читтән генә үртәлеп йөрүче пенсионер образы бирелгән.

Җитешсезлек күрсәм, җаным әрни,
Чын күңелдән янып көрсенәм.
Алай ярамый бит,
Ярамый дип,
Сакалымны учлап борчылам.

Үзе җәмәгать тормышыннан читләшсә дә, картны, күрәсең, коллективта онытып бетермиләр:

Бәйрәм көне булса, колоннада,
Ал байраклар белән уралган
Ямьле мәйдан,
Шәп тырпайган
Минем сакал бара иң алдан.

Шулай итеп, хөрмәт аның үзенә түгел, Хуҗа Насретдиндагыча, сакалына күрсәтелә булып чыга. Көлү монда тирәнгә яшерелгән. Автор үзенең героена каты бәрелүдән гаять сак. Лаеклы ялга чыккан хезмәт ветераннарыбызга гомуми хөрмәт хисе аны тотнаклы көлергә мәҗбүр итә.

Шагыйрь үз кулындагы коралының көчен яхшы аңлый:

Бернидән дә курыкмаган таш күңелләр
Хур булудан куркып кала куян төсле.

Әмма Гамил Афзалның сатира стиленә тәкәллефсезлек, дорфалык гомумән хас түгел. Ул, киресенчә, йомшак тотып катыга утыртырга ярата. Җыентык тикмәгә генә «Өф-өф итеп» дип аталмый.

Тыштан бик тыйнак күренергә тырышып та, эчтән олы хөрмәтне, зурны дәгъва итүче типларны бирүдә шагыйрьнең әдәби чаралары тагын үзенә бер төрле. «Сәләхетдин бабай сүзләре»ндә малайларының балда-майда йөзүе турында куык очырырга яраткан карт сүз саен диярлек үзенең мактанып сөйләмәвен искәртә. Ул хәтта бер төрлек тәмәкесе юклыгын икърарлаганда да шунсыз булдыра алмый:

Бер төрик әле, Сәйфулла,
Янчыгым юк минем монда,
Калган акча сандыгында,
Мактанып әйтү түгел.

**Мактанып әйтү түгел** диган юл һәр строфа саен кабатланып килә. Шигырьдә төп юмористик нагрузка мактанчыклар кулланырга яраткан шушы рефрен өстенә төшә. Бу исә шагыйрьнең көлүен тормышчан итә. «Сабитның Советка сайланасы килә» шигырендә көлке үткенлегенә начальник булу хыялы белән яшәгән Сабитның «тыйнаклыгы»н һәм дәгъвасын бергә үрү аша ирешелә. Ягъни геройның эчендәгесе дә, тышындагысы да бер монологка салына:

Дуслар әйтә:—Сине сайларга кирәк!
— Кирәкми,— дип этләшәм аяк терәп.

Сайлагыз, дим, берәр әйбәт егетне,
Ягъни, мин аклый алмам шул өметне.

Югыйсә, минем бабайлаö пырлетар,
Бер диган кадр булырга өмет бар.

Такыр инде минем белем амбарым,
Төрле курслар-фәләннәр бар-барын.

Юк, миңа кирәкми, дуслар, ул урын!
Миннән дә лаек егетләр юк-югын!

Гамил Афзал үзенең сатира һәм юмор иҗатында Тукайның шигырь үлчәмен гаять актив куллана. Әле генә карап үткән шигырь үзенең үлчәме һәм ритмы белән «Кисекбаш»ка тарта, «Бәркет» шигырендә «Ысулы кадимче» үлчәме файдаланылган. «Мәгъфия әбинең догасы», «Мөдир төше», «Бәхәс», «Кызыл балчык» промартелендә», «Тынгысыз һөнәр», «Безнең бригадада» шигырьләрендә «Йосыф — Зөләйха» үлчәмен төю читен түгел. Мәгълүм булганча, бу үлчәмне Тукай да бик киң кулланган. Чагыштыру өчен ике мисал:

...И ходаем, кәлиматен, тәнбәтен,
Бу арада оныттың син эш әртен.
Намазыңны куеп, бераз җиргә кара:
Акыл җитмәс могҗизалы эшләр бара...

(«Мәгъфия әбинең догасы»)

Менә, дуслар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Юсеф — Якуп китабы»ның көен көйлим...

(Тукай. «Дусларга бер сүз»)

Бу хәл шагыйрьне эпигонлыкка илтмиме! Киресенчә, Тукайның колоритлы строфикасын файдалану шагыйрьдәге форма колачын киңәйтеп җибәрә. Җитмәсә, Г. Афзал әһәмиятле фикерне белдергән фразаны кабатлау, рефрен кертү яки башка чаралар ярдәмендә бу үлчәмне эчтән төрләндереп тора. Аның яңа яңгырашларын эзләү юлында автор оригиналь табышларга очрый:

Җилләр исәр, яңгыр явар, кар да явар,
Иске ферма түбәсеннән тамчы тамар,
Балта остасы аннан-моннан такта кагар —
Әйдә ярар!

Күренгәнчә, шигырьнең баштагы юллары дүртәр иҗекле өч ритмик буыннан тора. Дүртенче юлда исә шагыйрь тота да бөтен ике ритмик буынны төшереп калдыра. Ни өчен! Ирониялә интонациягә урын ачар өчен, һәр строфа ахырында рефрен булып кабатланган шушы дүрт иҗекле эмоциональ тәгъбир (ягъни ялгыз калдырылган сыңар ритмик буын) шигырьдә төп сатирик вазифаны башкара. Строфалардагы тел тидергесез ритмик тәңгәллек авторның шигырьне шушы принципка коруын раслый. Соңгы строфа ахырында автор инде, рефреннан баш тартып, үзенең хөкем мөһерен сугу өчен башка эмоциональ тәгъбирдән (**Буш әңгәмә**) файдаланса да, ритмга хилаф

китерми. Чөнки бирәдә ике ритмик буынны төшерү хисабына ирешелгән интонация барын да хәл итә.

Тукай шигырьләренә пародиясендә Г. Әфзал юморның яңа чараларын таба. Аның «Аракыга каршы» шигырен тулысынча китереп үтәбез:

И, тәгалә, җир йөзеннән ал бу аракыңны, ал,—
Безне юлдан яздыручы шайтан-сабакыңны ал!

Ул явызны күп чөмерсәк, безнең акча аз кала,
Баш авырткач ошбу бәндә әрле-бирле чайкала.

Аракы юктан гына җирдә халыклар үлми ич,
Пусть мәләкләрең белән кунак чакыр да үзең эч!

Бу — Тукайның «Алтынга каршы» шигыренә пародия. Мәгълүм булганча, халык шагыйренең зар белән тулы әсәрендә капиталистик җәмгыятьтәге зур социаль золымга, алтынның кешеләрдәге бөтен яхшы сыйфатларны юкка чыгаруына протест белдерелә. Тукайдагы зарлы интонацияне саклаган хәлдә, Г. Әфзал үз шигырендә зарлануның сәбәбе итеп тормыш прозасының иң түбән һәм җәмгыятебезнең әхлагы каршында бик кечсез күренеше — эчкечелекне ала. Аракы бәласеннән коткарырлык бернинди реаль көч һәм чара булмагандай, әсәрдәге сатирик герой «тәгаләгә» ялвара. Бу исә аның үзен үк үтә кечерәйтә. Эчкече әхлагының иң хас сыйфаты булган ихтыярсызлык монда үзенең бөтен комиклыгында чагыла. Бер-берсеннән гаять ерак төшенчәләрне янәшә китерү, Тукай шигыренең «югары стиленә», олы зарның ихлас интонациясенә «түбән стильнең» вульгаризмнарын кертү аркылы шагыйрь юмор үткенлегенә ирешә. Беренче юлдагы җитди зардан соң вульгар жаргон «сабакы» килү шигырьгә кискен юмористик борылыш бирә. Әмма без әле һаман «герой»дагы зарның ихласлыгы әсирлегендә кала бирәбез, аның зарына теләктәшлек белдерә язабыз. Шунда шагыйрь герое авызына, үзенең объектив бирелешендә үк хәлгә, хәрәкәткә юмористик мөһер сугучы «чөмерсәк» сүзен салып, мәсьәләгә тәмам ачыклык кертә. Монда инде үзе зарланган сыекчаның тәмен белеп бетергән, аңарда шактый пешкән тип күз алдына килә. Нәүбәттәге юлда комик күренеш эчкеченең көндәлек прозасын («баш авырткач») классик поэзиянең югары стиле белән аралаштыру («Ошбу бәндә») ярдәмендә бирелә.

Тагын бер моментны күрсәтеп үтәргә кирәк. Шигырьнең башында алынган ихлас тембрда лириклык элементы бар. Ул нигездә алдарак киләсе вульгаризмга контраст өчен җирлек буларак, юмор чарасы ролен уйнаса, шул ук вакытта авторның зарга теләктәшлеген дә чагылдыра. Бу пародиядә тапкан юмористик ысулны шагыйрь башка шигырьләрендә дә уңышлы куллана.

«Изге хәзрәт тарихы» әсәрендә, шигырьнең исеме үк күрсәткәнчә, автор чын мәгънәсендә анахронизм күренешен ала. Геройның эчке асылы белән аның тормышка дәгъвасы арасындагы контраст күп төрле сәнгать чаралары аша бирелә. Героен үз теленнән фаш иттерү өчен, автор тәүбә-монолог формасын сайлаган. Исерек хәлдә төш күреп, хәзрәт үзен теге дөньяда сораль алдында калган кеше дип хис итә һәм бала чагыннан алып бүгенгәчә башыннан кичкәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Шул юл белән геройның заманга кире юнәлештә «үсүе», вак-төяк гөнаһлардан зур гөнаһка — кешеләрне алдап җыеп юл белән көн күрүгә күчүе сурәтләнә. Аның комик асылын ачу өчен, автор югарыда тукталып үткән пародиядәге ысулдан файдалана, ягъни «югары стильне» геройның үз чынбарлыгындагы детальләргә бәйле «түбән стиль» белән аралаштыра.

Менә «хәзрәтнең» мөнәҗәтләреннән бер өзек. Ул, үзенчә, «Мөхәммәдия»не укыган була:

Чын адәм җәннәтә керди,
Гарше нигъмәтләрен күрди,
Бер утырып махра төрди,
Кәеф-сафа кылып йөрди,
Ачуланма, рәсүлулла!

Дини укымышлылар моны ишетсә, авыр сулап ах-вах килерләр иде. Кайда ул классик әдәбият аша мәгълүм мулланың гарәп-фарсы тулы «югары стиле»! Бу юлларда инде Адәм галиәссәламның да әзе юк, биредә малай чагында ук «абыйсының тәмәкесен чәлгән» хәзрәт үзе. Һәм аның эндәшүе дә, «рәсүлулла»дан битәр, шешәдәшләренә кагыла сыман. «Ачуланма...» — гөнаһлының изге ялваруымы бу! Исерекнең үтенә белгән бердәнбер сүзе.

Үзе үтә нәфрәтләнгән күренешләргә ачы ирониясен белдерү өчен, шагыйрь киңәш формасын сайлый. Моның традициясен дә поэзиябездә Тукай эшләп калдырган. Халык шагыйренең «Дөньяда торыйммы!» — дип киңәшләшкән дустыма» әсәренннән шушы өзеккә генә күз салыйк:

Зинһар, иптәш, хаклык сөйгән булып йөрмә,
Ялган сөйлә, күрмә зиндан, күрмә төрмә;
Тип! дөньяда ач-ялангачларны белмә,
Иске дөнья тузанын ит күзгә сөрмә!

Г. Афзалның «Киңәш» шигырендә дә шушы әсәр рухы бар. Менә бер өзек:

Тыныч карап яхшылыкка, яманлыкка,
Әз генә дә хәтәр эшкә кулың тыкма.
Биләп алып, тыныч урын, җайлы урын,
Өстәл сугып патшалык ит, җепшек борын!

Әмма аерма шунда, Тукай шигырендәге тирән ирониядә зар тавышы, үз чорының иҗтимагый шартларына протест авазы да бар, ә Гамил Афзал үзе көлгән күренешнең көчсезлеген тоеп эш итә, обыватель психологияле карьеристны мәсхәрә хәленә калдыра. Тукайда ирония әлеге очракта лирика элементы булса, монда — сатира элементы.

Гамил Афзал бүгенге укучының югары культурасын, үскән зәвыгын бик яхшы аңлый. Бу аңа яңадан-яңа сатира-юмор чараларын әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирә. Җөмләдән берсе — комик типларны аларның тел культурасы аша фаш итү. Шагыйрьнең геройлары, үзләре гаепле була торып та, гаепне җансыз әйберләргә сылтаганда рустан алынган вульгаризмнарны еш кулланалар. Алар ачуларын «сабакы»га бушатырга яраталар. Моның бер мисалын «Аракыга каршы» шигырендә күреп үткән идек. «Механик кемне сүгә» шигырендә дә шундый ук хәл. Менә геройның тракторын әрләвеннән бер өзек:

Кайчан гына ремонтта булды,
Тагын ремонт сорый, әшәке!
Аның өчен миңа выговор кунды,
Тьфу, сабаке!

Ләкин шуны әйтергә кирәк, шагыйрь рус сүзләрен юмористик чара буларак кирәк урында да, кирәкмәгәндә дә куллана. Еш кына ул сүзләр көчәнеп көлдерү чарасына әверелә язалар. «Выговор», «молокосос», «деляга», «подхалим», «пусть», «легковой», «наград», «премия» кебек сүзләр урынына шундый ук комик вазифалы үткен татар сүзләре дә табып булмас идеме! Гамил Афзалның халык тапкырлыгына бай гаять сыгылмалы теле мондый гына бурычларны башкарырлык, әлбәттә.

Урыныннан очып төшкәч тә түрә чагындагы тәкәббер сөйләм стилен саклаучы председатель авызында [1] («Их, бар иде түрә чаклар...» исемле шигыре) рус сүзләре табигый яңгыраса, «Тәмәкене ташлаганда» шигырендә алар бөтенләй урынсыз. Монда «премия», «наград» сүзләре бер-бер артлы кулланыла. Шигырьнең юмор асылы бөтенләй башкада булганга («Вәгъдә булгач, димен, йөрәк, тукта! — Бер төрербез, әйдә, хатын юкта»), икенче телдән алынган синонимнар кирәксез зиннәткә әйләнә.

Шагыйрьнең юмор арсеналы мондый берьяклы мавыгуга мохтаҗ түгеллеккә җыентыкка исем биргән «Өф-өф итеп» шигыре мисалында да күрергә мөмкин. Савы-

---

[1] Шуннан миңа пупал, дустым,
Кабинеттан очып чыктым.
Хәзер атлар абзарында
Мин, значит, каравылда.

ла-сәвыла инде сөте беткән темага шагыйрь өр-яңа яңгыраш бирә. һәм шигырь, үз ишләрен күләгәдә калдырып, гаять популяр булып китте. Хикмәт нәрсәдә соң! Халык телендәге бай яңгырашлылыкның нечкә нюансларына сизгер шагыйрь сатирик тасвир өчен музыкаль чарага мөрәҗәгать итә. Балага артык назлы мөнәсәбәтнең ата-ана өчен шәфкатьсезлек булып кайтуы рифмалашып килүче аваз җиртемнәренең нечкә-нәфис яңгыраштан калын-дорфа яңгырашка күчә баруы ярдәмендә белдерелә. «Өф-өф итеп» үстерелгән малай «ресторанда голт-голт итеп коньяк эчә» һәм әти-әнисен «дөп-дөп» итеп кыйный башлый.

Геройларның әхлакый һәм культура йөзе түбән булуын күрсәтү өчен, шагыйрь эстетик һәм этик төшенчәләргә караган сүзләрне алар авызына мәгънәсез парлары белән янәшә сала.

Фикус-микус гөлләр тездем...

Колхоз председателе булып сайланган берәү үзенең бүлмәсен, «начальниклар эстетикасына» туры китереп, әнә шулай җиһазлый. Әмма бу нәрсә аның эчке ихтыяҗына туры килгәнгә түгел, бәлки, «мәһабәт» декорация өчен генә икәнлеге күренеп тора. Яки менә шул ук геройның мәхәббәткә азгыннарча мөнәсәбәтен күрсәткән икенче мисал:

Күн диванда гомер сөрәм,
Кәеф-сафа уйлап кына,
Агроном кыз Галия белән
Гыйшык-мыйшык уйнап кына.

Геройларының тел культурасын аларның рухи ярлылыгыннан килү өчен файдаланган кебек, шагыйрь стильләштерелгән культуралы телне дә юмор максатында файдалана. «Автор киңәш итми...» шигыреннең герое, бер тапкыр үзенең авызы пешкәч, тәкәллефле югары стильдә башкаларга менә нинди гыйбрәт бирә:

Ирле хатын янына
Киңәш итми барырга
Бу юлларның авторы.

Гамил Афзалны гаделлек сагында уяу торучы шагыйрь дисәк, һич тә арттырып әйтү булмас. Ләкин болай дию башка шагыйрьләребезгә күләгә төшермәсме! Чөнки бит шагыйрь исемен күтәргән кеше гаделлек көрәшчесе булмаска мөмкин түгел. Дөньядагы иң гадел җәмгыять җырчысы буларак, киң мәгънәдә алар — шушындый көрәшчеләр дә. Хәлбуки, җәмгыятебезнең «Барысы да кеше өчен» дигән төп принцибына ят күренешләрне үз вакытында тәнкыйтьләргә һәр шагыйрьнең дә йөрәге җитмәгән чаклар булды. Күп кенә кимчелекләрне без эш узгач гаепләргә яратабыз.

Гамил Афзалның «Тәвәккәл әби» шигырен укыганда кем генә рәхәтләнеп көлми икән! Динле дә, инсафлы да әбинең колхоз кибәнеңнән печән йолыкканда тотылгач биргән җавабы көлдерә:

Ул намазчы, изге килеш...
Котыртучы шайтан, имеш.

Әби гаять табигый, тормышчан тасвирланган. Шигырьдә наян көлү ярылып ята. Ләкин шул ук вакытта бик аяныч бер момент та бар: ул — әбине кышкы төндә чана тартып печән кайгыртырга мәҗбүр иткән сәбәп... Шигырь, шул рәвешчә, сугыштан соңгы еллар авыл чынбарлыгының реалистик бер күренешен гәүдәләндерә. Яки менә икенче шигырен алыйк. «Кызыл балчык» промартелендә» дип атала. Шигырьдән күренгәнчә, ике малай җилкәсендә ничаклы күпертелгән идарә аппараты яши! Начальнигы да, урынбасары да, секретаре, бухгалтеры, кладовойчысы, тәэминатчысы, технологы да бар бу артельнең. Ә хезмәт өчен үзләренең лаек өлешләрен алыр вакыт җиткәч:

Артель гөрли, артель эшли, контор яза,
Бәйрәм җитә, тантаналы утырыш бара.
Начальниклар елмаешып бүләк ала;
Ике малай доклад тыңлый һәм кул чаба.

Г. Афзал биредә хуҗалык реформасына чаклы промышленностьта хөкем сөргән кимчелекләрне тәнкыйтьли. Шигырьдә, сатирик гротеск чарасы буларак, миниатюра алымы кулланыла. Рефрен булып килүче «Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый» дигән юл авторның ирониясен дә, ачынуын да чагылдыра.

Шагыйрь халык җырлары калыбын да сатира-юмор максатында бик уңышлы куллана. Монда да аның диапазоны түбәнчелекле елмаюдан алып ачы көлүгәчә киң.

Сез, кәнишне, үзегез белерсез лә,
Сез аңламый торган түгелсез,
Харис абзый, Хафизәттәй,
Ялгыз йөрүләре күңелсез.

Без килештек, сездән рөхсәт кирәк,
Фатихагыз кирәк яшьләргә,
Харис абзый, Хафизәттәй,
Пар күгәрчен кебек яшәргә?!

(«Үзем язучы»)

Сатира һәм сатирик турында сүз алып барганда, бик еш «фаш итә», «ачып сала» кебек тәвәккәл, кискен тәгъбирләр кулланыла. Хәзер без сатира-юмор иҗатын күздән кичергән шагыйребез фаш иту белән генә чикләнсә, ул Гамил Афзал булмас иде. Гамил Афзалны халыкка аңлаешлы, якын һәм үз иткән сыйфат — аның көлүенең кешелеклелеге. Шигырьләрдә гуманист җаны, педагог кулы сизелә. Ул халык эчендә, көнкүрештә була торган кимчелекләрне күңелгә алганда, кешеләрнең яхшы якларын да онытмый. Аның тәнкыйтенә, юк итүдән битәр, яратып чиметү хас. Җәмгыятькә үтә ят күренешләр турында сөйләгәндә генә ул килешмәүчән, рәхимсез. Үзенең зур дошманы бюрократка, Тукай әйтмешли, «мисле хәнҗәр» кадала. Шагыйрьнең халыкчанлыгы аның гади телендә, кешеләргә халык әхлагының сәламәт үзәген тәшкил иткән хезмәткә мөнәсәбәт аша бәя бирүендә, көнкүрештәге кимчелекләрдән көлгәндә халыкның гореф-гадәтләренә инсафлы, сак мөнәсәбәтендә. Кайсакыт шагыйрь үзенең геройларына теләктәшлек тә белдереп куя. Шигырьләрдә бу лирик элемент аша бирелә. Үкенечкә калган «Донжуан Ногман» ахырында да, «Кызыл балчык» промартелендә»ге малайларга карата да бу сизелә. Андый мисалларны алдарак та күреп үттек.

Гамил Афзал, Сибгат Хәким әйтеп үткәнчә, туктаусыз эзләнүче шагыйрь. Шуңа күрә аның эчтәлеге ягыннан уйланган, формасы табылган шигырьләре белән янәшә уңышсыз тәҗрибәләре дә бар. «Вохмяков мистер булып карады» һәм югарыда карап үткән «Изге хәзрәт тарихы» кебек озын шигырьләрендә композицион таркаулык һәм күп сүзлелек үзләрен сиздерә.

«Стиляга сүзләре»ндә исә автор бу социаль типның асылын күрә һәм күрсәтә алмаган, шушы типка охшарга тырышучының кайбер тышкы сызыгын гына алган. Мәгълүм булганча, хәзерге стиляганың социаль психологиясен эгоизм, идеологик йөзсез имгәклек философиясе билгели. Хезмәткә нәфрәте һәм гражданлык импульсларының сүрәнлеге аны рухи буш итә. Шагыйрь бу типның туу лабораториясен «Өф-өф итеп...» шигырендә бик тегәл күрсәткән иде инде. Монда исә «оригинал» белән «орангутанг» сүзен уйнатуга корылган тапкырлык кына бар. Юкса Гамил Афзал үзенең күпчелек шигырьләрендә сатира нигезендә, Белинский әйткәнчә, «шаян һәм беркатлы тапкырлык түгел, бәлки, үтә тирән юмор ятырга» тиешлеген осталарча исбатлаган шагыйрь.

Гаять кызыклы бу шагыйрьнең бик күп башка шигырьләре һәм алардагы бай сатира-юмор алымнары турында, уңышлы һәм кайвакыт уңышсыз тәҗрибәләре хакында тагын да сөйләп булыр иде. Әмма ул — бер мәкалә мөмкинлекләренә генә сыймый торган җаваплы зур эш. Шагыйрь иҗаты яңа күзәтүләргә, яңа тикшерүләргә, һичшиксез, лаек.

# БЕЗНЕҢ САФКА

*Хәзер Татарстанда СССР язучылары союзы члены булган 120 язучы бар. Моннан тыш Мәскәүдә тәрҗемәче Разия Фәизова, әдәбият белгече, фәннәр кандидаты Роберт Бикмөхәммәтов, тәрҗемәче, шагыйрь һәм тәнкыйтьче Вил Ганиев иптәшләр тора. Түбәндә сез Язучылар союзына соңгы айларда кабул ителгән әдипләр белән танышырсыз.*

* * *



**Сафа Сабиров** — безнең әдәбиятта күптән эшләп килгән һәм үзенә тиешле урынны алган язучы. Мин моны аның соңгы егерме ел эчендә өзлексез язып торуына, инде 15 ләп китап чыгаруына карап кына әйтмим. Иң әһәмиятлесе — язучы буларак ул тәмам формалашып җиткән дип әйтәсем килә. Аның үз материалы, үз теле, үз стиле бар. Гомумән, Сафа Сабиров иҗатына яхшы мәгънәдәге гадилек, табигыйлек, сүзнең кадерен белеп язу, кешеләрне һәм вакыйгаларны ничек тә тормышчан, ышандырырлык итәргә тырышу бик хас нәрсә. Тулаем алганда, ул инде билгеле бер осталыкка ирешкән, үзен әдәбият дөньясында танытып өлгергән язучы.

ӘМИРХАН ЕНИКИ

* * *



**Мөхәммәт Мәһдиев** татар матбугатының, бигрәк тә Язучылар союзы органы «Казан утлары»ның бик актив язучыларыннан. Әдәбият тарихыбыз, фольклор, мәгърифәтчелек тарихыбыз буенча аның гыйльми эзләнүләре, әдәбиятыбызны популярлаштыру буенча бик мөһим мәкаләләре матбугатыбызны һәрвакыт бизәп килә. Бу югары квалификацияле белгеч үзенең анык фикерләре, гыйльми-тәнкыйди карашлары белән әдәбиятыбыз өчен җитешкән, кирәк кеше... Мәһдиев язучы-әдәбиятчы булып та, безгә якын киңәшче буларак та һәр вакыт безнең үз сафыбызда, үз арабызда булырга тиешле.

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ

* * *



**Ренат Харисов** Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң Арча педучилищесында укытты, байтак вакытлар ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында инструктор булып эшләде, хәзерге көндә — «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы секретаре. Кыскасы, тормышны белгән иптәш килә әдәбиятка.

Күп кенә яшь шагыйрьләрне Тукай, Такташ, Җәлил традицияләрен дәвам иттерүчеләр дип карарга күнеккәнбез. Ренат Харисов кыска язылган тирән фәлсәфи шигырьләре белән Дәрдмәндкә якын тора. Әйләнә-тирәбездәге мохитны тою һәм шуны шигырь итеп язу

ягыннан караганда, Ренат бик үзенчәлекле: аның иркле ак шигыре нык мускуллы, кино сценарийларындагы кебек картиналы-тәгәл, җисмани күз алдына китерерлек.

Ренат ун ел буе шигырь яза инде. Хәзергә ике җыентык чыгарды. Таләпчәнлек әйбәт сыйфат. «Казан утлары»нда басылган «Мулланур» поэмасы — бүгенге татар поэзиясендә әйбәт күренеш. Яшь шагыйрьгә бер генә теләк: новаторлыгын саклаган хәлдә, күбрәк халыкчанлыкка омтылсын иде.

ГАРИФ АХУНОВ

* * *



Нонна Орешинаның хикәяләрен һәм очеркларын — басылып чыкканнарын да, кулъязмаларын да — укыдым. Алар бик матур тәэсир калдырдылар. Орешинаның әдәби алымы хәзердән үк җитлеккән язучыларныкы кебек. Аның «Нюшка», «Лелька-Карамелька», «Чудо-юдо» хикәяләрен өлгереп җиткән әсәрләр дип карыйм.

Нонна Орешина профессиясе буенча инженер-химик һәм аның язар өчен үз җирлеге, үз материалы бар. Бу язучы өчен иң кирәк шартларның берсе инде.

ИБРАҺИМ ГАЗИ

* * *



Николай Беляев белән мин Казанда яшь язучылар семинарында таныштым. Озак та үтмәде, яшь шагыйрьнең «Голоса растояний» исемле беренче шигырьләр китабы басылып чыкты. Җыентыкта чын поэзия әсәрләре шактый күп. «Нарат», «Туган ил хисе», «Геолог Лида», «Яшь этюдлар» кебек шигырьләр шул хакта сөйли.

...Шагыйрь дөньяны үзенчә күрә белә. Ә бу исә шагыйрьнең шагыйрь булуы өчен төп шарт. Николай Беляев күргән тормыш зур һәм кызыклы. Шагыйрь профессиональ осталыкка ия, талант булганда бу инде кечкенә нәрсә түгел. Мин ышанам, Николай Беляев киләчәктә матур-матур әсәрләрне күп иҗат итәчәк.

ДАВИД КУГУЛЬТИНОВ

Элиста шәһәре.

**Гази Кашшаф**

# БАШКОРТСТАНДА

## Тау башында балкый бер кала...

Беренче ишетүдә үк күңелгә кереп кала торган җырлар була. Аны үзең җырлап бирә белмәсәң дә моңы онытылмый, ул сине һәр адымыңда озатып йөри.

Мин Башкортстанда булдым һәм анда алган тәэсирләр, шундый гүзәл җыр шикелле, күңелгә урнашып калды. Башкортстан халкы ыгы-зыгысыз, шау-шусыз гына үзенең 50 еллык бәйрәменә хәзерләнә иде.

Уфаның Совет мәйданында бизәкле боз таулары, эчендә төрле төстәге утлар кабынгач, алар тылсымлы әкиятләрне хәтерләтә. Боз әрҗәләрдән үсеп чыккан чыршылар, әкият рәсемнәре, дүрт ат белән чаптырып баручы Кыш бабай, аның артындагы рәсемдә күзгә бәрелмәслек һәм югалып та калмаслык итеп Башкорстанга 50 ел икәнен белдергән тыйнак язу! Мәйдан зур һәм киң, оста куллар бизәгән кышкы пейзаж!

Бу, ягымлы җыр кебек, сине үзенә тарта. Яңа ел, балалар каникулы күңелле һәм җанлы үтсен өчен эшләнгән ул. Ләкин инде Яңа ел да артта, каникуллар да күптән узган, ә җанлы бозлар мәйданны әле дә бизәп тордылар.

Республиканың 50 еллык бәйрәме һәркемнең күңелендә яши һәм һәркем аны Ленин биргән җимешнең чәчәк ату тантанасы дип тоя. Мин министр һәм партия эшчесе, дус язучылар, журналистлар белән сөйләштем. Ләкин берсе дә башка сыймый торган һәм үзе генә берни дә аңлатмый торган салкын саннар китереп тормадылар. Әйе, 50 еллык бәйрәмгә алар хәзерләнәләр, саннан да бигрәк, сыйфатны күтәрү өчен тырышалар! Әйбәт булсын, яхшы булсын, кешенең күзенә ягымлы булып күренсен, аның хисләрен иркәләсен! Җыр кебек дәртле яңгырасын!

Башкортстанда Агыйдел культы яши! Ике кардәш халыкның күңел көзгеседәй саф сулы, уйнап-уйнап ага торган, гасырлар буе җырларда мактала, дәртләндерә дә, сагышландыра да торган Агыйдел хәзерге Башкортстанның символы булып әверелгән. Бик матур бу. «Агыйдел» журналы, «Агыйдел» поезды, «Агыйдел» кунак йорты, «Агыйдел» электробритвасы...

Сүзне әнә шуннан башларга кирәк. Ирләр өчен бу — хыял! Андый яхшы бритваның әле булганы юк, диләр «Агыйдел» бритвасына ия булган кешеләр. «Агыйдел» маркасы — ул милли горурлык маркасы! Әйдәгез, файдаланыгыз һәм эссе көнне Агыйделдә коену рәхәтен татыган кебек, рәхәтләнегез! Менә шундый ул электробритва.

Башкорт кардәшләр Академия драма театры өчен яңа бина салганнар. Революциягә кадәр үзенең театры булмаган халык өчен бу — әверуча тантаналы күренеш һәм

миңа ул театр, аның актерлары гына түгел, бәлки бина өчен сайланган урыны да бик ошады. Ни өчен дисәң, ничектер театр сәнгатен әнә шул сайланган урын да югары күтәрә кебек. Матур, биек бина урамнан бик күпкә эчкә кертеп салынган. Фасад каршында зур сөзәк мәйдан ясалган. Театрга килүче, урамдагы гади агымнан аерылып, шул мәйданга аяк баса һәм үзен инде икенче бер тылсымлы сәнгать дөньясына кергән кебек хис итә башлый. Ул акрын гына атлап, өч-дүрт баскыч югары күтәрелә-күтәрелә театрга килеп керә. Әйбәт эшләнгән, зәвык белән җиһазланган бина бу! Аның бер генә кимчелеге бар, Олимп югарылыгына күтәрелгән бинаның йөзен нечкә колонналар бераз килешсез күрсәтәләр, ул колонналарга ит үстерәсе килә. Бары шул гына!..

Хәер, бу бинага күп йөри башлагач, күнегелә икән. Минем кичләрем анда уздыр диярлек. һәм без әле аңа әйләнеп кайтырбыз!

Уфага бар да Сәйфи Кудашны, Мостай Кәримне күрми кит, имеш! Ләкин башкорт поэзиясенең аксакалы, 1913 елда ук татар матбугатында шигырьләрен бастыра башлаган Башкортстан халык шагыйре Сәйфи агай сырхаулап тора иде, шулай да ул мине колач җәеп каршы алды. Иҗат эшеннән аерыла белми торган бу тынгысыз җан аз гына вакыт эчендә татар әдәбияты һәм татар журналистикасы тарихына кагылышлы әллә ничаклы кызыклы вакыйгалар сөйләп алды, документлар белән таныштырды.

1917 елда, февраль революциясеннән соң ук, 8(21) апрельдә Казанда чыга башлаган «Аваз» газетасын — патша төшерелгәч тә чыга башлаган социалистик юнәлештәге татар газетасын — Шәһит Әхмәдиев оештыра һәм редакцияли. Шушы газетада Сәйфи Кудаш бик актив язышa. Аның «Аваз»да басылган шигырьләрен бик күп укыганым бар, менә шуның тарихи бер документы: Шәһит Әхмәдиев 1917 елның 16 июлендә Сәйфи Кудашка хат җибәргән. Анда болай язылган: «Синең холус кәлебдән (ихлас күңелдән — Г. К.) язган шигырьләрең бертуктаусыз «Аваз»да басылып килделәр. Моннан соң да чын күңелле шагыйрь-мөхәррирләргә ул халык мәйданы ачыктыр. Җырлагыз, иптәш. Мәңге изелгән эшче, фәкыйрьләрнең керфекләрең күтәреп, йөрәкләрен йомшартыңыз һәм яңадан күңелсез тормышка атмасын өчен, мәгънәви коралландырыңыз!»

Хәзер Сәйфи агай гомеренең өч чирек гасырын тутырып килә. Башкортстанның үсү юлы, авырлыклар кичерүе, шатлыклы җиңүләре аның күз алдында, турыдан-туры аның катнашы белән узган. 50 елдан артык иҗат юлы узылган. Башкорт әдәбиятының беренче буразналарын сызышкан һәм аны Союз күләменә чыгарышуда көн-төн иҗат иткән, яшьләргә булышкан кеше. Бу — чыннан да Башкортстанның аксакалы. Бүгенге көндә дә ул авыруларын сул як җилкәсе аша төкереп ташлап, интенсив иҗат эшендә утыра. Аның әсәрләре төрле телләрдә басылалар, яратып укылалар.

Сәйфи агай, егетләрчә җитез генә торып, бай китапханәсе каршына килеп басты.

— Өчтомлыкны инде мин сиңа җибәргән идем...

— Алдым, Сәйфи агай, бик рәхмәт, бик пөхтә чыкканнар. «Яшьлек эзләре буйлап» әсәрегез дә әле шушы арада гына килде... Укып ятам,— дидем мин.

Ул арада аксакал кулына кече күләмле бер китап алды һәм миңа күрсәтеп:

— Укыдыңмы? — диде.

Бу шулай ук Казанда яңа гына чыккан китапларның берсе иде һәм мин әле аның басылып чыгуын да күрми киткән идем. Сәйфи агай исә аны укып чыккан һәм үз фикерләрен миңа сөйли башлады.

— Синең эшчәнлеккә сокланам мин, Сәйфи агай! — дидем мин, һәм чын күңелдән әйтелгән сүз иде бу. Чыннан да ул башкорт, татар әдәбиятын, аларның вакытлы матбугатларын системалы күзәтеп бару өстенә башка тугандаш республикалардагы шагыйрьләр, язучылар белән дә тыгыз бәйләнештә һәм аларның да иҗатларын күздән төшерми. Рус әдәбиятын күзәтеп баруны инде мин әйтмим, чөнки ул һәрберебезнең көндәлек эш нормасына кергән.

«Яшьлек эзләре буйлап» моннан берничә ел элек «Агыйдел» журналында басылып барды һәм мин беренче тапкыр шуннан укыган идем. Хәзер мин аның русчасын укып чыктым. Мәскәүдә аны җыйнак кына, матур гына китап итеп, шактый зур тираж белән (30 мең) русча бастырып чыгарганнар.

Китапка тулы анализ ясамастан, шуны әйтәсе килә: анда укучыны ике нәрсә куандыра. Бердән, Сәйфи Кудаш Гафурича бик гади һәм мавыктырып сөйли белә,

укучының игътибарын бәйләп куя белә. Икенчедән, ул бик күп кешеләрнең язмышын читтән күзәтүче булып түгел, бәлки шул язмыш өчен тирәннән борчылып яки шатланып, үзенең йөрәк җылысы аша сурәтли.

Сәйфи Кудаш узган көннәрне сагыну яки искене бүгенге белән чагыштыру өчен язмаган. Ул үткәнгә экскурсия ясап, хаксызга онытылган язучыларны, шагыйрьләрне тергезә, башкорт тарихына бәйле гаять кызыклы белешмәләр китерә, башка җирдән табып булмый торган тарихи вакыйгалар турында сөйли. Шул рәвешчә, ул укыр өчен генә кызыклы әсәр булмыйча, гыйльми белешмә буларак та кыйммәтле әсәргә әверелә. Шул ук вакытта ул әсәрдән без бүгенге халык шагыйренең — татар, башкорт һәм казах халыкларының кайгы-хәсрәтләре, шатлык-өметләре, җыр һәм моңнарына үрелеп тамырлануын күрәбез.

Картая белми торган олы йөрәкле, киң колачлы Сәйфи Кудаш турында уйлаганда, аның кебек халык шагыйрьләренә беркайчан да отставка бирелми, күрәсең, дип куясың.

Халык шагыйре Мостай Кәрим Уфадан еракта, иҗат йортында иде, шуңа күрә мин аның «Айгөл иле» белән генә очраштым...

Бүрәнәнең авыр башын күтәрергә әзер торган дуслыкка ни җитә?! Аэропортка аяк басу белән мин Ибраһим Абдуллин һәм Нәҗип Асанбаевның кайгыртучан хәстәрләрен күрә башладым. Икенче көнне Башкортстан язучылары союзында миңа шундый ук игътибар белән Хәким Гыйлаҗев, Вазыйх Исхаков, Гайнан Әмири иптәшләр сораштыра башладылар.

— Муса эзләре белән килдегезме?

— Без нинди ярдәм күрсәтә алабыз?

— Кайларда булырга теләисез?

— Нинди ярдәм кирәк?

Һәм мин үземнең ун көнлек программамны сөйләп бирдем. Ул арада республика белән яшьтәш Гали Ибраһимов килеп керде. Башкорт әдәбиятында тыйнак һәм ныклы урын алган Гали Ибраһимовка 50 яшь тула икән, аның юбилей кичәсенә әзерлек бара. Һәм ул кичәдә мин Башкортстан язучыларының барысын да очраттым. Каләмдәш дусларының бәйрәменә хатыннары белән килеп, ул бәйрәмгә үз бәйрәмнәре итеп караулары миңа ошады. Монда дуслык та, теләктәшлек тә, хөрмәт тә чагыла иде.

Миңа күптән түгел генә Япониядә булган һәм анда антропологлар конгрессында катнашкан галим һәм язучы Кирәй Мәргән, аның янында — икенче галим һәм шагыйрь Гыйлемдар Рамазанов. Юмор белән җылытылган җитди сүз очланганчы, Әхнәф Харисов килеп җитә, ул да галим һәм юморның ялкынына май сибеп җибәрә торган үткен сүзле язучы.

Сәгыйт Агиш, Нәҗар Нәҗми, Рафаэль Сафин һ. б. иптәшләр шул төркемгә килеп кушылгач, «күңелсез» дигән сүз гомумән онытыла. Ике сүзнең берендә мәзәк, юмор, иптәшләрчә чемете торган киная яңгырый. Дусларның теле каты тоелса да, күңеле йомшак була, дигән мәкаль бу очракта бик урынлы. Монда берәрсенең бәгыренә үтеп керерлек үткен сүз әйтәләр икән — үпкәләш юк, шундый ук борычлы сүз белән җавап кайтара бел.

Башкорт язучылары җырга, биюгә дә осталар. Башкортның борынгы озын көйләрен дә, бүгенгесен дә профессиональ такт белән башкара беләләр алар. Нәҗар Нәҗми исә Поль Робсон булып та җырлый...

Җырлый белгәннең күңеле киң, күңеле киңнең тормышы матур, иҗат дәрте мул.

Башкорт язучылары — олысы һәм яшьләре — чит илләрдә бик еш булалар икән — гади турист сыйфатында гына түгел. Алар Азия, Африка илләрендә дә, Европа, Скандинавия илләрендә дә, Япониядә дә булганнар һәм мондый сәяхәт аларда туган ил өчен горурлык хисе дә уяткан, интенсив иҗат теләген дә көчәйткән. Дөньяның төрле почмакларында гасырлар буе Акыл һәм Хезмәт җимеше булып барлыкка килгән мәшһүр һәйкәлләр аларда кызыклы гына хисләр һәм уйланулар тудырган. Барыннан да бигрәк, безнең туган илебездә, Ленин даһилыгы белән балкыган азат илдә, шундый ук яки алардан да ашып китә ала торган бөек сәнгать әсәрләре тудыру өчен барлык шартлар тудырылган икән, без моны максимум файдаланырга тиеш һәм шундый бөек сәнгать әсәрләре тудыруга омтылышны көчәйтергә тиеш, дигән нәтиҗә ясаткан.

«Известия» газетасында басылган бер мәкаләсендә, мәсәлән, Мостай Кәрим болай яза:

«Ун гасыр буе башкорт ат өстендә ук, җәя тотып утырды. Ләкин, билгеле булганча, сугышчы һөнәре — иҗат итү һөнәре түгел. Шуңа күрә үзебезнең ирек сөюче сугышчан бабаларыбыз турында уйланганда, миндә горурлык һәм соклану хисләре ачыну белән бергә кушыла. Шушы уңдырышлы, матур җирдә озак гасырлар буе кеше акылы һәм хезмәте биргән җимеш бик аз түгелме? Туган җирләрдән еракка китмәч, узган гасырларның даһилык һәм титаник хезмәтләре белән тудырылган бөек һәйкәлләрен карап йөргәндә, мин шул турыда өш кына борчулы уйларга чумам».

Бу — мәгънәле сүзләр. Чыннан да, чит илләрдә йөреп, кешелек акылы һәм хезмәте калдырган тарихи һәйкәлләрне күргәч, үз халкыңның казанышлары белән чагыштырып карау бик табигый нәрсә. Тик бу чагыштырудан дөрес нәтиҗә дә ясый белергә кирәк. Мостай Кәрим әнә шул дөрес фикерне әйткән. Узган гасырлар өчен борчыла икән, халыкта уятылмаган иҗади көчнең мәһабәтлеген таный, ә хәзер ул уятылгач, азатлык илендә яшәгәч, ул бүгенге чор өчен үзен икеләтә җаваплы сизә!

Үзебезнең бөек чор каршында җаваплылык тою һәм халыкның үз эчендә булган талант көчләренең үсүенә үзара булышуны мин һәр өлкәдә сиздем. Мин аларда тирән уйланулар, фәлсәфи фикерләр белән тулы әсәрләр күрәм.

Шуның өчен дә ирешелгән уңышлар илле ел эчендә генә түгел, бәлки йөз еллар-да туплангандыр кебек тоела. Моны Гыйлемдар Рамазанов шигъри тел белән болай яза:

> **Алты яшькә яшьмен илебездән**
> **һәм яшьтәш тә аңа мин бүген,**
> **Ниндәен юл — артта!**
> **Тоям кайчак**
> **Яшәгәндәй ике иллене.**

Дөрес, ун көн эчендә мин иҗади җимешләрнең барысын да һәм барлык тармакларын да күздән кичерергә өлгерә алмадым. Ләкин җыр, музыка, опера, театр сәнгате, драматургия өлкәсендәге казанышларга сокланмый мөмкин түгел. Сәнгатьнең бу тармаклары бер-берсеннән аерылмыйча, берсе-берсенә иҗади ярдәм итешеп, бер фронт тәшкил итеп алга баралар. Бәлки шуның өчендер Дәүләт премияләре лауреатлары күбрәк шушы тармактан. Башкорт сәнгатен Союз күләменә чыгару өчен әдәбият-сәнгать әһелләре бердәм эшләделәр һәм бу аларга уңыш китерде.

Башкортстанның бию ансамблен генә алып карагыз. Ул чит илләрдә бик еш була һәм кайсы гына илдә булмасын — Ленин нурлары белән җылытып үстерелгән халыкның иҗади сәләте чиксез булуын раслап, халыкларда соклану уята һәм һәркайдан макталып кайта. Нинди җитез хәрәкәт, пластика, яшьлек очкыны аларда. Шунысы характерлы: башкорт җырчылары һәм башкорт биючеләре дә юморны мул кулланалар. Бу бит үз көченә нык ышанган кеше өчен хас сыйфат.

Опера һәм балет театрында зур концерт бара, мин Асанбаевтан Башкортстан җырчылары турында сорашып утырам. Ул драма театрына бик якын булса да, опера театры көчләрен дә яхшы белә һәм һәркайсысы турында тәфсилләп сөйли тора... Җырчылар, биючеләр күп, кайберсе миңа электән үк таныш, җырчыларын еш кына радио аша да ишетеп торабыз, ләкин үз күзең белән күреп, каршыларында утырып тыңлауга ни җитә! Шулай да мин бер артист турында гына берничә сүз әйтәсем килә. Ул — бөтен илгә танылган, мәһабәт бәрхет тавышлы Мәгафур Хисмәтуллин — башкорт опера театрына тирән тамырлар җибәрергә өлгергән, опера солистлары династиясен башлап җибәргән җырчы. Хәзер аның улы да танылган солист.

Мәгафур Хисмәтуллинны мин концертта да, «Кодача» исемле музыкаль комедиядә дә күрдем. Талантлы шагыйрь һәм драматург мәрхүм Баязит Бикбайның «Кодача» комедиясе опера театры репертуарында нык урын алган һәм аны Опера һәм балет театры артистлары яшьлек дәрте белән башкаралар. Татарстанда да популяр композитор Заһир Исмәгыйлов «Кодача»ны музыкага салган һәм ул музыка колакка бик ягымлы ишетелә. Баязитның юморы, үзенә генә хас тапкыр сүзләре З. Исмәгыйловның музыкасына күмелеп калмаган, алар бер-берсен яхшы аңлап, бер-берсенең иҗатына канат куеп, күңелле әсәр иҗат иткәннәр. Бу спектакльдә Мәгафур Хисмәтуллин үзен

башкорт операсында әйдәп баручы солист итеп кенә түгел, бәлки талантлы артист итеп тә танытты. Мин мәрхүм Әмин Зөбәеровны күз алдыма китереп утырдым, чөнки ул даһи артистның гүзәл традициясе драма театрында гына түгел, опера театрында да дәвам итә кебек тоелды миңа. Хисмәтуллин шул традициянең яшәвен хәтерләтеп уйнады.

Мин шушы опера театры бинасында 1925 елны беренче тапкыр спектакль караган идем. Ул чакта бер бинада рус драмасы да, башкорт драмасы да эшли иде. Опера һәм балет театры турында әле хыялланырга гына мөмкин иде. Хәзер ул бар, аның традицияләре дә бар, үз репертуары һәм үз композиторлары да бар.

Минем программа буенча төп эшем — драма иҗаты һәм драматургия белән танышу иде.

Мин анда башкорт драма театрының берни белән дә үлчәп булмый торган уңышларын күрдем. Бу — иң элек, Академия театрына лаеклы уен осталыгы! Чын-чынлап халыкның мәхәббәтен яулап алган осталык! Бер карагач, яңадан карыйсы килү теләге уяткан профессиональ осталык! Беләм, моңа ирешүе җиңел булмагандыр, ләкин ул бар.

Хөрмәткә лаеклы артистлар исемлеге бик озын. Анда СССР халык артисты А. Мөбарәков, РСФСРның халык артистлары З. Бикбулатова, Г. Тукаев, РСФСРның атказанган артистлары Р. Сыртланов, Р. Янбулатова, Б. Йосыпова, В. Галимов, республиканың халык артистлары Т. Бикташева, Г. Сөләйманов, Т. Рәшитова, уннарча атказанган һәм югары исемнәрне алырга лаеклы сәхнә осталары бар.

Башкорт сәхнә культурасын үстерүгә язучыларның да көче күп салынган. Башкорт сәхнәсен Б. Бикбай, М. Кәрим, К. Даян, Н. Асанбаев, И. Абдуллин, Ә. Мирзаһитов, Ә. Атнабаев, В. Галимов, Н. Нәҗми һ. б. авторлардан башка күз алдына китерүе кыен.

Заманында Б. Бикбайның «Карлыгач», К. Даянның «Таңчулпан» драмалары башкорт театры үсешенең бер баскычын тәшкил итсәләр, хәзер дистәләрчә яңа һәм бүгенге көнне чагылдырган, кеше язмышын тирәннән алып яктырта торган, акылга һәм хискә мул азык бирә торган әсәрләр бар. Мостай Кәримнең драмалары аеруча зур уңыш казаналар һәм аның әсәрләре башкорт драматургиясен Союз күләмендәге сәхнәгә күтәрделәр. Бу — әлбәттә, башкорт халкының горурлыгы һәм казанышы. Ә. Атнабаев, Н. Асанбаев, Б. Бикбай, Н. Нәҗми, Ә. Мирзаһитовларның әсәрләре республика чикләрен күптән узып чыктылар инде.

Башкортстанның 50 еллыгы алдыннан гына Мостай Кәримнең яңа романтик драмасы сәхнәгә менде. Ул «Айгөл иле» исемле поэтик әсәр оста язылуы белән генә түгел, бәлки эчке мәгънәсенең көчлелеге белән дә тамашачыны таң калдыра. Драма кешелек дөньясына кагылышлы олы фикерләр белән тулы. Айгөл иленең (бүгенге Башкортстанның) бөеклеген, матурлыгын һәм туган илнең изгелеген җырлый торган бу романтик драма ил турында, чын цивилизация һәм бәхет турында, кешелек бурычы һәм мәҗбурият турында, кешенең намусы һәм аның характерында яшерелгән «өченчә» сыйфат турында, ягъни «юк» белән «әйе» арасында буталып йөрүче адәм имгәкләрә турында уйландыра торган әсәр.

«Айгөл иле» — ул романтика һәм бәхет, үз-үзеңне кыядан ташлата торган татлы хыялый яшьлек. Ул башкорт балы тамчысы кебек саф һәм хуш исле мәхәббәт! Шул ук вакытта анда горур табигатьле, кайгыны арканлап, үзләре югары күтәрелә торган эшчән кешеләр, ил турында олы фикер йөртә белә торган батырлар күрәбез.

Казан тамашачылары бу гүзәл спектакль белән җәйге гастрольләрдә очрашачаклар.

Башкорт язучылары балалар сәхнәсен дә онытмаганнар. Бу өлкәдә Шәриф Биккол, Әнвәр Бикчәнтәевнең уңышлы тәҗрибәләре бар. Мин Әнгам Атнабаевның «Ул кайтты» драмасын, В. Галимовның тәрек язучысы О. Кемаль романы буенча эшләнгән «Упкын» драмасын, Илшат Йомагуловның «Нәркәс» исемле драматик легендасын башкорт сәхнәсеннән карадым. Болардан тыш кульъязмадан ике драма һәм газета-журнал битләреннән сәхнә әсәрләрен укып чыктым.

Кыскасы, драматургларның күмәк көче белән башкорт халкының узган тарихыннан алып бүгенге көн батырларына чаклы тормышын сәхнәдә иңләп алган күп төрле һәм төрле жанрда бай драматургия җитлеккән. һәм ул драматургияне сәхнә сәнгатенә

салып халыкка җиткерә торган югары класслы актерлар коллективы үскән. Башка халыклар белән чын-чынлап иҗади бәхәскә чыкканнар башкорт кардәшләр, бу ашкынулы адымнарның тирән эзләрен күрмәскә мөмкин түгел.



## Үзәнлектә Туймазы

Поезд Агыйдел күперен гөрелдәтеп узганда, мин тәрәзәгә килеп капландым. Салкын томанга төренгән биек кыя өстендә мәһабәт булып Салават Юлаевның һәйкәле шәүләләнә. Ул кара тулпары белән биек яр өстеннән Агыйдел аша очып китәр төсле, үзе артыннан бөтен башкорт халкын югарыга, бәйсезлеккә, бәхеткә өнди кебек.

Поезд шәп бара, кайчандыр урман, болынлык булган җирләрдә — яңа йортлар, яңа предприятиеләр. Әледән-әле каршыдан выжылдап уза торган электровозларның нинди вагоннар таккан булуларына карап, мондагы җирләрнең байлыгын, нинди «җимешләр» бирүен чамаларга була. Нефть ташый торган симез цистерналарның санын, эшелоннарның озынлыгын кем үлчәгән?!

Әледән-әле манара сыман юан трубалар күзгә чалынып кала, буй-буй такталарданмы, әллә башка материалданмы киендерелгән дүрт почмаклы юан трубаларның киң авызларыннан иренеп кенә әллә төтен, әллә кайнар су буы бөркелә. Бу — башкорт җиренең тирәннән сулыш алуы, аның кан тибеше, ул үзенең киң күкрәгеннән илгә байлыгын бирә, шушындый салкын көнне дә кайнар сулыш алудан туктамый.

Менә хәзер поезд кинәт көнбатышка борылырга тиеш. Әйе, борылды. Менә тирән чокырдагы бетон күпер. Шушы турыдан Бүздәк районының Ышланлыкүл авылы башлана. Минем яшьлек елларым анда узган иде, өч ел буе, ач торып, белем алырга тырышкан идем мин анда. Чөнки бу авыл революциянең беренче елларында культура учагы хезмәтен үти иде. Революциягә чаклы ук 2-х классное училище (алтыеллык мәктәп) ачылган иде анда, фәкыйрь булса да китапханәсе дә бар иде.

Сандугач кунарлык та куаклардан, агач-бакчалардан мәхрүм булган шыксыз бу авылны алпавыт Хәйдәр Сыртланов сарайлары һәм аның мәһабәт бакчасы түгел, бәлки училищесы бизи иде. Бу училищега культура ягыннан шактый алда торган Бүздәк авылыннан гына түгел, башка авыллардан да яшүсмерләр килеп укыды.

1920 елда алпавыт йортында сирәк-мирәк булса да әдәби кичәләр, спектакльләр дә куела башлаган иде. Хәзер бу авылның шыңгырап торган училищесы да, тулай торагы да, каретниклары да, нигезе дә калмаган.

Аның каравы элек башлангыч мәктәбе дә булмаган Кандра зур эшчеләр поселогына әверелгән. Шәһәр диярсең — күп катлы йортлар, төзек урамнар, культура сарае... Моннан егерме ел элек салам түбәле авыл, район үзәге Туймазыга күчерелгәч, шул килеш калыр кебек иде, ә менә нефть аны нигезеннән үзгәрткән.

Ә Туймазы? Хәтеремдә, үзәккә үткән ачлык елның шушындый ук салкын кышта абыем белән Туймазы станциясенә төнлә килеп төшкән идек. Кечкенә вокзал һәм нәни амбардан башка нәрсә бар иде икән ул чакта? Вокзалның тирә-ягында Кыш бабай котырынып йөри, ә без, әле яшь малайлар, салкыннан куырылып, тагын да кечерәйдек һәм кереп җылынырлык бер будка да тапмагач, еракта шәүләләнгән Райман авылына киттек. Ай яктысы астында йоклаган авылда хәтта этләр дә өрми иде. Без, ике малай, кунып чыгарга урын таба алмыйча, бик озак йөргән идек. Ниһаять, бер мәрхәмәтле җиңги безгә ишеген ачты, тик ут кабындыра алмады. Учактагы күмер тәмам сүнә язган иде бугай, өреп-өреп тә чырага ут кабынмыйча җиңгине азаплады. Кабынгач, җиңги мичнең кучкарындагы кара бутылкага үрелде. Чүпрәктән ясалган фильтә калай белән кыстырылган һәм бутылкага чумдырылган. Бәлки, кайчандыр ул бутылка тулы керосин булгандыр, яна-яна ул кимегән һәм чүпрәк-фильтә аңа җитсен өчен керосинга су салып торганнар. Хәзер ул су белән тулы, аның өстендә берничә кузәнәк керосин йөзеп йөри. Билгеле, мондый хәлдә җиңги ут кабындыра алмады...

Күпме вакыт узды соң әле аңа?.. Мәрхәмәтле җиңги дә, без дә нефть диңгезе өстендә утыруыбызны, әлбәттә, башыбызга да кертмәгән идек. Чыннан да, ул чакта әле караңгы төндә бердәнбер яктылык — күктәге ай иде! Хәзер?..

Моннан егерме ел элек тә, хәтта ун ел элек тә Туймазы болай түгел иде. Аның шактый килешле һәм горур рәвештә күккә таба сузылган элеваторы, нефть производ-

ствосы идарәсе бар иде... Хәзер аның Союз күләмендә әһәмиятле булган предприятиеләре бик күп. Гомумән Башкортстан эшләп чыгарган продукцияләр күләмен исәпләгәндә — Туймазы бишенче урында тора. Анда медицина пыяласы (ампула, флакон кебек нәрсәләр) эшли торган завод, нефть чыгару өчен эшләнгән торбаларны пыялалау (аны футировка дип атыйлар икән), геофизика җиһазлары һәм аппаратлары эшли торган завод, газны яңа башттан эшләү, корым (шина ясау өчен) заводлары, кәгазь фабрикасы, ит комбинаты, сөт заводы, ике тегү фабрикасы; консерва, икмәк, сыра заводлары. Хәзер химия машина төзелеше заводының беренче чираты стройга баскан.

Кандра, Түбән Троицк, Серафимовск, Собханкул исемле дүрт эшчеләр поселогын кушып исәпләгәндә (ә алар зур шәһәрнең иярченнәре кебек, тирә-якта бик якын урнашканнар), Туймазының шәһәр халкы 56 меңнән артып киткән.

Партиянең шәһәр комитеты эшен күз алдына китергәндә, Кыдаштагы башкорт сукно комбинатын, Түбәнкул кирпеч заводын, тимер-бетон әйберләре эшләү заводын, индустриаль техникумны, медицина училищесы, профессиональ-техник мәктәпне, 115 гомуми уку мәктәбен, сигезәр еллык ике музыкаль мәктәпне дә истә тотарга кирәк. Район зур, анда 16 авыл Советына 130 авыл керә, алар 14 эреләндерелгән колхозга берләшкәннәр, районда биш совхоз бар.

Татарча һәм русча чыга торган «Ленин юлы» газетасы 16 мең данә тарала икән. Бу газетада Ватан сугышына кадәр Башкортстанның халык шагыйре Рәшит Нигъмәти дә эшләгән.

Шулкадәр катлаулы хуҗалык һәм промышленностьны, әлбәттә, белгечләр идарә итәләр. Районда югары квалификацияле белгечләр, промышленностька яңалык кертүче уйлап табучылар, хезмәттә дан казанган Социалистик Хезмәт Геройлары бар.

Тышкы үзгәрешләр, билгеле, халыкның рухи, интеллектуаль үсешеннән аерылгысыз. Моны газета-журналларга язылудан да күреп була: район буенча һәрбер мең кешегә 886, шәһәр буенча — 1 161 газета-журнал яздыралар икән, районда уртача — мең кешегә мең дә ун газета-журнал туры килә.

Яшермим, миндә горурлык хисе уянып китте, чөнки ни әйтсәң дә, Туймазыга беренчеләрдән булып йорт салучы һәм волость үзәген шунда күчерү өчен янып йөрүче кеше миңа бик якын кеше — Мирсәет җизни иде. Ул караңгы авылларда революция ясаучыларның берсе һәм соңгы сулышына кадәр үзенең туган халкын бәхетле итү, аның күңелен Ленин нурлары белән җылыту өчен тырышты. Волость үзәге Туймазыга күчкәч, ул волисполком, соңыннан райисполком председателе булып эшләде. Күптән инде ул юк, ләкин ул утырткан бакча Туймазыда шәһәр бакчасы булып гөрләп үсә. Яхшы кешенең яхшылыгы югалмый, диләр бит! Бәлки яхшыдан да бераз шәбрәктер?

Шагыйрь Хәниф Кәримнең шигыре искә төшә:

Тик син баскан җирдә эз кала,
Тере һәйкәл булып эш кала,
Дала киңлегендә ут яна,
Амәнәткә яхшы сүз кала...

Туймазы халкының эшчән куллары белән Ык үйсулыклары танымаслык хәлгә килгән. Дөрес, Туймазы ул Өсән буенда, ләкин шушыннан инде Ык үйсулыклары башлана. Бер кеше гомере эчендә генә әле бу тирәдә тимер юл да юк, авыллар да сирәк иде. Өсән белән Ык арасындагы әллә кайларга җәйрәп яткан үйсулыкта — кереп китсәң, чыга алмаслык болынлык, куаклык... Таң вакытларында, үлән яфраклары чык тамчыларын күтәрә алмыйча салынып төшкән вакытта, җәен балыклары койрыкларын авызга кабып, чыклы үлән естеннән тәгәрмәч кебек тәгәри-тәгәри, Ыктан Өсәнгә, Өсәннән Ыкка кунакка йөри торган булганнар, имеш. Шуларның берсен минем әти үз күзе белән күргәнлеген ике китеп һәм ходайның бер могҗизасы итеп сөйли иде. Хәзер бу үйсулыкта җәен балыкларына тәгәрәшеп йөрергә рәт калмаган. Үйсулыкта кеше тормышы кайный һәм ул электр утлары белән балкыган, ә балыкларның күзләре чагыла...

Гомере буе укытучы булып эшләгән Саҗидә апамның өе җылы һәм без анда шәһәр комитеты секретаре Марк Семенович Кудряшов һәм безнең авылның сөлек

кебек чибәр егете — шәһәр комитеты секретаре ярдәмчесе Фатих Дәүләтшин белән бу якларның тормышы, көнкүреше турында сөйләшеп утырабыз.

Алар мине станциядә каршы алдылар һәм шунда ук өч апам, бер сеңелем дә килеп җиткән иде, мин бераз каушабрак та калдым: төрле яктан миңа машина тәкъдим итәләр. Авылга барырга димлиләр.

— Авылдагы апам үзе килгән иң,— дим аларга, ә күңелемдә төрле хисләр уяна. Фатих аның саен кысрыклый:

— 1948 елдан бирле кайтканың юк!.. Әллә беләсеңме хәзер ул авылны?..

— Беләм, дүрт яктан тау, ә ул чокырда, кар астыннан морҗалары гына күренә булыр хәзер. Машина белән кереп батсаң, шунда калдың, дигән сүз, ә миңа дүшәмбе көн иртүк Уфада булырга кирәк. Эшем шундый!

Фатих Дәүләтшинның нечкә җиренә кагылдым шикелле, ул сикереп үк торды.

— Туктале, ничек безнең авыл турында син шулай уйлыйсың... Юк, болай булгач, көчләп алып китәбез. Күрсәтербез без сиңа карга күмелгән авылны...

Аны Марк Семенович куәтли һәм юлларның яхшылыгын, машинаның ни җитте генә түгеллеген әйтә дә:

— Ике толып җитәме? — дип сорый.— Берсе — аякларны төрергә, берсе — киярга...

Һәм ул шундук XXI партсъезд исемендәге колхоз җитәкчеләренә хәбәр итү чарасына керешә.

Чыннан да, туган илдән кем туйган? Минем бик кайтасым килә, тик кырыктан ашкан салкында түгел, җәй көне, юкә яфракларыннан бал тамып торган чакта...

1948 елның көзе иде, мин әни карчыкны үзем белән Казанга алып киту өчен кайтып кердем. Күрше-күлән белән генә очрашып, сөйләшеп утырдык. Аларның тормышы бик үк җиңел түгел, колхоз фәкыйрь, аякка баса алмый тора иде әле.

Бергә үскән чордашларны, бергәләп комсомол оешмасы оештырып, спектакльләр куеп йөргән кордашларны күрәсе килә, ә аларның берсе дә фронттан әйләнеп кайтмаган. Бәхетгәрәй, Исламгәрәй, Госам, Хисам, Батырҗан, Муллаҗан — кемнәрнә генә сорама:

**— Үлеп калды.**

— Хәбәрсез югалды.

— Ике ятим баласы бар.

— Хатыны да авылдан китеп барды инде...

— Күптән авылдан киткән иде, белмибез...

Дуслар белән, замандашлар белән бергә яшәү генә күңелле икәнен мин шул чакта тирәннән аңладым.

Әйе, авыр тойгылар белән киткән идем мин. Сугыш фаҗигасе безнең бәләкәй генә авылның һәр йортына кереп чыккан, хәтта бер генә тапкыр да түгел. Соңыннан белдем, авылдан китеп, Ватан сугышы кырларында гайрәт белән сугышкан, тантаналы Җиңү өчен башларын салган имәндәй таза ирләр-егетләрнең саны 57 гә җиткән. Авылда туып-үскән һәм сугыш алдыннан читтә эшләгән ирләрне бу санга кертмәгәннәр. Чыннан да кайдан белеп бетерәсең...

Мин күңелемнән авылдашларымны күз алдына китергәндә, Сәҗидә апа өстәлгә зур таба белән бәлеш китереп куйды.

— Без бит әле энебезне күрергә дә өлгермәдек, иркенләп бер сөйләшик әле, ичмасам!..

Горком секретаре:

— Юк, бүген ул сезнең янда гына була! — диде. Үзе колхоз һәм аның председателен мактарга кереште.

— Барысы да фронтта үлеп калмадылар бит, батырлар әйләнеп тә кайттылар һәм хезмәт фронтында да батырларча эшлиләр...

## Шайтанлы чишмәсе буенда

Безнең авылны дүрт яктан да таулар саклап, салкын җилләрдән ышыклап тора. Кышларын буран күмеп китә торган, тау астындагы нәни авыл, миңа һәрвакыт тау башында балкый кебек тоела һәм нурларын да тирә-якка, еракка чәчә төсле. Мин аны

кечкенәдән үк бик ярата идем һәм, Тукайның шигырен үзебезнең авылга карата язылган дип исәпләп, абый белән җырлап йөри идек:

**Тау башына салынгандыр безнең авыл,**
**Бер чишмә бар, якын безнең авылга үл...**

Тау күкрәген тишеп чыккан чишмәләр бездә берәү генә түгел, ләкин бөтен авыл Шайтанлы чишмәсен яратарак бирә, аның суын шифалырак дип таба, безгә Тукай да шул чишмә турында җырлагандыр кебек була.

Хәмит машинасын бик кызу алып бара. Ул олы юлны гына түгел, авыл араларындагы басу юлларын да яхшы белә — турыдан гына элдерә.

Горком секретареның:

— Аннан юл бармы соң? — дигән соравына:

— Табабыз! — дип кенә җавап бирә.

Без Кандраны, Кандра күлен сулъякта калдырып, үрләрдән генә чабабыз. Бер сәгать тә вакыт узмый, XXI партсъезд исемендәге колхоз правлениесенең кояш нурлары белән балкыган якты, җылы идарәсенә килеп керәбез.

Председательнең пөхтә, ләкин кәгазьләргә күмелгән өстәленә аркылы озын өстәл сузганнар. Кызыл материя белән ябылган бу өстәлдә бер өем газета-журналлар тора, мине нәкъ шул өем алдына китереп утырттылар. Сизеп торам, янәсе, күр, без аю өнендә яшәмибез, сезнең язганнарны күзәтеп торабыз.

Иң өстә «Казан утлары»ның соңгы саны, «Азат хатын», «Ялкын», «Агыйдел», «Башкорт кызы» журналлары — барысы да әле яңа һәм таушалмаган. «Кызыл таң» һәм «Совет Башкортстаны» газеталары.

— Барысын да укыйбыз! — диде партком секретаре Аскаров.

— Безнең колхозда ике китапханә, анда 20 меңләп китап бар, — ди кемдер, — Алардан тыш — ике мәктәп китапханәсе...

Танышу башлау китап турында сөйләшүдән ялганып китте.

— Халык бик күп укый бит хәзер. Китап җиткереп булмый. Безнең авыл Советы бюджеты ел саен китап алу өчен 200 сум билгели. Әмма сәүдә оешмалары китапларны без сораган вакытта һәм кирәк кадәр җибәрмиләр.

Моны авыл Советы председателе Әюпов иптәш әйтте. Аның сүзен куәтләп, Марк Семенович:

— Ана телендә китап җитми. Кыска пьесаларга бик сусыйбыз!..

— Эш зурдан китте, танышып бетик әле, — диде Фатих Дәүләтшин.

Монда колхозның җитәкчеләре — элекке фронтовиклар җыелган иде.

Менә минем кордаш Зәйнулла Хәмидуллин, ул инде олыгайган, калынайган, чәчләре дә чаларган, шулай да йөзе түгәрәк һәм яшьләрчә шома, матур һәм сөйкемле генә елмаеп тора.

Без аерылганнан соң аның башыннан ниләр генә узмаган. 1933 елда ул «Үрнәк» колхозы председателе булып эшләгән, аннан партиянең район комитетында инструктор, балык заводы директоры, аннан соң армия... 1945 елда фронттан кайткач, Фрунзе исемендәге колхозга председатель итеп сайлыйлар. Колхозлар эреләндерелә, Зәйнулла председатель булып сайлана.

— Хәрби биографиягезне дә сөйләп бирсәгез иде! — дим мин.

Зәйнулла, бераз уңайсызланамы, мактану дип аңламасыннар дип уйлыймы, бик коры гына, анкета тутырган кебек, белешмәләр әйтә. Ярый әле янәшәдә шәһәр комитеты секретаре тора, Марк Семенович аның өчен сөйләп, кайбер детальләр белән «анкетаны» җанландыра.

1 дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән Зәйнулла Ерак Көнчыгышта да, II Балтик буе, II Украина фронтларында да көрәшкән. Берничә кат яраланган. Немец снайпере аның күкрәгенә пуля җибәргән, пуля партбилетын тишеп, тәненә кергән. Зәйнулла госпитальдә озак дәваланган, яңадан стройга баскан.

— Ул партбилет бармы әле? — дим мин.

— Юк, алыштырдылар...

Бөек Ватан сугышы архивында дошман пулясы тишеп узган партбилет бәлки саклана дыр!

Венгриядә сугыш барганда Зәйнулла тагын яралана, ләкин стройдан чыкмый, үзенең пулемет взводы белән алга һөҗүм итә. Чехословакиядә Брно шәһәрен фашистлардан азат иткәндә өченче тапкыр яралана...

Җитез хәрәкәтле, интеллигентлыгы сүзеннән дә, эшеннән дә сизелеп торган элеккеге солдат Әкрәм Әюпов 1947 елдан бирле авыл Советы председателе булып эшли икән. Егерме елдан артык җирле Советта сайланып эшләү — үзе яхшы характеристика. Димәк, сайлаучылар аның эшен яраталар, ә ул сайлаучыларның ихтыяҗларын яхшы белә.

Колхоз коммунистларының җитәкчесе Әхнәф Аскаров та фронт утларын кичкән егет булып чыкты.

Хәзер партком 83 коммунистны берләштерә. Бу сан, бер карагында, бик күп түгел кебек. Ни өчен дисәң, безнең авылда гражданнар сугышы тынар-тынмас ук партия ячейкасы оеша башлаган иде инде.

Минем янда утырган Фатихның әтисе — Салих Дәүләтшин, мәсәлән, беренче коммунистлардан иде. Волостька, өязгә бик күп көрәшчеләр бирде ул ячейка. Хәзер дә аның сафларында чыныккан коммунистлар тирә-якта гадел хезмәт итәләр. Алар көче белән авыл яңарган, бәхетле юлга баскан. Озын булган бу юл, ай озын!

Аның озынлыгы — авылның тарихы белән үлчәнә. Ачылы күл буенда бер Каңлы башкорты Сорурбикә исемле кызын Арсланбәк исемле батыр егеткә кияүгә биргән. Кызның бирнәсенә җир бүләк иткән. Бабай белән кияү ат менеп чыкканнар да тау башыннан тау башына кучә-кучә җир бүлгәннәр. Бабай тиешле кеше, камчысы белән ишарәләп, ерактагы тау сыртларына күрсәткән:

— Әнә сезгә җир шул таудан монавы тауга чаклы, тегесеннән шушысына кадәр!

Җәй буе йөреп чыга алмаслык урманлык, болынлык, тау-ташлык җирләрне бабай җиңел генә бүлгән. Арсланбәк чибәр кәләшне алып шул җирдән үзенә урын сайлаган. Артта бабай тора, йозак нык дип уйлаган, күрәсең, ул Кандра күлгә таба килеп, дүрт яктан да тау ышыклап торган иңкү урынны сайлап, өй салып утырган.

Тырыш кеше булган Арсланбәк. Ләкин коры кул белән ул чаклы җирне эшкәртү — мөмкин булмаган эш. Табигать бүләк иткән байлык белән генә дә яшисе килмәгән аның. Җәен җир эшкәртсә, кышын аучылык аңа мул азык биргән. Җәнлек тиреләрен ул Уфага илтеп сата торган булган.

Нәсел үрчи, патша чиновниклары эзәрлекләгән кешеләр килеп, мондагы куе урманда ышык урын табалар, бергә-бергә көн итә башлыйлар.

Арсланбәк батырның токымнары Пугач явында да катнаша һәм бер асыл егет соңыннан сөргенгә озатыла. Ирек сөюче табигать баласына каторга ошамый, ул аннан кача һәм урманнарда яшеренеп йөри. Ул еш кына авылның тау башына килеп курай уйный торган булган.

Авыл халкы, йокыларыннан уянып, аны елый-елый тыңлыйлар икән. Ирек һәм бәхет даулаучы егет авылга төшмичә генә, карагайлы кара урман эченә кереп яшерена, ди. Авылга керсә — авыл халкы патша палачларына тотып бирергә тиеш булганнар, күрәсең.

Еллар узган, ләкин бәхет ташы ялтырамаган. Иксез-чиксез урманнар, болынлыклар да бәхет уңдырасы урында, күп очракта, борчу тудырганнар.

Аларны алдаганнар да, талаганнар да. Алпавыт Хәйдәр Сыртланов биш тиеннән мең десятина урман бүлеп алган. Ләкин мең генә десятина идеме икән ул? Украина, Казан якларыннан килгәннәр, кайсылары сорамыйча ук кереп утырган. Шулай итеп, без үскәндә, авыл картларының әйтүенә караганда, Арсланбәк белән Сорурбикәгә бүләк итеп бирелгән җирләрдә утыздан артык татар, башкорт, типтәр, украин, рус авыллары яши һәм шулар арасында иң фәкыйре безнең авыл иде.

Аның каравы, илле авылны берләштергән волостьта җиде мәктәп булса, берсе безнең авылда ачылган. Хәзер инде ул үзенең 70 еллыгына аяк басып килә. Шунда өч класслы белем алган безнең авыл яшьләре, бәхетне табу юлларын өйрәнер өчен, читкә киталәр, күмер, алтын шахталарына юл алалар иде. Таптылармы алар бәхетне, юкмы, ләкин азатлык көрәшеннән берсе дә читтә калмадылар.

XX йөзнең башында авылда русско-башкирская школа ачылган. Школаны яндырып та караганнар, ләкин аның саен яктылык куәт алган. Русча-татарча укытыла торган мәктәп яшьләрнең күзен ача килгән. Хәзер колхоз идарәсе аның урынына сигезьеллык

мәктәп салдырган, якты бүлмәләр, җиһазландырылган физика, химия кабинетлары, физкультура залы, пианино, китапханәләре белән мәктәп инде тау башына менеп утырган.

— Мәктәп тезелеше аның белән генә чикләнми,— ди Зәйнулла.— Мондый мәктәпне без икене, башлангыч мәктәпне икене салдык. Хөкүмәттән бер тиен сорамадык!.. Хәзер бездә укытучылар саны гына 43. Ә укучылар — 565.

— Яшьләр авылдан китмиләрме? — дип сорыйм мин.

— Яшьләр шәһәргә китә икән,— ди Аскаров,— белем алырга китә.

— Быел без уньеллык мәктәп өлгертергә уйлыйбыз,— ди Әюпов.— Аннан соң китүчеләр азаер.

Өстәлгә зур журнал китереп салалар, анда бухгалтер хуҗалыкның исәбен теркәп барган. Зәйнулла Хәмидуллин миңа язылган цифрларны күрсәтә:

— Менә, карагыз, бу — безнең файда!

Колхоз 1968 елда миллион өч йөз мең сум керем алган. Һәм һәр хезмәт көненә 3 сум 77 тиен түләгән.

— Авылдан элек киткәннәр дә кире әйләнеп кайттылар инде!

Халык шулкадәр бай, ул йомышы төшсә, ат сорамый, машина сорый. Колхозда 200 ат бар, машина — 16. Колхоз үзенең белгечләренә 10 мотоцикл алып биргән, ә үз акчаларына алганнары — 105 кеше, дүрт кеше инде автомобиль сатып алырга да өлгергән.

Соңыннан без Миңлеәгъзам абзыйга чәй эчәргә кергән идек. Мәэмина җиңгинең сый-хөрмәтен авыз иткәндә, шул ук бәхет, байлык турында сүз китте.

Сүз дә юк, халык бай тора: һәркемдә — алты почмаклы өй, шифоньер, радиоалгыч, тегү машинасы, диван-кровать. Телевизор бик тиз ишәеп килә, 215 хуҗалык инде баллон белән газ куллануга күчкән.

— Менә улым машина алыйк, дип әйтә,— ди Миңлеәгъзам Колыев.— Тугыз умартадан 15 фляга бал алган идем, кая куясың аны. Һәр флягасында 50 кило бит. Я, ашагыз әле, сатып алган бал түгел...

— Ә колхозда умарталар ничек? — дим мин.

Колхозның умарталыгы да ишле икән, дүрт кеше 240 умарта карый.

Сигезьеллык мәктәпне карап чыккач, Зәйнулла мине урманга каратып сорый башлады. Бу тау башыннан бик ерак җирләр күренә иде.

— Каратал түбәсен онытмадыңмы?

— Юк...

— Әнә ул, шуның итәгендә инде умарталыкның бер өлеше...

— Беләм, шау чәчәккә күмелеп утыра торган җирләр инде!..

— Болынлыклар да җитәрлек...

Мин Каратал түбәсенә, аның куе һәм биек агачларына карыйм. Миңа алар хәзер дә бал исе аңкытып торалар кебек тоела.

— Шайтанлы чишмәсе ничегрәк?

— Шайтанлы? — диде гаҗәпсенеп, Марк Семенович.— Кызык исем, ни өчен шулай атаганнар?

— Шайтан көче белән атылып чыга ул! — диде Зәйнулла.

— Аның легендалары да кызыклы,— дидем мин.

Сәрән авылы белән ике арадагы тау битеннән ургылып бер чишмә ага. Ян, Шәриф, мин — өчәүләп — ул чишмәнең суын авылга борып җибәрергә һәм бакчаларны сугару өчен файдаланырга мөмкин бит дип хыялланып йөри идек.

Без яшь чакта Шайтанлы чишмәсенә шайтаннар оялаган, алар тау битендәге имәнлек, юкәлектә яшеренеп яталар. Туйлары вакытына туры килсәң, таң әтәчләре кычкырганчы адаштырып йөртәләр, дип сөйлиләр иде. Адашып авыл башында әйләнеп йөргән кешеләрне исемнәре белән әйтәләр иде.

Без үскән вакытта инде әллә шайтаннар юашланды, әллә без алар белән дуслаштык, яздан алып, кара көзгә хәтле Шайтанлы буенда ат саклап куна идек, бер адашкан егет булмады.

Нинди генә куркыныч әкиятләр сөйләмәсеннәр, безнең авыл кызларының юлы Шайтанлыдан өзелмәде. Алар чупләмле алъяпкычларын киеп, ак яулыкларын колак өстеннән генә бәйләп, итәкләрен билләренә кыстырып, буялган көянтәләренә яшел

чиләкләрен асып, Шайтанлыга суга баралар иде. Җыелышып түгел, ялгыз-ялгыз барырга яраталар иде алар. Ни өчен шулай икәнен, егет булгач, үзем белдем: кызларга сөйгән егетләре белән күрешеп сөйләшергә бик уңайлы урын иде ул!

Безнең авыл шул Шайтанлы суын эчеп яши, ул су тәмле, саф, тешне камаштырырлык салкын. Кызлар чишмәгә килгәч, битләрен юалар, шуңа күрә аларның йөзе нәфис, йомшак була, ул суны эчеп үскән яшьләр зирәк-тапкыр булалар. Берәрсенең зирәклеге турында сүз чыкса:

— Аптырата алмассың, Шайтанлы суын эчеп үскән диләр аны! — дип горурланып та куялар иде.

Хәзер Шайтанлы чишмәсенең шайтан көчен колхоз үзенә буйсындырган. Тау итәгеннән терлек фермасына торбалар белән су керә, сыерлар, сарыклар автоэчергечтән шул Шайтанлы суын эчәләр. Шуңа күрә алар сөтне дә мул бирәләр, көрлекләре дә мактап бетергесез. Водопровод авылга да килгән: хәзер көянтә-чиләк күтәреп суга баручы кызлар юк, авыл урамында — су колонкалары...

Фермада эшләүче егетләр-кызлар белән әңгәмә ясаганда, зур кружканы тутырып минем алга Шайтанлы суын китереп куйдылар: сыйлаганда су эч, янәсе.

Ләкин бу суны сорап алып эчәргә кирәк! Әгәр безнең авылга килсәгез, Шайтанлы суын эчмичә китмәгез, аның тәме бер дә авыздан китми. Шифалы су ул.

— Ярый, сез бай, бәхетле яшисез. Бишьеллыкны да өч елда тәгәлләп, биш мең центнер арттырып ашлык биргәнсез. Яшьләрегез укуга омтыла, читтән торып укучылар да җитәрлек. Балалар да бала тудыру йортында гына дөньяга килаләр икән...

Минем сүзне партком секретаре бүлә:

— Соңгы дүрт ел эчендә балаларның үлү очраклары бөтенләй бетте.

— Ел саен 59 балага үрчеп торабыз,— дип өсти авыл Советы председателе.

— Авырлыклар да бардыр бит?

— Авырлык, дип, алар бар инде,— ди Зәйнулла.— Шифер саламны алыштырып бетерде, халык үз тормышыннан канәгать. Терлекчеләрнең 80 проценты инде бишдеңлек эш көненә күчте. Санаторий, курорт кирәк кешегә — түләүсез путевка бирәбез. Бәйрәм көннәрдә эшләгәннәр — ике хак алалар. Иген уңышы да район буенча гектардан 21,2 центнер булса, безнең колхозда өч мең гектар җирнең һәр гектары 22,3 центнер уңыш бирде. Шулай да безнең авырлыкларыбыз күп: безгә төзү материаллары җитми... Марк Семенович, бирегез әле безгә кирпеч, күбрәк итеп,— председатель шәһәр комитеты секретарена борылды.— Әнә Культура сараен да салып бетерәсе бар... Үзебездә безнең таудан таш чыгару бригадасы эшли, ул ташны без фермалар салу өчен генә файдаланабыз... Күпме акчабыз банкта ята. Төзү материаллары булса...

Авылны яңабаштан үзгәртеп салган, тормышны социалистик нормаларга яраклы рәвештә көйләп җибәргән бу ярсу йөрәкле абзыйлар-апалардан аерылып китәсе дә килми. Күңелле яшиләр алар!

# ЯШЬЛЕК ЭЗЛӘРЕННӘН

«Мин сукалар, тырмаларымнан аерылып, синең фән йортыңа — рабфагыңа килдем, Ташкала!»

*Ф. ӘСГАТЬ*



Мин еш кына шәһәребезнең үзәгендә горур басып торган Лобачевский һәйкәле янына, тын бакчага килəм. Бакча каршында — мәһабәт фән сарае, янәшәсендә генә Ленин китапханәсе. Кулларына китап-дәфтәрләрен тутырган сумкалар тоткан студентлар да күп була монда. Миңа калса, шәһәребездә шушы урыннан да ямьлерәк урын юк кебек.

...һәркемнең гомере буена онытылмаслык яшьлек хатирәләре була. Безнең дә олы юлыбыз нәкъ менә шушы тирәләрдән, Фәннәр сараеннан башланып китте. Шуңа монда еш киләм мин. Киләм дә ләззәтле уйларга чумам. Бакчадагы моннан кырык ел элек рабфакчылар утырткан агачлар да әнә нинди юан булып үскәннәр, тамырларын тирәнгә җәйгәннәр.

Ә кешеләре? Кешеләре дә җитлеккәннәр. Станокта эшләгән, шахтага төшкән, Ф. Әсгать әйтмешли сука, тырмаларыннан аерылып килгән егетләре дә, җиңнәрен сызганып, табак-савыт тирәсеннән күтәрелеп чыккан кызлары да хәзер чәчләре көмешләнгән, яшьлек эзләре маңгайларына сырланган зур галимнәр булганнар. Берән-сәрән генә түгел алар, бик күп. Яшьлек эзләре шушыннан — татар рабфагыннан башланып киткән галимнәр арасында хәзер Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел-әдәбият һәм тарих институтында иҗат итүче кордашларым да байтак. Рабфакны ачып җибәрү юлында зур тырышлык күрсәткән бөек әдип Галимҗан ага шушы урында әдәбият институты буласын һәм аның үз исеме белән аталачагын сизенгән диярсең.

Әйе, аның «Кызыл чәчәкләр»е уңдырышлы туфракка сибелгән. Без бүген бу чәчәкләрнең орлыкларын җыябыз. Шушындый изге җирне кем оныта алсын икән? Юк, һич онытыла, күмелеп кала торган сукмаклар түгел алар!

Меңнәрчә эшче һәм авыл ярлылары яшьләренә белем ачкычы тоттырган рабфакның ачылуына инде ярты гасыр вакыт үтеп тә киткән.

Бүтән мин шул рабфак стенасында сөялле кулларына каләм алып, беренче шигырьләрен, хикәя-очеркларын язган яшьлек дусларымны, сабакташларымны искә төшерәм. Аларның байтагы инде вафат. Ә күпләре исә бүген дә безнең арабызда иҗат эшләрен дәвам иттерәләр. Әнә Ленин китапханәсендә шул сабакташларымның романнары, хикәя һәм шигырьләре тупланган китапларны бүген аларның балалары, оныклары алып укыйлар.

Шуларның барысын-барысын искә төшерәм дә рабфак әдәбият түгәрәге тарихына, аның эшчәнлегенә әйләнеп кайтам.

Күз алдыма һаман хәрәкәтчән, фәннең бөтен серләрен өйрәнергә омтылып торган һәм, үзе дә кулына каләм алып, «сүзләрдән чәчәкләр» тезә башлаган Фәхри Әсгать килеп баса. Заманында «Мөхәммәдия»гә кереп тә үзенә җан азыгы таба алмаган ул егетнең дә яшьлек сукмаклары шушы тирәдә салынган. Моннан күп еллар элек «Ташкала»сын язган егет әнә шул инде. Аның тавышын тыңлап утырам:

«Мин синең биек пулатларыңа, зиннәтле гыйбадәтханәләреңә, зур кибетләрең һәм магазиннарыңа кызыгып килмәдем. Шулай ук Печән базарыңны, толчок, булакларыңны, ыгы-зыгы килеп, берсен-берсе алдаша торган нэпманнарыңны күрергә дә килмәдем. Каршымда аларның кыйммәте бик аз.

Төкерәм мин аларга!

Мин сиңа белем алырга, яңа юллар, яңа агымнар белән танышырга, күңелемә хәл, җанга азык, чишелмәгән сеальләргә җаваплар эзләргә килдем. Синең фән йортыңа — рабфагыңа килдем мин, Ташкала!..»

Рабфакка әнә шулай ашкынып килгән бу яшь язучының йөрәк түреннән чыккан көчле дә һәм ачулы да бу сүзләре тел галиме — укытучыбыз Мөхәммәтхан ага Фазлуллинны да дулкынландырган булса кирәк. Югыйсә укытучыбыз дәрес башланган саен Ф. Әсгатьнең «Ташкала» хикәясеннән шушы юлларны искә төшермәс иде. Ни өчендер «Рабфагыңа килдем, Ташкала» дигән сүзләрне остазыбыз аеруча басым ясап, класска күтәрелеп карап укый иде. Ихтимал, бу аның безгә тиздән сез дә шушындый көчле әсәрләр язып, сүзләрдән чәчәкләр тезәрсез, без сезне шуңа өйрәтергә чакырдык, дию булгандыр.

Укытучыбызның бу гадәтенең серенә без рабфак каршындагы әдәбият түгәрәгенә йөри башлагач төшендек. Егерменче еллар башында ук Фәхри Әсгать «Ташкалага» укырга килә. Тик, ни сәбәптәндер, ул башта рабфакка түгел, авыл хуҗалыгы институтына керә. Әмма аны әдәбият ныграк сихерли. Баштарак ул Гадел Кутуйлар белән университет әдәбият түгәрәгенә йөри. Рабфак түгәрәгендә дә еш катнаша. Белмим, түгәрәк үземе, әллә инде шул түгәрәкнең рухландыручысы, каләмдәше Муса кызыксындыргanмы аны? Ул күтәренке күңелле Мусага игътибар итә, бигрәк тә аның шигырьләренә колак сала.

Безнең тагын бер укытучыбыз, байтак еллар түгәрәк белән җитәкчелек иткән Садри Җәләл:

— Беләсезме, «Ташкала»ның авторы ул безнең үз язучыбыз,— ди торган иде.

Укытучыларымның сүзләрен тыңлый-тыңлый, менә мин бүген дә, фәннәр сарае бакчасына кергәч, шул юлларны кабатлап утырам:

— Мин синең фән йортыңа — рабфагыңа килдем, Ташкала!

Шундук күз алдымнан, елмаеп кына, гүя Муса узып бара. Әйтерсең лә, шагыйрь прозаик каләмдәше Фәхрине ишеткән дә, аның авазын шигырьгә салып, кулларын болгый-болгый сөйләп бара:

> Ленин сукмагыннан киң эз белән
> Үтүче ил!
> Синең каршыңа
> Сыналырга килдем
> Мин яшь егет —
> Мин туганмын көчү таңында.

— Туктагыз әле, туганнар! Мине дә тыңлап карагыз! Дөнья бит ул җыр белән ямьле. Йөрәкләргә дәрт биргән дә җыр, дулкынландырган да җыр,— дип дәшә бер моңлы аваз, һәм ул шунда, гүя җырлап та җибәрә:

> Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
> Эзләрем бик иртә салынган.

«Таң атканда» ук «Кайда да йөрәктә», «Җитен үстерүче кызлары»н онытa алмыйча, әкрен генә атлап килүче сабакташым Сибгат Хәким ләбаса бу! Әйе, ул. Әнә, ышанмасагыз култык астына кыстырган Тукай томына күз салыгыз. Шагыйрь бу китабын бүген дә калдырмаган.

Аннары:

— Миңа да катнашырга ярый торгандыр,— дип, Гали Хуҗи килеп керә. Һәм, ничәгрәк килеп чыкты икән диган сыман, тартынып кына шигырен укый:

Бу минем рабфак ишеген,
Беренче ачкан кенем.
Җирне кояш, ә кешене
Яктырта икән белем.—
Шуны белдем китаплардан —
Таптым чын дусларымны.

Аннары инде «Яшәү»нең ямен эзләп тапкан Шәрәф Мөдәррис комсомол сукмагыннан «Җыр үткән юл»дан «Яшьтәш»е турында җырлап уза:

Минем яшьтәш давыл алдының
Тынлыгында канат чыгарды,—
Баглап илгә яшьлек ялкынын,
Иҗат, хезмәт белән сыналды.

— Бетмәде әле, дуслар,— ди ул.— Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, шигырь генә язмыйк, хикәясен дә, мәкаләсен дә, әкиятен дә иҗат итик. Булгач булгач Тукайчарак булсын инде!

Шунда тагын бик күп сабакташларым күз алдыма килеп баса. Әнә, берәүгә дә артык исе китмәгәндәй, көлемсерәп кечә яшь студент Гариф Гобәй килә. Ул гүя: «Дусларым, мин әлегә язмыйча гына укып йөрим. «Без үскәндә» төрле хәлләр булуы мөмкин. Белмәссең, «Маякчы кызы»н очратсам, бәлки, дөртләнеп язып та куярмын. Без бит «Замана балалары», кирәк икән «Корьән серләре»н дә чишәрбез әле без сезнең белән»,— ди.

Әйе, шушы бакчада уйланып утырган хәлемдә, рабфак әдәбияты түгәрәгенә йөргән дусларымны күз алдымнан үткәрәм. Алар бик күп. Әмма бүген мин Муса Җәлилгә күбрәк тукталып үтмәкче булам.

* * *

Әгәр дә Муса бүген үзе исән булса һәм без аңа:

— Син егерме дүртенче елларда татар рабфагы әдәбият түгәрәгенең оештыручысы булгансың икән, дөресме? — дигән сорауны бирсәк, ул, мөгаен, елмаеп кына:

— Шулай ук булды микәнни? Әйе, хәтеремдә, мин рабфакта укыган елларымда, дәрес хәзерләүдән бушаган сәгатьләремдә, студентлар кичәләрендә шигырьләремне укыганым бар. Мандолинам да кулымда иде. Түгәрәк утырышларыннан калмадым. Каләмдәшләрем арасына хөрмәтле укытучыларым җитәкләп алып килделәр,— дип җавап биргән булыр иде.

1926 елның көзендә рабфакка кереп укый башлагач, без, яшүсмер авыл малайлары, бик кызыксынып, әдәбият түгәрәге утырышларына йөри башладык. Баштарак тыңлаучы булып кына. Ул чакта Муса, рабфакны тәмамлап, Орскида эшли иде инде. Әмма шагыйрь рабфакта шактый тирән эз калдырган икән. Югары курсларда укучы әдәбият түгәрәге членнары Мусаны бик еш телгә алалар, аны сагынып сөйлиләр. Ул чакта әле әдәбият түгәрәге ныклы план белән эшләмәгән. Аның членнары да аз булган. Әмма шунысы ачык, әледән-әле булып торган студент кичәләренә, әдәбият түгәрәгенә йөрүчеләр үзләренең шигырьләрен сабакташлары һәм укытучылары алдында сәхнәгә чыгып укый торган булганнар. Мусадан күчеп калган бу традиция студентларның яңа әсәрләренә үзенә күрә бер төрле сынау булган.

Рабфак күләмендә чыгып килгән «Татрабфак» стена газетасы һәм кулдан язылып чыга торган айлык «Яшь каләмнәр» журналы рабфак әдипләренең көзгесе иде. Һич

онытасым юк. Мусаның үзе кебек үк ачык чырайлы Зәйнәп Җәлилова, газетабызның редколлегия члены буларак, хәбәрләр, мәкаләләр, шигырьләр сорап, бер дә тынгылык бирми иде. Мусаны яхшы белгән әдәбият түгәрәге членнары:

— Бу хәтле абыйсы булыр икән, һич кенә дә тынгылык бирми бу Зәйнәп,— диләр иде.

Мусаның сабакташы, рабфакны аның белән бергә тәмамлаган Гайшә Байчурова үзенең истәлекләрендә түбәндәге юлларны яза: «Без рабфакны 1925 елны тәмамладык. Бу беренче чыгарылышта Муса Җәлил дә бар иде. Шушы вакыйгага багышлап, июнь аенда Татар академия театры бинасында зур тантаналы кичә булды. Кичәнең художество бүлеге өчен Муса махсус инсценировка язды. Аның бөтен эчтәлеге хәтеремдә калмаган. Ләкин сюжеты рабфакның икееллык тормышын, ягъни туып-үсү тарихын гәүдәләндерә иде. Уен тәмамлангач, көчле кул чабулар бөтен залны күтәрде. Тамашачылар бертавыштан:

— Авторны чыгарыгыз! — дип кычкыра башладылар.

Сәхнәгә йөгереп Муса килеп чыкты. Бер ялгызы бу зур сәхнәдә ул тагын да яшь бала сымак булып күренде. Миңа якын утырган бер агай:

— Әй, җаным, бигрәк бала икән шул! — дип куйды...

1927 елның Октябрь бәйрәме алды көннәре иде булса кирәк, без әдәбият түгәрәгенең нәүбәттәге утырышына җыйналдык. Яшь шагыйребез Әбүзәр Түрәй, кулларын болгый-болгый, үзенең яңа гына язган поэмасын сөйли башлады. Шул чак кинәт ишек ачылды һәм безнең янга Абдулла Алиш, Фатих Кәрим һәм Муса Җәлил килеп керделәр. Без тынып калдык. Муса елмаеп кына сәлам бирде дә:

— Дәвам итегез, коллегалар, тыңларга килдек,— дип студентлар янына, парта арасына кереп утырды.

Ә А. Алиш белән Ф. Кәрим безгә инде күптәннән танышлар иде. Алар икесе дә җир төзү техникумы укучылары. Техникумда әдәбият түгәрәге булмагандыр, ахры, алар безнең түгәрәк утырышларында еш кына катнашалар иде. А. Алишның мәгълүм «Якты күл буе» дигән озын хикәясенең кульязмасы безнең түгәрәктә укып тикшерелде. Соңыннан, бу хикәя китап булып басылып чыккач, автор аны зур ихтирам белән һәрберебезгә бүләк итте. Аның кулы белән язылган бу истәлек китабы әле дә минем китапханәмдә кадерләп саклана.

Без, үзебезне бик иркен тотып, түгәрәкнең эшен дәвам иттек. Әбүзәр Түрәй әсәре турында фикерләр алыштык. Вакыт шактый соң иде инде. Җитмәсә, залда кичә башланырга тора. Кичәгә кергәнче, Муса үзенең яңа гына басылып чыккан «Иптәшкә» исемле шигырьләр җыентыгын әдәбият түгәрәгенә бүләк итте. Ул шунда безгә карап торды да:

— Менә сез ничек үскәнсез, түгәрәктә кырыклап кеше катнаша. Димәк, безбиргән эстафета дәвам итә! — дип куанып әйтеп куйды.

Кичә башланды. Зал студентлар һәм укытучылар белән шыгрым тулы. Җыр-музыка номерларына аралаштырып, байтак шагыйрьләребез үзләренең әсәрләрен укыдылар. Шунда сәхнәгә запискалар ява башлады. Концертны алып баручы тамашачыларның Мусаны соравын әйтүе булды, зал көчле итеп кул чапты һәм Муса сәхнәгә менде. Башта ул, нәрсә укыйм икән дигәндәй, уйланып торды. Аннары кесәсеннән блокнотын чыгарып, кыска-кыска шигырьләрен укый да башлады. Аны уңлап шигырь укытмыйча сәхнәдән төшермәделәр. Шагыйрь гаять дулкынланган иде. Башка шигырьләре хәтеремдә ачык сакланмаган, әмма комсомолның уныеллыгына багышлап яңа гына язып килгән «Комсомолларга» дигән шигырен ул, гүя безгә атап укыды шикелле. Менә ул сәхнә алдына ук килеп басты да кулларын безгә таба сузды;

Барыгыз да яшел киенгәнсез,
Билегезне кысып буганыз,
Яр буенда кукрәп үскән
Нарат урманыдай булгансыз.

Чыннан да залда утыручыларның күбесе әле яңа гына чыккан ярым хәрби комсомол формасы кигән егетләр һәм кызлар иде.

Шигырен укып бетергәч, Муса безнең янга, залга төшеп утырды. Оркестр башкарган «Рабфак маршы»н ул аеруча бирелеп тыңлады. Оркестрда уйнаучыларның күбесе аңа инде күптәннән таныш икән.

Концерт тәмамлангач, Муса «Рабфак маршы»н язган студент Габделхак Гафуровны котлап кулын кысты. Аннан соң барлык музыкант дусларын кайсын кочаклады, кайсын үпте. Бик озак алар янынннан китмәде.

Шушы килүеннән соң да Муса Казанга кайткан саен рабфакка керми калмый иде. Ул һәрвакыт түгәрәк членнары белән якын элемтәдә торды. Бер килүендә, әдәбият түгәрәге утырышына катнашып, үзе тыңлаган берничә шигырь, очерк һәм кыска хикәяләребезне Мәскәүгә алып китте. Озак та үтмәде, аларны эшкәртеп, үзе эшләгән «Ударниклар» журналында бастырып та чыгарды. Безнең башлар күккә тиде. Рабфак укучысының шигыре башкала журналында басылып чыксын әле!

Менә болар үзләре генә дә Муса Җәлилнең рабфак түгәрәге белән якын бәйләнештә булуын, каләмдәшләренең үсү юллары белән даими кызыксынуын ачыклыйлар.

* * *

Иҗат адымнарын рабфакта атлаган, әдәби эшчәнлекләрен бүген дә дәвам иттерүче күпләр турында сөйләргә мөмкин булыр иде. Әйтелгәннәре белән чикләнеп, түгәрәгебезнең икенче бер күркәм ягына тукталып үтсәк, аның эшчәнлеге ачыграк чагылыр.

Сүз әдәбият түгәрәгенең бер бүлмәдә бикләнеп, студент массаларыннан аерылып эш итмәве турында бара. Бу яктан да рабфак түгәрәге яхшы үрнәк була ала. Күп очракларда түгәрәк занятиеләре рабфакның зур залында үткәрелеп, анда йөзләрчә кеше катнаша иде. Алар арасында, түгәрәккә йөреп тә, әле бер юл да әдәби әсәр язмаучылар булуы да гаҗәпләндерми иде. Кем белә, бәлки андыйлар «акыл җыеп», уйланып, алдагы олы юлларының юнәлешен төсмерләп йөргәннәрдер. Моның бик күркәм мисаллары да бар. Мин башта ук Гариф Гобәйне телгә алдым. Аның рабфакта укыганда бер генә әсәр дә язганын хәтерләмим. Әмма шунысы һич онытылмый, ул елларны яшь Гариф безнең иң күренекле, яраткан артистыбыз иде. Рабфак сәхнәсендә куелган әсәрләрнең кайсысында гына катнашмады икән ул? Һәрвакыт баш рольләрдә була иде. Без аның танылган артист булып китәчәгенә һич тә шик тотмадык. Әмма алай булып чыкмады бит. Күрәсең, укып, уйланып, «акыл җыйнап» йөргән бу студент, алдан ук язучылык профессиясен сайлап куйган булгандыр.

Түгәрәгебезнең сәнгать-музыка белән аваздаш булып яшәү традициясен безгә, мөгаен, Оренбургтан Муса алып килгәндер. Моны аның үз иҗаты үрнәкләре дә раслый. Шагыйрь дәртләнеп, гомере буе сәнгатьне, музыканы әдәбият белән бер бишеккә тирбәтте, һәм аның үзенең дә шушы юлда дәртләнеп эшләве барыбызга да мәгълүм. Түгәрәккә йөреп көч сынап караучылардан күпләре язучы да, артист та, композитор да булмадылар. Әмма аларның берсе дә түгәрәккә йөргән вакытларын бушка узган вакыт дип исәпләми торганнардыр. Аларның күбесе соңыннан журналист, тәрҗемәче, тел-әдәбият укытучысы, редактор булып китте.

Түгәрәк членнарының кайберләренең рабфакта укыган чакта ук аерым җыентыклар бастырып чыгаруларын, газета-журнал битләрендә әдәби әсәрләре белән катнашуларын әйткән идек инде. Әйе, түгәрәкнең әдәбият тарихыбызга кереп калырлык хезмәтләре дә күп. «Яшь каләмнәр» исемле кульъязма айлык журнал чыгарылды. Анда уннарча хикәяләр, шигырьләр, җырлар, очерклар, берәр пәрдәлек сәхнә әсәрләре тупланган. 1929 елда, рабфакның бишьеллыгына багышланып, махсус китап-альманах басылып чыкты. 1930 елны Мөхәммәт Парсин редакциясендә «Ударниклар килә» дигән җыентык дөньяга чыкты. Анда Гали Хуҗи, Хабра Рахманның берничә шигыре, бер пәрдәлек пьесалар, берничә хикәя һәм «Колхозга кайткач» исемле бер әдәби очерк урнаштырылган иде.

Һәр яхшы теләгеңә ирешүдә кемнеңдер сине әйдәве, өметләндерүе дә кирәктер, ахры. Бу яктан без бик бай идек. Дәрт, көч биреп, әдәбиятка мәхәббәт уятучылар — безнең укытучыларыбыз булды. Ә алар, бәхеткә каршы, рабфакта байтак иде. Исем-

нәрен генә әйтү дә җитә: тел галиме Мөхәммәтхан ага Фазлуллин, үзенең гүзәл «Дим буе» белән танылган, гаять кешелекле Садри Җәләл, таләпчән Хәй абый Хисмәтуллин, тыныш билгеләренне дөрес куймаган өчен «теңкәңә тия» торган Гариф ага Фәхри, ике куллап сәнгатькә әйдәп торган Заһидә ханым Тинчурина, тел укытучыбыз Касыйм ага Хәмзин һәм, ниһаять, Мәдәният йортында үткәрелә торган әдәби кичәләргә үзе белән җитәкләп алып йөрүче Гази Кашшаф, заманында «Галия» мәдрәсәсендә укып, Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Шәйхзадә Бабич, Фатих Сәйфи-Казанлы, Сәйфи Кудаш кебек өлкән әдипләребез белән якыннан аралашкан директорыбыз Зыя ага Насыйров. Аның «танышлыгы» аркасында без һади Такташ, Гадел Кутуй, Гомәр Толымбайский, Галимҗан Нигъмәти кебек танылган язучыларыбыз белән бик еш очраша, аларның киңәшләрен тыңлый идек. Директорыбыз әдәбиятны бик якын күрә иде. Китапханәбезне әледән-әле без сораган яңа китаплар белән тулыландырып тора. Кирәк чакта түгәрәк утырышларын үткәрү өчен үзенең кабинетын да кызганмый һәм үзе дә шунда безнең шигырьләребезне тыңлап утыра торган иде.

Үзенең унбиш ел яшәү дәверендә түгәрәк күп кенә яшь әдипләр үстерде. Менә безнең кулыбызда 1958 елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган Татар совет язучыларының био-библиографик белешмә китабы. Бу китапка кертелгән 90 язучының 12 се төрле елларда әнә шул түгәрәккә йөргән яки аңа җитәкчелек иткән танылган әдипләр.

Рабфак түгәрәгендә тәрбияләнгән әдипләрнең төрле елларда иҗат иткән 200 дән артык китабын кулыма алганым, укыганым бар. Аз түгел бу сан.

Менә шуларның барысын-барысын якты хатирәләр, матур уйлар белән күз алдымнан берәм-берәм үткәрәм дә куанып әйтеп куям: «Ничек кенә димә, рабфактагы яшьлек бушка узмаган. Телгә алып сөйләрлек, сокланырлык хатирәсе дә, кулга тотып, ләззәтләнеп укырлык китаплары да, моңайганда сузып җырларлык җырлары да бар икән әле бу яшьлекнең».

ГАРИФ МИҢНУЛ

# СОЧИДА ҮСӘ БЕР АГАЧ

Бөтен җир шарына билгеле булган шәһәрләр һәм авыллар, корабльләр һәм курганнар бик күп. Данлыклы агачлар да үсә. Без бу язмада шундый агачларның берсе турында сөйләргә телибез. Йөзләрчә ел дәвамында берничә кешенең колачы җитмәслек булып үскән һәм куышында туристлар ял итә алырлык гигант агач түгел ул. Бу агач бүтән ягы белән данлыклы. Планетаның бөтен почмакларында беләләр аның турында. Ул Сочида, дөньяның иң зур курортында үсә. Аны үстерүгә һәм агачның җимешләрен җыюга җир шарының 145 иленнән вәкилләр катнаша. Сочи иксез-чиксез Кара диңгезе, аяз зәңгәр күге, мәңге яшел пальмалары, кипарислары, кар һәм боз белән капланган биек-биек таулары, шифалы сулары, таңга калырлык сарайлары белән генә түгел, менә шушы агач белән дә атаклы.

Халыклар аны Дуслык агачы дип атаганнар. Ул агач кәүсәсендә төрле милләт, төрле раса, төрле караш кешеләре ялгаган ботак-тармаклар үсә, чәчәк ата һәм җимеш бирә. Карасу яшел бер ябалдашта Япония мандариннары, Италия лимоннары, Америка әфлисуннары, Һиндстан грейпфрутлары — саный китсәң, барлыгы 45 төрле җимеш күрергә мөмкин. Шул агач турында планета буйлап легендалар йөри. Хикмәтле бу бакчага дөньяның барлык почмакларыннан кешеләр килә. Кешеләр ул агачка җанлы автографларын язалар, алар «Кунаклар китабы»на җыр булып теркәлә.

«Сочидагы бу гүзәл бакчада мин бер сәгать булдым,— дип яза Сәгуд Гарәбстаныннан килгән күренекле дәүләт эшлеклесе Әхмәт аш Шөкәйри.— Ул борынгы грек философларының Афинадагы бакчасын хәтерләтә. Греклар бакчасы культура тараткан кебек, совет бакчасы кешеләргә шатлык өләшә».

Дуслык агачы янында булганда һәркем күңелендә иң изге фикерләр туа. Төгәл һәм киң мәгънәле сүз осталары — шагыйрьләр Дуслык агачын бигрәк тә образлы итеп сурәтлиләр. «Яфраклар белән язылган поэма»,— дип атый аны Гана шагыйре Эрик Хейман. Совет шагыйре Игорь Козбев, Африкадагы каләмдәше фикерен куәтләп,— Дуслык агачын кешеләр хезмәт, тынычлык турында кызыклы һәм дулкынландыргыч итеп язылган новеллалар җыентыгына тиңли.

Шул җыентыктан берничә новелла укыгыз.

## Кырыгынчы ел көзендә

Кара диңгез буйлары көзен, әкияттәге кебек, аеруча матур була. Кояш үзенең көлтә-көлтә нурларын бакчаларга, тауларга, яр буйларына мул итеп сибеп калырга ашыга. Диңгез дә сине үзенең кочагында иркәләнергә чакыра. Җәй буе яшел яфраклар ара-

сында яшеренеп яткан әфлисуннар, лимоннар, мандариннар, инде тамам өлгереп, куакларны алтын шарлар булып бизиләр.

Кавказның шушы гүзәл табигатенә соклана-соклана һәркем селекция бакчасына юнәлә. Монда чыннан да могҗизалар бар икән. Атаклы галим Иван Владимирович Мичуринның шәкерте Федор Зорин бер агачта әфлисун да, лимон да, мандарин дә үстерә башлаган. Бакчаны карап йөрүчеләрнең берсе бу агачны җентекләп күзәтергә керешкән. Аннан бакчачылар янына килгән дә:

— Алмаларны һәм грушаларны ялгый беләм, цитрусларны да ялгарга өйрәтсәгез иде,— дигән.

Бу кеше — атаклы совет котыпчысы һәм тикшеренүчесе Отто Юльевич Шмидт булып чыга. Бакчачылар академикка ботакларны һәм бөреләрне кисеп күрсәтәләр. Отто Юльевич ул агачка бер ботак ялгый дә аны табигать сөючеләргә истәлек итеп калдыра.

Бу хәл 1940 елның көзендә була. Шулай итеп, О. Ю. Шмидт хәзерге Дуслык агачына беренче ботак ялгый. Аның үрнәге башка бик күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Озак та үтми, табигатьне бөек үзгәртүчеләр — К. А. Тимирязев һәм И. В. Мичурин хөрмәтенә дә бу агачка ботаклар ялгана.

Сугыштан соң селекция бакчасына беренче чит ил кешесе — Югославия профессоры Ружица Гланивич килә. Ботак ялгаганнан соң, атаклы хатын-кыз галим болай ди:

«Үсемлекләр кояшка үрелгән кебек, бөтен дөнья кешеләре дә бер-берләре белән дуслыкка омтылалар. Менә шуңа күрә дә бу агачның үсеп китүе, чәчәк атуы, төрле милләт кешеләренең дуслык җимешләре белән каплануы бер дә очраклы хәл түгел».

Агачның ботаклары ишәйгәннән-ишәя, тамырлары ныгыганнан ныгый бара. Бу агач белән О. Ю. Шмидт шәкертләре дә бертуктаусыз кызыксынып торалар. Котыпчылар академик О. Ю. Шмидтның эшен Төньяк Боз океанында гына түгел, Сочиның Дуслык агачын үстерүдә дә дәвам иттерергә карар бирәләр.

1960 ел. Бакчачылар, шау-гөр килеп, В. Шамонтьев, И. Романов, Н. Корнилов һәм М. Коршунов иптәшләрне каршылый. Төньяк Боз океаныннан, академик йөргән яклардан кайткан бу галимнәр «Кунаклар китабы»на түбәндәге сүзләрне язып калдыралар:

«Без бу ботакны танылган совет котыпчысы һәм тикшеренүчесе О. Ю. Шмидт истәлегенә багышлап ялгыйбыз. Бу гаҗәеп агачка ботак ялгап калдырган халыкларның беркайчан да сугыш кырларында очрашмаячакларына нык ышанабыз».

Шулай итеп, Дуслык агачына котыпчыларның яңа яшел автографлары өстәлә, «Кунаклар китабы»ның икенче бите ачыла.

## «Дуслык күзсез дә күрә!..»

Бер зур ботакның яфраклары һәм җимешләре арасында берничә ак калай кисәге ялтырый. Монда ботакка ботак ялгаганнар. Селекция бакчасы сотрудниклары аны «Америка Кушма Штатларындагы тынычлык сөючеләр ботагы» дип йөртәләр. Аның ялгануына танылган негр җырчысы Поль Робсонның хатыны Эсланда белән бергәләп, Сочига килүе сәбәп. Америка кунаклары Дуслык агачына ул вакытта яңа җимеш — мандаринның әфлисун белән гибридын ялгыйлар.

...1963 елның җәе. Поль Робсон ботагы янында бер кеше басып тора. Ул үзенең гәүдәсе, тән төсе буенча да атаклы җырчыны хәтерләтә. Әмма бу кеше агачны да, аяз күкне дә күрми. Куакны ул бары тик куллары белән генә капшап карый. Ул — Америка Кушма Штатлары Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты члены Генри Уинстон. Терри-Хот төрмәсенең бер кешелек камерасында якты дөньяны күрүдән махрүм ителгән кеше. Уннарча мең кешеләрнең протесты һәм таләбе генә тынычлык өчен куркусыз көрәшчене төрмә газапларыннан азат итте.

— Дуслык күзсез дә күрә! — ди Г. Уинстон. Башта, улы Гай ярдәмендә, Поль Робсон ботагына бөре ялгый, аннары чит илләрдән килгән бик күп кунаклар белән бакчада алты төп яшь үсенте утыртуга катнаша.

Күп тә үтмәс, бу агачлар да шулай зур булып үсәрләр, җимеш бирерләр һәм бергәләп Дуслык бакчасын киңәйтерләр.

# Тылсымлы пәке

Бакчада — укучылар экскурсиясе. Алар субтропик үсемлекләр белән кызыксыналар. Зур яфраклы бананнар, тиз бамбуклар, чәй куаклары бик кызыксындыра аларны. Дуслык агачында күп төрле җимешләрнең үсүен карап балалар хәйран калалар.

— Сезнең, мөгаен, тылсымлы пәкегез бардыр. Шуның белән ботакларны кисеп алып бу агачка күчерәсездер,— диләр алар.

— Бернинди дә тылсым юк, бакчачыларның гади пәкесе ул,— ди институт сотрудницы Людмила Дмитренко. Безнең пәкене бөтен дөньяда беләләр. Ул барлык илләрдә дә бар.

Бу сөйләшү моннан берничә ел элек булган. Ә ул «тылсымлы» пәкенең тарихы мондый. Поль һәм Эсланда Робсоннар ботак ялгагач, пәкене, Дуслык агачы истәлеге итеп, Америкага алып китәргә телиләр. Бакчачылар моңа каршы килми. Шуннан соң башка илләрнең кешеләре дә пәке сорый башлый. Бакчачы инструменты дуслык символына әйләнә. Павлово заводы коллективы Сочи селекционерларына махсус пәкеләр эшли, хәзер ботак ялгаган һәр кешегә аны бирәләр. «Сочи» дип язылган бу пәке ике мәгънәне аңлата: беренчесе — аның иясе ботак ялгау буенча өч минутлык «халыкара мактап»не үтә, икенчесе — Дуслык агачында ул ялгаган ботак үсә.

Узган ел биредә яшел автограф авторларына тагын бер «диплом» бирү гадәткә керде. Сочи шәһәр Советы башкарма Комитеты эшләткән таныклык ул. Беренче битенә җир шары рәсеме һәм Дуслык агачы сурәтләнгән. Агачның ябалдашын ак, сары, кызыл һәм кара төстәге куллар күтәреп тора. Әчке битләренә рус, инглиз, немец һәм француз телләрендә бакчага килеп Дуслык агачында ботак ялгаган кешеләргә «Дуслык бакчачысы» дигән мактаулы исем бирелү турында язылган.

«Тылсымлы пәке» һәм бу таныклык ияләренең берсе, Бразилиянең танылган җәмәгать эшлеклесе һәм халыкара Ленин премиясе лауреаты Элиза Бранко, бу кечкенә сувенирларның әһәмиятен болай бәяли: «Кадерле дуслар, бу кечкенә пәкене бармаклар көч-хәл белән генә тотып торалар. Шулай да ул хезмәттәшлек һәм тынычлыкка омтылуның бик зур көченә ия, анда сугыш уты кабызучыларның танклары юлын кисәрлек көч бар».

# Материклар Сочида күрешә

Август, 1961 ел. Бу көннәрне бөтен дөнья хәтерли. Кариб диңгезендәге кечкенә генә утрау үзенең азатлыгын һәм бәйсезлеген яклап империалистларга каршы көрәшә. Авыр, бик авыр бу утрауга. Бөтен халкы кулына корал ала. Африка континентында да шундый ук хәл. Конго халкы, күп югалтуларга дучар хәлдә, бәйсезлек яулый.

Шушы канлы көннәрне истә калдырып, Куба революциясе геройларыннан берсе — Хуан Альмейдо болай дип яза:

«Мин Конго халкының бөек лидеры, империализм корбаны Патрис Лумумба истәлегенә Дуслык агачына ботак ялгыйм... Ватан яки үлем. Без барыбер җиңәчәкбез!»

Яңа яшь сабак Куба халкының африкалыларга анты һәм җавап сәламе булып үсә.

Әйе, Сочида Америка белән Африка, Австралия белән Европа, Азия белән Америка материклары очраша. Дуслык агачы җимешләрен төрле континентларның меңнәрчә кешеләре үстерәләр. Яфраклар белән язылган поэманың Уругвай парламенты депутаты Луис Педро Бановита калдырган өлешен укыгач, бу фикер тагын да көчәя: «Бик борынгы заманнардан ук агач кешегә эчке хисләрен аңлату өчен хезмәт иткән. Мәсәлән, зәйтүн агачы — тынычлык, мәңге яшел яфраклы, хуш исле лавр — дан билгесе. Чәнечкеле күгән агачы исә кырыслык һәм җәза гәүдәләнеше булган. Ә Сочидагы селекция бакчасында Дуслык агачы иң солидар җәмгыятьнең символы төсендә үсә».



*Эфиопиянең депутатлар палатасы председателе Фитаурази Бекса Джалло «Кунаклар китабы»на яза.*

## Дуслык симфониясе

Күренекле дирижер, музыкантларның Чайковский исемендәге беренче халыкара конкурсы лауреаты Ван Клиберн да, озак сәяхәттән һәм дөньяның бик күп илләрендә җаваплы чыгышлардан соң, Сочига килә. Селекционер, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Федор Михайлович Зорин, теплицадан чүлмәккә утыртылган кечкенә генә эфлисун агачы алып чыга да, музыкантка:

— Моны Мәскәүдән минем иң кадерле кешем — туган әнием җибәрде,— ди.— Озакламый аңа туксан яшь тула. Моны ул — Дуслык агачында өлгергән җимеш орлыгыннан үстерде. Мин аны моннан ике ел элек әнинең туган көненә бүләк итеп җибәргән идем. Хәзер әнием, бакчага ботак ялгарга килүчеләргә дип, үзенең үтенечен җиткерүемне сорый.

— Гомерем буена моннан да куанычлырак тәкъдимне әйтүче кеше әле булмады,— ди Ван Клиберн, елмаеп.

Шул чакта төшереп алынган рәсемнәрдән Ван Клибернның эшкә бик зур җитдилек белән керешүе һәм ботакны чиксез саклык белән ялгавы күренеп тора. Бакчачылар белән аерылышканда ул: «Бу ботакта мин сезгә дуслыгымны һәм мәхәббәт хисләремне калдырам»,— ди. Соңыннан ул Дуслык агачында үскән җимеш орлыкларын сорап ала.

Дирижер ялгаган үсенте хәзер зур ботак инде. 1963 елда бу ботак агачтагы иң күп тармаклы ботакларның берсенә әверелә. Сочига «Литва» теплоходы белән бер юлы 69 илнең вәкилләре — журналистларның өченче бөтендөнья очрашуында катнашучылар — килә. Барысы да ботак ялгауны шул көнне нәкъ 24 яшь тулган Аргентина журналисты Эдуардо Хосимага тапшыралар.

В. Клиберн ботагындагы яңа үсентене журналистлар тынычлыкка һәм халыклар арасында дуслыкка багышлыйлар.



Медицина докторы Огуро Сентаро (Япония) дуслык агачы янында.

## Японнар ботагы

Кара диңгез буенда яз. Агач бөреләреннән яшь яфраклар калкып чыга, бакчалар яшел диңгез сыман булып дулкынлана башлый. Шундый ямьле көннәрнең берсендә бирегә Көнчыгыштан килгән кунаклар, дуслык агачы тармакларын күреп, таңга калалар.

«Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр дә, табигатьнең шушы агачтагы җимешләре кебек, хаким сыйныфларсыз, дошманлыксыз һәм эчкерсез генә үссен иде»,— дигән изге теләк белән алар кулы белән беренче ботак ялгана. Яшел автограф авторларының берсе — Япония социалистлар партиясе генеральный секретаре Томоми Нарита, икенчесе — Японияләнең СССРдагы илчесе Хисанари Ямада. Японнар ботак ялгау белән генә чикләнмиләр. Аның үсешен күзәтәләр, уңышын җыярга да киләләр.

Дуслык агачы куркү белмәс разведчик, Советлар Союзы герое Рихард Зоргеның якын дусты Исии Ханако игътибарыннан да читтә калмый. 1965 елның маенда ул шушы бакчага килү бәхетенә ирешә. Агачтагы һәр ботакны, аларга эленгән ак калайларны җентекләп карый. Аннары «Кунаклар китабы»на болай дип яза: «Рихард Зорге тынычлык өчен көрәште. Шуңа күрә мин ботакны Зорге исеме белән ялгыйм. Халыклар аны мәңге онытмасыннар!»

## Космос батырларына

Чәчәккә һәм ямьгә мул көннәрнең берсендә бакчага космонавт Герман Титов килә. Институт сотрудниклары галәм батырын хөрмәтләп каршы алалар. Герман Степанович агачны һәм аның ботакларындагы этикетларны кызыксынып укый. Кинәт бер тармак янына тукталып кала. Үз күзләренә ышанмыйча, агачка якынрак килә. Анда, чыннан да, «Г. С. Титов хөрмәтенә» дип язылган икән бит!

— Сез «Восток — 2» корабле белән галәм гизгәндә ялганды ул ботак,— дип аңлата аңа Людмила Дмитренко.— Ул чакта безгә кунакка Кореядан Хезмәт Герое Тен Сен Хи килгән иде. Ул үз ботагын, тынычлык сөюче барлык аналар исеменнән, сезнең тиңдәшсез батырлыгыгызга багышлады...

Герман Степанович Тен Сен Хи ботагы янында тагын бер үсентенең үсуен тели һәм аңа яңа ботак ялгый.

...1964 ел көзенең соңгы көннәре үтеп бара. Инде розалар, хризантемалар чәчәкләрен койганнар. Шул чакны Сочига космонавт Павел Попович килеп чыга. Дуслык агачы янында бакчачылар аңа да пәке тоттыралар.

— Миңа ботак ялгау — таныш эш. Мин бит авылда үстем,— дип шаярта Павел Романович.

— Сез моны бик оста һәм яхшы итеп ялгарга тиешсез. Югыйсә, башка планеталарда алмалар үсмәс,— диләр аңа бакчачылар, елмаеп.

Икенче көнне бакчага Юрий Гагарин, Андриян Николаев, Валентина Терешкова-Николаева, «Восход» корабленең командиры Владимир Комаровлар да килә. Агачка тагын ботаклар ялгана. Институт сотрудниклары галәм батырларын аңарда үскән җимешләр белән сыйлыйлар.

## Аның исеме—Муса

Мин Кара диңгез буенда ял итә идем. Шулай бер көнне Сочидагы коллегам Александр Романович Арустаменко мине Бөтенсоюз фәнни-тикшерену институты бакчасын карарга чакырды.

Без таш баскычлар буйлап югары күтәреләбез. Тирә-яктагы гүзәллеккә хәйран каласың. Әнә зәп-зәңгәр сулы Кара диңгез, Сочи портының, санаторийларның берсеннән-берсе күркәм корпуслары. Һәр төштә чәчәкләр, субтропик үсемлекләр. Ә безнең легендар агач — Дуслык агачын тизрәк күрәсебез килә...

Ниһаять, менә ул меңнәр кулы белән иҗат ителгән ямь-яшел һәм мәһабәт елъязма! Ул, ничектер, шәфкатьле елмаеп, яшел кулларын сузып, һәр кешене үз кочагына алырга әзер торадыр кебек. Бик тә ишле аның семьясы: Лев Толстой, Сергей Есенин, Николай Островский, Манолис Глезос, Җавахарлал Неру, Хо Ши Мин, Вальтер Ульбрихт, Рейхстаг геройлары, Константин Циалковский, Чарльз Дарвин, Михаил Лермонтов, Петр Чайковский, Михаил Ломоносов, илебезнең фронт һәм хезмәт батырлары, дөньяның күренекле җәмәгать һәм фән эшлеклеләре...

Хәтта тиз генә санап чыгарга да мөмкин түгел. Шуларның барысын да күрә торгач, миндә кинәт Дуслык агачына Муса Җәлил хөрмәтенә бер ботак ялгау фикере туды. Институт дирекциясеннән моңа рөхсәт алгач, иркенләп сулап куйдым. Ләкин иртәрәк булып чыкты. Агачны үстерүче гыйльми сотрудник Людмила Дмитренко Краснодарда командировкада икән. Ә минем китәр чак җитә. Тиз генә телефонга чабам. Йөрүләрем бушка булмады. Дмитренко иртәгесен Сочига кайтып җиткән иде инде!

Менә минем кулымда да бакчачылар пәкесе. Питомниктан бик саклык белән бөре кисеп алам. Бөре һәм ялганачак ботак сайлауда миңа Дмитренко булыша. Лев Толстой һәм Сергей Есенин үсентеләре арасыннан бер ботак сайлап алабыз. Ә агачта исә Совет-Германия дуслыгына егерме ел тулу хөрмәтенә ялганган ботак үсә. Муса урыны нәкъ менә шуның янәшәсендә булырга тиеш!

Чиксез тантаналы һәм дулкынландыргыч, җаваплы минут. Фәнни сотрудниклар бөренең төгәл куелуын күзәтәләр. Ә минем кулларым калтырый. Юк, кабаланмыйча, бик зур саклык белән эш итәргә кирәк! Менә кадерле һәм затлы бөре, ниһаять, дәү агач ботагына ябышты да. Хәзер аны лента белән урыйсы гына калды...

Шулай итеп Дуслык агачына тагын бер яңа бөре ялганды. Аның туган көне — 1968 елның 20 июне, иртәнге сәгать 7. Исеме — Муса.

Аның тууы «Кунаклар китабы»нда ничәмә-ничә телдә, күпме куллар язган сүзләр арасына татарча итеп шундый җөмләләр белән теркәлде: «Патриот шагыйрь Муса Җәлил үзенең шигырьләрендә халыклар дуслыгы һәм бәхете, тынычлык һәм хезмәт турында җырлады. Ул үз Ватанын чиксез ярата иде. Бу ботак аның үлмәс исеме белән аталсын, һәм шагыйрьнең җырлары кебек, барлык милләт халыкларын дуслыкка, тынычлыкка өндәп торсын! Ул җир шарындагы тынычлык сөюче барлык халыкларның дуслык символы булып чәчәк атсын, татлы җимешләр бирсен!»

Татарстан журналистлары һәм язучылары исеменнән, бөтен халык исеменнән әйтелгән сүз иде бу.

# Хатлар сөйли

Дуслык агачы — тулы мәгънәсендә тынычлык символы ул. Аның янында көн саен тынычлык, дуслык, хезмәттәшлек турында сүз бара. Кешеләр, төрле телләрдә сөйләшсәләр дә, бер-берләрен яхшы аңлыйлар. Чөнки тынычлык һәм дуслык теле — интернациональ тел.

Ә бирегә көн саен күпме хат һәм посылка килә! Адресы бик гади: «Сочи, Дуслык агачына». Нинди телдә язылган булсалар да, аларны аңлатып тору кирәкми, кыска-кыска юлларның һәркайсы тирән мәгънәле.

*«Мин бөтен дөнья халыкларының да шушы агач ботаклары кебек дус һәм тату яшәүләрен телим.*

*ТОРАРИНСОН, ИСЛАНДИЯ».*

*«Бу агач тынычлыкка, дуслыкка, бәхеткә һәм чәчәк атуга ирешүдә халыклар бер-берләренә ярдәм итешеп яшәсеннәр дип өндәр өчен табигать тарафыннан кешелек дөньясына җибәрелгән бер илче.*

*КЕВАЛУ СИНГ, ҺИНДСТАН».*

*«Моңа кадәр бакчачылык дуслыкка хезмәт итә дип һич уйламаган идем. Кара әле, нинди уңышлы!*

*ВАШИРЕСЕ, ФРАНЦИЯ».*

*«Сезнең Дуслык агачы искиткеч матур бер идея! Ул дөнья халыкларын берләштерә. Кеше табигатенә дә җир анабызга ышанган кебек ышансак, нинди шәп булыр иде, ә!*

*РОБЕРТСОН, АНГЛИЯ».*

Дуслык агачы музеенда бик зур хисләр уята торган бер тартма да саклана. Аны Сергей Есенинның якташлары җибәргәннәр. Тышына түбәндәге сүзләр язылган:

*«Дуслык агачына килүчеләргә.*
*Дуслар! Иптәшләр!*
*Бу тартманы ачыгыз. Анда бер уч туфрак. Ул Россия улы һәм җырчысы Сергей Есенин туган җирдән алынды.*
*Ока елгасы буйларының бу туфрагына яр буе уләннәре кыштырдавы, таллар һәм каеннар шаулавы, болыннарның хуш исе, торналар тавышы сеңгән дип белегез.*
*Бу туфрактан саркып чыккан су «кызыл миләшләр учагы»н кабызды, бу туфракта алтын аланнар «Язгы каен теле белән» сөйләштеләр.*
*Кавказ туфрагы, таулар!*
*Сезне Есенин яраткан! Ул сезгә серләрен сөйләгән!..»*

Хәзерге гүзәл Кавказда ботакларын киң җәеп, бөтен дөньяга танылып үсүчә Дуслык агачына Есенин каеннары шавы шулай кушыла.

Дуслык! Бер караганда гади генә булып күренгән бу дулкынландыргыч һәм мәгънәле сүздән башка тынычлык һәм бәхетле кешеләрнең якты киләчәген күз алдына китерергә һич мөмкин түгел. Сочидагы мәңге яшел гаҗәеп бу агач — дөнья халыкларының дуслыкка, тынычлыкка омтылышын күрсәтүче иң ачык дәлил. Бу турыда швед язучысы Карл Энглунд бигрәк тә образлы итеп әйткән: «Дуслык өчен, генералларның тарихта гына калу көне өчен, кылычларны Дуслык агачлары үстергәндә кирәкле пәкеләр итеп кояр вакытлар өчен!»

Кылычларны тыныч хезмәтнең эш коралы итеп коярга! Бу фикер — «Кунаклар китабы»ндагы бик күп язмаларның төп темасы. Аларда, бер тамчы суда зур кояш үзе чагылгандай, безнең илебезнең тынычлык өчен, халыклар бәхете һәм азатлыгы өчен көрәшүе бик ачык булып тагын бер кабат күренә.

**МӘГЪСУМ ГӘРӘЕВ.**

# ҖЫЛЫЛЫК ХИСЕ

Шамахә тышлы бу бәләкәй җыентыкны[1] кызыксыну катыш гаҗәпләнү белән, сәерсенеп һәм шикләнебрәк кулга алган идем...

Гаҗәпләнерлек тә: Лирон Хәмидуллинның моңарчы матбугатта бөтенләй күренгәне дә юк иде диярлек. Ә ул әнә, тоткан да, уйламаганда-көтмәгәндә, тулы бер җыентык хикәяләр бастырып чыгарган. Шыпырт кына язып яткан икән.

Аннан соң, шушы хикәяләр китабы кулга килеп күргәч, күңел түрендә һәртөрле шик-шөбһәләр кузгалган икән — бусы да тикмәгә түгел. Дөресен әйтергә кирәк, әдәбият мәйданына яшь язучылар өзлексез рәвештә килеп һәм аларның китаплары бер-бер артлы чыгып торса да, поэзиядән кала башка жанрларга үз йөзе, үз стиле булган талантлар чагыштырмача сирәгрәк һәм азрак килә. Килгәннәре дә озаклап, бик көттереп һәм зарыктырып өлгерә. Иҗат юлларын шактый өметле башлап та бер урында таптанып торганнары никадәр, үзләренә өмет һәм ышаныч баглатып та, шуны аклый алмаганнары күпме... Кыскасы, кызыксыну катыш гаҗәпләнергә дә, шигәеп калырга һәм сәерсенергә дә сәбәпләр җитәрлек монда.

Бәхеткә каршы, әлеге шамахә тышлы китап, андагы әсәрләр белән танышып чыккач, мин күңел төбендә туган шик-шөбһәләрнең, һәртөрле сәерсенуләрнең бу очракта шактый урынсыз һәм нигезсез булуын аңладым. Җыентыкта урын алган алты хикәянең һәммәсе дә саф алтын түгел, билгеле. Арада таркаураклары, бөтен бер әсәр булып оешып җитмәгәннәре дә бар. Зур таләпләр югарылыгыннан, сизгер художник позициясеннән торып хөкем итканде, башка төрлерәк кимчелекләр дә очратырга мөмкиндер. Әмма ни генә булмасын, җыентыктагы алты хикәянең кимендә өчесе нигездә уңышлы, күңелдә җылы тәэсир калдырырлык. Һәрхәлдә, тәүге китабын чыгарган башлап язучы өчен һич кенә дә кызарырлык түгел.

Сүзне «Буранда» исемле хикәядән башлыйсы килә. Бер караганда, әллә ни искитәрлек җире дә юк кебек ул хикәянең. Каядыр еракта, көчле җилләр, каты бураннар котырган таулар арасында Тека Яр исемле тимер юл разъезды урнашкан. Әлеге бәләкәй генә разъездда бер төркем юл караучылар яши икән. Әсәр шул кешеләр, аларның борчу һәм мәшәкать белән тулы тынгысыз тормышы турында.

... Олы калаларда яшәүчеләр вакытында рәхәтләнеп ял итә, кино-театрларга йөриләрдер. Тека Яр кешеләренә генә элакми андый бәхет. Әнә бит, бер генә яйны тынычлап өйдә уздырабыз, ахры, дип өметләнеп торганда, барак-казарманы ярып телефон шалтырый: Хәлил кичүе дип йөртелгән урында рельс шартлаган, тиз генә барып шуны төзәтергә кирәк икән. Күз ачкысыз буранда яшь бригадир Байрәм 5—6 кешелек бригадасын, үзләренең җылы өйләреннән — кемне чәй, кемне аш янынннан — кузгатып, әллә кайдагы Хәлил кичүенә алып китә. Җәфалана-азаплана булса да барып җитәләр, вакытында юлны төзәтеп исән-сау әйләнеп кайталар. Хикәядә телгә алып сөйләрлек бөтен вакыйга әнә шул. Әммә мәсьәлә әсәрдәге вакыйганың зур яки кечкенә, кызыклы яки кызыксыз булуында гына түгел. Хикмәт башка нәрсәләрдә икән әле...

Шушы кечкенә генә хикәядә юл караучылар тормышын гаҗәеп җанлы, чынбарлыктагыча итеп күз алдына бастырырдай әллә никадәр әдәби деталь бар. Алар

[1] Лирон Хәмидуллин. Юлда. Хикәяләр. Казан. 1968 ел.

авторның күзәтүчәнлеге, сәләте хакында сөйлиләр.

Шушы ярты гына табаклык хикәядә бер-ике генә штрих белән ясалган һәм хәтердә калырдай җанлы кешеләр күпме! Әнә бу ялда да өй эшләрен эшләргә җай чыкмаганга җене кузгалган Шәмсегаләм: «... Ай буе җыелып килгән керемне уарга тотынган идем. Кая! Безне рәзе тик тоталар!» дип зарланып бара. Аның ире обходчик Хисмәткә күз салыгыз. Башка вакытларда «кулына кызыл флаг тотып, авыз күтәреп юк-барны сөйләп йөрүдән узмаган агач актив» Хисмәт бүген бөтенләй икенче кешегә әйләнгән. Кирәк чакта тапкыр да, эшчән дә була ала икән ич. Әнә таш бәгырьле, кырыс Кәрам, әнә карчыгы Агафьяның урын җәеп бирүен түземсезлек белән көтеп утырган карт мастер Иван Иванович. Шул кырыс холыклы, эшчән кешеләргә бүген тагы, әнисе өчен, үзенең каникул көннәрендә әнисенә ял бирер өчен генә, яшь җилбәзәк Дилүсә иярган. Башы тулы иләсмиләс уйлар үзенең.

Рельс өстеннән таеп төшмәс өчен, кулларын ян-якка сузган хәлдә эзгә-эз басып килгән кызны яшь бригадир Бәйрәм күреп ала. Һәм артыннан куып җитәр-җитмәстән, **үзенә дә ят булып чыккан** тавыш белән:

— Чү, егыла күрмә,— дип, кызның кулыннан килеп тота. Юеш бияләйләре аша аның кайнар кул җылысын тойгандай була һәм ихтыярсыздан йөзенә күтәрелеп карый.

Кәрамның үзе кебек үк таза, төптән йомыры кызына кара син! Йөзе аның ай кебек якты, йолдыздай нурлы икән ләбаса! Бер дә әтисе йөзе түгел. Әнисе юашлыгы да юк анда. Үзенә үзгә дөнья икән ләбаса. Таш бәгырьле Кәрам токымында да шундый хәлләр булыр дип кем уйлаган? Ничек моңарчы бер дә күрмәде икән аны Бәйрәм? Хәйран хәл!..

Дөрес, эш үбешүләргә, антлар бирешүгә кадәр барып җитми, мәхәббәт дигән сүз хәтта телгә дә алынмый кебек. Әмма Дилүсә һәм Бәйрәм күңелендә уянган мәхәббәт хисе гаять табигый, тормышчан һәм матур итеп бирелгән.

Ниһаять, шуларның барысы: гаҗәп уңышлы тотылган тормышчан детальләр, бер-ике штрих белән хәтердә калырлык итеп эшләнгән персонажлар, романтик табигатьле Дилүсә белән басынкы холыклы бригадир егет Бәйрәм арасында кузгалган саф мәхәббәт хисләре естенә, авторның әсәрдә сурәтләнгән кешеләргә һәм тормыш материалына үз мөнәсәбәте, якын килә белүе бар әле. Хикәядә тагын сөйләп, аңлатып булмый торган, әмма укучыны иләсләндерә, аның күңелен нечкәртә һәм сафландыра торган үзгә бер моң, **настроение**, әчке бер көй бар. Шәриф Камал новеллаларыннан, Мин Шабай хикәяләреннән килә торган сыйфатмы ул? Әйтүе кыен. Бәлки, шулайдыр да. Әмма ул бар, бар гына да түгел, Л. Хәмидуллин хикәяләренең төп үзенчәлеген билгели. Һәм шул үзенчәлек аның хикәяләрен, ничектер, бөтенәйтә, аларга аерым бер аһәң һәм яңгыраш бирә.

Әле генә сөйләп узган бу сыйфатларның күбесе Лирон Хәмидуллинның башка хикәяләре өчен дә хас. Бу яктан минем үземә «Юл караучылар» һәм «Кыш үткән юл буйлап» дип исемләнгәннәре аеруча нык ошады.

«Буранда» исемле беренче хикәя кебек үк, «Юл караучылар» да тимер юл эшчеләре тормышына багышланган. Һәм беренче хикәядәге кебек үк, монда да авыз тутырып сөйләрлек әллә ни кызыклы вакыйга да юк.

Әсәрнең никадәр тегәл һәм бөтен эшләнүенә, шулай ук башка якларына җентекләп тукталып тормастан, андагы төп персонажлардан Һарун абзый белән Оркыя турында, дөресрәге, аларның үзара мөнәсәбәтләре, никадәр гадел һәм саф күңелле булулары хакында гына берничә сүз әйтәсе килә. Очрашып сөйләшә башлагач, сүз ияре сүз чыгып, Оркыя ире Таҗидан зарланырга тотына:

«... Әнә, минем Таҗи чирне сатып алып, тоташ авырып йөри. Сугышудан башканы белми дә... Их, абзый. Синең йөрәккә аның буе булса...

— Шулайдыр. Фагыйлә җиңги улын иркәләде шул. Сүз тидермәде. Бердәнберем диген булды. Әйткәнне колагына алмады.

— Шулай, бакчи. Шулай. Әнкәй әле дә аның яклы...

— Болтларны майларга соңлагансың,— дип, Һарун сүзне икенчегә борды.

— Пружинлы шайбалар булмады. Мастерыбыз Карп Ильич...

— Тагын өлгермәгәнме?.. Башкалар алып бетергән, ул йоклап калганмы?

Оркыяның карт мастер алдында хәзергесен оятка калдырасы килмәде. Яклаган итте.

— Юк. Булмый торды...» (29 бит).

Сизгәнсездер: гайбәт чәйнәүдән, вак җанлылыктан никадәр өстен алар. Автор шундый кешеләрне күрә һәм күрсәтә алган. Хикәянең төп уңышы, минемчә, әнә шуның белән аңлатыла да.

Бүгенге мул, рәхәт тормыш җиңел генә килмәгән. Без муллыкта яшәсен өчен, кемнәрдер тир түккән, иза чиккән. Без тынычта яшәсен өчен, кемнәрдер гомерләрен биргән. Безнең өчен тир түккәннәрне, безнең өчен гомерләрен биргәннәрне онытмаска тиешбез. Үзенең «Кыш үткән юл буйлап» исемле хикәясе, ул хикәядәге гаҗәп сөйкемле һәм мөлаем Бәдүк образы белән автор нәкъ шул хакта сөйли, нәкъ шул идеяне уздыра. Эчке моңы, укучы күңелен пакьландыра торган көче ягыннан бу хикәя, мөгаен, җыентыктагы әсәрләрнең иң характерлысы, иң көчлеседер.

Аерым уңышлы персонажлар, истә калырлык эпизодлар һәм тормышчан детальләр «Митәйнең язмышы», «Яшь тирәк», «Урак өстендә» исемле хикәяләрдә дә байтак. Әмма, тулаем алганда, алар без сүз алып барган баштагы хикәяләрдән таркаурак, кайтышрак һәм төссезрәк чыкканнар кебек тоелды миңа.

Сүзне түгәрәкли төшеп, шуны гына әйтәсе килә.

Беренче җыентыгы белән Лирон Хәмидуллин үзен шактый үзенчәлекле прозаик итеп таныта һәм үзенә өмет баглата алды. Бу беренче хикәяләренә хас уңай сыйфатларын киләчәктә дә җуймасын иде. Аларны тагын да баета һәм камилләштерә төшсен, бүгенге тормыш мәсьәләләренә кыюрак алынсын, иҗат активлыгын көчәйтә төшсен иде.

**Ф. МИННУЛЛИН.**

# БЕЛМӘМЕШ ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘ

Ямьле инеш буена әйтеп бетергесез матур бер шәһәр урнашкан. Шәһәрнең бөтен өйләре аллы-гөлле чәчәкләргә күмелеп утыра. Шуңа күрә аның үзен дә Чәчкәле шәһәре дип йөртәләр икән.

Әлеге ямьле инешнең аргы ягыннан ук зур урман башланып китә. Шәһәр халкы шул урманга гөмбә, чикләвек җыярга йөри. Тик шунысы бар: гөмбә, чикләвек җыю Чәчкәле халкы өчен бик авыр һәм кыен эш икән. Гөмбәне алар башта пычкы белән төбеннән кисеп аударалар, аннары тураклыйлар, шуннан соң гына, кисәкләп күтәреп, өйләренә ташыйлар. Чикләвекне дә безнең кебек куакларны бөгеп кенә җыя алмыйлар, ботакларга үрмәләп менеп, пычкы белән кисеп азапланалар. Ни өчен дисәң, бик-бик бәләкәй кешеләр, икенче төрле әйткәндә, нәнүсләр яши бу шәһәрдә.

Шәһәрдәге урамнарның берсе Кыңгырау чәчәк урамы дип йөртелә. Әнә шул урамдагы йортларның берсендә уналты нәнүс яши. Барысы да малайлар. Араларыннан Беләмән исемле берсе — башлыклары. Тикмәгә генә алай дип йөртмиләр: бер генә дә белмәгән нәрсәсе юк үзенең. Малайларны һәртөрле чирдән дәвалаучы Ачыташ исемле врач та, һөнәрмән белән Көйләрмән дигән механиклар да, Рәсемҗан исемле художник та яши бу йортта. Әмма арада иң атаклысы — Белмәмеш. Уңганлыгы, акыллылыгы белән түгел, билгеле. Җилкуар, надан булуы белән танылa. Хәер, соңыннан яхшыра ул...

Шулай бервакыт Кыңгырау чәчәк урамы малайлары, һава шарына утырып, сәяхәткә чыгып китәләр. Очалар, очалар болар, оча торгач, кызлар гына яши торган бик матур бер шәһәргә килеп төшәләр. Анда берникадәр яшәп, төрле кызыклар күреп, кунак булгач, туган илләренә әйләнеп кайталар.

... Белмәмеш өч игелекле эш эшли. Шуның өчен бер узгынчы бабай аңа тылсымлы таяк бүләк итә. Ул таякның кодрәте чиксез икән: ни кушасың, шуны үти, ни телисең, күз ачып йомганчы алдыңа китерә дә куя. Белмәмеш әлеге серле таяк кодрәте белән барлыкка килгән машинага үзе белән Чуаркай исемле малайны һәм Төймәкәй исемле кызны да алып кабат сәяхәткә чыгып китә. Күп җәфалардан соң, алар Кояшлы шәһәренә барып керәләр. Ул чын-чынлап могҗизалар шәһәре икән. Урамнары киң, иркен, йортлары шундый матурлар, биекләр. Һәр җирдә — чисталык, яшеллек. Шәһәрдә фән-техника иң югары дәрәҗәгә ирешкән: бөтен эшләрне автоматлар башкара. Монда үзе йөри торган таксилар, кешесез эшли торган тузан суырткычлар, шахматчы машиналар, юындыру аппаратлары, ерактан торып идарә ителә, радиомагнит энергиясе белән эшли һәм берьюлы ура, суга, чәчә торган комбайннар һәм тагын башка хикмәтле машиналар күрергә мөмкин. Шәһәр коне-төне яктылык нурларына коена. Шуңа күрә дә аны Кояшлы шәһәре дип атаганнар.

Кояшлыда күп тамашалар күреп, Белмәмешләр яңадан туган шәһәрләренә әйләнеп кайталар. Ләкин Белмәмеш маҗаралары моның белән генә бетми әле. Аны алда тагын да искиткечрәк сәяхәтләр, бик күп кызык хәлләр көтә... Боларның бөтенесен дә белү өчен, күренекле рус язучысы Николай Носовның «Белмәмеш маҗаралары», «Белмәмешнең Кояшлыга сәяхәте» һәм «Белмәмешнең Айга сәяхәте» дигән китапларын укырга кирәк. Аларның икесе татар теленә тәрҗемә ителеп басылып чыкты инде. Өченчесе — «Белмәмешнең Айга сәяхәте» типографиядә. Тиздән ул да дөньяга чыгар.

Бу китапларның тәрҗемәләре балаларны оригиналы кебек үк дулкынландыра, мавыктыра алырмы? Татарча китапларның телләре русчаларыныкы кебек үк матур, җанлы һәм образлымы? Бу мәкаләнең максаты — әнә шул сорауларга җавап биреп китү.

«Белмәмеш» трилогиясе — әкият жанрында язылган әсәр, һәм бу аның телендә дә чагылыш тапкан. Татар халык әкиятләре кебек үк, рус әкиятләре дә, гадәттә, үзләренә бер төрле интонация, көй белән сөйләнә һәм укылалар. Бу исә сүзләрнең, сүз тезмәләренең сөйләмдә билгеле бер тәртип белән урнашуы, эзлекле рәвештә кабатланып баруы, ягъни сөйләмнең үзенә күрә бер төрле оешуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Без сүз алып бара торган әсәрләрне тәрҗемә иткән кеше алдында торган таләпләрнең берсе — менә шул үзенчәлекне саклау. Әйтергә кирәк, тәрҗемәче бу таләпне истән чыгармаган: китапларда әкият стиле нигездә сакланган. Мисал өчен кечкенә генә бер өзекне карап китик.

«Бер көн көтә аны Очыргычлар шәһәре нәнүсләре, ике көн көтә. Шуннан инде имеш-мимешләр китә. Берәүләр әйтә, имештер, юл өстендә убырлы карчык тыра икән, юлда күренгән бер малайны авызына тутыра икән, ди. Икенчеләре, нинди убырлы булсын, Кощей ич ул, ди. Өченчеләре, Кощей түгел, өч башлы аждаһа икән, Яшел шәһәрнең үзендә үк яши, көн саен бер кызны ашый, ә инде шәһәрдә малайлар күренсә, аларны да тотып ашый икән, ди»[1].

---

[1] Н. Носов. Белмәмеш маҗаралары. Казан, 1967 ел. 190 бит. Алга таба трилогиянең томнары һәм битләре генә күрсәтелер.

«Белмәмеш» трилогиясе — мәктәп балаларына адресланган әсәр. Шул сәбәпле оригиналның теле гади, җанлы, үзенчәлекле, кыскасы, балалар теле. Оригиналның бу үзенчәлеге тәрҗемәдә дә сакланган. Белмәмеш, Көйләрмән, һөнәрмәннәр, реаль чынбарлыктагы Фәритләр, Илдуслар кебек үк, үзләренә бер төрле җанлы, дорфарак, тапкыр телдә сөйләшәләр:

«Бер минут эчендә сәяхәтчеләр, автомобильгә утырып, юлларын дәвам иттерделәр. Пароход исенә төшкән саен Белмәмеш таңга кала:

— Менә, ичмасам, пароход! Тау чаклы шундый нәрсәнең судан йөзеп баруына үлсәм дә ышанмас идем,— ди.

Төймәкәй дә гаҗәпләнә. Чуаркай гына башта гаҗәпләнергә уйлаган иде дә, бернигә исе китмәскә тиешлеге хәтеренә төшкәч.

— Пароход, имеш, инде! Нәрсәсе бар соң аның? Көймә ни, бу ни,— дигән булды.

— Тагарак ни, бу ни, диярсең тагын син! — дип куйды Белмәмеш.

— Нишләп алай булсын? Тагарак булса — мин аңа тагарак дияр идем, көймә димәс идем.

— Карале, Чуаркай, син минем каныма тоз салма! Руль тоткан нәнүснең канына тоз салырга ярамый, авария була.

— Син руль тоткан дип, нәрсә, ялган сөйләргә дигәнмени миңа?» (II—39.)

Әсәрдә диалоглар, ягъни геройларның кара-каршы сөйләшүләре зур урын алып тора. Диалогларда теге яки бу телнең специфик үзенчәлекләре аеруча нык сизелә торган була, һәм бу очракта сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү бигрәк тә ярамый. Бу — без сүз алып бара торган китапларда тәрҗемәче рус телендәге диалогларны татар теленә гомумкулланышта йөргән сүзләр белән генә биреп калмаган, бәлки оригиналның җөмләсе яки аннан да зуррак берәмлеге белдергән мәгънәләрне бирерлек тел формалары эзләп тапкан. Икенче төрле әйткәндә, тәрҗемәче оригинал әсәрдәге тел чараларына функциональ-стилистик яктан, ягъни башкарган вазифалары һәм кулланылу шартлары буенча туры килерлек чаралар тапкан.

Сурәтләү чараларын, образлылык элементларын оригиналдагы дәрәҗәдә гәүдәләндергәндә генә тәрҗемә тулы кыйммәтле була ала.

Тагын шуны әйтеп китәргә кирәк: бер телдәге сурәтләү чараларын икенче телдә бирү аеруча кыен һәм авыр мәсьәләләрнең

берсе. Образлылык чаралары — телнең специфик үзенчәлеген тәшкил итүче элементлар. Һәм шуңа күрә дә аларны еш кына бер телдән икенче телгә турыдан-туры тәржемә итеп тә булмый. Шуннан чыгып, тәржемәчеләр кайчак, андый чараларны, ягъни образлылык элементларын, тәржемә итәргә омтылыш та ясап тормыйча, туган тел сүзлек составыннан теге яки бу образлы элементка тиң килердәй чаралар эзли башлыйлар яки, аларның образлылыгын югалтып, логик мәгънәсен бирү белән генә чикләнү юлына басалар. Нәтиҗәдә тәржемә ителерлек нәрсәләр дә тәржемә ителми кала. «Белмәмеш трилогиясе»нең тәржемәчесе мондый юл белән бармаган. Ул ике телдә дә уртак җирлеге булган һәм татар укучыларына җиңел аңлашыла торган сурәтләү чараларын сүзгә-сүз диярлек тәржемә иткән: «дрожал как осиновый лист» — «усак яфрагыдай калтырарга тотынды»; «образовалась пробка» — «бөке хасил булды» һ. б. Күрәсез, бу очракта сурәтләү чараларын турыдан-туры тәржемә итү мәгънәгә дә, әсәрнең образлылыгына да зыян китермәгән.

Ләкин сурәтләү чараларын турыдан-туры тәржемә итү һәрвакытта да уңышка китерми. Мәсәлән, рус телендәге «что верно, то верно» дигән әйтемне сүзгә-сүз тәржемә итсәң, ниндидер мәгънәсезлек килеп чыгар иде. Тәржемәче аны мәгънәсе һәм образлылыгы буенча тиң торырдай татарча әйтем белән алыштыра: «хак сүзгә җавап юк». Шул ук юл белән «раздавить в лепешку» «измәбезне изәргә» әйләнгән. Яки менә русларның «голубчик», «голубушка» кебек эндәш сүзләрен алып карыйк. Әгәр без аны, русча-татарча сүзлектә бирелгәнчә, «күгәрченкәем», «күгәрченем» яки «күгәрченкәй» дип тәржемә итсәк, ул безнең тел өчен сәер, ят булыр иде. Чөнки татарлар бер-берсенә «акыллым», «кадерлем», «алтыным», «алмам», «хөрмәм», «былбылым» дип дәшергә яраталар. Тәржемәче, урынына карап, аны «алтыным», «туганкай» һ. б. дип биргән.

Әмма сурәтләү чараларын бирү мәсьәләсендә тәржемәче алдында җиңел булмастай киртәләр дә очрый. Кайчак татар телендә оригиналдагы теге яки бу сурәтләү чарасына тиң килердәй чара табарга бөтенләй мөмкин булмый. Бу — телләрнең лексик-фразеологик байлыкларының төрлечә булуына бәйләнгән объектив күренеш. Ләкин, моннан чыгып, тәржемәне оригинал кебек үк образлы итеп эшләргә мөмкин түгел дигән нәтиҗә ясарга ярыймы икән? Тәржемә практикасы бу сорауга тискәре җавап бирә. Тәржемәчеләр мондый очракларда компенсация алымы кулланалар. Ул шуннан гыйбарәт: әйтик, бер урында оригиналдагы сурәтләү чарасына тиң булырдай чара табылмый һәм әсәрдәге образлылык, эмоциональлек бирелеп җитми кала, ди. Икенче бер урында тәржемәче, әлеге нәрсәне истә тотып, оригиналдагы гади элементны образлы чара белән алмаштыра. Ягъни бер урында югалган нәрсә икенче урында кире кайтарыла. Нәтиҗәдә тәржемә, гомумән алганда, оригинал әсәргә тиң булып чыга. Бу — тәржемә практикасы һәм теориясе тарафыннан күптән расланган һичшиксез дөрес алым. Ләкин монда шуны истә тоту әһәмиятле: компенсация дигән нәрсә оригинал белән ирекле эш итәргә яратучыларга котылу юлы була алмый. Тәржемәче оригиналдагы теге яки бу элементны, әдәби чараны, туган телнең бөтен мөмкинлекләрен эшкә җигеп, үзенең бөтен осталыгын файдаланып, тәржемәсендә бирергә тырышырга тиеш. Һәм бары тик бернинди мөмкинлек күренмәгән очракта, соңгы чиктә генә ул компенсация алымына мөрәҗәгать итә ала.

Компенсация алымы «Белмәмеш трилогиясе» тәржемәсендә дә кулланылган. Әйтик, оригиналда «это дело десятое» дигән фразеология бар. Татар телендә ул мәгънәдәге әйләнмә юк. Шуңа күрә тәржемәче аның матди мәгънәсен бирү белән чикләнә: «анысы вак мәсьәлә». Ә икенче бер урында ул «обрадовались» дигән гади сүзне «түбәләре күккә тия» рәвешендә образлы итеп тәржемә итә. Яки менә икенче бер мисал. Оригиналда «чудеса в решете» дигән фразеологик берәмлек очрый. Тәржемәдә ул гадиләштерелеп «кызык чкән» дип бирелгән. Ләкин икенче урында бу җитешсезлекнең дә каруы кайтарыла: «вот в чем тут дело» тәгъбире «имәндә икән чикләвек» дип тәржемә ителә. Кыскасы, әсәрне татар телендә дә рус телендәге кебек образлы, җанлы итү, ягъни тулы кыйммәтле (адекват) итү өчен тәржемәче зур көч куйган.

Тәржемәнең стиль ягыннан оригиналга туры килүен күп кенә башка мәсьәләләрдә дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, оригиналда берничә урында аерым персонажлар тарафыннан бозып сөйләшүләр бар. Тәржемәче аларны саклаган. Шулай ук оригиналда кайбер персонажлар үзенчәлекле телдә сөйләшәләр: билгеле бер сүзләрне еш

кабатлыйлар, җөмләләре өзелеп кала һ. б. ш. Тәрҗемәче тегe очракта да, бу очракта да индивидуаль сөйләмнәрне, алардагы үзенчәлекләрне татар теленә оста күчергән. Моңа мисалларны икенче китапның 140, 161, 162 битләрендә (оригиналда 620, 644 битләр), өченче китапның 170, 171 битләрендә (оригиналда 279, 280 битләр) күрергә мөмкин.

Тәрҗемәнең сыйфаты сөйләм төзелешенең, җөмләләрнең ничек бирелүенә нык бәйләнгән. Чөнки, мәгълүм булганча, язучының стиле, үзенә генә хас үзенчәлекләре әсәрнең сантаксик төзелешендә дә чагыла. Шуңа күрә тәрҗемәче оригиналның синтаксик үзенчәлекләренә: җөмләләрнең характерына, кыскалыгына яки озынлыгына, алардагы кабатлауларга, параллель конструкцияләргә игътибар итми кала алмый һәм аларны мөмкин булганча төгәл чагылдырырга тырыша. Мөмкин булганча дигәнне тәрҗемә теле нормаларына туры килгән дәрәҗәдә дип аңларга кирәк. Ә менә еш кына рус теленең синтаксик формалары татар теленең синтаксик чараларына туры килми, чөнки төрле телләрнең грамматик төзелешләре төрлечә. Шуны исәпкә алмыйча, рус теленең грамматик формаларын татар теленә механик рәвештә күчереп куюаркасында безнең тәрҗемәләр кайчак гарип булып чыгалар. Аларның телләре ясалма, авыр, кытыршы була. Сүзләре татарча булса да, сөйләм төзелеше, җөмләләре татарча булмый. Без тикшерә торган тәрҗемәдә бу масьәлә дә уңай хәл ителгән. Тәрҗемәче, рус теле җөмләсендәге фикерне татар телендә биргәндә, туган тел синтаксисы кагыйдәләреннән чыгып эш иткән. Шуңа күрә аның җөмләләре җиңел аңлаешлы һәм татарча булып чыккан. Бу, әлбәттә, тәрҗемәче рус теле җөмлә төзелеше белән исәпләшмәгән, һәр урында оригинал конструкцияләрен (төзелешләрен) ватып барган дигән сүз түгел. Татар теле нормаларына каршы килмәгәндә, ул рус теле конструкцияләрен саклый. Монда аңа татар телендә, бигрәк тә аның сөйләм телендә актив кулланылышта булган аналитик төр җөмләләр ярдәмгә килгән. Мәгълүм булганча, татар телендәге аналитик җөмләләр рус теле җөмләләре белән бертөрле төзелештә, һәм алар тәрҗемәдә әсәрнең стилен, үзенчәлекләрен бирү өчен уңай чара булып хезмәт итәләр. Оригиналның грамматик формалары татар теле өчен ятышсыз, чит булган очракларда исә тәрҗемәче алар белдергән мәгънәне татар теленең үз синтаксик төзелешләренә салып биргән. Рус теле җөмләсе артык озын, катлаулы булып, аны шул рәвешчә тәрҗемә итү фикер буталчыклыгына китерә торган булса, андый җөмлә бүгәләнеп тәрҗемә ителгән. Һәм, киресенчә, оригиналның янәшә торган ике яки берничә (күбесенчә ике) җөмләсе күләмнәре буенча зур булмыйча, мәгънәләре буенча бер-берсенә якын торганда, тәрҗемәдә алар берләштерелеп, бер җөмлә итеп бирелгән очраклар да бар.

Тәрҗемәченең җөмлә төзелешләрен тәрҗемә итүгә иҗади килгәнлеге башка нәрсәләрдә дә күренә. Мәсәлән, ул урыны белән туры сөйләмнән кыек сөйләм ясый һәм киресенчә дә эшли; кирәк булса, фигыльләрнең юнәлеш категорияләрен үзгәртә, җөмләне актив формадан пассив формага күчерә һәм киресенчә итә, оригинал җөмләсендәге бик әһәмиятле булмаган сүзләрне, алар татар телендә сөйләм агышына комачаулаганда, төшереп калдыра, ә җөмләнең мәгънәсен тулырак белдерергә кирәк булганда, оригиналда булмаган сүзләр дә өсти. Ләкин боларның берсен дә тәрҗемәченең артык иреклелеге, оригиналны бозуы дип әйтеп булмый. Чөнки аларның барысы да оригиналның мәгънә эчтәлеге дөрес итеп бирелсен, художество кыйммәте тулы саклансын һәм тәрҗемә теле дөрес, әдәби тел булсын дигән бурычны үтәүгә юнәлтелгән. Совет тәрҗемә мәктәбе тәрҗемәче тел өлкәсендә ирекле дип һәм тәрҗемәче эше иҗади эш дип өйрәтә. Әле әйтелгәннәргә берничә мисал күрсәтеп китик.

«В одном из домов Знайка увидел шкаф с книгами и сказал, что когда вернется домой, то и себе сделает книжный шкаф» (стр. 438).

«Бер өйдә Белəмəн, китап шкафы күреп:

— Кайткач үзем дә шундый шкаф ясыйм әле! — дип куя» (1—147).

«Малышки разошлись по домам. Всем было невесело» (стр. 456).

«Боегып калган кызлар өйләренә таралышалар» (1—162).

«Двенадцать малышек, нарядившись в красивые, разноцветные платья с лентами, танцевали разные танцы, среди которых самым лучшим оказался танец «Репка» (стр. 450).

«Төрле төстәге күлмәкләр кигән, тасмалар таккан унике кыз чыгып төрле биюләрне башкарды. Тамашачыларга иң ошаганы «Шалкан» дигәне булды» (1—158).

Без сүз алып бара торган тәрҗемәдә кеше, шәһәр, урам, елга исемнәрен бирү алымнары да игътибарга лаек. Бу әсәрдәге ялгызлык исемнәренең күбесе үз иянәренең берәр төрле сыйфатын белдерә, ягъни мәгънәле исемнәр. Мондый үзенчәлек тәрҗемәдә чагылыш тапмый кала алмый, әлбәттә. Һәм бу эш тәрҗемәчедән шактый тапкырлык, сәләт таләп иткән. Әйтергә кирәк, татарча исемнәр нигездә бу таләпләргә җавап бирәләр. Мәсәлән, Знайка—Беләмән; Незнайка — Белмәмеш; Винтик белән Шпунтик — Һөнәрмән белән Көйләрмән; Тюбик — Рәсемҗан; Молчун — Майкап; Кнопочка — Төймәкәй; Огурцовая речка — Кыярлы инеше; Цветочный город — Чәчкәле шәһәре дип тәрҗемә ителгән. «Коротышка»ны «нәнүс» дип алу да уңышлы шикелле.

Тәрҗемәченең уңышлы эшләве хакында сөйләрлек күп кенә башка мисаллар да китерергә мөмкин булыр иде. Сөйләнгәннәрне йомгаклап шуны әйтеп китәргә кирәк: тәрҗемәче гомумән алганда иҗади эшләгән, оригинал теле формаларын механик рәвештә күчерү белән шөгыльләнмичә, татар теле үзенчәлекләреннән чыгып, һәр очракта контексттан, конкрет обстановкадан чыгып эш иткән. Ул үзенә барыннан да бигрәк оригиналның тегә яки бу формасы белдергән мәгънәне тәрҗемәдә мөмкин кадәр тулы бирү бурычын куйган, туган тел байлыгыннан оригиналдагы тегә яки бу элементка тиң элемент эзләгәндә, аларның эмоциональ, экспрессив яктан, стиль ягыннан туры килүләрен кайгырткан. Тагын шунысы бар: тәрҗемәче оригиналдагы аерым сүзләргә, сүзтезмәләргә туры киперлек бәрамлекләр эзләгәндә, аларның диалектик бердәмлеген, бөтен бер текстны, әсәрне күздә тотып эш иткән. Оригиналдагы аерым детальләр белән бер бөтеннең үзара бәйләнешен дөрес аңлаган һәм шуны тәрҗемәдә дә саклап калган. Тәрҗемәнең уңышын менә шушы нәрсәләр хәл иткән.

Ләкин укучыларда тәрҗемәче эшендә бер дә житешсезлекләр юк икән дигән фикер тумасын. Тәрҗемә, нигездә, һичшиксез, уңышлы эшләнгән. Шуның белән бергә анда әле, безнең фикеребезчә, икенче төрлерәк хәл ителәсе нәрсәләр дә юк түгел. Шундый нәрсәләрнең берсе — китапларда фигыль заманнарын дөрес кулланукулланмау мәсьәләсе. Эш шунда: татар телендә үткән заман фигыльләренең биш төре бар һәм аларның төрлесе төрле функция башкара һәм төрле мәгънә белдерә. Еш кына тәрҗемәчеләр бер форма белән генә эш итәләр. Бу форма гадәттә «ды-де», «ты-те» кушымчалары белән килгән категорик үткән заман була. Болай эшләү еш кына зур хаталарга китерә. Чөнки категорик үткән заман кагыйдә буларак эшнең үтәлүен сөйләүче яки язучы үзе күреп сөйләгәндә яисә язганда кулланыла. Ә безнең кайбер китапларда, матбугат битләрендә әллә кайларда һәм әллә кайчаннар булган, язучының үзе күрүе берничек тә мөмкин булмаган очракларда да категорик үткән заман формасы кулланыла.

«Белмәмеш трилогиясе»ндә тәрҗемәче мондый очракларда хәзерге заман формасын кулланган, ләкин һәр җирдә түгел. Ул «ды-де», «ты-те» кушымчалары белән ясалган категорик үткән заманга шактый еш мөрәҗәгать итә, җитмәсә тагын аның бер заманнан икенче заманга күчешләре кискен, кытыршы, ятышсызрак килеп чыга, акланмый. Мисал өчен беренче китапның 14, 26, 27, 156 һәм башка битләренә күз салырга мөмкин. Нәтиҗәле үткән заман формасын исә тәрҗемәче бөтенләй диярлек кулланмый. Н. Носов әсәрен тәрҗемә иткәндә үткән заман фигыльләрне хәзерге заман һәм нәтиҗәле үткән заман фигыль формалары белән бирү уңышлы булыр иде. Чөнки бу — әкият әсәр, ә татар халык әкиятләре нәкъ әнә шул ике заман формасына корылган булалар.

«Белмәмеш трилогиясе» тәрҗемәчесе халык телендәге үткен, образлы сүзләрне, әйтемнәрне иркен кулланып яхшы эшләгән. Ләкин кайчан ул моның белән мавыгып киткән һәм шуның нәтиҗәсендә әдәби нормага туры килми торган сүзләр дә кертеп җибәргән. Мәсәлән, «хәйран да шәп мастерлар» (I—23), «берсенең дә юп сабасы килми» (II — 213), «җалу бирәм» (I — 52), «элекләре» (I—152), «сиңа була (сиңа карап — Р. Ю.) морожныемны йоттым» (II — 34), «һава шарын резиннан ясарга кирәк» (I — 29), «театрга таба юлланды» (II — 94), «үзе өтели торган үтүк» (II — 184), «алдан әйтешле түгел» (III — 20), «янына килергә итә» (III — 43). «Гел» сүзе әдәби телдә «һаман» сүзенең синонимы булып йөри, ә кайбер урыннарда халык аны «бөтенләй» мәгънәсендә дә куллана. Ул сүз әлеге китапларда да еш кына соңгы мәгънәдә кулланылган (мәсәлән, «гел күренмәс була»). Моны уңышлы дип әйтеп булмый. Анннары тагын тәрҗемәченең «ник дисәң» («чөнки» мәгънәсендә) рәвешендәге яраткан әйләнмәсе бар. Аның еш кулланылуы

да уңышлы түгел. Китапларның балаларга адресланган булуын һәм аларны әдәби телдә сөйләшергә һәм язарга өйрәтергә кирәклеген, китаптагы һәр сүзнең укучыга аңлашылырга тиеш икәнлеген искә алып эш иткәндә, әдәби нормага туры килми торган сүзләр кулланырга ярамаганлыгы аңлашыла булса кирәк. Шул ук таләпләрдән чыгып караганда, без сүз алып бара торган китапларда кайбер архаик сүзләр очравын да уңышлы хәл дип әйтеп булмый: «гафу кыласыз», «барча халык», «Чалбари атлы бер малай», «җәмгысы», тәрҗемәи хәле», «дустанә», «күздән гаип итә торган бүрек» һ. б. Татарча эквивалентлары булган берничә сүз тәрҗемә ителмәгән: «крушение», «стойка», «лабиринт...»

Кайбер ялгызлык исемнәренең тәрҗемә ителүенә карата да бер-ике сүз әйтеп китәргә кирәк. Оригиналда Ворчун исемле малай бар. Автор аны гел сукранып, бернәрсәдән дә канәгать булмыйча йөргәнгә шулай атаган («ворчать» сүзеннән). Һәм аның шул исеме текстның мәгънәсе белән дә бәйләнештә бирелгән. Мәсәлән, Незнайка аңа: «Ты, Ворчун, совсем не переменился. Ворчишь, как всегда», — ди (стр. 367). Татарчада Ворчун Сыбызгы дип алынган, һәм шуның аркасында мәгънәгә дә зыян килә. Белмәмеш Сыбызгыга (Ворчунга): « — Син бер дә үзгәрмәгәнсең икән, Сыбызгы. һаман сызгырасың икән, — дип куя» (I — 84).

Аучы Пулька — беренче китапта Мәргән, ә икенче китапта — Дарбай. Бер үк кешенең ике төрле исемдә йөрүе, дөресрәге, исеме үзгәрүе яхшы түгел. Шутило Шаян дип алынган. Аны Шаянҗан, Шаянгали кебегрәк иткәндә әйбәтрәк булыр иде. Перышкин Каурый дип бирелгән. Аны да Каурыев кебек итеп фамилиягә охшатырга кирәк, чөнки оригиналда Перо гына түгел, ә Перышкин.

Ләкин нигездә дөрес метод белән эшләнгән өч китап өчен бу җитешсезлекләр күп түгел һәм алар хезмәткә зур зыян китерә алмыйлар.

Рецензияләнгән хезмәтнең иң әһәмиятле ягы, оригиналның эчтәлеге тулы сакланган хәлдә, аңа художество кыйммәте буенча, ягъни эстетик яктан тиң булуында. Н. Н. Носовның югарыда исемнәре әйтелгән өч китабы да татар телендә рус телендәге кебек үк образлы, җанлы телдә язылган, рус телендәге кебек үк җиңел укыла һәм татар укучыларын да рус укучыларын тәэсирләндергән кебек тәэсирләндерә. Чөнки тәрҗемәче оригиналның идея һәм художество эчтәлеген саф татар телендә тулы итеп бирүгә ирешкән. Шуңа күрә дә татар укучылары Белмәмеш һәм аның дуслары турындагы бу китапларны бик яратып укыйлардыр һәм укырлар дип шикләнмичә әйтергә була. Меңләгән татар малайларының һәм кызларының күңелләреннән әкият дөньяларында, галәм киңлекләрендә йөзә алуларында, батыр, гадел кешеләргә сокланып, яман кешеләргә нәфрәтләнеп, хыялларында үзләре дә әллә нинди батырлыклар эшләп йөри алуларында Николай Носов белән бергә Кыям Миңлебаевның да хезмәте зур. Чөнки Н. Носовның Незнайка турындагы китапларын татар теленә Кыям Миңлебаев тәрҗемә иткән.

Хәзер инде, тәрҗемәченең исемен атагач, бу китапларның яхшы тәрҗемә ителүе очраклы хәл түгел дип әйтергә дә була. Кыям Миңлебаев — В. Шишковның «Угрюм-река»сын һәм башка берничә китапны тәрҗемә иткән кеше. Ул үзен беренче хезмәтләреннән үк туган телне һәм рус телен яхшы белүче, татар теле байлыкларын тулы файдаланучы, иҗади эшләүче тәрҗемәче итеп танытты. Ул китаптан китапка эш алымнарын камилләштерә, каләмен шомарта бара. Н. Н. Носовның «Белмәмеш трилогия-се»нең татар теленә тәрҗемәсе моның ачык мисалы.

**Р. ЮСУПОВ.**

## Зәки Нури



### Сәгать

Кыңгырауль бер сәгать
Тора өстәл кырында.
Шуны тиз-тиз алам да
Китерәм мин борынга.
Ләкин ул тек-тек итми,
Ләкин ул йөреп китми.
Нәрсәдә икән сәбәп?
Ни булды сиңа, сәгать?

Аннары мин сәгатьне
Китерәмен күземә.
Менә-менә тек-тек дип,
Эндәшер кук үземә!
Ләкин, юк, йөреп китми,
Ләкин, юк, тек-тек итми.
Нәрсәдә икән сәбәп?
Ни булды сиңа, сәгать?

Сәгатьне мин колакка
Куйган идем китереп.
Шунда ук йөреп китте
Менә диган иттереп.
Төшендем серенә мин,
Тиз аңлашылды сәбәп:
Борынга да, күзгә дә
Ишетелми икән сәгать...

## Кичә, бүген, иртәгә...



Кич күктә ай калыкты да
Кичәге көн бетте.
Инде безгә кояш нурын
Бүгенге көн сипте.

Тагын төн килер, ул бездән
Бүгенгене куар.
Иртән иртәге исемле
Өр-яңа көн туар.

Тагын кояш чыксын өчен
Төн үтәргә тиеш...
Көннәр, көннәр ашыгыгыз! —
Без үсәргә тиеш.

## Берсе тирги, берсе аклана

Ана тирги: — Биш конфетны
Бер үзең ашагансың —
Энең белән сеңелең барын
Оныта башлагансың...

Аклана бала: — Әнием,
Шуны да белмисеңме:
Ничек өчкә бүләргә ди
Синең ул бер бишеңне!

# ҮЛМӘС ЧӘЧӘК ЛЕГЕНДАСЫ

Моннан ун ел элек «Пионерская правда» газетасында Советлар Союзы Герое Шакирҗан Казанбаев турында бер мәкалә басылып чыга. Аның батырлыгы һәм тәвәккәллеге шагыйрь Мостафа Богманның күңелен бик нык дулкынландыра һәм ул әдәби әсәр язар өчен материал җыя башлый. Һәм ул геройның туган якларына — Пермь өлкәсе, Барда районы, Сараш авылына барып чыга. Анда геройның туганнары һәм замандашлары белән очраша, Тол елгасы буеның матур табигатенә сокланып бик озак уйланып йөри. Ләкин шагыйрь шулар белән генә канәгатьләнеп калмый. Менә ул Мәскәүдә Совет Армиясенең үзәк музеенда Шакирҗан Казанбаевка кагылышлы тарихи документлар белән таныша, ул коткарып алып чыккан полк байрагына сокланып карап тора. Аннан шагыйрь геройның соңгы тамчы каны тамган тугандаш Молдавия җиренә юл тота. Менә Челаятьен авылы янындагы тере чәчәкләр белән күмелгән туганнар каберлеге. Мәрмәр обелискка алтын хәрефләр белән монда күмелгән батырлар исемнәре язылган. Беренче булып Советлар Союзы Герое Шакирҗан Казанбаев исеме тора. Каберлек өстендә чәчәкләр, кып-кызыл чәчәкләр. Әйтерсең, алар туган илебезнең азатлыгын яклап шунда башларын куйган батыр улларыбызның түккән каннарыннан шытып чыкканнар. Нинди генә юк соң аларның монда: Россия җирләре болыннарында үскән георгиннар дисеңме, Украина далаларында үскән хризантемаларны, Урал тауларында үскән сөмбеләләр дисеңме — бар да бар монда. Шулай итеп, геройның эзләре буйлап йөреп чыкканнан соң гына, шагыйрь үз әсәрен язарга тотына. «Үлмәс чәчәкләр легендасы» исемле документаль-драматик поэма әнә шулай туа.

Бу поэма әле беркая да басылып чыкмаган. Без Шакирҗан Казанбаевның якташлары — Сараш авылы кешеләре аны беренче тыңлаучылар булдык.

Бу әсәр балалар өчен язылган, ләкин ул зурлар өчен дә бик кызыклы. Авторның укучыларга әйтергә теләгән төп фикере: яшьләр халыкка һәм Ватанга герой Казанбаев кебек турылыклы булып үсеннәр. Поэманы тыңлаганда туган илебезнең матурлыгына, замандашларыбызның күңел байлыгына сокланып туймыйсың. Поэманың халык җырларына якын торуы, легенда һәм әкиятләргә охшаш сурәтләү чараларына бай булуы, эмоциональ телдә язылуы — авторның уңышы.

Герой Казанбаев образы поэмада гомумиләштереп бирелгән. Шагыйрь аның балачагы, яшьлек еллары һәм Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары ту-

рында ачык тел белән җанлы итеп сөйли, бай фантазия белән яза. Казанбаев, Василий Теркин кебек ук, тапкыр, шаян, җырга-биюгә һәвәс, курку белмәс батыр егет икән. Әнә шундый уллар үстергән халкыбыз өчен без чиксез горурланабыз.

МӘҮЛЕҖАН БУКАЕВ.
Пермь өлкәсе, Барда районы.
Сараш авылы.

## «ТИК БЕР ӨМЕТ» ОЧЕРКЫН УКЫГАЧ

Мин татар легионы язмышы турында үтә борчылып йөри идем. Кайда, ничек, нинди һәлакәтләрдә корбан булдылар икән? дигән уй тынгылык бирми иде.

Ниһаять, алар табылды.

Коточкыч драматизм! Тот та очерк кына түгел, тетрәндергеч роман, трагедия, эпопея яз!

Күңелдә бу очерк турында да җылы, әйбәт фикерләр ята. Без аны район радиосы буенча тапшырдык һәм «Казан утлары» журналына күзәтү бирдек. Подписчиклар саны арта тора.

Инде тәкъдимнәрем: легионның үткән юлын тикшерү бик катлаулы, бик авыр эш. Моны бер генә кеше һич тә башкарып чыга алмаячак. Шуңлыктан аны тикшерү буенча студентлардан торган группа төзергә, шул якларга берничә айга командировкага җибәрергә кирәк. Тәҗрибәле язучыларны да бу эшкә тартырга кирәк.

Сугыш һәлакәте тагын ыржайган бу көннәрдә — бу легионны биеккә күтәреп язарга, илгә тугрылыкны бик нык пропагандаларга кирәк. Бу очеркны мин белгән гади тезүчеләрдән-эшчеләрдән Илдус Гыйлемҗанов, Радик Гыйззәтуллин, Фаршат Сафин, Фәннур Сафин, Фәния Хуҗиәхмәтова кебек иптәшләр дә укып чыктылар һәм бик югары бәяләделәр, яраттылар. Гомумән, аңа сокланмаган кеше булды микән!

«Социалистик Татарстан» газетасының
Түбән Камадагы үз хәбәрчесе
РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛИН.

### ЛЕНИНГА БАГЫШЛАП

#### Музыкаль фестиваль

Барлык илләрнең хезмәт ияләре белән берлектә, совет кешеләре олы бәйрәмгә әзерләнәләр. Маркс һәм Энгельс тәгълиматын даһиларча дәвам иттергән, Советлар Союзы Коммунистлар партиясен оештырган, дөньядагы иң беренче социалистик дәүләтнең нигезен салышкан бөек юлбашчыбызның 100 еллыгы якынлашып килә. Һәм безнең тормышыбызда бу тантананың рухы, ритмы, сулышы көннән-көн тирәнәя, көчәя бара. Бу — республикабызның әдәби һәм мәдәни тормышында да бик ачык сизелә.

Даһи юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин яшәгән һәм аның эшчәнлегенә бәйле шәһәрләрдә сәнгать бәйрәмнәре үткәрү матур бер традициягә әйләнеп бара. Безнең шәһәребездә, мәсәлән, андый бәйрәм инде җиде ел рәттән уздырылып килә.

Быелгы фестиваль концертлары тамашачылар күңелендә аеруча җылы тәэсир калдырды. Казанлылар һәм республикабыз җәмәгатьчелеге алдында совет сәнгатенең иң күренекле вәкилләре һәм иҗат коллективлары чыгыш ясады. Татарстан дәүләт симфоник оркестры (дирижеры СССРның халык артисты, профессор Натан Рахлин), Ленинград филармониясенең симфоник оркестры (дирижеры Юрий Тимерканов), М. Глинка исемендәге Ленинград дәүләт академия капелласы (художество житәкчесе Ф. Козлов), Танеев исемендәге Ленинград дәүләт квартеты, Ленинградның яңа камера балеты (художество җитәкчесе РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе П. Гусев), «Дуслык» ансамбле (художество җитәкчесе А. Броневицкий) кебек иҗат коллективларын киң илебезнең бөтен почмакларында беләләр.

СССРның халык артисты, профессор П. Серебряков, РСФСРның атказанган артистлары Эдуард Хиль һәм Бен Бенцианов, Бөтенсоюз һәм халыкара конкурслар лауреатлары Л. Филатова һәм Е. Нестеренко, Татарстанның атказанган артисткасы Э. Афзалова кебек башкаручылар катнашы белән узган концертлар турында да күп һәм киң итеп сөйләп булыр иде.

В. И. Ленинга багышланган музыкаль фестивальдә катнашу өчен, Казанга Нева ярларыннан күп кенә танылган композиторлар килде: Ленин премиясе лауреаты, ике тапкыр дәүләт премиясе лауреаты, СССРның халык артисты В. И. Соловьев-Седой, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклеләре Г. Носов, Д. Прицкер, Ю. Зарицкий, С. Пожлаков һәм башкалар.

Концерт программаларының гаять бай, тирән эчтәлекле һәм күп яклы булганлыгын билгеләп үтәргә кирәк. 10 апрельдән 23 апрельгә кадәр дәвам иткән фестиваль концертларында юлбашчыбыз Ленинга һәм Бөек Октябрь революциясенә багышлап язылган яңа әсәрләр, бөтендөнья һәм совет музыка сәнгатенең иң гүзәл җәүһәрләре башкарылды. Татар дәүләт филармониясе артистлары «Ильич тормышында музыка», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән темаларга лекция-концертлар бирделәр.

Җиденче музыкаль фестиваль концертлары М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры, Качалов исемендәге Зур драма театры, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры биналарында, шәһәребезнең концерт залларында, культура сарайларында һәм клубларда, югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә барды.

#### Лениннананың өченче китабы

Азатлык иҗатчысы даһи Ленинга бөтен дөнья хезмәт ияләренең хөрмәте һәм мәхәббәте чиксез зур. Революция юлбашчысын олылаган җырлар, легендалар, хикәяләр җир шарының төрле почмакларында иҗат ителә. Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Ленинның якты юлыннан» исемле китапка дөнья халыклары әдәбиятының Ленин темасына язылган әсәрләреннән үрнәкләр тупланган. Ул — лениннананың татар телендә чыккан өченче китабы. Китапның төзүчесе шагыйрь Зәки Нури.

#### Яңа фильм

Казан киностудиясенең «Ленин Казанда», «80 ел үткәч» кебек фильмнары тамашачыларга яхшы таныш. Студия бу әһә-

миятле тема өстендә эзләнүләрен дәвам итә. Апрель аенда республикабыз экраннарында режиссер А. Стремяковның «Володя Ульянов» исемле яңа документаль фильмы күрсәтелә башлады. Киң экранлы бу фильм яшь Ульяновның революцион хәрәкәт юлына килүе турында сөйли.

**Ленин образы — сәхнәдә**

Татарстан дәүләт музеенда «В. И. Ленин образы — сәхнәдә» дигән темага кичә уздырылды. Анда Качалов исемендәге Зур драма театрының бөек юлбашчы ролен башкарган һәм аңа багышланган спектакльләрдә катнашкан артистлары чыгыш ясады.

**Китап уникөнлеге**

22 апрельдән Таткниготоргның китап магазиннарында, бөек Ленинның туган көненә багышлап, политик әдәбиятны пропагандалау декадасы башланды. Декада көннәрендә В. И. Ленин әсәрләрен, аның турында язылган китапларны күргәзмә сату оештырылды. Китап сөючеләр клубында һәм зур магазиннарда укучылар революция һәм гражданнар сугышы ветераннары, карт большевиклар белән очраштылар.

**Халык кибете**

Моннан бер ел элек В. И. Ленинның Казандагы музей-йортында халык китап кибете оештырылган иде. Анда бөек юлбашчының үз әсәрләре, аның турында язылган яки аңа багышланган китаплар һәм фотоальбомнар сатыла.

Данлы юбилей алдыннан кибет үзенең эшен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрде, һәм сатып алучылар саны да бермә-бер артты.

**Сувенирлар**

Владимир Ильич Ленинның 100 еллыгына һәм Татарстанның 50 еллыгына багышлап, республикабызда сувенирлар һәм бүләк әйберләр эшләү буенча конкурс уздырылды. Беренче марттан июнь аена кадәр дәвам иткән бу конкурста бик күп иҗат коллективлары һәм аерым авторлар катнашты. Алар Ленинның Татарстандагы тормышына һәм эшчәнлегенә, ленинчыл идеяләренең бөеклегенә һәм тантанасына, совет халкының героик эшләренә, Татарстан хезмәт ияләренең экономика һәм культура өлкәсендәге казанышларына багышланган барельефлар, значоклар, сувенир альбомнар, металлдан, пыяладан, агачтан һәм керамикадан эшләнгән сәнгать әсәрләре иҗат иттеләр.

22 апрельдә Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләренең тантаналы кичәсе булды. В. И. Ленинның тууына 99 ел тулуга багышланган доклад белән ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыев чыкты.

Соңыннан үзешчән сәнгатьтә катнашучылар көче белән зур концерт бирелде.

* * *

Татарстан язучыларының, китап нәшрияты һәм газета-журнал эшчеләренең В. И. Ленинга багышланган тантаналы кичәсе 23 апрельдә Габдулла Тукай исемендәге клубта уздырылды.

## БАЛАЛАР ХАКЫНДА КАЙГЫРТЫП

Балаларга һәм яшьләргә багышланган әсәрләр иҗат итүче әдәбият һәм сәнгать әһелләрен кызыксындыру максатыннан чыгып, РСФСР Министрлар Советы балалар һәм яшьләр өчен иҗат ителгән күренекле сәнгать әсәрләре өчен РСФСРның Н. К. Крупская исемендәге бер дәүләт премиясен булдыру турында карар чыгарды.

РСФСРның башка дәүләт премияләре кебек үк, Н. К. Крупская исемендәге премия дә һәр елның 1 январенда биреләчәк.

РСФСР Министрлар Советы янындагы РСФСР дәүләт премияләре комиссиясе 1968 елның 15 июненә кадәр басылып чыккан, башкарылган һәм күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итә.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Һәр елның апрель ахырларында шигъри сөючеләр халкыбызның иң сөекле, иң олы шагыйре Габдулла Тукай һәйкәле янына җыелалар. Халык шагыйрьгә үзенен тирән мәхәббәт хисләрен белдерергә, чәчәкләр куярга килә, әдип-шагыйрьләр исә аның каршына шигърияттән имтихан тотарга дип тә киләләр.

Һәр елны шулай. Бу матур бәйрәм Тукай һәйкәле алдында башланып китә дә, аннан клубларда, культура сарайларында, мәктәпләрдә дәвам итә.

Быелгы бәйрәм 26 апрельдә үткәрелде. Аны шагыйрь Нури Арсланов ачып җибәрде. Татарстан шагыйрьләре үзләренең иң яхшы әсәрләрен укыдылар, артистлар Ту-

кай шигырьләрен, аның сүзләренә иҗат ителгән җырларны башкардылар.

Кичен шигырь клубларга, уку йортларына, радио һәм телевидение залларына күчте. Шигырь бәйрәменә багышланган кичәләрдә Н. Арсланов, Ә. Баян, Ш. Галиев, Г. Латыйп, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Г. Рәхим, М. Фәйзуллина, Г. Зәйнашева, М. Шабаев, М. Ногман һәм башка шагыйрьләребез катнашты.

## УТЫРЫШЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР ҺӘМ ОЧРАШУЛАР

Татарстан язучылар союзы идарәсенең 21 апрельдә уздырылган утырышында Касыйм Фәсәховның иҗат отчеты тыңланды. Ул язган шигырь-поэмалар һәм легендалар, шулай ук аның тәрҗемәләре буенча фикер алышуларда филология фәннәре кандидатлары Т. Галиуллин һәм Н. Юзиев, шагыйрьләрдән Р. Харисов, Ә. Баянов, С. Хәким, И. Юзеев, Ш. Маннурлар катнашты. Сөйләшү бик җитди һәм принципиаль характерда барды. Идарә утырышы матбугат битләрендә әдәби халтурага юлны ябу юнәлешендә конкрет чаралар билгеләде.

* * *

Атилла Расихның «Ике буйдак» исемле мәгълүм романы күптән түгел Мәскәүдә рус телендә аерым китап булып басылып чыккан иде. 9 апрельдә Казан ветеринария институтында шушы әсәр буенча укучылар конференциясе уздырылды. Фикер алышуларда югары уку йортының профессорлары, укытучылары һәм гыйльми хезмәткәрләре, шулай ук студентлар катнашты.

* * *

Язучылардан Г. Бакиров, С. Шакир һәм М. Фәйзуллина Татарстанның Мамадыш районы авылларында укучылар белән очраштылар, әдәби кичәләр, конференцияләр оештырдылар.

* * *

Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Г. Ахунов республика пропагандистлары каршында «Татар әдәбиятында Ленин образы» дигән темага чыгыш ясады.

* * *

Алабуга шәһәрендәге культура-агарту хезмәткәрләре хәзерли торган училищеда Ә. Касыймовның «Томан аша» романы буенча укучылар конференциясе уздырылды.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

1 мартта бүлек каршында оештырылган әдәби түгәрәкнең чираттагы утырышы булды. Яшь һәм башлап язучылар алдында Г. Афзал, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин чыгыш ясады.

* * *

7 мартта Г. Афзал, С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин «50 лет Октября» совхозында авыл хезмәт ияләре белән очраштылар. Очрашу Мамадыш авылы китапханәсендә үтте. Язучылар Ленинның тууына 100, Татарстан республикасы төзелүгә 50 ел юбилейларына хәзерлекләр турында, үз иҗатлары хакында сөйләделәр, китап сөючеләрнең күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

* * *

21 март көнне Баулы районының Тат. Тумбарлы авылында мәктәп директоры булып эшләүче И. Миңлебаев иҗаты тикшерелде. Авторның ике пьесасы, бер повесте анализланды. Әсәрләрне ахыргача эшләү юнәлешендә күп кенә киңәшләр бирелде. Утырышта Г. Афзал, Ә. Маликов, Р. Фәйзуллин, Һ. Сафина, М. Хәбибуллин, А. Ганиев, Ш. Бикчурин, А. Хәсәнов, М. Хәсәнов, Р. Төхфәтуллин катнашты.

* * *

Шул ук 21 март көнне Әлмәт бүлеге һәм Горький исемендәге клуб идарәсе тарафыннан зур әдәби-музыкаль кичә оештырды.

Кичәдә Казаннан килгән язучы Гариф Гобәй дә катнашты. «Корьән серләре» әсәре буенча фикер алышу булды. Авторга күп төрле сораулар бирелде, тәкъдим-теләкләр әйтелде.

Кичәнең икенче өлешендә шәһәр үзешчәннәре концерты булды.

* * *

25 март көнне Г. Афзал һәм Р. Фәйзуллин Азнакай эшчеләр поселогында «Маяк» газетасы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәк членнары белән очраштылар. Җыелышта җиде яшь авторның әсәрләре тикшерелде. Түгәрәк эшен тагын да җайландыру турында җитди сөйләшү булды.

* * *

26 март көнне Әлмәт язучылары Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, Ә. Маликов, Ю. Әминев, Һ. Сафина, Р. Фәйзуллиннар дүртенче мәктәп укытучылары коллективы белән очраштылар. 4 мәктәпкә Әлмәт шәһәре

мәктәпләрендә татар әдәбияты һәм теле укытучылары да җыелган иде. Укытучылар һәм язучылар арасында эшлекле һәм файдалы сөйләшү булды. Очрашуда «Совет мәктәбе» журналының бүлек мөдире Мәхмүт Әхмәтҗанов, шәһәр укыту бүлеге инспекторы Хәйдәров иптәшләр дә катнашты.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ КИЧӘСЕ

18 мартта нефтехимиклар шәһәре халкыбызның күренекле әдибе Галимҗан Ибраһимовның тууына 82 ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп үтте.

Тантаналы кичәне КПССның Түбән Кама шәһәр комитетының агитация-пропаганда бүлеге мөдире Таһир Гыйльметдинов ачты. Докладны «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең җаваплы секретаре Айдар Хәлим ясады.

Кичәнең икенче өлешендә зур концерт булды.

## «ӘБУГАЛИСИНА» — САРАТОВ СӘХНӘСЕНДӘ

Яшь язучы Роберт Батуллинның «Әбугалисина» исемле пьесасы Казан курчак театры сәхнәсендә уңыш белән бара. Күптән түгел Саратов курчак театрында да бу спектакльнең премьерасы булды. Әсәрне сәхнәгә Игорь Москалев куйган. Декорацияләрне художник Аркадий Бриклин ясаган. Спектакльгә музыканы Мирсәет Яруллин һәм Саратов композиторы Е. Линович язган. Саратов балалары «Әбугалисина» әсәрен яратып каршы алдылар.

## ГАШЕК — БӨГЕЛМӘ СӘХНӘСЕНДӘ

Татарстанның илле еллыгына Бөгелмә театры чех язучысы Ярослав Гашек турында «Башлап җырлаучыга дан» дигән спектакль куярга әзерләнә. Пьесаның авторы — Казан журналисты Станислав Антонов. Ул күп еллар буенча Гашекның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнде. М. Горький исемендәге институтта С. Антонов шушы темага диплом эше язды. Ул «Ярослав Гашек Башкортстанда», «Гашек Идел буйларында» дигән китаплар чыгарды, чех язучысының моңа кадәр укучыларга билгеле булмаган әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итте.

Бөгелмә театрының Гашек турындагы пьесаны сәхнәләштерә башлавы очраклы хәл түгел. Моннан ярты гасыр элек Ярослав Гашек Кызыл Армия сафларында көрәшә, Бөгелмә шәһәре коменданты ярдәмчесе булып хезмәт итә.

Шәһәрдә өченче ел инде Ярослав Гашек исемендәге музей эшли.

## СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МУЗЕЕНДА

Март ахырында Татарстанның сынлы сәнгать музеенда республикабызның күренекле рәссамы, Тукай премиясе лауреаты Бакый ага Урманченың шәхси күргәзмәсе ачылды. Анда рәссамның ике йөздән артык хезмәте тупланган. Күргәзмә тамашачылар тарафыннан гаять җылы каршыланды.

* * *

Татарстан сынлы сәнгать музеенда Н. В. Гогольның тууына 160 ел тулуга багышланган күргәзмә ачылды. Анда бөек язучының тормыш юлын, иҗатын, Украина табигатен тасвирлаган картиналар, рәсемнәр һәм иллюстрацияләр тупланган. Күргәзмәдә Н. Гогольның «Тарас Бульба», «Үле җаннар», «Рождество алды төнендә», «Шинель», «Борын», «Ревизор», «Өйләнү» исемле һәм башка әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр белән дә танышырга мөмкин. Алар арасында П. Боклевский, И. Репин һәм Кукрыниксылар кебек күренекле художникларның хезмәтләре бар.

* * *

Татарстан художниклары йортында Гайшә Рахманкулова акварельләре күргәзмәсе бара. Анда художникның 50 хезмәте куелган. Г. Рахманкулованың туган як табигатен сурәтләгән әсәрләре күргәзмәдә киң урын алган. Анда Казан һәм чит ил шәһәрләре күренешләре, балалар портретлары белән дә танышырга мөмкин. Рәссамның «Ленин бакчасы», «Пятигорскида яз», «Татар өендә», «Иран сирене», «Федосеев урамы» кебек акварельләре тамашачыларда җылы тәэсир калдыра.

* * *

Татарстан сынлы сәнгать музеенда латыш художнигы Павел Глаудан картиналары һәм акварельләре күргәзмәсе ачылды. Анда художникның иллегә якын хезмәте бар.

Художникның әсәрләрендә Балтик буе илләренә хас булган табигать күренешләре, ярсу диңгез дулкыннарына күкрәк куючы кыю балыкчылар һәм башка профессия кешеләре калку итеп гәүдәләнәләр. П. Глауданның акварельләре тирән лиризм белән сугарылган.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Түбәндәге китапларны почта аша китап кибетеннән сорытып алырга мөмкин:

Ю. КОРОЛЬКОВ. Кыю разведчик. Повесть. 55 тиен.
Н. ОСТРОВСКИЙ. Корыч ничек чыныкты. Роман. 85 тиен.
М. ШОЛОХОВ. Күтәрелгән чирәм. Роман. 1—2 том. 1 сум 46 тиен.
Н. ХИКМӘТ. Романтика. Роман. 38 тиен.
Ш. МАННУР. Муса. Роман. 1 сум 48 тиен.
М. ӘМИР. Сайланма әсәрләр. 1—3 т. т. 2 сум 93 тиен.
Ф. ХӨСНИ. Сайланма әсәрләр. 2, 3 том. 2 сум 02 тиен.
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Сайланма әсәрләр. 1—2 т. т. 1 сум 84 тиен.
Г. ИДЕЛЛЕ. Ул көннәр. Истәлекләр. 46 тиен.
С. ХӘКИМ. Сайланма әсәрләр. 1 сум 81 тиен.
Ленинның якты юлыннан. 84 тиен.
Г. КАШШАФ. Чүл буенда. Хикәя. 24 тиен.
И. ГАЗИ. Гади кешеләр. Роман. 70 тиен.
К. ТИНЧУРИН. Хикәяләр. 81 тиен.
Г. ЛАТЫЙП. Адымнар. Шигырьләр. 53 тиен.
М. САДРИ. Сайра, сандугач. Шигырьләр. 71 тиен.
Г. ХУҖИЕВ. Янар йөрәкләр. Шигырьләр. 56 тиен.
Ялкынлы еллар поэзиясе. 88 тиен.
В. МАЯКОВСКИЙ. Шигырьләр. 1 сум 08 тиен.
М. ШАБАЙ. Сайланма әсәрләр. 65 тиен.

*Кибетнең адресы: Казан, Бауман урамы, 19, беренче номерлы магазин, татар китаплары бүлеге.*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210